ISSN 0206—4189

# КАЗАН УТЛАРЫ

9. 1998



# JAZUCЬLARЬBЬZ CIT ILLƏRDƏ



Jazucь һəm çəməƣət eşleklese **Fəyziə Bəjrəmova** һəm Tərkiənen, «Bəjek Berlek» partiəse rəise **Məəsin Jazьcьoƣlь** əlege partiənen, IV qorьltajьnda. *(Ankara şəһəre, 1998 jьl.)*



Jazucь **Təyfiq Əjdi** һəm «Azatlьk» radiosьnьn, elekkege xezmətkəre **Ƣarif Soltan**. *(Almaniə, Mynxen şəһəre, 1998 jьl.)*

# Казан утлары
# Qazan utlarь

1998

# 9

**(911)**

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

**Татарстан хөкүмәте,
Татарстан Язучылар берлеге,
редакциянең хезмәт коллективы**

Баш мөхәррире
**Равил Фәйзуллин**

**Идарә:**
Гариф Ахунов, Харрас Әюпов, Нәҗип Бакиров, Хәлим Гайнуллин, Тәлгат Галиуллин, Миркасыйм Госманов, Аяз Гыйләҗев, Флүс Латыйфи (*баш мөхәррир урынбасары*), Салих Маннапов, Туфан Миңнуллин, Хатип Миңнегулов, Ринат Мөхәммәдиев, Наҗар Нәҗми, Рашат Низамиев, Булат Солтанбәков, Ренат Харис, Розалина Шаһиева.

**Мөхәррирләр:**
Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Алмаз Гыймадиев, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин, Марс Шабаев.

**Гамәли хезмәткәрләр:**
Тәслимә Сибгатуллина, Гөлзадә Фәйзуллина, Лилия Гатауллина, Альбина Әхмәтова, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.

**Исәп-хисап бүлеге:**
Асия Рәхимова.

✉✉:
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎☎:
Баш мөхәррир — 49-36-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09.
Җаваплы сәркәтип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 49-36-61, чәчмә әсәрләр, хатлар, тәнкыйть — 49-36-63, корректорлар — 49-36-65.
Исәп-хисап бүлеге — 43-56-12.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИЖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

*Бу санда*

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Шәүкәт ГАЛИЕВ. Вакыт ага безнең аркылы. *Шигырьләр* ... 5
Барлас КАМАЛОВ. Хатирәләр янарган көн. *Повесть* ... 10
Лена ШАГЫЙРЬҖАН. Янар, янаркошым! *Шигырьләр* ... 30
Таһир НӘБИУЛЛИН. Качкын. *Повесть* ... 35
Шамил АНАК. Үткәннәр авазы. *Шигырьләр* ... 120
Нәҗибә ӘМИНЕВА. Мәңгелек теләгән җаным. *Шигырьләр* ... 124

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Фәүзия БӘЙРӘМОВА. Тәгәри китте йомгагым... *(Хаҗ көндәлеге)* ... 127
Наис ГАМБӘР. "Әйдә, халыкка хезмәткә!.." *(Нәҗип Нәкъкаш белән әңгәмә)* ... 146

**ХӘТЕР**

Марс ШАБАЕВ. Туган җирнең баласы иде... ... 155

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Миргазиян ЮНЫС. Акъәбинең кабере янында ... 163

**ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА**

Рәмил ИСЛАМОВ. Алтын Урда әдәбияты ... 173
Мөсгуд ГАЙНЕТДИН. "Хаким вә хөр гакыл бар дип..." ... 177

**ҮТКЕН МӘСЬӘЛӘ**

Адлер ТИМЕРГАЛИН. Кая таба һәм ... кая тикле? ... 181

Укучы сүзе ... 189
Саубуллашу сүзе ... 190
Ижтимагый-мәдәни тормышыбыздан ... 191

## В НАШЕМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

"Проза и поэзия": повесть Б. КАМАЛОВА "День нахлынувших воспоминаний"; повесть Т. НАБИУЛЛИНА "Беглец".
"Публицистика": путевые заметки Ф. БАЙРАМОВОЙ; беседа Н. ГАМБАРА с художником-каллиграфом Н. Наккашем.
"Память": статья М. ШАБАЕВА "Дитя родной земли".
"Литературная критика": статья М. ЮНУСА "У старой могилы".
"К истории литературы": статьи Р. ИСЛАМОВА "Литература Золотой Орды"; М. ГАЙНУТДИНА о Ш. Марджани.
"Острая проблема": размышления писателя А. ТИМЕРГАЛИНА о проблемах научной терминологии.
Письма читателей.
Слова прощания.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: вечерний этюд; писатель Адхат Синугыл.

## IN OUR ISSUE:

*The magazin edits monthly*

" Prose and poetry ": B. KAMALOV'S story "The day of reminiscences", T. NABIULLIN'S story "The fugitive";
"Publicism": The travelling notes of F. BAIRAMOVA, the conversation of N. GAMBAR with artist N. Nakkash.
"Memory": M. SHABAEV'S article "The child of nalive land".
" Literary criticism ": the article of M. UNUS "Near the old grave"
"To a history of the literature": R. ISLAMOV'S article "The literature of Gold Orda", M. GAINUTDIN'S article about Sh. Marjani's creative work.
"The sharp problem" A. TIMERGALIN'S reflections about problems of scientific terminologic
The letters of the reades.
The pardon words.
The diary of social and cultural life.
In our covers: evening sketch, the writer Adkhat Sinugil.

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән житешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 49-36-62 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 22.08.98 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108$^{1}/_{16}$.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 11238 Заказ Я-393
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 1998 ел.

# ШИГЪРИЯТ



## Шәүкәт Галиев

### ВАКЫТ АГА БЕЗНЕҢ АРКЫЛЫ

### Озон катламы

Канатлары сыман фәрештәнең
Җир өстендә озон катламы —
Әткәм-әнкәм әхлак-фатихасы
Күңелне дә шулай саклады.

Имансызлык белән сыный дөнья,
Миражлары юлдан яздыра —
Тәннәр-тәмнәр белән ымсындырып,
Рәхәт биреп алдап аздыра.

Хыялларны корбан итә-итә
Тормыш сиратларын кичәсең,
Гөнаһлардан хали түгелбез дип,
Нәфес агуларын эчәсең.

Үтә көннәр тәүбәләрдән качып,
Үзең белән үзең тартышып,
Дөмбер-дөмбер намусыңа кага —
Колакларда шайтан алкышы.

... Гел югары бара кешелекнең
Вөҗдан дигән озон катламы,
Изге урыннарны били килә —
Бии килә а з г ы н катламы...

*1997. Май.*

### Кизәнү

Тын күңел дә тулып таша,
Кыланышы хәттин аша,
Күтәлмәгән бер тамаша:
Сабыр иде, түзем иде,
Тиктомалга
Кеше ник тәрәзә вата?!

Артык сыйлангanмы,
Дөньяга сыймаганмы?
Болай дию булыр хата,
Гөртләп кабынгандыр хафа.
Тәрәзәдән кергән тормышны
Бәлкем ул күреп туймыштыр?
Әллә инде,
Торгын һаваны җилләтеп,
Үзгәртмәк дөнья килбәтен?

*1988.*

## Киләчәгең...

Сагынырлык көннәр бардыр ла ул,
Хәтер яшьнәп искә алырлык, —
Елларында дәвер йөге иде,
Бәгырьләрне басты авырлык.

Безнең гомер шулай башланды шул:
Канлы — сугыш, мохтаҗ — тынычлык.
Алга карап көттек җиңеллекне,
Шушы өмет белән тырыштык.

Әйләнде дә куйды заманалар,
Тот капчыгың — бирде көткәнне!
Киләчәгең бер көләчәк икән,
Ул — кабатлау икән үткәнне...

*1997. Март.*

## Язда калган күзләр...

Без еллар һәм урын алыштырып
Яшьлегеннән киткән качаклар;
Өзелгәндер, дисәң, сагындырып,
Таныш кыллар зыңлый кайчакта.

Очып кайтам йөргән урамнарга,
Өнем итеп татлы төшемне,
Яшьлек күкләреннән, күңелкәем,
Юксынган бу җиргә төш инде.

Таныш йортлар, якын кешеләрне
Син ымсынып хәзер эзләмә,
Ярты гасыр күчкән, җиле кискән,
Син үзең дә инде үзгә лә.

Язын күзләр тышта кала иде,
Төштә калган бүген күзләрем:
Мәхәббәтем иясен мин кайтып
Кызлар арасыннан эзләдем...

... Өзелгәндер, дисәң — сагындырып,
Әрнеп кыллар зыңлый кайчакта:
Яшьлек үзе үткән,
Мәхәббәттән
Без ирекле киткән качаклар...

*1997. Май.*

## Ком сәгате

Карт кешедән көлеп әйтәләр:
“Моның инде комы коела...”
Яшьләр өчен кызык бу сүзләр
Өлкәннәргә авыр тоела...

Үзебез дә шундый идек лә,
Кичерик бу яшьлек гадәтен:
Вакыт ага безнең аркылы —
Һәркайсыбыз комлы сәгать ул.

*1988. Сентябрь.*

## Тукай музеенда күргәзмәм

*Мәсгуткә*

Рәсемнәргә карап уйланабыз —
Безнең хезмәтләргә күзгә бу.
Уңышларны көзен җыялар бит —
Безнең гомерләрнең көзе бу.

Күктәге Ай сыман Тукай шаһит,
Туган телнең хәлен сорагыз —
Югалтмадык!
Ә сез ничек? — диеп
Киләчәккә карап торабыз...

*1997. Декабрь.*

## Ни чәчсәң...

Урысча укыды балаң,
Урысчалап булды һаман:
Үгиләнде ата-бабаң —
Чү, у к ы н д ы р д ы заман.

Токымың иман алмашты,
Инде аптырап торырсың...
Милләт әйтер туп-турысын:
“Ни чәчсәң, шуны у р ы с ы ң!”

*1997. Апрель.*

## Эчке “штатлар”

Бабайлар инанган:
Ике иңдә ике фәрештә
Теркиләр икән кылган гамәлеңне,
Күз-колак синең һәр эшкә...
Алар сөрелгәчтен,
Кешегә
Шактый эш арткан,
Бүселеп өелгән җилкәгә
Һәрбер чор өстәгән яңа “штатлар”...

Әйтик, эчке редактор утыра —
Кулында үтмәс кайчысы:
Кискәли, тигезли, хәл итә —

Кайсы үтәр,
Үтмәс кайсысы?

Бар тагын
Иминлек сакчысы:
"Бу сүзең — иртәрәк...
Ә бусы — хәвефсез —
Шул булыр тәңгәле, яхшысы!"

Чикли-чикли
Тәмам сагайтып
Телгә остарттылар —
Хас сүзне яшертеп,
Уйны кыскарттылар...

Чәчрәп чыкма,
Үзеңне сакла дип,
Тынычландыра алар, юата.
Саклана торгач,
Кала тик эчке "штат" —
Шәхес абзый үзен югалта...

Вакыты нәкъ бүген —
Артык штаттан
Арынсын күңел!
Әмма мавыгып
Чама чиген дә узмамын,
Тигезлек бизмәнен
Бозмамын —
Ике иңемдә
Булыр ике канатым —
Намус һәм Вөжданым!

*1988.*

## Тормыш-язмыш

*Рәссам Фаил Зыязовка*

Тәүге мәхәббәтем — Рәсем иде.
Тик теләгем чынга ашмады:
Сугыш вакытында сагышымны
Шигырь итеп яза башладым.

Ымсындырып калган татлы хыял —
Мин аны бик озак сагындым:
Үкенечле аҗаганнар булып
Күңелемдә төсләр кабынды.

Кырыс җирдә тормыш шаярта шул,
Бирмәде ул күктән көткәнне.
Шигъриятем, диеп йөргән берәү
Бәлкем рәссам булып киткәндер.

Алмашканбыз ахры хыялларны,
Язмыш шулай кушкач, нишләсе...

Бердәй булгач җанның сусаулары
Очраштырды илһам чишмәсе.

Үпкәләмә, Рәсем-мәхәббәтем,
Шигырь юлларыннан үттем мин —
Насыйп булдың ныграк сөйгәннәргә,
Үз тиңеңә булдың, үкенмим.

*1997. Гыйнвар.*

***

*Айрат Арслановка*

Татар улы, шигъриятнең чын үзе син:
Синдә моң да, горурлык та, синдә гайрәт.
Туган телнең даһилары исеменнән
Син лаеклы, вәкаләтле илче Айрат.

Күрде илләр, ишеттеләр һәр тарафта,
Шигареңдә Тукай-Гимн, Җәлил-Байрак,
Күтәрелдең, һәм күтәрдең күңелләрне
Сәхнәбезнең уртасында күкрәп-кайнап.

Халкыбызда бу затлылык вә күркәмлек
Киләдер ул борынгыдан, алыслардан.
Юк, вакланмый, яши милләт, иманы сау,
Туа тора дөньябызга Арсланнар!

*1996. Март.*

## Яшәү төсе

Тарих даласыннан тәгәрәргә
Без дүңгәләк түгел тамырсыз,
Безнең әзләр тирән тарихларда:
Һәйкәл-шәҗәрәдән танырсыз.

Таш каладан комнар ишә-ишә
Узып тора гасыр-давыллар...
Киң кырлары белән мәңгелеккә
Береккән дә яши авыллар!

Уңдырышлы туфрак — безнең хәтер,
Чәчеп-урып шуны яңартам —
Үлемсезлек дәрте сүнмәсен дип,
Язлар саен җанда янар кан.

Киләчәкләр килер-китәр алар,
Син сорама минем яшемне —
Гасырларны ялгар орлык бирә
Мәңгелек төс — яшәү яшеле.

Чәчелмәгән кырдан тәгәрәргә
Без дүңгәләк түгел тамырсыз —
Гел өзелмәс безнең кавемне сез
Үлмәс арышлардан танырсыз.

*1997. Март.*

# ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР



**Барлас Камалов**

# ХАТИРӘЛӘР ЯҢАРГАН КӨН

ПОВЕСТЬ

## 1

Ул әллә нигә борчылып йокыдан уянганда таң да атмаган иде әле. Тышта ай яктысы. Балкон тәрәзәләрендә рәссам-суык төшергән асыл челтәр сыман бизәкләр. Февраль дилбегәне нык тота иде әле.

Нурмөхәммәт тәрәзәгә карап, уйланып ятты.

Айның күмәче кителә башлаган бугай. Ул шундый якын тоела, кул сузымында ук димәсәң дә, мылтыктан атсаң, тидереп булыр төсле. Көмеш мишень!

Яшьлегендә кече калибрлы мылтыктан һәм пистолеттан бик оста ата иде ул. Беренче разряды бар иде. Мишеньнең нәкъ "алмасы"на чүкү егеткә әйтеп бетергесез рәхәтлек бирә иде. Шул маһирлыгы аңа солдат хезмәтен иткәндә дә бик ярап куйды, ярыштан-ярышка гына йөрде, округта дан алды. Өстәвенә ул бик яхшы йөзә дә иде.

Дөнья көткәндә дә, шөкер, шулай була килде. Кырык сигезен тутырды, абынып-сөрлегеп авыз-борын канатмады, чокыр-чакырга төшеп, кул-аяк имгәтмәде, белер-белмәс барып, таш диварга бәрелгәне, маңгай күперткәне булмады. Тәфсилли китсәң, сикереп чыга алмаган киртәләр булгалагандыр, тулаем алганда, тормышта ул үз дигәненә ирешә килде, ниятләрен чынга ашыра торды. Тешләгән җирдән өзәргә, тоткан җирдән сындырырга күнекте. Хезмәтендә дә югалып калмады, мәхәббәттә дә махы бирмәде.

Олыгая баруның сәер бер галәмәтедер инде, яшьлек ярсуы белән өретелгән еллар торган саен исенә ешрак төшә.

Район үзәге — Ташлытау поселогындагы урта мәктәпнең унынчы классында укый башлаган көннәрә. Аларны, чыгарылыш классы укучыларын, инде соңгы мәртәбә булыр диптер, дәресләрдән соң мәктәп бакчасына, кышлык сортлы алмаларны җыярга алып чыктылар. Әй, күңелле булган иде алма өмәсе! Ә кичен алар ата-аналар өчен уку елы башында ук уздырыла торган җыелыштан соң концерт куйдылар. Сәхнәдә Нурмөхәммәт белән Аланлыктан килеп укучы кыз Даимә парлашып җырладылар. Классташлары Талип аларга баянда уйнап торды.

Мәктәп кагыйдәләре ноктасыннан ни дәрәҗәдә аклангандыр, яшьләр былтыр ук өйрәнеп, хәстәрләп куйган "Зөләйха" җырын башкардылар. Җыелышка килгән апа-абыйлар бик яратып тыңладылар, җырны кабатлаттырдылар хәтта.

Талип кына бу хәлгә үртәлә иде. Баян сыздырырга иренгәннән түгел, жырның соңгы ике юлын Даимә кабатлаганны ишетмәс өчен... Нурмөхәммәтнең чибәр йөзенә текәлеп жырлый бит Даимә:

Шул егетне яратам, дип,
Әйтермен мин әнкәмә...

Нурмөхәммәткә исә шул гына кирәк! Жәннәткә түләүсез путевка алганнан ким сөенми.

"Зөләйха"ны кабат жырлап бетергәч, алкышлар тынар-тынмас арада аларның класс житәкчесе сәхнәгә бик матур кечкенә кәрзин белән алмалар алып менде. Залдагыларга ул:

— Бу уку елындагы чыгарылыш класстан Даимә Газизова, Нурмөхәммәт Шакиров, Талип Сәяров бүгенге өмәдә алма жыю алдынгылары булдылар. Бу алмалар — уңганнарга күчтәнәч... Бәхет алмалары! — диде.

Талип сәхнә артындагы класска беренче булып чыкты да, баянын иңennән салып куйгач, алмалы кәрзинне күтәреп керде һәм багалмаларның иң матурын сайлап Даимәгә сузды. Шул мизгелдә Нурмөхәммәт ялт иттереп алманы аның кулыннан тартып алды, бик шартын китереп, елмая-көлә Даимәгә тоттырды.

— Гөлсем Әдһәмовна бәхет алмалары, диде бит. Авыз ит тә бәхетле бул! — дип тә куйды.

— Рәхмәт! — Даимә аңа сихерле елмаю белән жавап кайтарды.

... Чыгарылыш кичәсе. Жәйге таңда, кичәне түгәрәкләгәч, шау-гөр килеп мәктәп залыннан чыккан минутлар. Бозлы елгасы буена, Болынбай урманына юнәлгән чак.

Чандыр гәүдәле, урта буйлы, озын толымлы Даимәнең шатлыктан балкыган йөзе. Карга канатыдай елкылдап торган чәч, чигә бөдрәләре. Төн карасы төсле күзләр. Шуларны күзгүдән саклаган кебек сирпелешкән нуркерфекләр. Озын да, куе да алар. Менә-менә көлемсерим дип торган иреннәр. Һәм тагын табигатьнең аңа гына салган тамгасы — уң колак йомшагындагы соргылт кечкенә миң. Аны колагалка дугасы да томаламый иде. Өстендә зәңгәр жирлеккә алмагач чәчәкләре төшкән жиңел күлмәк. Аякларында ак туфлиләр. Башында пәрәвездәй генә ефәк яулык.

Уң ягында Талип. Аның иңендә баян. Сул тарафында Нурмөхәммәт. Каяндыр табып алган чыбыгы белән балагына суккалап бара.

Бөтен класс урманга кузгалгач, туып килгән көннең йомшак тынлыгын ярып, Талип баянын аерата бер ярсу белән уйнады. Янәшәсеннән атлыйатлый Даимә әйтте:

—Үзәкләремне өзә шул уйнауларың, әй! Кышын булса, Бозлы суының бозын эретер идең, — диде.

Бу сүзләр Талип өчен барлык мактаулардан да өстен иде. Шуңа бик кәефе килептер, ул:

— Йөрәгемдә пожар, Даимә, Фаренгейт буенча исәпләсәң, ике мең градус кызулык, ут капмасын үзеңә, — дип шаяртты.

Кызның да жавабы әзер иде.

— Утларын кабызсаң, суларын да сибәрсең, — диде. Әлеге сүзләр Нурмөхәммәтне без белән чәнчегәндәй итте.

— Пожарникларга мохтажлык юк. Йөрәк ялкынын, мәсәлән, мин үзем бик тиз сүндерә алам, — дип куйды. Бу минутта егет Даимәнең беләгеннән тоткан, йөзенә үк якын килгән иде ( ни гомердер үзенә игътибар итмәүдән килеп туган гарьлекне дә гашыйк булу галәмәтенә чутлаучылар да бар бит ул!).

Даимә аңа сәер генә елмайган иде.

Урманга життеләр. Агачлар, куаклар, үләннәр июнь таңында юмарт төшкән чыкка манчылып калган иде. Һава гажәеп саф, ылыс һәм чәчәкләр исе сулышны жиңеләйтә иде. Иртәнге тынлыкта наратлардагы бихисап ылысларның зыңлавы ишетелә иде кебек. Билгеле инде, төркемнәре белән яшьләр килеп кергәч, урман аланыннан тынлык качты. Яшьләр ул иртәдә "Матур булсын!" дигән жырны берничә мәртәбә жырладылар.

Илебезнең халыклары
Матур тормыш коралар;
Тыныч булсын, тыныч булсын,
Тыныч булсын дөньялар!

Егетләрнең-кызларның килер көннәргә булган теләк-өметләрен сөйли иде кебек ул җыр. Һәммә ниятләре, корган планнары чынга ашсын өчен, илнең-көннең имин булуы өчен тынычлык кирәген һәммәсе аңлый иде.

Җырлап арыгач, танцевать иттеләр (Талип баяныннан арына алмый иде, уйнады да уйнады). Күпмедер вакыт узгач (кояш күтәрелеп бара иде инде), "Мәктәп вальсы" яңгырады. Шулчак Талип игътибар итте: Даимә дә, Нурмөхәммәт тә аланда юк иделәр...

* * *

Даимә Казанга, педагогия институтының филология факультетына керергә дип китте, ә Нурмөхәммәт шул институтның спорт һәм физик тәрбия факультетын сайлады. Даимә керде, Нурмөхәммәт конкурстан үтмәде, керә алмады. Борылып кайткач, аны оборона җәмгыятенең район оешмасына инструктор итеп чакырдылар. "Мотоциклы бар. Авылларга йөрергә әйбәт буласы!" — диделәр. Шуннан эшләп киткән иде Нурмөхәммәт. Армиядән дә шунда кайтты. Аннары райбашкармага эшкә күчте. Университетка укырга керде, тарих бүлеген тәмамлап, диплом алды. Суда гына түгел, тормышта да әйбәт йөзә белә иде. Тире-ярычы әтисе — юан Зариф тормыш җаен төбенә төшеп өйрәнгән кеше иде. Алма агачыннан ерак төшми, диләр бит. Зарифелгыр вак-төяк кешене күрми дә, район җитәкчеләре алдында исә келәм булып җәелә белә иде. Ташлытауныкылар аңардан көнләшәләр дә иде бугай. Хәер, күрә алмаучылар да юк түгел иде шикелле.

Нурмөхәммәт әтисенең ул елларда әйткәннәрен бүген дә хәтерли. "Кеше таный бел, — ди иде аңа әткәсе, — хатынның күндәмен, сүзсезен сайла, бугазыңа хуҗа була бел (кирле-кирәкмәгән адәмнәр белән кайда җитте шунда эчәсе булма!), чит хатын-кызга күз алартма (һәр итәккә иярәсе булсаң, үлемең Газраилдан түгел, шул "ярык тояклар"дан килер!). Әтисенең алтын сүзләрен асыл ташка тиңләп яшәде һәм яши Нурмөхәммәт Зарипович...

Әйе, әйе З а р и п о в и ч . Күптән инде шулай дип олылыйлар аны. Яшерми, бик ярата олылаганны. Җитәр! Урта мәктәптә чакта да байтак туры килде аңа Зариф малае икәнлеген онытып торырга. Математикадан өйдә эшләргә бирелгән мәсьәләләрне чишә алмый килгәндә кечерәергә мәҗбүр иде ул. Кем теленә ничек килә, шулай эндәшәләр иде бит аңа. Нурмөхәммәт дип тә, Мөхәммәт дип тә, Хәмәт кенә дип тә. Кучерт кенә син аңа мәсьәләне, чүлмәк дисәң дә ачуланасы юк иде ул вакытта. Рус әдәбиятыннан сочинение дигәндә, Даимә булыша иде аңа.

Өлгергәнлек аттестатына имтихан тотканда, тригонометрик ысулларны кулланып, геометриядән язма эш башкарганда, Нурмөхәммәт таш сын шикелле утырып торган иде. Тактага язып куелган мәсьәләне ул бөтенләй аңламый да иде. Шуңа күрә класска кереп, һәркем аерым өстәл артында язма эш башкарырга керешер алдыннан ул Талип Сәяровтан бик гозерләгән иде: "Үтермә мине, малай, яме. Мәсьәләсен генә эшләп, чыгарып куй мынау таш астына, яме. Миңа "өчле" булса, хәттин ашкан, яме".

Бәхетсезгә җил каршы дигәндәй, аларны шулай итеп утырттылар. Талип белән Нурмөхәммәт икесе ике вариантны чишәргә тиеш булып чыктылар. Өзеп вәгъдә бирмәгән булса да, кызганды шикелле Талип Зариф абзыйның чибәр малаен. Башта аның вариантындагы мәсьәләне чиште. Аннары кулына язу карасы түгеп, кул юарга дип йортка чыкты, алдан килешенгән буенча, мәсьәлә чишелеше теркәлгән дәфтәр битен таш астына куеп керде. Шуннан соң гына үз вариантындагы мәсьәлә һәм мисалларны чишә башлады. Өлгерде тагын, "бишле"гә башкарган иде.

Нурмөхәммәт тә, билгеле инде, сәбәп табып чыгып әйләнде. Бәхетенә, укытучылар аның өстендә атлы казак булып тормадылар. Нурмөхәммәт Шакиров таш астыннан алган серле "хәзинә"не акламага туп-туры күчерде һәм тәки "өчле" алды, котылды!

Талипка таянып, ни рәвешле бәладән котылуын сизенгән идеме икән, математика буенча телдән имтихан бирергә килгәч, мәктәп директоры, "Дан" орденнарының тулы кавалеры Сабирҗан абый Халиков әйткән иде Нурмөхәммәткә: "Утта янмассың, суда батмассың син, Шакиров", — дигән иде.

— Ник алай дидегез әле, Сабирҗан Шәрипович! — Егет һични аңламаганга салышып, шулай сораган иде.

— Кояшка да туп-туры карый аласың, шуңа әйтүем... —Директор мәгънәле генә көлемсерәү белән чикләнгән иде.

Тормыш ярыннан гомер дөньясының әчкәресенә шулай йөзеп кереп киткән иде Зариф абзыйның төпчек улы. Колачны ничек салырга икәнен үзеннән югарыраклардан өйрәнә-өйрәнә, күчерә-күчерә, озак еллар йөзде. Ташлытауда партия райкомының өченче секретаре булып эшләде, аннары икенчесе итеп сайладылар, җирле Советларга сайлауларның берсендә аны район Советы башкарма комитетының рәисе иттеләр. Ул постта шартын китереп утырды. Моның беренче секретарьлыкка сикереш кәнәфисе икәнен Шакиров яхшы төшенә иде. Тормышта андый трамплиннарны аз күзәтмәде ул. Нәкъ шулай булып чыкты. Конференцияләрнең берсендә, ниһаять, беренче итеп сайланды. Кайчандыр өйдә чишәргә бирелгән мәсьәләләрне, язып килергә кушылган сочинениеләрне дәфтәрләреннән күчереп йөргән классташларына бер дә тартынмыйча акыл өйрәтә башлады. Аларны еш кына шелтәләде, хәтта җәзага тартканы да булды.

Килде бер көн, инде ул район хакимияте башлыгы дип атала башлады. Янәдән район патшасы булып алгач, аның күңеле айның унбишенче кичәсендәгечә түгәрәкләнде.

... Шактый вәкарьле караш белән Нурмөхәммәт янә Айның көмеш табагына текәлде. Бүген, менә бүген көмеш мишеньгә атып тидерә алырмы ул? Таң алды йокысыннан хафаланып уянып китүе дә шул сорау бимазалап торганнан икән бит!

Казаннан зур комиссия киләчәк. Илбашы аппаратыннан бер белеше кисәтеп куйган иде инде аны, фронталь тикшерү булачак, дип. Президентка сезнең районнан зар хатлары байтак килде, дигән иде.

Нурмөхәммәтнең үртәлгәне комиссия үзе түгел. Алар әүвәл-әүвәлдән була килделәр. Үзгәртеп кору, демократия, хокукый дәүләткә йөз тоту дип, Совет властеның гомерендә булмаганнарны уйлап чыгардылар. Альтернатив кандидатлар дигәнен худка җибәрделәр. Халык алдында исәп-хисап тоту дип кыбырсыйлар... Нервыларны сынау, нервыларга имтихан. Уйлан, шикләп, өметлән, өметсезлән... Таптылар бит, билләһи! Демократия, имеш! Безнең халыкка артыгын юл куйсаң, анархиягә ташланырга да күп сорамый ул. Өйрәнгәнмени ул демократиягә?!

Соңгы берничә елда бик үзгәрде халык. Батырайды. Сүз сөйләргә остарды. Пычак теллегә әйләнде. Туп-туры сиптерәләр... Шулар арасында Талип Сәяровлар түш киереп йөри. Андыйлар алга чыгып бара хәзер...

Талип шәп механизатор булып танылды. Урта мәктәптән соң, читтән торып Чистай авыл хуҗалыгы техникумы дипломын алды. Район халкы бик үз итә аны... Бу кеше урта мәктәп тәмамлагандагы хәлләрне бик белә бит! Менә шул кадәресе Нурмөхәммәтнең күңеленә тия.

Нурмөхәммәт өчен уйларында гына булса да үз-үзенә дә ачылып китә алмаган тагын бер "ни" бар. Анысы эчтән яман кимерә. Еллар буе чарасыздәвасыз игәп тора. Башыннан чыгарып, күңеленнән себереп ташлый алмый шуны. Бу — Даимәнең яшьлектә Талипка булган хисләре. Нурмөхәммәт һәммәсен дә һәрдаим белеп яшәде бит: тугрылыклы, әдәпле, тәртип-низамлы хатын, бар булдыгы белән ахырынача балаларына бирелгән ана булса да, Даимәсе тәне-гәүдәсе белән генә Нурмөхәммәт гаиләсендә, җаны белән Талип хозурында иде ул.

Яшьлегендә Шакиров үз тантанасына исереп, башын салават күперенә күтәреп йөрде: “Районның гүзәлен үземә караттым! Үземнеке иттем. Зариф Нурмөхәммәтенә сакал тегә алмадылар. Минеке аста калмады!”

Еллар үтү белән инанды: Даимә аның туфрагында чәчәк атар гөл булып чыкмады! Кызның күңел аязлыгы юк булды. Йөзеннән елмаю качты, көләчлек бизде. Сүзләреннән жорлык югалды. Ташып торган дәрте сүнеп-сүрелеп калды. Көн үтсенгә яши башлады Даимә. Яшерен сагыну һәрчак авыр. Байлык-житешлек тә, үзләре чолганышындагы ихтирам-олылау да бер бөртек тә кызыксындырмас булды аны... Нурмөхәммәт аны үзенеке итте итүен, тик Даимәнең бәхетен юлда коеп калдырганын абайламады...

Еш кына шулайрак килеп чыга бит, егет кешенең чибәр кызга булган хисләре әллә ни тирән дә, кайнар да түгел. Өйләнүгә аны хөсетлек аралаш көнчелек-ярыш кычынуы этәрә. Күреп тора: кызның дуслар, таныш-белешләр хозурында абруе зур. Бу да чибәркәй йөрәгенә һөжүм итә. Омтылышларына уңай җавап алгач, ахыр чиктә морадына ирешкәч, чибәрнең ире булуны авырга саный башлый, гәрчә хаталануында үзенең шөһрәт сөюеннән гайре һичкем катнашмаса да, хатынын үз өметләрен алдауда гаепләргә керешә.

Язмыш үт сытардай хәлләрне аслы-өсле өйсә өя бит! Менә хәзер яра өстенә тозы да бар. Анысы да арынырлык, качып котылырлык кына түгел бугай инде!..

Нурмөхәммәт болай ачыргаланганда, район прокуроры ярдәмчесе Илсур Сәяров белән (ул — университетның юридик факультеты дипломын алып кайткан егет) кызы Айгөл мөнәсәбәтләрен уенда тота. Авыл хуҗалыгы институтын узган җәйдә генә тәмамлап, район җиләк-җимеш питомнигына кайткан кызы — кирәк бит! — Талип улы белән якын дуслык, мәхәббәт багланышына тарыды.

Соңгы көннәрдә яшьләрнең араларыннан кара мәче узгалап тора бугай да торуын, аларныкын белмәссең, бүген — болай, иртәгә гел уйга да китерә алмаганча... Чын мәхәббәт булса, сөешү диген тыелгысыз зур көч алып ыргытмаслык киртәләр юк дөньяда. Мәхәббәт өермә ул, туфан. Яхшы якка да, яманга да көче житә. Гүзәллекне тудыра да, җимерә дә ала. Тылсымлы да ул, сихерле дә, күз буучан да. Күңелең төшкән кешене чибәр, акыллы, булдыклы итеп күрсәтергә дә, җаның тартмаган чибәрне алдыңа пәриләндереп бастырырга да хәленнән килә...

Караваt үлчәп ятып мәгънә чыкмасын аңлады Нурмөхәммәт. Торды, юынды, өйдәгелеккә киенеп куйды һәм эш бүлмәсенә чыкты.

Урындык алып утырды. Укырлык түгел, караңгы иде әле. “Ут кабызырга кирәк. — Нурмөхәммәт өстәл лампасын тоташтырырга дип күтәрелде. — Тормышта миңа һичкем чыра яндырып та, электр балкытып та тормый бит инде. Моңа тикле ни майтара алган булсам, нинди “лампа” кабызырга кулымнан килгән булса, калган гомерне шуның яктысында яшәргә тиешмен. Барыр юлны ярыйсы яктыртырмы ул, әйле-шәйле генә нур бирерме, өзеп әйтүе кыен. Бүгенге хәлләр бу сорауга да өлешчә булса да җавап бирердер...”

## 2

Нурмөхәммәт Шакиров бәгыренә учлап тоз салган хәлләр һәм яшьләрнең “соңгы көннәрендә араларында кара мәче йөреп тору”ның үзенә күрә тарихы бар.

... Февраль башы. Суык гайрәт күрсәтә. Ә бүлмәдә мамыклы җылы. Малай чагыннан ук гөлләргә, чәчәкләргә гашыйк Илсур. Кәгазьләрдән арынып торган минутларында кабинеты тәрәзә төпләрендәге кактусларга су сибә. Кайчак аларга нәни балаларга эндәшкәндәй сүз куша.

— Көннәрнең язга авышырга иткәнен тоя башладыгызмы, итләч сабаклар? Минем күңелдә дә яз җыры туып килә! Яз үзе Аның тавышы белән җырлый, Ул булып моң түгә...

Кинәт Илсур, утка пешкәндәй, гөлгә сузган кулын тартып алды. Онытылып китеп, бармагын чәнчеткән икән...

Иртәгесен Айгөл белән эш сәгате азагында Илсурның хезмәт урынында очраштылар. Агроном кызның җиләк-җимеш питомнигыннан кайтып барышы. Ул килеп керүгә, Илсур бүлмәсендә кояш чыга, гөлләр чәчәк ата башлый сыман. Егет күңеленә шулай тоела.

Буйга-сынга, төскә-биткә чибәр Айгөл. Сөйкемле дә, акыллы да. Матур җырлый. Сандугач инде менә! Егет колагына шулай ишетелә. Айгөл белән бергә булган минутларда Илсур үзен матуррак та, зирәгрәк тә, көчлерәк тә итеп сизә. Баеп киткәндәй була, миллионерларың бер якта торсын! Тик бүген кызның чырае бер генә дә җырдан ләззәт табып кинәнүченекенә охшамаган иде. Матурлыгы да каядыр посканмы соң әллә? Дорфалыкка якын кырыслык бер дә йогышмый иде аңа. Егет моны күрде генә түгел, җаны белән тойды гына да түгел, тәненең һәммә күзәнәге белән сизде. Ул әйләнеч юллар эзли белми, туп-туры сорады:

— Кәефең киткән диимме, Айгөл? Ни булды? Берәр күңелсезлек бармы әллә?

— Күңелле лек! — диде кыз, сабый балаларча турсаеп.

— Уз, утыр, җылын.

Айгөлнең йөзе карала бирде.

— Вакытым тар. Мин сиңа: "Әти алдында гафу үтен!" — дип әйтергә генә кердем. Аңладыңмы?

— Аңламаган кая! Тик Нурмөхәммәт Зарипович сиңа барысын да дөрес ирештердеме икән соң?

— Алдашып йөрергә сигездә түгел, кырык сигездә ул.

— Алайса син һәммәсен дә дөп-дөрес аңладыңмы икән?

— Ахмакларны бүтән җирдән эзлә!

— Димәк, син әтиең позициясен тулысынча хуплыйсың? Ә мин, мәхлук, фикердәшем булырсың дип көткән идем.

Айгөл, пәке белән сызып җибәргәндәй, әйтте:

— Җете кызыл булма! Ул заманнар узып китте шикелле. Мин Павлик Морозов үрнәгендә тәрбияләнмәгәнмен, беләсең килсә, хуш!

Ул, командага буйсынгандай, кырт борылып чыгып китте. Илсур аның артыннан иярмәде. Бары тик өзгәләнеп:

— Нишләвең бу, Айгөл? — дип сорап калырга гына өлгерде. Аннары лып итеп урындыкка утырды. Гүя аның иңнәренә албасты көрәктәй кулларын салган иде.

"Ничек була соң әле бу? Фиданның әнисендә бер хәсрәт. Аның күңел җәрәхәтенә кислота тамызабыз түгелме? Нурмөхәммәт абыйның үз кырыгы — кырык.

Улы Чечнядә һәлак булган ханым Нурмөхәммәт Шакиров янына авыр хәлен аңлатырга, ярдәм гозерләргә дип килгән булган. "Мин җәмгыяте хәйриядә утырмыйм", дип, теге хатынны куып чыгаргандай кыланган. Зар түгеп килгән ананы тыңлаганнан соң Илсур телефоннан Нурмөхәммәт Зарипович белән кырыс кына сөйләшкән иде. Абзый үзеннән яшь кешенең сүзләрен авырга алган, хәтта кызына да зарланган.

Айгөл, мин — ата-ана сатучы түгелмен, димәкче. Тиздән бергә булырга вәгъдәләшкән кешеңне сатсаң да ярый булып чыгамы? Бәлки аның һәммәсен турыдан-туры әйтүе хәерлегәдер. Киләчәккә калдырмавы... Парлы тормыш коруны гафу үтенүләрдән башлап җибәрү егетлекме? Бу хакта Айгөл белән уртага салып сөйләшер, аңлашыр җай да бетте... Ничек кенә булмасын, иманга хилаф итмәскә кирәк!"

Нурмөхәммәт яшьләрнең низагын "Яратышулары көчле булганга кылтаешалар" дип юраса да, Илсур белән Айгөл мөнәсәбәтләре, ай-һай, кылтаешу гына микән?

## 3

Кышкы төн үтте, таң алды эңгер-меңгер узды. Ташлытау артыннан кояшның тәүге нур сөңгеләре офыкка кадалды.

Нурмөхәммәт Шакиров гаиләсе гомер итә торган особняк —һәммә

кирәк-ярагы тулаем житешле аерым йорт — район үзәге поселогының көнтуар ягында урнашкан. Шуңа күрә кояш иң әүвәле алар тирәсен яктырта да, җылыта та башлый.

Булып узды еллар, яшьрәк чаклар дип әйтикме, Нурмөхәммәт, хыял катыш романтикага бирелеп, болайрак уйлый иде: "Тау артыннан чыгу белән, кояш башта безнең урамны нурландыра, чөнки ул безгә якынрак, аннары инде бөтен дөньяга нур чәчә башлый. Һәммә төбәкне җылытырга керешә. Барча җан иясен куандыра. Хәтта ташлар да кояшта назлануга шат булалардыр кебек. Без моннан бер дә көнләшмибез. Бүтәннәр дә кояшның бу төбәктә башлап безне иркәләвенә хөсетләнмәсеннәр. Кояш чиксез көчлекодрәтле бит, барыбызга да мәңге-мәңгегә җитә..."

Ул моңа охшашлырак сүзләрне кайсыдыр язучыдан укыган иде шикелле, тик аларны үзенеке итте. Дөресрәге, язучы сүзләре аның күңел тибрәнешләренә туры килә иде. Шуңа үз итә алды, үз итәсе килде.

Тора-бара, еллар үтү белән, фикер һәм теләкләр дә үзгәрүчән икән. Хәер, кем ничектер? Нурмөхәммәт Зарипович нилектән, ни сәбәптәндер, соңгы елларда кояшның бүтәннәргә нур чәчү-чәчмәве белән әлләни кызыксынмас булып китте. Көн туганмы? Туган. Аязмы? Аяз. Бүтәннәргә дә төшәме кояш нурлары? Төшәр, төшми калмас... Кая барсаң да бер кояш, дип җырлыйлар ич. Төшмәсә ни хәл итим? Утлы шарның руле минем кулда түгел...

Балигъ булган көннәреннән алып яшәүләренең соңгы сәгатьләренә кадәр үзләренең төп уйларыннан, калыпланган фикерләреннән, цементланган принципларыннан бер карыш та тайпылмаучы затлардан аермалы буларак, Шакиров иптәштә ваемсызлык борынлый башлады. Дөресен әйтик, баштарак бу хәл аны борчый иде, җанына тынгысызлык китерә, күңел эчкәресендә "ике мин" тудыра һәм алар бик җилле бәхәсләшәләр иде. Соңрак җаны андый газаплардан арынды. Шул көннәрдәдер, Нурмөхәммәткә, республика халык депутаты буларак, зур гозер белән кергән берәү, район башлыгының гамьсезлек-битарафлыгына чыдый алмыйча: "Хәлегездән килсә, бүтәннәр өстенә кояш та чыгармас идегез. Әкәм-төкәмлек бу!" — дип чыгып киткән иде.

Гаҗәбе шул: ядрә-сүзләр дә Нурмөхәммәтнең кәефен кырмаган иде. Ул сүзләр аның бер колагыннан керде, икенчесеннән чыгып та китте. Башлыкның тән тиресе тәнкыйть үтмәслек булып каешланган иде, күрәсең.

Быел, бүген янә үзгәртергә кирәк. Югыйсә менә ничәнче ел инде Чынбарлык: "Сытам! Изәм!" — дип тора. Хакыйкать меңнәр, миллионнар биргән вәкаләт белән өскә ябырылып килә. Ә үзгәреп булмый. Үткәннең тимер-бетон конструкциясе шул тикле нык, йә элек ничек корган булсалар, шул килеш үрә катып торырга, теге елларда ятлаганнарны сөйли бирергә, йә шартлап сынарга кирәк.

Өченче юл юкмы соң? Бардыр сыман тоела Нурмөхәммәт Зариповичка.

Никадәр генә оста, җитез, куәтле булсаң да, агымга каршы йөзү турында уйларга да ярамый. Теге вакытларда да мөмкин булмаган эш иде ул, хәзер инде бигрәк тә. Бер генә колач салып кара агымга каршы, сулыш алырга да өлгермәссең, ай-вай кубачак. Эте-бете шәрран ярачак, нәгърә орачак. Бәс, бичарадан ни чара? Агым уңаена йөзәргә! Фәкать! Йон уңаена сыпырырга! Тыңлыйсың килмәсә дә тыңларга (хәзер һәркем сөйләргә өйрәнде!), тибеп очырыр тәкъдирдә дә кабул күрергә, чемету-чәнчүләргә чырай сытмаска, булдыра алсаң, елмаерга. Вәгъдәне кызганмаска. Үтәлешен буйсынуындагыларга йөкләргә. Алар җилкәсе чиләнсен!

Үз дигәннәреңә таян, тыштан сиздермә. Үземә яраклы дигәннәрне култыкса итәргә җай юк түгел...

Инде дә тамырдан, тирәннән үзгәртү дигәннән, кычкырып әйтеп булмый инде, тузга язмаган нәрсә ул. Кем үзгәрә? Ничек үзгәрә? Булмый ул! Утопия! Нурмөхәммәт Зариповичмы? Бүтән районнардагы башлыкламы? Булмаганны! Барыбыз да җайлашачакбыз, шул гына. Без бит һәммәбез дә — хәзер дулый-дулый сүгә торган система кешеләре, шул системаның тулышып пешкән җимешләре. Лидерларыбыз да бик аз гына алгарак карый алучылар...

Уйларына чумган килеш Нурмөхәммәт Зарипович җиренә җиткереп кырынды, озаклап юынды. Чисталык-пөхтәлек дигәндә, җаны фида. Иртәнге чәен ашыкмый-кыбырсымый гына эчте. Эш урынына кереп тормастан, туптуры Культура йортында булачак киңәшмәгә барырга исәпли иде. Көн тәртибендә җитди мәсьәлә —"район хакимиятенең узган елдагы эшчәнлеге хакында хисап, алда торган бурычлар турында".

Айгөл эшкә бик иртә кузгалды, Даимәсе мәктәпкә җыена иде.

— Костюмнарыңның кайсын киясең? — Хатыны атап сорады. Казангафәләнгә барасы булса, Нурмөхәммәт киемнәренең кешелеккә дигәннәренең дә шәбрәген киючән, районда гына булса, бер чама йөри.

— Бу проблеманы синең белән хәл итик инде, карчык. — Нурмөхәммәт елмаеп-көлеп шулай диде. Тик барыбер көләчләнүе ясалма булып калды. Эчтән көйрәвен томалый алмады. Даимә моны бик сизсә дә, белдермәскә тырышты. Юатуга охшаган сүзләр әйтә калсаң, отыры хафаланачак.

— Яңа алганын ки... — Хатыны энәдән-җептән генә чыккан костюмын киеп баруын тели иде.

Нурмөхәммәт ялт итеп хәләленә карады.

— Район башлыгы халыкка ошарга тели, күрдегезме ничек киенепясанып килгән, димәсләрме соң?

Даимәнең торып-торып кырт кисә торган гадәте бар. Бу юлы да сакланып калмады.

— Нигә, максатың шул түгелмени? — дип сорады.

— Шулаен шулай да... — Йорт башы эчендәгесен әйтеп бетермәде. Гомер иткән хатыны аңлады, төшенми калмады. Белә бит ул иренең зур бавырлы икәнен. "Ошарга тырышып, бер дә тәтиләнәсем килми шул. Алай итү баш июгә якынлаша түгелме соң? Мин бит гомерем буе баш имәдем, бил бөкмәдем, гозерле белмәдем. Өстән куштылар, сайладылар. Мин моңа бик канәгать идем. Хәзер кичерәюләре бик авыр..." — димәкче иде Нурмөхәммәт. Акылы җитте, әйтмәде. Балаларының анасы булса да, чирек гасыр бергә гомер кичерсәң дә, хатын бит әле ул, хатын... Еш кына үзең әйткәннәрне үзеңә каршы пистолет итүче зат...

Шул минутта аның хәтеренә хатыннар турында гарәпчә әйтелгән сүзләр килде. Университетта укыганда карт бер галимнән ишетеп, язып алган иде ул аларны. "Ля хәйре минһөннә, вля бөддә фиһөннә" (Алрдан хәер (яхшылык) юк, ләкин алардан башка чара да юк).

— Ярый, синең киңәшне тотыйм, әниләре! — Нурмөхәммәт егетләрчә җитезләнеп, кием шкафыннан өр-яңа костюмын алды. — Инде күлмәге дә моңа иш була торгандыр бит? Галстугы да?

Зәвык белән киенергә дигәндә, купшылана белә инде Шакиров әфәнде. Тире-ярычы гаиләсендә үскән димәссең. Апасы бик нечкә зәвыклы иде аның. Укытучы ханым. Аннан да битәр җизнәсе. Озак еллар хәрби хезмәттә булган офицер. Шулар зәвык әлифбасын өйрәткәннәр иде...

— Күлмәгең дә, галстугың да әзер. Кульяулыгың да. — Даимә урындык аркасына кигереп куйган зәңгәрсу күлмәккә һәм зәңгәр җирлеккә сизелерсизелмәс кенә кызгылт сызыклар төшкән галстукка ишарәләде. Зәңгәр каймалы кульяулыгы да шунда иде. — Җылы ботинкаларыңның карасын ки, чистартып-кремләп куйдым...

— Һай, рәхмәт, карчык! Моның өчен бер үпми булмас үзеңне, билләһи!

— Андый эшләрне дә онытмадыңмыни соң әле? — Даимә кинәнеп көлеп җибәрде.

— Онытмадым, иптәш хатын, онытмадым.

Даимә тыела алмый көлә башлады.

— Киемнәрегезгә тәмәке исе сеңгән шикелле җаннарыгызга да формализм сеңеп беткән инде... Иптәш хатын, имеш! Ай, аллам! Тиздән гражданка Шакирова дип эндәшә башларсыңмы?

Нурмөхәммәт үтә җитдиләнгән булып җавап бирде.

— Юк! Ул дәрәҗәгә җитмәмендер. Даимә ханым диярмен...

Киенеп алгач, йорт башы яшәреп киткәндәй булды. Зур соры күзлә-

рендә нур ишәйде шикелле. Кара тут йөзе яктыра төште. Еллар кыравы белән аралаша башлаган куе кара чәчләрен дә тарап куйгач, тәмам чибәрләнде. Көзге каршына килгән иде, үз чагылышы үзенә дә ошап куйды булса кирәк, күз кысып алды, елмайды.

— Егет жилле!

— Ярый әле бөтенләй карсак түгелсең, буең бар, — диде Даимә. — Корсагың үсүне ничек яшерер идең?

— Нишләтим соң, Даимә ханым? Хезмәтем гел кабинетта да, машинада бит.

— Якынрак колхозларга җәяү йөр. Чаңгыда чыккала...

Нурмөхәммәт хатынына томырылып карады да бер тын сүзсез торды. Нидер уйлап алды.

— Чаңгы шуарга дигәнең — хак, тик оешып булмый ич. Ә инде колхозларга җәяү тәпиләү дигәнең...

Тагын әйтеп бетермәде, әмма бик аңлашыла иде. Җәяү авылларга барып керүне күз алдына китерә алмый администрация башлыгы. Шту син! Укасы коелачак...

Өйдән ирле-хатынлы бергә чыктылар. Бер-берсенә хәерле көн теләделәр. Шул сүзләрне ишетеп, Даимәдән аерылып киткәндә, Нурмөхәммәт күңеленә шом төшеп алды: "Хәерле булырмы соң бу шимбә аның өчен?"

Район Культура йорты янында аны бик җылы каршыладылар. Төрле яктан сәлам бирделәр. Үз тирәсендә һәрдаим бөтергәләнүчеләр кул биреп күрештеләр.

Зал тулы дип әйтерлек иде инде.

Таныш-белешләргә кул сузып та, ияк кагып та сәлам бирә-бирә, Нурмөхәммәт алга узды. Ярый әле, бик тиз башына барып житте, килә-килешкә үк туп-туры сәхнәгә менеп китмәде. Жыелышлар түрендә булырга шул чаклы күнегелгән! Хурга калырсың тегеләй...

Ул алгы рәтләрнең берсенә барып утырды. Президиумга менәсе кешеләр жыелсыннар инде...

Доклады җентекле язылган иде, уңышлар да күрсәтелде, алдынгылар шәрәфенә мактау сүзләре дә шактый жилле әйтелде (күңелләре булсын, ичмаса алары каһәр сүзеннән тыелып торырлар), кимчелекләрне дә читләтеп үтмәде, туп-туры күрсәтте. Үзен дә гадәттә бик еш булмаганча тәнкыйть суына манып алды, мин дә фәрештә түгел, янәсе. Шунсыз булмый, ярамый! Заманасы шундый. Жыелыш имин-аман үтеп киткәч, күз күрер әле...

Маңгайга бәреп торган саннарны атау киңәшмәгә килүчеләрне уятып жибәргәндәй итте. Район башлыгы сүзләренә алкышлар ялганды. Кул чабулар тынгач, залда үзара сөйләшү, фикер йөртү тавышы булып алды.

Шул аралыктан файдаланып, техник секретарь Нурмөхәммәт Шакировка хат китереп бирде. Адреска карап кына Нурмөхәммәт хатның кемнән икәнен ачыклый алмады. Кульязу таныш та, таныш түгел дә кебек иде. Ул конвертны ачты. Хатта мондый юллар тезелеп киткән иде:

*"Нурмөхәммәт Зарипович!*

*Ничегрәк эндәшсәм кулай булыр икән дип тордым-тордым да, рәсми сүз кушасы иттем.*

*Бу юлларны Сиңа күптәнге танышың, инде, мөгаен, хәтереңнән чыгарга да өлгергәндер кеше — Зәйтүнә Мифтахова яза. Миңа Сине бик-бик күрергә кирәк. Махсус килдем. Бүген үк китәм дә. Жыелышыгыз ничәдә бетсә дә көтәм. Зинһар берничә минут вакытыңны кызганма. Әүвәл булып узган дуслык хакына. Үтенеп сорыйм. Мин Сине үзең эшли торган бина янында көтәрмен. Кат-кат гозерләп: Зәйтүнә".*

Нурмөхәммәт упкынга төшеп киткәндәй булды. Нинди жилләр ташлаган бу хатынны ни гомерләр үткәннән соң? Аның белән бер генә тапкыр да күрешмәгәнгә чирек гасыр вакыт узды бит инде! Менә сиңа очрашу!..

## 4

Университетта укыганда, беренче көннән үк танышып киткәннәр иде алар. Бер курста, бер группада укыдылар. Нурмөхәммәт тулай торакта яшәде. Зәйтүнә — Казан кызы. Галантерея кибетендә эшләүче әнисе һәм урта мәктәпне тәмамлап килә торган энесе белән тора иде. Әтисе берничә ел элек дөнья куйган иде инде. "Фронт яралары иртә алып китте аны!" — диләр иде.

Зәйтүнә Мифтахова, урта мәктәпне тәмамлагач, комсомолның ул чактагы Дзержинский райкомында икенче секретарь булып эшләгән, аннары партиянең район комитетына алганнар, елдан артык инструктор булган, шуннан "Укырга кирәк!" дип, гаиләдә кинәш-уңаш иткәннәр дә, университетка керү имтиханнары тапшырган.

Чая, чибәр кыз курсташлары белән тиз аралашып китте. Нурмөхәммәтне кай арададыр үз итеп өлгерде һәм аңа баш түбәсеннән гашыйк булды. Әмма сәер гыйшык иде ул: егеткә үзенең мөнәсәбәтен болай дип белдерде: "Укып бетергәч, син авыл районына китәсең. Шунлыктан мин сиңа кияүгә чыга алмыйм, ләкин мин сине үлеп яратам!" — диде.

Мондый ап-ачык аңлатудан соң алар арасындагы мөнәсәбәтнең нинди төс алуын чамалавы бик авыр түгел (Нурмөхәммәт хәтта әтисе өйрәткәннәрдән читкә китүдән дә тайчанмады).

Лекцияләрне алар аудиторияләрнең иң арттагы рәтендә янәшә утырып тыңладылар, әбәдкә ашханәгә бергә йөрделәр, дәресләрдән соң китапханәнең уку залына икәүләшеп кереп чумдылар. Театрга, концерт залларына, кинога гел бергә баручан булып киттеләр. Семинарларда берсе чыгыш ясаса, икенчесе өстәми яки тулыландырмый калмас иде. Зачетлар биргәндә, имтиханнар тапшырганда, доцент яки профессор хозурына алфавит тәртибендә керү законлаштырылганлыктан (тыңлаучыларның үзләренең карары!), Зәйтүнә Мифтахова белән Нурмөхәммәт Шакиров группа исемлегендә беренчеләр булып теркәлгән Айтуганова һәм Алимов белән чират алмашып, бергә узалар иде. Тегеләре башлап чирканчык алып, галимнәр каршына керергә никтер базмый торганнар иде.

Бик еш булмаса да, Нурмөхәммәт Зәйтүнәләрнең Нариман урамындагы фатирларына да барып чыккалый һәм сыйлангалап кайта иде. ВУЗның тулай торагы шартларында Иблис шөгыленнән дә яман саналган эшне Мифтаховлар табынында кѳтелгән кунакның күңелен күрүгә чутлыйлар иде.

Икенче курста укыганда, кышын, Мифтаховалар группасына шимбә-якшәмбе көннәрендә булу өчен Яр буе Морквашындагы ял йортына юлламалар бирделәр. Егермеләп кеше караңгылы-яктылы шунда кузгалдылар. Ашау — байдан, әҗәл — Ходайдан, дип, кинәнеп ял иттеләр. Ике көндә дә чаңгыда шуып рәхәтләнделәр.

Шимбә кичендә Казандагы кайсыдыр зур заводның үзешчәннәре килделәр, концерт күрсәттеләр. Концерттан соң үзләре сыйланып-җырлашып утырдылар. Кышкы төннең уртасы авышкач кына үз бүлмәләренә таралыштылар. Мондый чакта — уку йортының әчке тәртип кагыйдәләреннән котылып торган араларда — ир-ат заты да, кызлар да — гап-гади кешеләр булып калалар, тозлы-борычлы мәзәкләр сөйлиләр, баштан үткәннәрне искә төшерәләр, мәхәббәт мажаралары тыңлыйлар...

Шимбәдә, Яшел үзәннән килеп укучы бүлмәдәш егет өенә киткәч, төн берендә, Зәйтүнә белән Нурмөхәммәт тә мажара кылдылар. Ул хәл Нурмөхәммәтнең: "Безнең бүлмә бүген әбиләр аулагы кичерә. Танцылардан соң шома гына безнең резиденциягә күтәрел!" дигәненнән башланды. Курсташлары янына тулай торакка кичәгә дип килгән Казан кызы егетнең тел төбендәгене үзе шәрәләндерде һәм: "Шуңа кыюлыгың житәрме?" — дип сорады. Ә үзе мондый кыюлыкны күптән карусыз кабул итәр фикердә иде.

Кышкы озаклап атучан таңны алар йокысыз каршыладылар. Арыганнар, талчыкканнар иде. Иртән Зәйтүнә йокы симертеп алырга бик теләгән иде дә, Нурмөхәммәт нык торды. "Тулай торак халкын белмисең шул син рәтләп! Хәзер пәке теллегә әйләнәчәкләр", — диде. Керфеккә керфек тә ормый

уздырган төн өчен һич кенә үкенмәсә дә, Зәйтүнә аңкы-тинке хәлдә калды, аның җорлыгын, үткерлеген, җитез-җәһәтлеген пәриләр урлаган иде.

Иртәгәсен дә, аннары да, тулай торакта да, университетта да үзләренә төрткеле сүз әйтүче табылмады. Шулай да бу хакта сүз ректоратка барып ирешкән иде. Ул елларда посынып шикаять итүчеләрнең исемнәрен сер итеп саклау модасы бар иде, шунлыктан, теге яки бу гөнаһлар өчен бирелә торган җәзалар яраксыз гамәл кылучыларның үз икърарларына таянып эшләнә иде.

Проректор беренче итеп Зәйтүнә Мифтахованы чакыртты, каршысындагы кәнәфигә урын тәкъдим итте һәм, әйләнеч сукмаклар эзләп маташмыйча, дипломатиясез-мазарсыз турыдан ярды.

— Иптәш Мифтахова, тулай торак режимын тупас бозып, иптәш Шакиров белән төн кичерүегез турында сигнал бар. Студентка буларак, этика кысасына сыймаган бу күренешне ничек аңлатасыз? Турысын-дөресен сөйләгез, бәя бирегез, — диде.

— Әйе, без Нурмөхәммәт Шакиров белән сөйләшеп таң аттырдык. — Зәйтүнә чекерәеп проректорга карады, әйтерсең лә тегенең керфегенә кунарга җыена иде. — Бу хәлдә бернинди дә крамола күрмим. Без — балигъ кешеләр, нишләгәнебезгә отчет бирер дәрәҗәдәбез. Без дә бер-берсен яратышырга, һич югында иптәшләрчә ихтирам итешергә хокуклы гражданнардыр дип беләм.

Проректор мондый кыю җавапка беркадәр аптырабрак та калды шикелле. Аннары, үзенең көчсезлеген сиздермәскә теләп, Зәйтүнәгә каршы төште.

— Мәхәббәт — бер нәрсә, аның нинди формада чагылыш табуы — бөтенләй бүтән эш. Сез бит үз өегездә түгел, җәмәгать урынында бергәләп таң аттыргансыз, Мифтахова сеңлем!

Зәйтүнә бер кагылуда иярдән мәтәлүчеләрдән түгел иде.

— Мин сезгә барысын һәм турысын әйттем. Мәхәббәтнең бормалары, йөрәк серләре турында кагыйдәләр тупланмасы юк. Мәхәббәттә гомумкешелек нормалары яши, — дип кырт кисте. — Бүтән җавапны кешелеген җуеп, гайбәт сөйләүчеләрдән алырсыз. Минем сезгә зар җылап килгәнем юк һәм булмас!..

Проректорның аргументлары беткән иде. Ул Зәйтүнәгә китәргә рөхсәт итте.

Саубуллашып чыгып барганда, Зәйтүнә Нурмөхәммәткә каршы очрады. Керфек каккан арада гына тукталыш ясады да, бик тыныч кына сөйләнеп алды: "Без — мәхәббәт дуслары. Серләшеп таң аттырдык. И все!" — диде. Аңлашылуынча, аның син дә шул ук сүзләрне кабатла, диюе иде. — Аңлат шул профессорга, тормыш, мәхәббәт, никах, гаилә күзләрен шар итеп күзәтергә яраткан ахмаклардан аулакта булырга тиеш ләбаса. Үзе сөекле хатынын кеше алдында назлар идеме соң?"

Зәйтүнә Мифтахованың кыюлыгы, гайбәткә, аны тыңлаучыларга, сөешүчеләргә ниндидер чаралар күрергә куллары кычытып торучыларга ажгырып каршы баруы тулай торактагы аулак татуның телдә тибрәнүенә чик куйды.

Тулай тораклагы шул төннән соң алар Нариман урамындагы фатирның аулакта калуын (андый хәл бик еш булмый иде) зарыгып көтүчән булып киттеләр.

Курсташлары аларны менә-менә өйләнешәләр, туй итәрләр дип йөргәннәр иде, алай булып чыкмады.

Нурмөхәммәт, аралары суынып та тормагандай итеп, Даимә Газизова белән дуслыгын өр-яңадан ныгытып җибәрде. Шул адым аларны гаилә кешеләре итте.

Зәйтүнә Мифтахова хатын аерган сәүдәгәргә кияүгә чыкты. Читенсенү кичермичә генә Нурмөхәммәтне никах туена да чакырган иде, тегесе бармый калды.

## 5

Район администрациясе хисап тоткан җыелышта сөйләшүдә бернича кеше катнашты. Нурмөхәммәт бәян иткәннәрне тулысынча диярлек яклап, "Алга" колхозы рәисе Сәйфелмөлек Әмирханов чыгыш ясады. Хезмәтне оештыруда җибәрелгән хаталарны берәм-берәм санап, "Төяк" совхозы

директоры сөйләде. Талип Сәяров авыл хуҗалыгында төп йөкне тартып баручы механизаторларга игътибар җитмәвен тәнкыйтьләде. Аңа ияреп дигәндәй, тагын ике механизатор — комбайнчы һәм тракторчы —район башлыгы алдына, баш белгечләр каршына җитди таләпләр куйдылар. Аннары трибунага тимер юлчылар вәкиле — Ташлытау станциясе дежурные Николай Вахрушев менде.

Алардан соң район ветераннар советы рәисе, Ташлытау төбәгенең мөхтәрәм кешесе, пенсионер-укытучысы Сабирҗан Халиков сүз алды. Гомерен шул райүзәктә уздырган зат, кырык еллап балалар укыткан, мәктәп директоры булган карт. Үзе җитәкләгән мәктәбеннән ул Бөек Ватан сугышына китеп, яраланып кайткан ир. Таягын бүгенгәчә ташлый алганы юк. Фашист "күчтәнәче" үзен ярты гасыр инде һәр тумыш көндә генә түгел, һәр атлаган адымында сиздереп тора.

Сабирҗан Шәриповичка сүз биргәч тә, зал кул чабып алды. Монда утыручыларның яртысы аның укучылары дисәң дә, хаклыкка хилаф булмас. Беләләр, укытучы абыйлары хакыйкатьнең үзе кебек, чын кеше...

Сабирҗан агай һичкайчан ашыгып төшмәс, бер фикерне башлап, икенчесен ташламас. Аның әйтергә теләгәннәре бик табигый килеп чыгар, муенса төймәләре кебек, берсе янәшәсенә икенчесе тезелә барыр.

Сабирҗан абзый сүзенә администрация җитәкчесенә сораулары да булачагын әйтеп кереште.

— Сез докладыгызда икътисадый мәсьәләләргә дә, сәяси-әхлакый тәрбия проблемаларына да туктадыгыз. Бу хәл миңа сорау бирергә дә урын калдыра дип беләм.

Тәрбия эше качышлы уйнаганны яратмый. Бигрәк тә тәрбиясез тәрбиячеләрне халык хөкеменнән йолып калырга маташу — безнең өчен чит булырга тиеш. Аланлык мәктәбендә тарих укытучы кайнишегез Айдар Газизов үзе укыта торган кызның өйләренә кереп көчләргә ябышкач, бу хәлне яшереп калдыру өчен тырышуыгызны ничек бәялисез? Район прокурорына басым ясавыгызны ничек аңлатасыз? Республика прокуратурасында эшләгән танышыгызның да бу эшкә катнашы барына нинди бәя бирәсез? — Сабирҗан Шәрипович дулкынлана идеме, нервылары чыгырдан чыктымы, сүзен бүлеп, авыр-авыр сулап торды. Ярга алып бәргән балык диярсең. Шактый сүзсез торгач кына дәвам итте. — Икенче сорау: сезне үз иткән берәүне — колхоз рәисе Әмирхановны Канаш айныткычыннан үз машинагызда барып алуыгызны, аның җитәкче исеменә пычрак ягу фактын сылап-сыйпап калдыруыгызны эшнәлекнең әшәке мисалы дип саныйсызмы?

Өченче соравым да бар. Карагайлы совхозыннан каршыгызга гозерләнеп килгән икенче группа инвалид Хәнәфиевне кабинетыгыздан куып чыгару фактын, шуннан соң Бөек Ватан сугышы батырының ай буе үлем белән тартышып больницада ятуын ни дип бәялисез?

Мин хәзер әйткән һәр сүземә җавап бирергә тулысынча әзермен. Район ветераннар советында тиешле белешмәләр бар...

Көтелмәгән иде бу чыгыш. Ни гомер иткән кешеләрнең дә мондыйны ишеткәннәре юк иде әле. Кайберәүләр бөрешеп килделәр, гүя Шакиров кылган әшәкелекләрдә алар гаепле иде. Шуннан чамалап булса кирәк, күзгә бәреп турысын әйтү бездә күптән юкка чыккан булган шул!..

Шакиров сүз алды, нидер аңлатырга теләде. Әмма бу минутта ул үзе бер нәрсәне ачыклар хәлдә түгел иде: яңалык тугандагы тулгакмы соң бу әкәмәтләр, әллә Нурмөхәммәтнең үлем алды тыпырчынуы — агониямe?

Кояш тотылганда урман эчендә калган юлаучылар төсле, залдагы кешеләр әллә аны рәтле-юньле тыңламый, әллә тыңлап та һични аңламый идеме?

Нурмөхәммәт телсез кала язды. Йөзең — кара, телең кыска, диләрме әле!..

## 6

Нурмөхәммәт Шакиров кабинетына кайтып бикләнде. Техник секретарьны катгый кисәтте, Казаннан гына шылтыратмасалар, минем

телефонны бирәү белән дә тоташтырма, диде. Үз хәсрәте ярларыннан ашканда, Зәйтүнә Мифтахованы бөтенләй хәтереннән чыгарган иде.

Кабинетына керә-керешкә үк район администрация башлыгы пальтосын гына түгел, пинжәген дә салып элде, галстугын бушатты. Һәммә киеменнән "бәдрәф хушбуе" исе килә төсле тоелды аңа. Заманасында үзен укыткан карт педагог район җәмәгатьчелеге алдында тизәккә салып аунатты бит аны!.. Әүвәл-әүвәлдән өнәп житкермәде ул абзый аны. Өлгергәнлек аттестатына имтиханнар биреп йөргәндә үк "Син кояшка да туры карый аласың!" — дигән иде бит. Бик базусың, нахаллыгың хөттин ашкан, дикюе булгандыр, күрәсең. Менә бүген әйтәсен әйтеп бетерде инде!..

Әйләнмәле йомшак кәнәфиенә утырыр алдыннан ян дивар буендагы аяклы зур көзгегә күз салды: чырае тәмам качкан иде. Күзләренең нуры юкка чыккан. Иреннәре, турсаюдан булса кирәк, умарта корты чаккандай, шешенкеләнеп күренде. Маңгайдан уелып кергән пеләше дә киңәя төшкән кебек иде. Житмәсә, сул кулының баш бармагы ойый төсле, кан тамырлары күперенә кебек. Әллә нишләп кенә муены да авырта башлады. Көтмәгәндә килеп чыккан аяусыз яңаклаудан нерв җепселләре кысылды микәнни? Колагына да нидер булды: торып-торып тавышны ишетә, ә сүзләрне аңламый. Тетрәнү шулай итә, күрәсең...

Өстәл артына килеп утыргач, ул шул тикле тирән сулады, яшел постаулы киң өстәлдәге кәгазьләр, очып китәргә ниятләгән сыман, кыймылдашып куйдылар. Чалбар каешы кысып тормаса, Нурмөхәммәт үзе дә, кыршау аткан мичкә сыман, таралыр төсле иде. Иң әүвәле үзен елмаеп каршылаячак хатыны Даимәне күз алдына китерде ул. Тырышып елмаер да (Нурмөхәммәт белә: хатыны гомер буе аңа ихластан елмаймый!) әйтер Даимә: "Үтеп киттеме, әтиләре, җыелышыгыз?" — дияр. Хәләленең менә шул сүзләре асылынган кеше өендә бау хакында сөйләшү булып ишетелер инде. Аннары Нурмөхәммәт әллә ни исе китмәгәндәй генә әйтер: "Уздырдык, әниләре. Бер быел гына түгел бит инде андый җыелышлар", — диер. Бүген исә алай дип кенә котыла алмас шул! Алмас! Баксаң-торсаң, сасы хәбәр мәктәпкә барып та ирешкәндер инде...

Авылларга таралышкан активистлар теленда дә пенсионер Сабирҗан карт сүзләредер. Шулай булмыйни! Бүген ул карт —сабан туе батыры! Алай гына да түгел... Яратмады ул мине, сөйкемсез сөяк булдым мин ул аксак хәшәраткә... "Кояшка да туры карый аласың!" Халыкта кояшка туры карый алуны зинадан туганлык белән яисә кеше хакын ашау белән бәйләп әйтәләр икән ич. Затсыз, оятсыз, ил үчергеч дигәннәре...

"Вәт, парин, — диләрдер авыллардан килгән активистлар, —нинди көннәр килде! Шакировка каршы да туп-туры сиптерәләрме?! Сиптерерләр шул, Нурмөхәммәт Зарипович кына Алланың кашка тәкәсе түгел, ул да күктән төшмәгән, якты дөньяга безнең юлдан килгән..."

Шулай диләр булыр. Соңгы дүрт-биш елда аеруча үзгәрде халык. Батырайды, гайрәтләнде. Хәнҗәр теллегә әйләнде. Туп-туры тондыралар, кашың-ны-күзеңне карап тормыйлар... Де-мо-кра-ти-я!..

Миендә районның башлыгы булып калу-калмавы хакында сискәндергеч уй сызылып үтте. Президентка бүген үк барып ирешәчәк җыелыш хәлләре. Иртәгә булмаса, берсекөнгә Илбашы келәмгә чакырачак. Бирәү дә тәхеткә мәңгегә килмәгән. Тик тизәкле себерке белән себереп, сасы соскыга төяп ташласалар, бу инде... бу инде...

Нурмөхәммәт шуннан артыгын күзаллыйсы итмәде. Булдыра алмады. Күңеленең бик тирән эчкәресендә сукыр песи баласына охшап, зәгыйфь бер өмет сәләмәсе кыймылдады. Пешкән тал чыбыгы белән пешекләп, гаебеңне эш белән йол, дисәләр! Ә? Анлык егәр табылыр идеме? Дөньядан типкендә киткәнче, сеңер тартышканчы көчәнеп булмас идемени?..

Аның әлеге халәте бу кешенең бөтенләй үк тә җансыз карачкыга әйләнмәвен сөйли иде түгелме? Шул нәрсә Нурмөхәммәт Шакировны культурадан мәхрүм, эшне җентекләп белмәүче, идарә итү сәләте булмаган, мәгәр командалык дилбегәсен кулына алырга базулыгы җиткән бюрократлардан бер карыш кына булса да аерып тормыймы? Югыйсә бит, безнең үз туфрагыбызда, бөтен

шартларын китереп үстергән бюрократларыбыз, идарә итә белмәстән, искиткеч буйсына беләләр. Ялагайлыкта чыныккан бу адәмнәр үзгәртеп кору дигәнне җиңел кабул күрделәр, элеккеге парад чыгышларын үзтәнкыйтькә алыштырдылар. Иң югары хакимиятнең түземлелеген аның көчсезлегенә юрап, үз вазифаларын җансыз-йөрәксез башкаручы шушы кәгазь кортлары илне икътисадый кризиска —көрчеккә китереп терәделәр. Көрчек дигәнең бер башландымы, ярдан ишелгән ком инде ул!.. Матди кризис кына да түгел бит, сәяси кризиска, забастовкаларга, бихисап җирләрдә ачлык игълан итүләргә җиткерделәр. Иң хәвефлесе — алда яктылык күренми, дөм-караңгы мәгарәдә капшанып барабыз. Аның каруы санаулы гына капиотлар өере мәмләкәт хәзинәсен үзенә генә түгел, балаларына гына түгел, балаларының балаларына да гомер кичәрлек итеп мал туплый бирә.

Халык сызлана, ыңгыраша, яшь түгә, ил башындагыларга каһәрен чәчә. Хөкүмәт дигәненнән тереге халык ихтыяры һәм ихтирамы түгел, камчы уйнатучы атлы казаклар...

Соңгы тамчы намусы калган Көнбатыш бюрократы, бөтен илгә яңгыраган үтергеч тәнкыйтьне ишеткәч, мөгаен, бик тиз отставкага китәр иде. Безнекеләр бу тәнкыйтькә сәерсенеп тора бирәләр. Йөзләрендә әллә елмаю, әллә сызлану галәмәте... Йөрәк ямаулы булса да, хакимият нәфсесе төкәнерлек түгел бугай...

Нурмөхәммәт тә, төшенгәнегезчә, шулар өереннән, югарыга карап фикер йөрткән, өстәгеләрдән өйрәнгән адәм. Шулай да, отставка яки чөеп ату ихтималы турында уй килде бит әле башына...

Ул тыныч кына утыра алмады, сикереп торды да, кышын ачлыктан оясын ташлап чыккан аю сыман, иркен бүлмә буйлап арлы-бирле гасабиланып йөренә башлады. Бүгенге дөмбәсләнүенең төп сәбәбенә нечкәләп төшенергә тели иде ул. Кабер якасына баскан Сабирҗан Шәриповичка ни җитми? Нәрсә дип сабыр савыты ташыган әле? Тулаем алсаң бит районда эшләр йөзгә төкерерлек үк түгел. Кукмара, Балтачларга иш булмаса да, ул җитәкләп бара торган район да республика сводкаларының соңгы басмаларында йөрми. Урталыкта диярлек. Дәүләт планнары, авыр булса да, үтәлә тора. Ике план-фәлән дип авыз ачкан юк анысы. Берсен үтәми калган еллар да булгалый. Республиканың уртача күрсәткечләренә җитә язып барабыз. Дөрес, социаль проблемалар дигәннәре белән чиләнәбез. Уңны-сулны абайламыйча, "перспективасыз авыллар" җырына кушылу да сукты тез астына, сукты! Хакыйкать югарыдан килә дип белдек. Бу — начар да түгел иде шикелле... Юллар дигәндә дә күз йомып хаталандык бугай. Клубы-мазары да качмас әле, дип, дөрес итмәдек шикелле... Ну бит безнең район ишеләр янә дә бар әле. Җитешсезлекләр өчен суктыра торалар, җәзасыз калмыйбыз. Партия бар чакта, Әхмәтҗаныч заманынында ничек пешерәләр иде, чи ит янган ис чыга торган иде ләбаса! Анысы, өстән тәнкыйтькә түзәсең лә ул, аның гарьлеге азрак, астан өрмәсеннәр иде. Хәзер бит түбәннән чәңгелди башладылар. Шунысына тәкать итәр хәл юк. Бигрәк тә бу ягы — түбәннән контрольдә тотарга маташалар. Производство дигәнеңә туган-тумачаң белән мөнәсәбәтне дә китереп ялгыйлар. Болай барса, хатының янына да җәмәгатьчелек рөхсәте белән генә ятарсың тегеләй...

Нурмөхәммәт Зарипович, бик сирәк тартучан кеше, зур өстәленең кайсыдыр тартмасыннан папирос кабы сөйрәп чыгарды, аннан бер папирос алып капты да шырпы сызды. Тәмәкесе көйрәмәде, шырпы сүнде. Тагын сызды, янә сүнде, тагын... Аптырагач, җенләнеп, авызындагы папиросын да, шырпы тартмасын да чүп савытына ыргытты.

Аның күз алдына өзек-төтек булып соңгы араларда кешеләр белән чәкәшү күренешләре килә башлады. Шулай да кайнише бәласе иң беренче булып чиметте аны. Суккин сын! Ата дөя — Каранар! — Нурмөхәммәт Чыңгыз Айтматов романындагы дөяне хәтерләде. — Тапкан бит ымсыныр кеше! Үз кызыдай нәрсәгә ябышмаса... Сасысы чыкмый каламы соң андый хәлнең?! Менә өр-яңадан сүзли башласалар, белер селәгәй! Утыртачаклар бит! Сүз дә юк, утыртачаклар!..

... Былтыр язын, чәчү өстендә шикелле, республика газетасыннан хәбәрче

килде. Әйе, әйе, чәчүнең иң кызган чагы иде. Кылны кырыкка ярыр көннәр. Ә ул бер инвалид тормышы белән кызыксынып, теңкә корытты. Урман бетедәй кадалды, әткәй мәрхүм әйткәндәй. Кадалды да язып та чыкты. "Тәрәүле өйдә хөрмәт язуы". Рисвай итте. Районда климат шуннан соң нык үзгәрде түгелме?

Карагайлы совхозында яши ул сәлперәеп картайган инвалид. Сугыш гарибе. Берлинны алганда каты яраланган. Сугыштан кайткач, хәл-хәленчә совхозда эшләгән. Соңгы елларда тәмам хезмәткә яраксыз булып калган. Өйләнә алмаган, әнисе белән көн иткән. Карчык та үлеп киткәч, ялгызы тирә-күрше хозурында гомер итә. Сугышка тикле үк әтисе салган өйдә биш-алты тәрәү икән. Шул йортның баганалары череп кыйшайган капкасына "Монда Бөек Ватан сугышы инвалиды, орденлы сугышчы яши" дип язып кадакла-ганнар. Безобразие! Язмасалар, булмый идеме? Әүвәлге директор ул инвалидка хуҗасыз бүтән йортка күчәргә әйтеп караган, теге киребеткән ризалашмаган. "Ремонтламасагыз да ата-баба нигезендә үләм", — ди икән. Яңа директорның күзе дә, кулы да җитмәгән. Военком да кымтыклап караган югыйсә... Шул хәлләрнең җимеше — теге мәкалә. Журналисты бик үҗәт нәрсә булып чыкты. Югарыда терәге бардыр, мөгаен. Юкка ул чама кыю кыланмас иде. Ә саубулла-шып киткәндә нәрсә дип чәнчеде бит? "Докладларыгызның берсендә генә булса да отчет-сайлау чорында ничә кешене бәхетле итүегезне әйткәнегез булдымы", имеш! Бигрәк тә җенне чыгарганы шул иде. "Җитәкче кадрларны, Нурмөхәммәт Зарипович, акыллы да, намуслы да кешеләр хисабына үстерергә кирәк. Алар мөмкин кадәр яшьрәк, иң мөһиме — аппарат күгәреге һәм өскә үрмәләү чире йокмаган кешеләр булсын иде", — дип күзгә бәреп әйтте. Ул китеп олаккач, уздымы икән өч-дүрт көн, бюро утырышы буласы дигәндә, сөйрәлеп килмәсенме теге инвалид үзе!.. Тыела алмадым, ташындым, тузындым. Хәзер, эш узгач, үкенүдән ни мәгънә?!

... Сәйфелмөлеге дә җанлы бәлагә әйләнде. Тере имгәк! Йотканын буена сеңдерә алмый. Эчә белмәгәч, ник кагылырга стаканга? Исереп Канаш айныткычына эләккән дә, шуннан шылтыратып ята бит, килеп ал, ди, күзен дә йоммый. Бармый арт тотмый, диләрме? Шуннан ашагач ни?! Әйткәнем бар үз-үземә, алданмам шуларның калҗаларына, дип. Юк бит, юып булмаса, чайкап сарылалар...

... Фаяз Сиражиев дигән пенсионер тагын. Аңа багышлап шигырь язган район шагыйре — редакциядәге малай.

Килеп керде Иркутск өлкәсенең җәһәннәм читендәге алтын приискасында эшләп, олыгайган көнендә туган якка кайтып төпләнгән Фаяз дигәннәре. Үзе турында да бер-ике бит язылган китап тоткан, Иркутскида урысча чыккан.

— Укып карагыз әле, голова района, — ди, китапның фәләненче битен күрсәтә. Укымый булмады. Бу агай, рас, уникe килодан артыграклы самородок тапкан. Аны "Пәһлеван" дип атаганнар, илнең "Алмаз фонды"на куйганнар. Абзыйга Мактау кәгазе генә дә бирмәгәннәр. Ярамаган тагын татарга дигәннәр бугай...

— Күп сөйләшмәскә дип имзам бар иде, һични кыла алмадым. Ул елларны ни... менә хәзер күтәреп карыйк әле шуны, Шакиров туган, ди. Ни әйтәсең?

— Былтыр яуган карны эзләп йөрисең ләбаса син, абзый, —дияргә туры килде шул. Ә ул нәрсә ди?

— Лаек икән, кешегә үзе үлгәннән соң да Герой исеме дә, лауреат исеме дә бирәләр. Нигә әле сез булышып караудан да баш тартасыз? Курка-курка куян тизәгенә калгансыз! — Шулай диде дә ишекне бәреп чыгып та китте.

Бер атнадан район газетасында шигырь. Анда тасвир кылынганча, унда — Эшче, сулда — Лидер. Алар янында берәү хәйран калып карап тора. Лидер "Пәһлеван"нан ясалган йолдызларны түшенә тезә... Теге егет кисәген чакырып сөйләшми булмады. Чатлатып эрепләшә, безобразие! "Кемнәр таба? Фаяз абыйлар! Кемнәр тага? Элек Брежневлар иде. Хәзер... Ә без — авыз ачып карап торучылар", — ди. Егетне "өшкерү" бөтен районга таралды. Президентка хәтле язганнар. Сөрлегүне тоймый да калдым, безобразие!

... Бәгырьне телгәләп, тоз сипкәне яңа административ бина сала башлау

тарихы. Ул бинаны төзергә дип Ташлытау поселогы читендәге парк агачларының берничәсен кистерә башлаган идек. Туктатырга туры килде. Бистәнекеләр ду купты. Җир аларныкы бит, парк аларныкы.

Җыен җыярга мәҗбүр булынды. Анын түренә поссовет рәисе, райүзәкнең мөхтәрәм кешеләре утырды. Район архитекторы да, үзем дә паркта башланган эшне нигезли алмадык.

— Без бу парктан әтиләрне сугышка озаттык!

— Монда һәлак булганнарга һәйкәл!

— Балаларнын таганнарына кагылырга хакыгыз юк!

— Мондагы агачларны заманасында сабыйлардан алып аксакалларга кадәр утыртты. Балта чапканнарның кулы корысын! — диделәр, өермә куптардылар.

Райүзәк уянды, үзсүзләнде, аяк терәде. Әйләнеч юл да табылмады түгел түгелен. Ул бинаны төзегәч, паркны басу ягына таба киңәйтүгә миллион сум акча бирелә, диелде. Әрсезләр төпчелә торгач, бу сумманың арттырып әйтелгәнен ачыкладылар. Янә оттырдык. Бер сугыш ветераны һаваны ярып кычкырды:

— Халык теләгенә каршы тыпырчынмагыз, иптәш Шакиров! — диде. — Поссовет сездән узып әтәчләнә алмый ул. Ә сез халыктан уза алмассыз!.. Яраксызга санагач, Кама аланында төзелә башлаган атом электр станциясе корылышын да яптылар, шуны онытмагыз. Халык әйтсә — хак әйтә. Халыкны кара сарыкка санаудан туктамасагыз, аяу көтмәгез!..

Икенче бер ветеран, таягына көч-хәл таянып торучы карт, янә маңгайга терәп сорады: "Сез, иптәш район башлыгы, парк капкасы өстенә язып куйганны укыганыгыз бармы соң? Анда бит "Чын демократия Законнан тыш һәм Законнан өстен була алмый", — дип язылган", — диде...

Чигенергә мәҗбүр булдык. Бер чигенденме, бетте инде! Кайда ул әүвәлге еллар?!

Һәм башкалар, һәм башкалар...

Нурмөхәммәт Шакировның үз квартирасына, үз гаиләсе янына кайтасы килми. Аягы тартмый, җаны тартмый. Ә бит кайчан гына әле райүзәк туфрагына каты басып йөри иде. Кичә иде шул...

## 7

Талип үзе дә аңлап бетермәслек халәт кичерә иде. Сөенергә кирәк булгандыр инде аңа. Уңышлы чыгышын хупладылар, котладылар. Ә ул борчыла сыман. Шакировны җайсыз хәлдә калдыруга ул гаепле диярсең.

Туган авылы район үзәге поселогыннан өч-дүрт кенә чакрымда. Үр генә менеп төшәсе. Җәяүләп кенә Таңчулпанына юл тотты. Атлавы рәхәт! Талип олы юлдан түгел, кыр ышыклау урманы буеннан сузылган ат юлыннан кайтасы итте.

Борма-борма юл сузылды, механизатор күнелендә борма-борма истәлекләр яңарды. Бүгенге җыелышта булып узганнарга кагылышлы хатирәләр еллар томаны артыннан калкып чыктылар. Хәтер Нурмөхәммәткә кагылдымы, Даимәне күз алдына китерми калмый. Кыз белән үзенең арасында субүләр ясаган җәйге иртә мең дә беренче мәртәбә искә төшә.

... Берничә классташы белән бергә, Талип та урманнан мәктәпнең тулай торагына кайтты. Даимә анда да юк иде. Егет көтте, кыз күренмәде. Ачыргаланып, Талип Таңчулпанга кайтып китте. Балалар бакчасында тәрбияче булып эшләүче әнисе хезмәтенә китәргә җыена иде. Әтисе — гомерлек тракторчы-комбайнчы — машиналар паркында...

Улының өлгергәнлек аттестаты алып кайтуы, мәгълүм инде, ана өчен зур сөенеч иде. Сәлимә ханым Талипны тәбрикләде, кечкенә чагындагы шикелле итеп, аркасыннан сөеп куйды.

— Чәй кайнар, утыр, аша-эч. Аннары ятып ял итәрсең, төнне йокысыз кичтегез бит инде сез, — диде.

Талипның әнисеннән һәм сеңелләреннән яшерен сере юк иде. Шуңа күрә уендагысын әйтеп салды.

— Ял итәргә исәп юк әле, әни, — диде. — Велосипедка атланам да

Аланлыкка китәм. Даимә урманнан китеп барган. Тулай торакта да юк. Миңа үпкәләпме, авылларына ук кайтып киткән булса кирәк...

— Ачуланыштыгызмыни? — Әнисе шелтәле караш ташлаган төсле булды. Әмма үзе нигәдер шатлана да кебек иде.

— Мин үзләрен танцевать иттергән арада юкка чыкты. Нәрсәгәдер кәефе кырылды, күрәсең, — диде улы.

— Өйләренә барып йөрү кирәкме икән соң, Талип? — Шулай диде дә әнисе эшкә кузгалды. Талип, билгеле инде, Аланлык юлына җен-пәриләр киртә корса да бармый калмаячак иде. Китте. Җиде-сигез чакрым араны җилдәй сызгырып үткән төсле булды. Елга күперен чыкканда гына велосипедтан төшәргә туры килде. Аргы як яр шактый текә иде. Аннары тагын җилдерде генә.

Даимә өйләренә дә кайтмаган иде.

— Кайтып җитмәде шул әле, — диде кызның әнисе. Ул Талипка чекерәеп карады. — Сез кем буласыз соң, энем?

— Мин — аның классташы, — дип җавап бирде егет.

— Исемегез ничек?

— Талип. Талип Сәяров.

— Алай... Сәлимә улы буласызмыни?

— Әйе. Сез педтехникумда әни белән бергә укыгансыз.

— Укыдык... — Бу сүзне Даимәнең әнисе теләр-теләмәс кенә әйткән кебек булды. Һәрхәлдә, Талип аның йөзендә ниндидер канәгатьсезлекне шәйләп алды. Хуҗа хатын шундук сүзне икенчегә борды.

— Сез соң, энем, чыгарылыш кичәсендә булмадыгызмыни?

— Булдым, апа, булдым.

— Алайса, Даимә булмадымы кичәдә?

— Ул да булды. Тик ул иртәрәк кайтып китте. Мин инде аны авылыгызга кайтып җиткәндер дигән идем.

— Ашыгыч йомышыгыз чыктымыни соң?

— Әйе, бер йомыш кисәге бар иде шул, — диде Талип. Кургашын солдат кебек басып торыр хәл юк иде, кайтырга кузгалды. Кирегә юлны ниндидер явыз сихерләп озынайткан иде. Велосипедына утырып, җан-фәрманга куып та карады, аны җитәкләп җәяү дә атлап бакты, юлы үрчемәде генә. Ике авыл арасындагы кыр ышыклау урманы буенда утырып ял да итте. Шунда сыйрак язып утырганда район үзәге ягыннан Даимә күренмәсме дип өметләнде. Юк, кыз күренмәде...

Җаны тәненә сыешмас хәлдә өч көн уздырды Талип, дүрт көн. Чыгарылыш кичәсеннән соң биш көн дигәндә янә Аланлыкка килде. Бу килүендә кыз әнисенең җавабы егетнең башына гөрзи белән орган кебек итте.

— Казанга китте Даимә, — диде ханым кырыс кына. — Имтиханнарга тикле кайтып йөрмәсен әйтте. Апаларының дачасында торып әзерләнәсе булып китте. Суыксу дигән авыл янында...

— Миңа дип язу-фәлән калдырмадымы? — Бу сорау, турысын әйткәндә, аптыраган үрдәкнең арты белән күлгә чумуы иде. Даимәнең әнисе бу сорауга гаҗәпләнде дә, гаҗәпләнмәде дә шикелле. Беравык тын торгач, сүз өстенә сүз бастырып әйтте:

— Язу-мазар калдырмады. Сорап килүче булса, "Ара өзек безнең!" — дип әйтергә генә кушты. Алар анда теге, кем, ни атлы егет әле, Нурмөхәммәт белән бергә хәзерләнәчәкләр... Зариф абый улы физкультурныйга кеpә икән бит... Чаңгыда шәп йөри, бик әйбәт йөзүче, оста ата, мәргән дигәне бар иде Даимәнең... Әнә шуның белән хәзерләнәчәкләр...

Бу сүзләр гөрзинең биниһая зурысы иде инде. Саубуллаштымы Талип, юкмы, бусаганы ничек атлап чыкканын, капканы ничек япканын, Аланлыктан елга буена килеп җиткәнен хәтерләми. Килеп җитеп, сөзәк ярга ятып, җылымса су эчеп азапланганы, мәгәр йөрәк януын алай гына баса алмаганы истә...

Даимә әнисенең үзен өнәмәүнең сәбәбен Талип төшенә иде. Педтехникумда укыганда аның әнисе белән Даимәнең әнисе бер егетне ызгыш алмасы иткәннәр. Ә егет исә бөтенләй башка бер кызга өйләнгән дә куйган.

* * *

Мәхәббәт газабы, сызланулы сагыш тиз генә басыла торган газап түгеллеген Талип бик белде, бик авыр кичерде үз вакытында. Сыртына сагызланган михнәт бөкресе иде ул газап үз чорында. Шулай да очрашмый яшәгәч, ул газап акрынлап кимегән төсле икән...

Алар кабат очрашканда, яшьлек кайнарлыгы белән авыл араларын таптаганнан соң байтак еллар узган иде инде. Талип армиядә хезмәт итеп кайткан, әтисе җитәкчелек иткән механизаторлар бригадасында үз колхозларында эшли, ә Даимә педагогия институтын тәмамлап, Ташлытау урта мәктәбенә укытырга кайткан иде. Нурмөхәммәт белән өйләнешкәннәр иде.

Талип Даимәне урта мәктәпкә унынчы класста укучылар алдында механизатор һөнәренең абруе турында сөйләргә дип килгәч очратты. Яшь педагогны үзеннән аз гына диярлек яшь егетләр һәм кызларның класс җитәкчесе итеп билгеләгәннәр иде. Класстагы әңгәмәдән соң Даимә Талипны мәктәп йортына кадәр озата барды. Үз хәлләренә кагылышлы үткәннәрнең башын калкытып тору мөмкин дә булмаган, кирәге дә калмаган эш төсле иде. Талип тел тибрәтеп сыңар сүз дә әйтмәскә ант беркетеп куйган иде. Даимә күңелендә ниндидер ачыкланып җитмәгән бер сораумы, әллә гап-гади кызыксынумы үлеп җитмәгән булып чыкты. Ул, урау юллар эзләп тормастан, бик кинәт итеп сорады:

— Чынын әйт әле, Талип, — диде, — теге елгы дуамаллыгымны кичерә алыр идеңме?

— Үткән эшкә салават, ди минем әти. Кичермәсәм, ни хәл итәсең дә, кичерсәм, ни үзгәрә? — Талипның җавабы шул булды.

— Кичерсәң, мин тынычрак көн итәрмен, шул...

— Бәхетле бул, Даимә!

Яшь хатын шундый томырылып карады, күзләренең төн карасы Талип күзләренә күчте диярсең. Аннары ул ярым пышылдап:

— Сөюенә хыянәт иткән кеше бәхетле була алмый! — диде һәм, кырт борылып, мәктәпкә кереп китте. Куып җибәргәндәй. Өреп очыргандай...

Шул рәвешле уйга салган иде Даимә Талипны. "Хаталануына үкенә, күрәсең..." — дип фикер йөрткән иде ул. Шулай дип үз уйларына чик куярга тырышкан иде. Үткәннәрнең сүрелгән кояшында кызыныр чак түгел, өендә аны буе-сыны түгәрәкләнеп килүче хатыны көтә иде. Аңа игътибар булырга тиеш, аңа наз.

Шулай да, ни дип теге елны Нурмөхәммәткә алгысыды икән соң Даимә? Бик нык тормышлы кешеләр иде шул, ялт итеп йөрде Зариф абзыйның кадерле улы. Шул яктан алдыруы булгандыр. Талипларның өй тулы бала, киртә сикерергә түгел, очын-очка ялгап барырга да зур тырышлык кирәк иде. Механизатор булып механизаторга шулай көчәнергә кирәк иде бит әле. Гомерлек тракторчы Галләм Сәяровка. Гаиләдә хәлләр шундыйрак булганга, Талип институтка китәм дип авыз да ачмады. Бәлки Талип Сәяровның гади колхозчы-механизатор гына булып калачагы хыяллары белән җиденче кат күктә йөзгән Аланлык кызының ихласын чигергән булгандыр? Бәлки...

## 8

Ничаклы газаплы, күңел кыйнагыч булмасын, өйгә кайтмый ярамый иде.

Нурмөхәммәт балтырына герләр аскан сыман, бик авырлык белән генә өйләнмәле кәнәфиеннән күтәрелде һәм, давылга каршы барып хәлсезләнгән кешедәй, сөйрәлеп кенә кием элгече янына килде. Теләр-теләмәс кенә киенеп, урамга чыкты. Миен сарган сөремнән шунда гына айнып киткән кебек булды. Болдыр буенда күшегеп-туңып беткән Зәйтүнә Мифтахова аны әле һаман да көтеп тора иде. Суык ханымның үзегенә үткән, аның рәтле-юньле сөйләшер хәле дә калмаган иде.

— Кереп барганда ничек искәрмәдем соң мин сине? —Нурмөхәммәт исәнләшергә дә онытып, шулай сорады. — Әйдә, беренче эш итеп кунакханәгә

урнаштырыйм, аннары ресторанда тамак ялгарбыз. Суык тидереп, авырып китүең бар...

Нурмөхәммәт Казан хатынына тырнак очы кадәр дә илтифат күрсәтә алмавына бик җайсызлана иде. Теләсә-теләмәсә дә, февраль салкынында көне буе урамда тотты булып чыга бит ул аны. Аны, кайчандыр кайнар кочагында назлаган кешене!

— Әйдә! — Нурмөхәммәт аның затлы тун җиңенә кагылды һәм кунакханәгә юл тотарга дип борылды.

Зәйтүнә, дерелдәү-калтырауларын җиңеп, батыраерга маташты, беркая да кереп торырга теләмәвен әйтте, карыны да туклыгын исбатламак булды. Сөйләшеп кенә алырга кирәк, аннары төнге поезд белән китәчәкмен, диде.

— Юк! — Нурмөхәммәт кырт кисте. — Гостиницага урнаштырам. Ашап-эчеп җылынасың. Шунда сөйләшербез. Аннары йокы туйдырасың. Иртәгесен шофер сине станциягә илтеп куяр. Урамнан борып җибәрергә кем дип белдең син мине?

Нурмөхәммәт җанында бүген кыйналып биртелгән кичәге арслан уянды. Уянды да бик тиз кире урынына ятты, сырт сөяге сынган иде. Әмма җаны — җанварлар патшасы — ыңгырашмады, шыңшымады, сыкрап сыктамады. Анысы Зәйтүнә Мифтахова белгән Шакировча булмас иде. Нурмөхәммәт һич югы шушы төнгә генә, бары тик Зәйтүнәне озатканчыга чаклы гына булса да, район арсланы булып калырга тели иде.

Кунакханәдә, Шакиров тикле Шакиров үзе урнаштыра килгәч, югарыдан килүче кунаклар бүлмәсендә бик тиз урын җайладылар. Администратор хатын хәтта кичке ашны да люкска гына китертте.

Район кунакханәләренең башлыкларына бер нәрсәне дә чәйнәп каптырасы түгел, җәннәтнен җиде серен яхшы белүчән халык алар. Администратор да, Зәйтүнә кул юып йөргән арада, Нурмөхәммәт янына килеп, сорашып алды.

— Виномы, Нурмөхәммәт Зарипович, көчлерәгенме? Кунагыгыз туңган бугай...

Соңгы елларда бу хакта ачыктан-ачык сөйләшүләр булмаска әйләнгән иде әйләнүен. Тик бүген икеләнеп-шикләнеп тормастан, Нурмөхәммәт өзеп әйтте.

— Тегесен дә, монысын да... Кат-кат йөрергә булмасын дигәнем. Акчасын хәзер үк алыгыз, яме. — Ул кесәсенә тыгылды. Тик администратор хатын, Зәйтүнәнең килеп баруын искәртеп, кирәкмәс дигән мәгънәдә кул селтәде.

— Качмас әле, Нурмөхәммәт Зарипович! — Башлыкның үзе белән хәмер-шәраб мәсьәләләсендә турыдан-туры сөйләшеп китүенә ханым бик канәгать иде.

Өстәл әзерләнгәч, администратор песи кебек кенә чыгып китте һәм люкс ишеген нык итеп ябып куйды.

Тәкәллефлек саклап тормый гына, бик үз итеп, кайгыртучанлык күрсәтеп, Нурмөхәммәт Зәйтүнәгә:

— Ач карынга аракы эч. Эчеңә сарган салкынны алса шул алып ыргытыр, — диде. Каршы сүз әйтергә җай да калдырмады шикелле. Зәйтүнә алай да:

— Исереп китәм бит аннары, — дип карулашкан булды.

— Исерек айный, ахмак кына акылына кайта алмый... — дип, үз сүзендә булды Нурмөхәммәт. — Үземнең тәҗрибәмнән беләм. Бер елны язгы ташу суын муеннан ерып чыккач та, корыга аяк басу белән әлеге сыеклыкны авыз иткәч, чуртым да булмады.

— Вино гына авыз итсәм? — Зәйтүнә чынында да аракы эчәргә авырсына идеме, әллә азмы-күпме чытыклануы булдымы, шулай сорап куйды.

Нурмөхәммәт үз фикерен куәтләде.

— Борын-борын заманда, — диде ул көлемсерәп, — синең белән сөйләшкәнебез хәтердә әле, "Будьте здоровы!" дип эчү аракының фәкать дәва гына булган чагыннан калган ич! Доктор сырхауга шулай тәкъдим итеп эчергән. Кашыклап кына. Безнең үтә цивилизацияле чорыбызда күбрәк авыз итү мөмкинлеге бар.

Бик авырыксынып кына, чырай сыта-сыта гына эчәргә мәҗбүр булды

Зәйтүнә. Озак та үтмәде, аның бит урталары кызарып чыкты, ул жылынып-киңәеп калды.

— Инде аша нигытып!

— Үзең бер дә авыз итмисеңмени? — Ханым Нурмөхәммәткә гажәпләнеп карады.

— Бүген мине алмас ул, Зәйтүнә.

— Ник алай диден әле?

Нурмөхәммәт бүгенге хәлләрне бик кыска, бик өстән генә сөйлисе итте. Ханымның беренче чыганактан ишетеп инанганы хәерле. Моны ул минминлеге серкәсенә су тидермәскә теләгәннән әйтте. Шулай да очы-кырые ялганмады.

Җылынып алгач, тамак ялгагач, Зәйтүнә үз гозерен ишеттерде. Автомобильләр кибетендә эшләүче энесенен хәлләре көрчеккә терәлгән икән.

Беренче хатыны үлгәч, өч бүлмәле квартирасы була торып, бер хатынга йортка кергән. Үз квартирасына Кавказ ягының сәүдә кылучы ир-атын кертеп торган, көрәп акча алган. Тик хикмәтнең кендеге анда гына түгел. Анысы гына садакадан булыр иде. Тау ягы агайлары энесенең квартирасында чын мәгънәсендә фәхешханә ачканнар. Алай гына да түгел гөнаһ шомлыгы! Ул квартирада шәраб цехы оештырганнар, стандарт булмаган эчемлек ясап, таныш киоскычыларга, кибетчеләргә продукция озатып саттырырга керешкәннәр. Чөй өстенә тукмак, кыскасы!

Күршеләре бу хәлләрне тиешле органнарга житкергәннәр, тәкатьләре калмаган. Энесен квартирадан мәхрүм итәргә, дәүләт торак мәйданы белән алып-сатарлык иткәне, ул мәйданны бозыклык оясына һәм шәраб цехына әйләндерергә юл куйганы өчен таш капчыкка тыгулары бик тә бик ихтимал икән. Зәйтүнә Нурмөхәммәттән республика прокуратурасындагы дустына барып, ярдәм соравын үтенде. "Син гозерләсәң, колак салмый калмас. Бәлки ярдәменнән дә ташламас иде. Карчыклар әйткәндәй, ышанычым бер Алла да, син инде, Нурмөхәммәт. Күңелеңдә миңа карата бер тамчы жылы калган булса, суза күр ярдәм кулыңны! Алла хакына!.."

Зәйтүнә шулай ялварды.

Бик озак уйланды Нурмөхәммәт. Зәйтүнәнең зарын-гозерен тыңлап бетерүгә, аның каршысына Сабиржан Шәрипович килеп басты шикелле. Ул таягын Нурмөхәммәтнең баш өстендә уйната һәм: "Монысы намуслы кешеләрчәме?" — дип вөжданына тукына иде кебек.

— Тырышып карармын... — Озын-озак тынычтан соң Нурмөхәммәтнең жавабы шул булды. — Карармын... Әмма өзеп вәгъдә бирә алмыйм. Соңыннан рәнжерлек булма...

Шул сүзләрдән соң аерылыштылар.

Февраль төне райүзәк өстенә күгелҗем-кара чыбылдыгын корган иде инде. Сизелерлек суыткан. Җылыдан чыккангадыр, Нурмөхәммәт чирканчык алгандай булды, пальто якасын күтәреп куйды. Тротуарга сыланып яткан кар аның аяк астында шыгырдап кала иде.

Күк йөзе ап-аяз димәле түгел, кысыр болытлар айның көмеш түгәрәге өстеннән шуышкалап чыга торалар. Гөмбәз яктырткычы бер балкып ала, бер тоныкланып кала. Ул инде таң алдындагыча кул сузымында гына булып тоелмый. Еракта, бик еракта.

"Легендар мәргән мылтыгыннан атып та тидерерлек түгел бу мишеньгә... — Нурмөхәммәт Шакиров башына шундый уй килеп керде. — Американнарча космик корабль белән барып ирешсәң генә... Андый ракеталарны ияргәрлек чакларым үтте бугай шул инде. Хыялыңда бөркет канатлы булсаң да, асылда чыпчык хәлендә калгач ни..."

Үзе яши торган йортка кайтып житәрәк, Нурмөхәммәт алдан парлашып атлаучыларны шәйләп алды: кызы Айгөл белән Илсур Сәяров.

— Нишләтәсең бу яшьләрне?! — Ул үзе дә сизмәстән сөйләнеп куйды. — Ике мәче талаша, берсен-берсе ялаша... Чөй өстенә тукмак ясарга йөриләр...

# ШИГЪРИЯТ



## Лена Шагыйрьҗан

**ЯҢАР, ЯНАРКОШЫМ!**

***

**Укы әле, дустым, бер шәп шигырь! —**
**Иң шәп атлар белән тыңлашерлек.**
**Мәйданнарда җиңеп даннар тоткан**
**Иң шәп җегетләр дә көнләшерлек.**

**Биегәйтеп Күңел манарасын,**
**Киңәйтерлек — чиген офыкларның.**
**Аксакалың торсын тел шартлатып,**
**Онытып торсын уенын — оныкларың...**

**Ник сүрелде болай ут-очкының,**
**Чакмасы бит түгел Бохарада...**
**Тел үлми ул, Сүзне үтермәсәң,**
**Тере Сүзгә кытлык бу арада.**

**Шигырь җенең китте мәллә качып,**
**Каның корыды мәллә җәнҗаллардан?**
**Мәлҗерәде мәллә җан-җегәрең,**
**Алҗып, алдакчы зат-дәҗҗаллардан?..**

**Яңар көлдән кабат, Янаркошым!**
**Яңрат хисең кайнар-кискеннәрен!**
**Күркә-кукырларның шиңсен тажы,**
**Күкрәт рухын мохтаҗ-мескеннәрнең!**

**Яшьнәт, Шагыйрь, тансык яшен серен,**
**Вөҗдан йокысыннан уятырлык!**
**Яса безгә шундый шигъри бәйрәм —**
**Бәрбән кагып, быргы уйнатырлык!..**

***1998. 25-26 апрель.***

### Шигъри сөлге

**И сеңелкәш! Яңа гасыр кызы!..**
**Без сырлаган шигъри алмазлар**

Сезнең өчен кызык булмас инде,
Яшьләр безне аңлый алмаслар...
Сизеп торам — компьютерлар кызы,
Син тилмереп шигырь язмассың.
Безнең язмыш сезгә көлке тоелыр,
Алай яшәү сезгә язмасын!..
Ә шулай да өстәп генә карап,
Гаепләргә безне ашыкма...
Мин әверелеп тордым бертуктаусыз
Әле — ташка, әле — гашыйкка..
Безнең гасыр яман чиргә баткан.
Газап чигүчеләр аз түгел.
Адәмнәрнең җанын дәваларга
Каләм белән моңлы саз түгел —
Әллә ниткән дарулар да җитмәс,
"Пычракизм"нарга баткан Җир.
Җимешләрен сезгә әзерлидер
Бу гасырда чәчәк аткан чир...
Әби-бабаларың исән булса,
Сораш — мине белми калмаслар.
Әле болай боегып утыргач та...
Мин сырладым шигъри алмазлар.
Сезгә артык соры күренер, бәлки,
Безнең мохит — тирә-әйләнә.
Мин бик серле үзем — әле бозга,
Әле эреп, назга әйләнәм...
Хыялларны безнең төтен итеп
Очырдылар кара морҗадан:
Шәрекъ алиһәсе була алмасын —
Узмасын, дип, гади "марҗа"дан...
И, сеңелкәш! Безнең яшәешне
Ала күрмә, зинһар, өлгегә, —
Безнең мәхәббәтнең чигешләре
Матур күренсә дә сөлгедә...
Хәер,
Мәхәббәттән сез тиз савыгырсыз,
Иммунитет сездә көчәер...
Мәхәббәттән чиргә сабышулар
Сабыйлык ул, беләм ич, сәер...
Беркемне дә күккә чөймәссез сез,
Беркемне дә үлеп сөймәссез.
"Күз бетереп" китап укымассыз,
Шагыйрьгә дә бик баш имәссез...
Тик —
Гасыр картайса да, җил картаймас,
Туар барыбер шагыйрь сеңелләр.
Бездән сезгә моңлы сәлам булып
Җилфердәшер шигъри сөлгеләр...

*1994.*

## Мәңге булмас үз бакчамда...

Мәңге булмас үз бакчамда
Шомырт шау чәчәккә баткан.
Ак чәчәкләр хуш-ис бөркеп,
Ачык тәрәзәмнән баккан.

Мәңге булмас түр бакчамда
Кызарыплар чия пешкән.
Ефәк пәрдәләрем аша
Кичке кояш нуры төшкән...

Мәңге булмас тын бакчамда
Миләш тәлгәшләре яна.
Үрелеп өзеп алмак булам,
Ымсынып ачы ялганга...

Беркайчан да булмаячак
Шул бакчамда йөрим, имеш.
Кызыктыра күзләремне
Пешеп тулган һәрбер җимеш.

Мәңге булмас шул түр бакчам
Керә көзге төшләремә.
Яфрак төсле сары кошлар
Куна килеп түшләремә...

Бакчамның тар сукмагына
Язгы-көзге сагыш яткан.
Шаккаттырып көзнең үзен,
Сандугачлар ...кире кайткан...

Гаҗәпләнеп сәер хәлгә,
Катып калган ялгыз каен.
"Тузга язылганмы соң бу?.." —
Сорау шыткан ботак саен...

Сөяләм дә шул каенга,
Чумам тирән көзге уйга.
Кем килер, дип анда җилләр
Ал-капканы ачып куйган...

*1997.*

## Чикерткәле өй

Чикерткәләр иялэште өемә.
И җырлыйлар "чикерт-чикерт" көенә!...
Бер тыңлыйм да, никтер куям шомланып.
Бер тыңлыйм да, янә күңелем сөенә..

Төне буе җырлый болар чик тә чирт.
Мин шуларның җырын язып утырам...
Бер шакмаксыз, юлсыз кәгазь битләрен
Сукмак-сукмак шигырь белән тутырам.

Чикерткәләр шул сукмактан кергәндер,
Монда шагыйрь яшәгәнен белгәндер.
Моңлы йортта иялэшэ алар, дип
Ишеттем, сөйләшкәчтен кем беләндер...

"Социалистик атрибут" — дип куймасмы! —
Сәясәткә бора, каһәр, һәммәсен.
Юк, мин фәкыйрь түгел, шөкер, Ходайга! —
Сайрасыннар чикерткәләр, әйдә соң...

Сайласыннар — кайда рәхәт торырга,
Үзләренчә шунда оя корырга...
Тик кайвакыт туйдырып та куялар,
"Җитте!" — дисәм, тавышларын тыялар...

Китте болар беркөн барыбер күченеп.
Тынып калды бушап өем әче бик.
Хәзер инде сагынам шул "концерт"ны,
Аңламассың — мин дә сәер кеше бик...

Чикерткәләр сайрый җылы төннәрдә...
"Минекеләр" күчте икән кемнәргә?
Киттеләр шул, инде кире кайтмыйлар,
Аптырагач, куеп карыйм җимнәр дә...

Нәрсә ашап торды алар икән, дим.
Гөл яфрагы, гөл туфрагы микән, дим.
Вакытлыча гына булса да, нигә
Миндә яшәп торды алар икән? — дим...

*1995.*

## Кыш җитә...

Менә тагын кыш җитә,
Күземне алып китә.
Кыр казлары йөрәккә
Сагыш-хат салып китә...

Очып китәр идем лә
Мин дә җылы якларга.
Мине анда кем көтә? —
Мин кирәкмим ятларга...

Мин кирәкмим беркемгә,
Айга түгел — бер көнгә.
Күктә ялгыз Ай гына
Минем сыман кайгыда.

Яз җитсә дә — бер төсле,
Көз җитсә дә — бер төсле.
Бер кителә — бер тула,
Яңарса да, гел иске.

Кыш җитә, дип мин генә
Утырмыйм ла боегып.
Тышта ата мәче дә
Кыскан әнә койрыгын.

*1997.*

## Төнге яңгырлар

Төнге яңгырларның шаһите мин,
төнге яңгырларга гашыйкмын.
Тәрәзәмне ачып карап торам,
күзге гүзәллектән шашып мин.

**Йөгереп чыгар идем, төн караңгы...**
**Көндез яуса, китми исем дә.**
**Төнлә яуган көзге яңгырлардан**
**яңара күк язгы хисем дә...**

**Рәхәтләнеп коя төнге яңгыр,**
**бер кеше юк — тәмам кылана...**
**Тамырыма хәтле үтә сеңеп,**
**җаным манма булып чылана...**

**Әй шул төнге яңгырларның шавы —**
**ярсып беткән җанга дәва күк.**
**Әйтерсең лә җиргә тылсым ява,**
**юмартланган гүя һава-күк...**

**Яңгыр исе тула кереп өйгә,**
**яфрак исе — урам һавасы...**
**Бу халәткә җитми тәңгәл сүзләр,**
**ничек кенә эзләп табасы?..**

**Ләззәтле бер сусау били җанны,**
**Үзе — яңгыр, үзе — сусата...**
**Үткән җәйнең үкенеч-тузаннарын**
**юып, күңелемне бушата...**

**Ул изрәтә, изгеләтә мине,**
**җаным җеби, рухым чистара..**
**Гүя озын-озак дәвам иткән**
**кайгылы юл кими, кыскара...**

**Сөрсеп беткән тынчу "тынычлыктан"**
**уята күк яңгыр тавышы.**
**Җәннәт бакчасының фонтаныдай,**
**баса фани дөнья сагышын...**

**Әйтерсең лә җаным мунча керә,**
**арулана күңел һавасы.**
**Бар җиһанны юар өчен, үзем**
**яңгыр булып килә явасы...**

**Яву гына түгел, ярсып-ярсып,**
**шарлавыктай килә коясым.**
**Шул ташкында эреп-җебеп бетеп,**
**тамчы хәлен килә тоясым...**

**Төн парие булып беттем тәмам...**
**Йоклый гавам... Ә мин — шаһите**
**шаулап яуган төнге яңгырларның.**
**Карап торам изрәп, "аһ" итеп...**

**Сентябрьнең соңгы төне бүген.**
**Җылы яңгыр — сәер галәмәт...**
**Көзге яңгыр! Җәйге яшеннәргә**
**шагыйрәдән моңлы сәлам әйт!...**

***1997 ел. 30 сентябрь.***

## ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР



Таһир Нәбиуллин

# КАЧКЫН

ПОВЕСТЬ

## I

Төн буе яуган яңгыр иртә белән дә туктамады. Киресенчә, салкын жил көчәеп, бәреп яуган яңгыр вакыт-вакыт жепшек карга әйләнә иде. Төньяктан искән жил үзе белән катлам-катлам күксел болытларны куып китерә торды. Алар, егылып төшәргә житешеп, азмы-күпме күтәрелеп торган калкулыкларны каплап алалар һәм итәкләренә терәлеп калырга тырышалар шикелле. Әмма көчле жил бу болытларны, анда торып калырга, ял итәргә ирек бирмичә, тигезлеккә куып төшерә бара һәм мәжбүри рәвештә жиргә тияр-тимәс биеклектә мәңгелек юлларын дәвам иттертә иде.

Мондый көндә ашыгыч эшләре булган кешеләр дә юлга чыкмаслар иде, мөгаен. Кырда яшел үлән булуга карамастан, малларын да көтүгә чыгармадылар бу көнне. Этләр генә түгел, хәтта бүреләр дә бу шыксызда урман ышыгында ятуны кулайрак күрәләр.

Юк икән шул, бөтен жан иясе дә алай итми икән. Ниндилер һич кичектерми торган йомыш әнә ике кешене жылы өеннән чыгарып жибәргән.

Болар — Мостафа белән аның улы Галимжан иде. Аларның таналарын житәкләп базарга барулары. Өйләрендә кәжәдән гайре хайван заты калмаса да, тананы сатарга булды алар. Чөнки озакламый имана паен түләмәүчеләрдән мал жыеп йөриячәкләр иде. Андый чакларда акчасы яки икмәге юкларның әйберләрен алып чыгачаклар. Әйбер дип, шул, сырма-юрганнары да мендәр-ястыкларыннан ары ярыйсы маллары да юк-югын. Менә шул мендәр-ястыклары белән ике юрганны бирәсе килмәгәнгә күрә, шундый эт чыкмастай көндә юлга кузгалырга мәжбүр булдылар.

Әйберләр бик кызганыч булмас иде дә бит, ястык өстендә Мостафаның хәләл жефете Шаһидә хасталап ята, күптәннән, сөмбелә* аенда ук урынга ятарга туры килде аңа. Бәлки соңгы көннәре дә житәдер...

... Имана пае күп тә түгел анысы. Елына ике тәңкә. Әнә, урыс

---

Таһир НӘБИУЛЛИН (1933) — *язучы. Балалар өчен язылган дүрт китап авторы. "Казан утлары" журналында беренче тапкыр басыла. Түбән Кама шәһәрендә яши.*

*Сөмбелә ае 22 августтан башлана.

диненә күчкәннәрдән бөтенләй тулатмиләр. Динен сатучыларга кызыгып исенә төшерүе түгел Мостафаның, алла сакласын! Дөнья малы дип, ахирәттә үзенне, мәрхүм ата-ананны мәңгелек тәмуг утына дучар итәргә ходай үзе язмасын. Тик тананы сатмыйча, ул ике тәңкәне дә табар хәл юк шул. Ярый ла малкайны дүрт тәңкәгә алучы булса. Имана паеннан кала, өйгә кирәк-ярак, өскә-башка ни-нәрсә юнәтеп булыр иде. Бәлки, берәр бозау да... Күккә карасаң, күк биек. Ни барына разый булып, шөкер итеп яшәргә насыйп итсен. Ходай тәгалә исәнлектән генә аермасын иде дә бит, менә хәләл жефете Шаһидә хасталанды. Саклап булмады шул үзен. Ир кеше эшен эшләп кенә урынга егылды, бахыр. Нигә кирәк иде инде аңа кул арбасы белән пычрак көннәрдә көлтә ташырга? Мостафа үзе дә өлгергән булыр иде әле. Дөрес, урак беткәч үк ул Әптүш байга ышна ачарга мәжбүр булды. Бармас иде дә бит, ул аңарга бурычлы. Бай чакырган чакта Мостафа бармыйча булдыра алмый шул, бурычын түләргә кирәк.

Урган арышны, арпаны кышын да сугып була анысы. Урып чүмәләгә куйган көлтәләрне өй тирәсенә ташып, вакытында кибәнләп куя алсаң. Мостафа өчен бу иң авыр эш, чөнки аның аты юк. Аты булган кешеләр жиңел генә ташып куя һәм кышның зыкы салкын көннәрендә өмә ясый, чабагач белән сугуны оештыра. Аннары ышыкта, әвеслек астында ике яктан да капкаларын ачып яки читән-коймасын сүтеп үтәли жил булдыра, суккан икмәкне агач көрәк аша үткәреп, ягъни көшел суырып, чүптән-кибәктән чистарта...

Уйлары белән еракка кереп китте бугай Мостафа. Улы Галимжанга борылып карады. Бу шыксыз салкын, үзәккә үтә торган жилле-давыллы көндә үзенә зуррак булган әнкәсе бишмәтенең жиңнәрен өскә бөкләп алган, кызарып беткән кулына чыбык тоткан балакай... Ярый әле зарланмый. Ара-тирә яшел үлән кыякларын өзеп кабарга тырышып атлаучы танасын чыбык белән куалый бирә.

Борылып каравы белән, Мостафаның кылт итеп үзенең балачагы исенә төште. Галимжан кебек чагында Мостафаның әтисе юк иде инде. Ышна ачканда агач басып үтергән иде аны. Әнкәсе Мәрхәбә кайгысыннан елый-елый сукырайды. Мостафага аны житәкләп йөрергә туры килә иде. Уртак исәптән кешегә биреп чәчтерә торган имана жире уңышының аларга тигән өлеше ярты кышка да житми иде, шуна күрә күбрәк саилчелек белән көн күреп үсте ул. Ә Галимжан, яхшымы-яманмы, әтисе карамагында. Үзенә мондый иркәлекләр насыйп булмады шул. Тик менә Шаһидәнең сырхау булуы гына... Нишләтәсең, ходай шулай язгандыр инде...

Шунда арттан ниндидер пар ат куып житте. Бу шыксыз көндә тагын кемне нинди бәла юлга чыгарга мәжбүр итте икән, дип уйларга өлгермәде Мостафа, атлы кеше аларны юл пычрагына күмеп узып та китте һәм ерак булмаган елга күпере аша олыс үзәге Шомгатыга кереп югалды. Мостафа аның күрше авылдагы Хәмзә морза икәнен генә абайлап калды.

## 2

Базарлар ни төрле генә булмый? Әйтик, Бәки базары мөгезле эре терлек, атлар сату белән дан тота. Анда шомарып беткән, шул шөгыльгә күнеккән арадашлар сиңа теләсәң нинди атны алып бирә беләләр. Мәгәриченне генә кызганма. Ялчек базары кызыл мал, икмәк сатуы белән абруйлы. Атаклы Шәмәк базары чүлмәк, алтын-көмештән ясалган бизәнү әйберләре, пыяла сатуы белән шөһрәтле. Ә менә Хәмзә бай пар атына утырып килгән Шомгаты базары сәүдә товарларының төрлелеге белән берсенә дә охшамаган. Олыс түрәләре урнашкан авылда булганга күрә, бу базар иң бае. Монда үзенә кирәк кешеләрне дә ешрак очратасың.

Бу базарда Хәмзәнең үз йомышы, үз максаты, юлда очраган йолкыш Мостафаныкы кебек кенә түгел аның шөгыле. Ул, иң беренче, үзенең монда урнашкан кибетенә сугылырга булды. Гадәтенчә, кәтмәгәндә генә

килеп чыгарга, сатучыларының ничек сату итүләрен читтән торып күзәтергә ярата ул. Кешеләр белән нинди мөгамәләдә була хезмәтчен, аларны товар белән кызыксындыра беләме, бәясен чамалыймы, арзанга сатмыймы? Бигрәк тә бүгенге шыксыз көндә аның киләсен башларына китермиләр иде хезмәтчеләре.

Хәмзә бай, пар атын үзе гел кереп йөри торган Спиридон хәрчәүнәсе абзарында калдырып, базарга җәяүләп кенә атлады. Аның тире-каештан, сүстән-киндердән ясалган ат-арба дирбияләре сата торган кибете ачык булырга тиеш. Мондый пычрак көннәрдә базарга килүчеләрнең тәртә тәҗесе, камыт бавы, аркалык, ыңгырчак баулары яки эшлиясе өзелгәли яисә кайтыр юлга түзмәслек хәлгә килгән була.

Кибете ачык иде. Сатучы Габделхәй, гадәтенчә, үз урынында. Кереп сәламләшкәч, сүз алышып, дөнья хәл-әхвәлләрен сөйләшеп алдылар.

— Монда Ырынбур якларыннан бер сәүдәгәр килеп чыккан, диделәр, — Габделхәй шундый хәбәр житкерде, — Канзафар атлы икән. Ул татар сәүдәгәрләре белән аралашырга тели, ахрысы. Сиңа аның белән танышу зыян итмәстер.

— Аны кай тарафтан табып була?

— Шул Спиридон хәрчәүнәсендә тукталган булырга тиеш.

Хәмзә базарда анда-монда күз салгалап, товар бәяләрен сорашып берникадәр йөрде дә кире хәрчәүнәгә кайтып китте.

Спиридон йортында җыелган сәүдәгәрләр гадәтләре буенча мәҗлес башлап җибәргәннәр иде инде.

Хәмзә морза тегеләрнең кызыксынуларын үз ихтыярларына калдырып, Ырынбур сәүдәгәре турында сорашты. Спиридон аңа сәүдәгәрнең бүлмәсен күрсәтте.

Бүлмә хуҗасы нәрсәдер уйланып, ишекле-түрле йөри иде булса кирәк, чөнки ишек ачылганда ул бүлмә уртасында басып тора иде.

— Әссәләмегаләйкүм!

— Вәгаләйкем әссәлам! Әйдәгез, хуш киләсез. Йә, бер утырып дога кылыйк.

Дога кылып алдылар.

— Сезне кем дип белик инде, дус кеше?

Танышып киттеләр. Икесе дә сәүдәгәр булгач, аларның уртак сүзләре байтак табылды, тәмләп чәй эчә-эчә, теге-бу хәбәрләрне бер-берсеннән эләктереп алгандай, сорашып-сөйләшеп туймадылар.

Сөйләшә торгач, мәгълүм булды ки, Канзафар үзе дә татар җирендә туып үскән кеше икән. Чыгышы белән Келәүледән. Ырынбур каласы салына башлагач, шул далаларның башкортлар яшәгән бер читенә, Акъярга, Таналык елгасы буена ук барып чыккан һәм шунда урнашып калган.

Ул яшәгән даладагы киңлек, иркенлекне, андагы башкортларның, әгәр үзең саф күңелле була калсаң, дустанә халык икәннәрен әйтеп узды Канзафар.

Көнкүреше белән ул Хәмзә морза кебек үк йомышлы татарлардан икән. Шулай ук шактый җир били, ләкин мондагы кебек, җирне сөреп, икмәк чәчми, ә анда көтү-көтү хайван асрый. Аның берничә дистәләп куй, сыер, ат көтүләре бар. Шул куйларын, көтү-көтү елкыларын кыргыз-кайсак яки казакъ илләренә кудырта, аннан башка токым атлар алып кайта һәм шуның белән табыш итеп яши икән.

Мондый алыш-бирештә Ырынбур губернаторы Неплюев әфәнде үзе кан-кардәш татар-башкорт һәм казакъларның үзара аралашуларын хуплый икән. Ул якларда икмәк белән сәүдә итүчеләр өчен аерым иркенчелек, тамга салымын түләмичә сәүдә итү мөмкинлекләре зур икән. Хәмзә морзаны мондый иркенлекләр таңга калдырды, хисләндерде. Үзләрендәге хакимиятнең кысып торуыннан гаҗиз булган бай морза башкорт якларына чыгып сәүдә итәргә хыялланды-ымсынды.

Әгәр ул да, Канзафар кебек, шул якларга китеп, сәүдә җәелдереп җибәрсә, икмәк сату буенча бөтен башкорт-казакъ җирендә беренче

сәүдәгәр булачак ич! Мондый мөмкинлекнең Канзафар сәүдәгәр белән очрашканга кадәр төшенә дә кергәне юк иде әле.

Кыскасы, Канзафарны Хәмзә бай үз өенә кунакка чакырды. Хәмзәгә бу адәм нәрсәдер әйтеп бетерми кук тоелды. Олы юллардан читтә торган бу аулак төбәккә килеп чыгуының бер сере бардыр бит инде. Шулай да берничә сүзе белән ул үзенең сәүдә эшенә маһирлыгын сиздерде.

Алар Хәмзәнең пар атына утырып чыкканда яңгыр туктаган, болытлар сирәгәйгән, җил дә ул кадәр куәтле исми иде инде.

## 3

Галимҗан өчен базарга бару кызык та, көенечле дә булды. Әнкәсенең тананы кызганудан елап, сеңлесе Фатиханың аңламастан аптырап калуы барып җиткәнче күз алдыннан китмәде. Барып җиткәч, кешеләрнең, мал, товарның күплегеннән ул югалып та калды.

Әтисе тананы сату белән мәшгуль булган арада, гаҗәп күренешләрдән авызын ябарга да онытып, атлар сатыла торган рәткә килеп җитте Галимҗан. Монда кырыкмыш тайлар да, өсләре ялык-йолык итеп торган бияләр дә, баскан урыннарында биеп торучы аргамаклар да, киң күкрәкле, көчләре ташып торган алашалар да, хәтта нукта өстенә йөгән кигезгән, тезген урынына ике чылбыр белән ике баганага бәйләп куйган бер туры айгыр да бар иде.

Галимҗан бу атларга бик озак карап торды. Күңеле белән шул атларның әле берсенә, әле икенчесенә атланды, атланып әллә кайларга очты. Атларны су коендырып кайтканда башка малайлардан уза торган Сафи мулла малае Солтангали кара айгырын да узды ул хыялында...

Галимҗанның икенче шатлыгы хыялый түгел, ә чынбарлык булды. Әтисе янына борылып килгәндә тана юк иде инде, әтисе кулында аның муенчагы гына калган иде. Хайванны сатканда муенчагын, атны сатканда йөгәнен бирмиләр. Алай итсәң, кул китә, киләчәктә йортка рәтле хайван керми, ди. Галимҗанның күңеле тулды, күзләренә яшь килде — таналарын озатып кала алмады ич!

— Саттыңмыни, әткәй?, — дип сорый алды ул.

— Саттым, улым. Әйдә, бергә базарны әйләник әле...

Алар ипи рәтендә авыз суы китерерлек бер түгәрәк бодай күмәче алдылар. Аннары чалгы-пычак рәтенә юнәлделәр. Анда инде Галимҗанны чын бәхет көтә иде. Күптән хыялланып йөргән пәке, агач саплы, ачылаябыла торган чын чалгы пәке алып бирде аңа әтисе.

Юлда кайтканда кесәсендәге пәкесен капшый-капшый, тула оеклы чабатасы аркылы салкын су үткәнен дә сизмичә, кая атлап, кая йөгереп кайтты ул. Пәке — корал ул. Ә корал булгач, барысын да эшләп була, теләгең һәм осталыгың гына булсын. Һөнәргә ул авылның остасына — Кадермәт абзыйга барып өйрәнер, аңа хезмәт итәр, аның мактавын казаныр. Барыннан да бигрәк, ул курай ясарга өйрәнер. Курайны камыштан ясыйлар. Тик камыш озакка түзми. Менә артыш сабагыннан ясалган курай түзә.

Мостафа исә күбрәк хафаланып кайтты. Чөнки, көн әйбәтләнсә, имана паен җыярга чыгачаклар. Кайтып кына житсеннәр... Юкса, авыру Шаһидәсен, бәләкәч кызын елатып, имана акчасы хакына әйберләрен алып чыгып китүләре бар. Әгәр алар урамына килеп җитсәләр, Җәгъфәрсадыйк старостаның Мостафа йортына тукталмый узарына өмет юк. Авыл кешеләренә дә мәгълүм хәл бу. Чөнки Җәгъфәрсадыйк ятим үскән Мостафага үзенең зәгыйфь кызын ярәшмәкче иде. Ләкин Мостафа бу кызга да, аның белән киләсе мул бирнәгә дә кызыкмады. Авылдан үзе кебек бер ярлы кызы Шаһидә белән никахлашты. Староста моны кичермәде. Әледән-әле дошманлыгын сиздерә торды.

Кайтып житәрәк, авыл күз алдында пәйда булгач та, Мостафа арган-талган улын кызганып, бераз ял итәргә булды. Ул арада яңгыр

туктаган, болытлар сирәгәйгән иде. Ара-тирә кояш та күренгәләп ала. Ләкин салкын җил һаман көчле иде әле. Алар юл буендагы күлнең яр ышыгына төшеп утырдылар. Мостафа, улының күнеле күтәрелсен өчендер инде, пәкесен сорап алды. Әлеге күмәчтән бер телем, улы яраткан кибән башын кисеп бирде. Үзенә дә кискән иде, тик бераз карап торгач, чүпрәккә төрде дә кире күшиленә салып куйды. Галимҗан пәкесе эшкә яраганга куанды, күмәчен комсызланып ашарга керешге. Ашап бетергәч, күл өстенә чүмәшеп, куш учлап су эчте. Әтисе шул пәке белән нидер юнып маташты. Ботаклы тал кисәгеннән әкәмәт кызыклы, куллы-аяклы курчак килеп чыкты!

— Бусы сеңлеңә күчтәнәч, — диде әтисе.

Юлчылар тагын алга атладылар. Аларга тизрәк кайтып житәргә кирәк иде.

## 4

Иркә бала булып үсте Хәмзә морзаның кызы. Абыйсыннан соң көттереп туганга күрәме, бәләкәйдән үк бар игътибар аңа булды. Заһидә үз-үзен белә башлаганда ук әтисенең кул арасына керә башлаган абыйсы Якубмы яки әтисе үземе, базарларга барган саен бүләксез кайтмыйлар иде. Ә базарга алар, билгеле, бик еш йөриләр. Бала чакта ук кызчыкның кием-салымнары, читекләре, көмеш беләзек-алкалары бик күп буй җиткән кызларның да күз явын алырлык иде.

Заһидә үзе дә ачык йөзле, якты чырайлы, һәркемнең дикъкатен җәлеп итәрлек сөйкемле бала булып үсте. Абыйсы, бигрәк тә әтисе кайтып төшсә, һәрвакыт диярлек каршы йөгереп чыгар һәм бертуктамый сорашыр иде:

— Әткәй, ничек йөреп кайттың? Юлларың ундымы? Хәвеф-хәтәргә очрамадыңмы? Бүген көн сүрән, җил чыгып тора, туңмадыңмы?

Юлда йончылган булса да, әтисе газиз кызының өтәләнеп шулай каршы алуына ифрат та канәгать, бөтен арганлыгын онытып, кызын кочып ала торган иде. Үсә төшкәч тә аркасыннан сыйпап, бер үк сүзләр белән җавап кайтара килде:

— Бик шөкер, кызым, сәфәрем бу юлы да унды. Синең бәхеткәдер әле, Аллаһы боерган булса.

Шулай килештереп каршы алган ягымлы баланы ничек күчтәнәчсез-бүләксез калдырасың инде?

Бала чакта Заһидәгә зур ирек куйдылар. Аңа күбрәк малайларның уеннары ошый иде: качыш, чабата, мәрәй, кыекбаш уеннары. Балаларга хас булганча, хәрәмләшкән өчен кайберләренең түбәсенә менеп төшәргә дә күп алмый иде ул.

Ләкин аның башка балаларның берсендә дә булмый торган гадәте бар иде: ул да булса — табигатькә мөкиббән китү. Ул урман сулышын, су агышын, җәнлек-җанвар, кош-кортларны бер гаҗәп күргәндәй онытылып, сәгатьләр буе күзәтә торган булды.

Моңа, бәлки, тирә-як мөхит сәбәпче булгандыр. Атасының йорты артында зур алмагач бакчасы бар иде. Анда, төрле алмагачлардан кала, чия һәм урман чикләвеге куаклары, кура җиләге дә үсә иде. Бакчаның аргы башында тар гына инеш ага. Инешнең теге ягында берничә адым аша калын кара урман башлана.

Көннәрнең берсендә, ваемсыз гына бакчада йөргән чагында, Заһидә бер кызык манзарага тап булды: инешнең ар ягында ул төлке күрде. Төлке нәрсә беләндер бик мавыккан иде, ахрысы, Заһидәне абайламады. Баксаң, ул нindидер түгәрәк йомгак белән уйный, аны суга таба тәгәрәтә икән. Исе китеп карап торган кызга бу гаҗәп тоелды. Төлке алгы аяклары белән сак кына теге йомгакка кагылып ала. Баксаң, ул аны тәгәрәтә икән. Ниһаять, йомгак суга төшеп ага башлады һәм шул вакытта языльп

китте. Бу йомгак керпе булып чыкты. Төлке сай суга керде һәм керпене каптырырга чамалады. Төлкенең хәйләсен аңлап алу белән, Заһидә бер чыбык тотты да, чырыйлап кычкыра-кычкыра, төлкене куарга керешге. Төлке ырылдап алды һәм теләр-теләмәс кенә урманга кереп шылды. Керпе исә, инешне кичеп бакчага, чикләвек куаклары арасына кереп югалды. Соңыннан да Заһидә үзе котказган керпенең яфракларны кыштырдата-кыштырдата бакчада йөрүен мавыгып күзәтә торган булып китте.

Үзен беркайчан да ялгыз итеп сизмәде кыз. Дус кызлары да булды аның. Бигрәк тә үзләренең күршесе, әти-әнисе Хәмзә байга хезмәт итүчеләрнең кызлары, үзеннән кечерәк Фәридә белән дус иде Заһидә. Алар бергә хәйләсез беркатлы уеннар уйнадылар, курчак тирбәттеләр. Заһидәнең таш курчагы булу башка кызчыкларны да аның янына тарта иде бугай...

Иптәш кызлары, малайлар арасында Фәсхетдин атлы бер малай бар иде. Ике-өч яшькә олырак бу малай Хәмзәнең терлек-туарын, атларын карап торучыларның малайлары булып, күршедә генә яши һәм көн саен аларның абзар-кура тирәсендә була иде. Бу Фәсхетдин Заһидәне каз талаудан, кәҗә сөзүдән аралый башлаганнан алып һаман аның яклаучысы була килде. Бик бәләкәй чакта бакчаның аргы башында адашып, инеш аркылы чыккач, урманга таба китеп баручы кызчыкны күреп алучы һәм аны җитәкләп өенә алып кайтучы да шул ук Фәсхетдин булды. Тузбаш еланнан курыккан чагында юатып, тынычландыручы да ул иде.

Тора-бара, балалар үсә төшкәч, ир һәм кыз балаларның аралашулары сирәгәйде. Ун яшькә җиткәндә авыл кызлары әниләренә булышырга керешәләр, хатын-кызга хас булган йорт эшләренә, җеп эрләү, киндер, палас сугу, тегү-чигү кебек бетмәс-төкәнмәс эшләргә тотыналар. Малайлар исә, әтиләре, абыйлары кул астында кыр эшләренә, терлек-туар карарга, балта, чүкеч тотырга өйрәнәләр.

Фәсхетдингә башкалардан үзгәрәк эш насыйп булды — алмагач бакчасында эшләргә тиеш иде ул, шулай итеп, тора-бара бакчаның бердәнбер караучысы булып китте: төпләрен йомшарта, корыган ботаклардан арындыра, яшь үрентеләрне чүп үләннәреннән чистарта торган булды. Кура җиләге, чия җыю кебек күңелле эшләргә Заһидәне, ә Заһидә исә башка кызларны чакыра иде. Алма җыяр вакыт җиткәч, алар төрен төргә аерып, әрҗәләргә тутыра һәм базарларга озата иделәр. Тора-бара Фәсхетдинне алма сатар өчен якын-тирәдәге авылларга җибәрә башладылар. Тик алманы күбесенчә тавык йомыркасына гына алмашып булганга күрә, бу шөгыль табышлы түгел иде. Үсә төшкәч тә, Заһидә белән Фәсхетдиннең аралары өзелмәде. Әледән-әле очрашып, сөйләшеп үстеләр. Араларындагы дуслык шулкадәр самими һәм эчкерсез иде ки, абыстайдан сабак ала башлагач та Заһидә иң әүвәл өйрәнгән әлифләрен Фәсхетдингә күрсәтә килде. Үзе дә сизмәстән, аны хәреф танырга, укырга өйрәтә башлады. Тора-бара бергә китап укырга күнегеп киттеләр. Заһидәнең укырга хирыслыгын күреп, әтисе белән абыйсы яңа китаплар алып кайталар, аңа акчаларын кызганмыйлар иде.

Фәсхетдиннең ат вә сыер-сарык арасыннан чыкмаучы әтисе дә улына уку дәртен өстәп торды. Үзе хәреф таный белмәсә дә, аның сүзе саллы иде:

— Улым, дөньяда акчага, байлыкка кызыкма: кулыңнан тиз шуар; хатын-кызга табынма: үкенечле булыр; урыслар кебек тәрегә табынма, чиркәүгә башың орма: ул ялган. Дөньяда иң кыйммәтле байлык — галимлек, иң татлы нәрсә — ирек.

## 5

Мостафалар кайтып җиткәндә, имана пае җыючылар алар өеннән узып, Гайнулла абзыйларга килеп җиткәннәр иде инде. Өйгә кереп чыкканнар, билгеле. Ә-әһ, чирек сәгатькә генә алдарак кайтып өлгермәделәр шул...

— Җәгъфәрсадыйк абзый, минем ястыгым белән юрганымны кайтарып бир, зинһар! — дип ялварды Мостафа, арбада үз әйберләрен күреп. — Өйдә сырхау җәмәгатем ята бит, менә, имана паен хәзер үк түлим, акчам бар.

Мостафа никадәр ялынса да, чәй тәлинкәсе хәтле бакыр тәңкә тамгасын муенына таккан староста аңа:

— Иртәгә әйберләреңне сатып алучылар булмаса, каравыл өеннән түләп алырсың, — дип кенә җавап бирде.

Әйберләрен йолып кала алмаган Мостафа ашыгып өенә кергәндә Шаһидә мичкә аркасын сөяп, коры сәкедә утыра иде. Итәгендә — кызы Фатиха. Хатыны хәлсез куллары белән кызын кочаклаган, күзләре йомык. Мостафа тиз генә сәкегә чоланнан каты киез алып кереп салды, урын җәймәсен җәйде һәм мендәр йомшартып куйды. Шаһидәне җайлап урынга яткырды, өстендәге бишмәтен салып хатыны өстенә япты.

— Бик аз гына иртәрәк кайтсак, сине урыныңнан кузгаттырмас идем дә, өлгереп булмады шул.

— Анисы ярар, сиңа әйтәм, исән-имин йөреп кайттыгызмы? — дип сорады Шаһидә хәлсез тавышы белән.

— Әйбәт кайттык. Син ятып тор, бераз хәл ал, мин тамакка әзерләп алыйм, — диде Мостафа, үзен сабыр тотарга тырышып. Ул мичкә ягып җибәрде, төннекне ачты. Кара мичнең төтене төннеккә юнәлгәч, борчак оныннан ботка ясады. Аны сосып, шул ук казанда су кайнатты.

Ул арада Шаһидә тынычлангандай булды. Кызы Фатиха кулында күмәч сыныгы күргәч, елмаеп куйды. Фатихага исә дөнья җитте, ул комсызланып кулындагы сыныкны ашарга керешгә. Абыйсы Галимҗан чалгы пәкесен күрсәткәч, бөтен балалыгы белән:

— Абый, нәрсә ул, мин дә тотып карыйм әле? — диде.

Әтисе кызына ясаган бүләген — агач курчакны чыгарып тоттыргач, бала бөтен дөньясын онытты, шул курчактан башка берни күрмәс-белмәс булды, башы түшәмгә тиде. Рәхмәт әйтергә дә онытып, курчагын киндер чүпрәк кисәгенә бер төреп-бер сүтеп, уенга бирелде.

— Шаһидә, син борчылма, әйберләрне иртәгә иртүк алып кайтырмын, — дип юатты Мостафа җәмәгатен, сәкегә аш табыны әзерли-әзерли. — Тананы әйбәт саттым. Имана паен түләгәч, берәр бозау алып җибәрербез. Тагын тернәкләнербез, алла боерган булса, менә күрерсең.

Таштабакка салган борчак боткасын базар күмәче белән ашадылар. Аннары чәй эчтеләр. Җылы өйдә хәзер урын-җирсез дә йокларга була иде инде. Арган-талчыккан Галимҗан, тамагы туйгач, яту белән изрәп йокыга талды. Фатиха да курчагын кочаклаган килеш йоклап китте. Бүген барысына да рәхәт иде.

Ләкин бозау алырга туры килмәде аларга. Озакламый Шаһидә, ике баласын, ике күз нурын ятим калдырып, якты дөнья белән бәхилләште.

Хәләл җефете вафат булгач, Мостафа бермәл бөтенләй югалып калды. Ярый әле, мәрхәмәтле күршеләре Гайнулла абзый белән аның карчыгы Гайниҗамал абыстайлар ярдәмгә килде. Үз балалары булмагач, алар Галимҗан белән Фатихага әби белән бабай була белделәр. Теге чакта имана паен түләмәгән өчен староста Гайнуллаларның да кәҗәләрен алып киткән иде. Тана саткан акчага Мостафа аларның да салымын түләп, кәҗәне кире алып кайткач, Галимҗан аны “безнең кәҗә” дип йөртә башлады.

Мостафага Шаһидәсеннән башка яшәү авыр булды, билгеле. Ләкин ул балалары хакына яшәргә, көн итәргә тиеш иде. Балаларының да ятим калуларына җаны көйде. Аларны кызганды һәм балаларын бер сүз белән дә кыерсытмады, булдыра алган кадәр теләкләрен үтәргә тырышты. Тагын башлы-күзле булыр иде, ике бала өстенә кем килсен соң? Аннары тагын, өйләнер өчен азмы-күпме хәл дә кирәк бит әле.

Үткән кыш улы Галимҗанны мәдрәсәгә биргән иде ул. Бала сабагын тиз отып алуы белән хәлфәне гаҗәпләндергән иде. Быел менә биреп булмады инде.

## 6

Әйе, Хәмзә олыста бердәнбер булып калган морза. Элек аларның нәселе зур, ишле иде. Гаять абруйлы токым. Хак булса, тамырлары Туктамыш ханга ук барып тоташкан. Заманында аларның Тау ягында бер дигән утарлары бар иде. Ул утарда күп санлы хезмәтчеләреннән кала беркем дә яшәмәде. Утарны да, бу — морзалар утары дип, тирә-юньдә көн күрүче кара халык ерактан әйләнеп уза торган иде. Хәмзә хәтерли әле: нәселнең олпатлыгы, олуглыгы атасы Хәкимҗан яшь чакта ук, тирә-якта дан тоткан бабасы Күкси вафат булгач тоныклана башлады. Иң элек Хәмзәнең әнкәсе Бибикамал, егерме биш яшендә фаҗигале үлем белән дөньядан китеп барды. Хәмзәнең исендә — җәйнең башында булды бу фаҗига.

Тау ягының горурлыгы дип әйтергә кирәк, анда бердәнбер зур елга — Зөя елгасы бар. Тау ягында шактый еш була торган яшенле яңгырлардан соң, җәйнең теләсә кайсы вакытында ташый Зөя.

Менә шул холыксыз елганың корбаны булды да инде Хәмзәнең әнкәсе.

Күкси морза элек-электән үк Тәтеш, Әтрәч, соңрак Йомралы байлары, мулла-монтагайлар белән аралашып яшәде. Улы Хәкимҗанга да Йомралының Атнагол ахун кызы Бибикамалны хатынлыкка яучылап алып бирде. Ирен ир дип олылый белә торган акыллы, яшь хатын Бибикамалга морзаларча зур ирек куелды. Ул елына бер-ике тапкыр пар ат белән карт ата-аналарына атна-ун көнгә утырмага барып кайта торган иде.

Бу юлы Бибикамал, озак көттереп туган бәләкәй кызы Айсылуны бабасы белән әбисенә күрсәтер өчен, Йомралыга утырмага барды. Читән чыбыктан үргән кәрмәле йомшак тарантаска ун яшьлек улы Хәмзәне дә алган иде, атнадан артык кунакта булдылар алар. Иртә белән куәтле яңгыр явып туктагач, Йомралыдан саратан* аеның бер көнендә юлга кузгалдылар. Яңгырдан соң көн ачылып, җылынып киткән иде. Озакламый Зөя буена да килеп җиттеләр. Бу вакытта Зөя күбекләнгән, суы болганган, гадәттәге кыяфәтеннән шактый үзгәргән булып чыкты.

Яр буена килеп җиткәч тә ат башындагы малай әйтә куйды:

— Абыстай, Зөя болганган, суын арттыра бара, әллә кичмичәрәк, бераз сабыр итеп торыйкмы? — диде.

— Монда кайтып җиткәч, туктап тормыйк, чыгыйк, олан, — диде Бибикамал, тизрәк кайтып җитәргә ашкынып. — Кара, Айсылу да ялыккан, көйсезләнеп тора.

Ат тотучы малай, алай-болай була калса дип, Хәмзәне үзе белән янәшә утыртып, атларны болганчык суга куып кертте, ләкин алар өске борылыштан йорт биеклегендәге су дулкыны киләсен чамаламаганнар иде. Ә дулкын, болар елганың уртасына да җитмәс борын, пар атны күмеп китте һәм бикә утырган тарантасны әйләндереп каплады. Шул арада көчләре ташып торган атлар, дәһшәтле дулкын астыннан өскә калыктылар һәм бар хәлләренә каршы як ярга ыргылдылар. Ат башындагы малай Хәмзәне чытырдатып үзенә кысты, дилбегәсен кулына чорнап тотты. Куәтле атлар аларны, су йотып өлгерсәләр дә, икенче як ярга алып чыктылар.

Әмма Бибикамалның хәле мөшкел иде. Тарантас астыннан калкып чыкканда Бибикамалның кулыннан юрганга төргән баласы ычкынып китте. Шул мизгелдә су ташкынының яңа дулкыны китереп бәрде. Юрганга төрелгән бала йомычкасыман бөтерелә-бөтерелә агып, әнкәсеннән шактый ераклашкан иде инде. Баласы артыннан ташланучы Бибикамалның битен башына бәйләгән ефәк шәле каплады. Шуннан соң ул бер-ике кат су өстендә калкып күренеп китте дә күздән югалды. Судан исән-имин чыга алган ат тотучы малай гына бу фаҗигане күреп торды, тик ул берничек тә ярдәм итә алмый иде шул. Ә шактый су эчкәннән соң укшудан арына алмаган Хәмзә исә фаҗигане аңлап та өлгермәде.

---

*Саратан — 22 июннән башлана.

Бибикамалы һәм нарасые фажигале төстә һәлак булгач, Хәкимҗан морзаның дөньяга, гомумән, тормышка карашы үзгәрде. Хәләл җефетен өзелеп яратуына юрадылар аның бу халәтен. Ләкин эш башкада иде.

Бу фаҗига булыр алдыннан Хәкимҗан морзаны олысның земский нәчәльниге господин Садовников белән бергә Тәтешкә, земский управага чакырдылар. Өяз каласы Тәтештә аларны управа нәчәльниге майор Караев бик җылы каршылады.

Сүз унаенда ул патша хәзрәтләренең указы булуын, анда лашман хезмәтенә йомышлы татарларны да тарту турында әйтелгәнен аңлатты. Морза кадәр морза булган Хәкимҗан әфәндегә үзе барып яки ун яшьлек улы Хәмзәне җибәреп эшләтергә майорның вөҗданы кушмый, янәсе. Шуңа күрә ул бер тәкъдим ясады: Хәкимҗан морзаның Морзалар утарыннан күренеп торган, бик үк уңдырышлы да түгел, балчыксыман тоташ сазлы җире бар икән. Байтак кына урыслар шул тарафка, Зөя буена килеп урнашырга телиләр, имеш. Әгәр дә Хәкимҗан морза шул батκаксазлык җирләрен урысларга бүләк итсә, майор Караев хәзер үк ике башлы бөркет төшерелгән мөһерле язу бирәчәк. Анда морза Хәкимҗан һәм аның нәселе лашман хезмәтеннән мәңгегә азат ителә дип язылган булыр. Әгәр Хәкимҗан морза моңа риза булып, шул турыдагы кәгазьгә кул куйса, теге килеп урнашкан урыслар аны үзләренең хуҗалары итеп таныйрлар һәм аңа һәрвакыт иң дәрәҗәле урын булыр.

“Күпме көтүлекләремнән мәхрүм булам икән мин?”- дип уйга калган морзага майор Караев тагын бер “баллы прәннек” ыргытты: киләсе урыслар Кострома якларыннан икән. Сазлык арасында көн күреп күнеккәннәр, монда сезнең Зөя елгасында балык тотарлар, барлык тоткан балыкларын җир хуҗасына — сиңа тапшырырлар, ә син аларны сатарсың яки балык мае, җилем ясарсың.

— Кайда сатармын соң мин аны?

— Анысы да хәл ителмәслек мәсьәлә түгел. Әйтик, менә монда, өяз каласы Тәтештә кибет ачып җибәрерсең, яки олыс Шомгатыда бер түгел ике кибет ач! Рөхсәт кәгазен мәрхәмәтле господин Садовников хәзер үк язып бирергә әзер.

Ничек кенә булмасын, Хәкимҗан морза урыс түрәләренең таләпләре белән килешергә, тиешле кәгазьгә кул куярга мәҗбүр булды.

Озакламый Зөя буена каекларга төялеп, уннан артык урыс гаиләсе килеп төште. Урыслар киндер ыштаннан, чабатадан, билләре киндерә белән буылган озын киндер күлмәктән иде. Хатын-кызлары да озын житен сарафаннан, үзләре яланаяк, күзләренә батырып, сынап караучы бәндәләр иде.

Озын буйлы, аксыл озын чәчле, киң сакаллы бер урыс Хәкимҗан морзага якынлашты. — Син Хәкимҗан морза буласыңмы? — дип сорады ул. — Миңа син каршы алырсың дип әйткәннәр иде. Мин бу урысларның башлыгы, староста Стеклов булам.

Үзенең дәрәҗәсен төшерергә теләмичә, морза озакламый утарына кайтып китте. Икенче кат әйләнгәндә урыслар һаман урнашып бетмәгәннәр иде әле. Өченче-дүртенче барышында морза урысларның читәннән үреп, ярым җиргә сеңеп торган абзар-кура коруларын күзәтте. Урыслар зур-зур имәннәрне екканнар, шул бүрәнәләрдән йортлар да салып маташалар иде инде.

Хәләл җефете белән булган фаҗигадән соң, морза бу урыслар урнашкан авылга йөрүен ешлата башлады. Урысларның исерткеч әче суларыннан да баш тартмады. Ә урысларның һәрбер якшәмбесе ял көне өстәвенә, дини бәйрәмнәре дә бик күп икән. Кыскасы, алар бәйрәм итәргә маһир халык булып чыкты. Һәрберсе, хәтта хатын-кызы да, әчеп алалар да, җырлашабиешә башлыйлар. Әчәләр дә җырлыйлар. Әчәләр дә бииләр. Татарларга хас булмаган бу җырлаш-биешләр авылларының исемендә дә чагылыш тапты — авылны татарлар Биеш дип атадылар. Хатыннарының кайберләре үзләренә ошаган ирләрне әрәмәлеккә мавыктырып алып кереп китүдән дә тартынмый иде.

Хәзер инде хатынсыз калган Хәкимҗан морза да мондый вәсвәсәгә бирелеп, ымсынып йөри торган булып китте. Староста Стеклов, морзаның мондый йомшаклыгын сизеп, төрле тозаклар әзерли һәм капкынына еш кына эләктерә дә иде.

Хәмзә морза, әнисе иртә вафат булу сәбәпле, кешегә мәрхәмәтлек, яхшылык итү гадәтләрен үзләштерә алмый калган иде. Шулай да гайрәтле әтисе Хәкимҗан морзадан тәкәбберлек, горурлык, үзен башкалардан өстен тоту сыйфатларын үзләштереп өлгерде. Шуңа күрәме, әтисе шактый какшаткан нәсел абруен ул хәленнән килгәнчә ныгытыр, беркетер өчен бөтен көчен сарыф итәргә тырыша иде. Ләкин заман үзгәрүен, урыс даирәләренең үзе шикелле йомышлы татарлар белән хәзер артык кызыксынмауларын ул төшенеп бетмәде.

## 7

Быел көз авылда гадәттән тыш җыелыш көтелә иде. Анда ун елга бер тапкыр гына эшләнә торган эш — җир бүлү турында сүз булачак. Җир бүлү — авылда иң мөһим, иң четерекле, иң катлаулы, иң каршылыклы, иң җаваплы мәсьәлә.

Билгеле, җирне иманалап, авылның ир затына гына бүләләр. Һәрбер ир кешегә — олымы ул, кечеме, карт кешеме, имчәк баласымы — бер имана тиеш. Авылның старостасы белән муллага гына өстәмә бирәр имана, аннары староста ярдәмчесе белән мөәзингә бирәр дисәтинә җир өстәлә. Шуның өстенә аларга бирәр чалулык* та бирелә.

Ун ел эчендә авылда ниләр генә булып бетми?! Картлар яки яңа туган балалар гына түгел, типсә тимер өзәрлек ир-егетләр дә теге дөньяга китә баралар. Имана җире исә шул гаиләдә кала бирә. Шуның аркасында атасы вафат булган бертуганнар арасында еш кына ызгыш чыга. Шул ук вакытта кайбер ир балалар ун ел буенча өлешсез-иманасыз калалар. Андыйлар исәбенә Галимҗан да кергәнгә күрә, Мостафага дүрт җанга бер имана гына тиеш иде. Менә Галимҗанга инде сигез яшь, ә ул һаман иманасыз. Бер имана белән ат асрап та, сыер һәм башка терлек үрчетеп тә булмый. Ә терлек-туарсыз нинди тормыш инде ул? Бер иманалы гаиләгә, күпме тырыш булмасын, ярлылыктан котылмак юк.

Авылның кырлары бертигез булмаганлыктан, ун ел буена кайберсе кара туфраклы уңдырышлы җирдән файдаланып килсә, кайберсенә кызыл балчыклы яки комлы җир насыйп була. Өченче ишләренә бөтенләйгә сазлыклы, язларын яки явымлы җәйләрдә озак кына су җыелып торган җирләр эләгә. Андыйлар шобага белән җир үлчәүче фәлән абзыйга, ул кеше әллә кайчан вафат булган суратта дә, рәнҗиләр, аны каһәрлиләр.

Авыл түрәләре, хакимлекләрен югалтмаска тырыша, ирешкән дәрәҗәсен саклап калу турында уйлана, төрле хәйлә кора. Авылда ун ел арасында икәүдән-икәү генә, бала-чагасыз гомер итүчеләр картая, эшләрлек кодрәтләре калмый, бәләкәй балалы ялгыз тол хатыннар да бар. Андыйлар шул ук түрәләргә барып:

— Фәлән абзый (энем), зинһар, ходай тәгалә хакына ал, эшкәрт минем җиремне, — дип ялына.

Бай түрә тиз генә ризалашмый:

— Мин синең җиреңне белəм, ул түбән басуда каз күле буенда — туфрагы юшкынлы, уңдырышсыз. Сукалаганда суканны җимертүең бар. Аны яхшылап тиресләргә кирәк. Ярты уңышы өчен генә җиреңне үз өстемә ала алмыйм, — дип ялындыра.

Ахырдан, сине кызгану йөзеннән генә, дигән булып ризалык бирә. Яисә мондый тәкъдим ясый:

— Минем югары басудагы җирем белән бөтенләйгә алмашсак...

---

*Чалулык — печән чаба торган кечерәк болын яки сазлык тирәсе.

Минем жир тиресле, мамык кебек йомшак, сөрергә-чәчәргә җиңел, егерме пот арыш бирә.

Фәлән абзыйның ризалашмый хәле юк, чөнки кем белән сөйләшсә дә, килешүне шул ук түрә раслый.

Бу унайдан Җәгъфәрсадыйк староста Гайнулла абзыйга сүз катып караган иде:

— Гайнулла абзый, синең җиреңминекеннән ерак түгел, берраттән мин чәчеп, эшкәртеп бирә алам. Көлтәләреңне дә үзем ташып бирермен. Уртакка риза бул.

— Рәхмәт тәкъдимеңә, Җәгъфәрсадыйк, — диде моңа каршы Гайнулла. — Без күрше Мостафа белән ничек булса да үзебез башкарып карарга ният быелга.

Шуңа күрә дә инде имана акчасын җыеп йөргәндә аны да читләтеп узмады староста, кәҗәсен алып чыгып китте.

Шундый шартларда, җир кытлыгында бу мөһим, зур җыенга һәрбер гаилә башлыгы, һәрбер кеше үзенчә әзерләнә. Ихтыяҗлары бердәй булганнар аерым төркемнәргә тупланып, алдан ук гәпләшә башлый, фикер алыша, җыенда үзенең фикерен уздырырга ниятли.

## 8

Фәсхетдин һаман бакча караучы иде. Шул ук вакытта ул китап укырга һәвәсләнде, кулына кергән һәрбер китапны —догалык булсынмы ул, мөнәҗәтме — берсен дә калдырмый укып барды. Ә китапларны ул Заһидә аша таба иде. Заһидәнең әтисе белән абыйсы, китап ишенең юнен-рәтен белмәгәнгә күрә, Фәсхетдин күңеленә хуш килерлек китаплар алып кайтмыйлар иде шул. Шуңа күрә Фәсхетдиннең боларга күңеле ризасызлана башлады. Аның ихтыяҗын берәр укыганрак кеше белсен иде дә күңеленә хуш килердәй кызыклы китаплар тәкъдим итсен иде.

Тукта әле, авылда Кәлимулла мулла бар бит! Бөтен кеше аны олылый, ул барсына да яхшы мөгамәләле, ярдәмчел, һәр кешенең хәленә кереп сөйләшә, киңәш бирә, диләр. Әгәр аңа мөрәҗәгать итеп караса? Бу турыда озак уйлады Фәсхетдин. Кыюлыгы гына житми торды...

Ниһаять, көннәрдән бер көнне җөрьәт итеп, муллага барып керде. Бәхеткә, Кәлимулла мулла ишек алдында иде.

— Әссәламегаләйкем, мулла абзый! — дип шактый кычкырып сәлам бирде Фәсхетдин.

— Вәгаләйкем әссәлам! Ни йомыш белән килүең? — дип йомшак кына сәламне алды мулла. Әмма тузган йомычкаларны себеркесе белән себерүен дәвам итте.

— Мулла абзый, мин ни... Берәр китап сорап тормакчы булып килүем иде. Укырга берәр китап бирмәссеңме икән?

Кәлимулла бу малайның соравына гаҗәпләнеп, себеркесен куйды. Үзе утын бүкәненә утырды һәм сораштырырга керешде:

— Улым, иҗекләрне кайдан өйрәндең соң, мәдрәсәгә дә йөрмисең бугай?

— Мин ни... Хәмзә абзыйның кызы Заһидәдән күреп өйрәндем. Ул абыстайдан сабак ала.

— Догалар да беләсеңме?

— И, аларны китаптан укымагач та беләсең инде аны. Аларны кечкенәдән үк әнкәй өйрәтте.

— Нинди догалар беләсең, йә укып күрсәт әле!

Фәсхетдин, җиренә җиткереп, әгүзе-бисмилладан башлап, үзе белгән "Әлхәм", "Колһу-аллаһу", "Аятел-көрси"ләрне укып чыкты. Көенә китереп, житди кыяфәттә мавыгып укуы Кәлимулла мулланың күңеленә хуш килде. Ул, иренмичә, малай белән шактый вакыт сөйләшеп утырды.

Фәсхетдин дә тора-бара киеренкелегеннән арынды, үзен шактый иркен тота башлады.

Мулла абзый өеннән калын "Кисекбаш" китабын алып чыкты. Бер битен ачып, малайга укып күрсәтергә кушты. Аның шактый йөгерек укуын күргәч, китапны биреп җибәрергә булды.

— Монда пәйгамбәребезнең сәхабәсе хәзрәте Гали батырлыклары турында язылган. Бик гыйбрәтле китап ул, — дип, малайны башыннан сыйпап озатты. — Хәмзә бай белән дә, атаң белән дә сөйләшермен. Атнага бер тапкыр минем йортыма килеп йөрерсең, мин сиңа сабак бирермен. Укуың түләүсез булыр.

Мулланың бу соңгы сүзләрен аңлап бетермәде Фәсхетдин, кулына шундый калын, мавыктыргыч китап килеп эләккәч, аның болай да түбәсе күккә тигән иде инде.

Өенә кайту белән Фәсхетдин әлеге китапка капланды. Иртәгесен аны бакчага кыстырып чыкты. Анда көндәлек эшләрен эшләгәч, кире алачыгына — китап укырга ашыкты.

Хәмзә бай да, әтисе дә Фәсхетдингә атнага бер тапкыр Кәлимулла мулла янына сабакка йөрүне рөхсәт иттеләр. Ул сабакка бик теләп, һәвәсләнеп йөрде. Тиз арада "Һәфтияк"не үтте. Кайбер шәкертләр мәдрәсәдә торып та кесәгә сыймалы бу китапны икешәр ел өйрәнгәндә, эшеннән бушаган арада гына да Фәсхетдиннең бик тиз үзләштерүе Кәлимулла хәзрәтнең күңеленә хуш килде. Әмма Фәсхетдинне иң мавыктырганы маҗаралы "Кисекбаш" китабы булды. Мөхәммәт пәйгамбәрнең кияве хәзрәте Галинең ислам дине өчен, гаделлек өчен дию белән көрәше тасвирланган, көйләп укыла торган бу китап Фәсхетдин күңелендә зур тәэсир калдырды. Сабакның иң зур файдасы шул булды — малай язу кануннарын өйрәнде. Тора-бара ул Коръән-кәримнең төп нөхсәсен, ягъни өтер-тәшвишләп уку кагыйдәсен үзләштерде.

Шулай итеп, берничә ел узып китте. Бу арада икесе ике дәрәҗәдә — малай ялчы хезмәтендә, ә Заһидә бай кызы сыйфатында үсәләр дә, берберсенә булган дуслык мөнәсәбәтләре какшамады. Киресенчә, аларның күңел аралары якыная гына барды.

Соңгы вакытта үсмер кыз белән малай күңелләренә хуш килердәй тагын бер шөгыль таптылар. Үзенең Алмачуарын иярләп кырга-болынга чыгып йөрергә ярата иде Заһидә. Зурая төшкәч, ялгыз гына йөрергә аңа рөхсәт итми башладылар. Кызны озатып йөрүче кеше кирәк булды. Бу бурычны, билгеле, кызның балачак дусты Фәсхетдингә йөкләделәр. Алар, атнага бер булса да, икәү бергә атларга атланып, кырларны әйләнеп кайта торганнар иде. Урак өсте туры килгән кызу кояшлы көннәрдә үзләре белән бер кувшин тутырып салкын әйрән, икенчесенә юл уңаенда салкын чишмә суы алырлар иде дә, Хәмзә бай җирләрендә урак уручы хатын-кызлар янына чыгып китәрләр иде.

Көз дә житте. Ураклар бетте, кырдагы чүмәләләр ташылып ындырларга, әвен базлары тирәсенә кибәннәргә куелды. Иген кырларында кара каргалар, сыерчыклар, ара-тирә көртлек гаиләләре генә бер урыннан икенчесенә очып йөрделәр. Агарып калган кырларда әле анда, әле монда яшелләнеп җәйрәгән уҗымнар гына кырларга бераз төс кертәләр, ләкин уҗымнар да гомуми моңнан арындырмыйлар иде. Урманнар да бу сихри моңга кушылганнар: агачлар җилсез көннәрдә дә яфракларын коеп утыралар.

Гадәттәгечә, Заһидә белән Фәсхетдин атларына атланып, чираттагы сәяхәтләренә юнәлделәр. Бу юлы алар күзләре кая төбәлсә, шунда юл тоттылар. Әкрен генә, вак-төяк сүзләр белән мавыгып, урман куелыгына кереп китүләрен сизмәделәр дә. Бу вакытта көн сүрәнләнеп, кич якынлашкан иде. Аның өстенә, алар кереп киткән куе урман арасында болай да караңгылык хөкем сөрә иде.

Бу үсмерләр, фәкать икесе өчен генә кызык булган сүзләр белән мавыгып, көн кичкә авышуны чамаламастан, һаман максатсыз юнәлешләрендә булдылар. Алар вакытны да, караңгылыкны да тоймадылар, табигать

күренешләре дә тәэсир итмәде, атларының тынычсызлануылары, пошкырулары да борчымады, гүя алар дөньяда тик икәүдән-икәү, алардан башка җиһанда беркем юк һәм беркемнең аларда, аларның беркемдә эшләре юк иде.

Ярым карангылыктагы тынлык берьюлы ике эчкерсез яшь йөрәктә сүз куешмастан ихтыяр көче, өметле дә, көенечле дә сыман әлегә кадәр билгеле булмаган газаплы һәм дәртле куаныч кузгатты. Үзеннән-үзе хасил булган бу мәхәббәт чаткысы, шәфкатьле фәрештәләр ирештергән татлы табышмак җир йөзеннән түгел, ә җиде кат күктән индерелгән изге тойгы сусаган күңелләрен биләп алды.

Күңелләре белән бер-берсенә омтылган бу вакытта алар иркәләнешергә, сыенышырга әзерләр иде. Аяк астыннан кинәт сискәндереп бака сикерсә дә, бер-беренә ташланачаклар иде. Ләкин бернинди дә этәрешсез назланышырга бу егет белән кызны табигый тыйнаклыклары тыеп калды.

Бары тик кичке урманда мәче башлы ябалакның балалар елавына охшаган үксү тавышына исәеп, әлегә кадәр ваемсыз бу халәтләренә үзләре дә гаҗәпләнделәр һәм кире борылдылар. Ләкин урманнан чыгып житәр алдыннан аларны хәтәр мажара көтә икән.

Атларын кызулатып барган чакта кинәт атлар пошкырып куйдылар һәм алга ыргылдылар. Баксалар, юлдан кырыйда агачка тотынып, арт аякларында аю басып тора икән. Бу күренеш яшьләрнең котларын алды. Аю үкереп җибәрде дә, боларның артларыннан ташланды. Аю житез иде, бар көчләренә чабучы атларны менә-менә куып житә язды.

Шул арада аларны Фәсхетдиннең бер тапкырлыгы коткарды. Заһидәдән арттарак чабып баручы Фәсхетдин, аланга килеп чыккач, балан куаклары янынннан узганда аю юлына үзенең түбәтәен ташлап калдырды. Очып баручы түбәтәй, аюның борыны очыннан гына узып, аның игътибарын үзенә җәлеп итте, ерткыч балан куагы арасына ташланды.

Эзәрлекләүдән котылгач та алар озак чаптылар. Ниһаять, үз авылларына якынлаштылар. Күбеккә баткан атлар, куркынычтан котылгач, акрынайдылар, азрак юртып баргач, адымлауга күчтеләр һәм, хәлсезләнеп, Заһидәләрнең бакча инеше артындагы юан имән буенда бөтенләй туктап калдылар.

Аттан төшүе белән Заһидәнең күңеле ташып чыкты. Ул, үзе дә сизмәстән, үксеп елый-елый, Фәсхетдиннең күкрәгенә капланды. Баштарак ул, бу коточкыч халәттән әнисе куенына кереп кинәнүче бала сыман, эчен бушатырга, иркәләнеп, теге куркынычтан арынырга омтылган кебек булса да, егет куенына керү белән кинәт башка, әлегә билгеле булмаган хискә чумды. Аңа бу мизгелдә бик-бик рәхәт иде.

Фәсхетдин исә, Заһидәне сеңлесе, юк, кочагына үз баласы сыман кабул итте һәм үзе дә сизмәстән, мәхәббәт ялкыны аша иркәләргә, юатырга кереште. Заһидәнең калкып торган йомры күкрәкләре Фәсхетдиннең киң күкрәгенә ябышты. Егет бу мизгелдә эреп калды, аннары ирексездән, бөтен дәрте белән кызны кысып кочаклады. Балачак дусты Заһидә бер мизгелдә дөньяда иң кадерле, сөекле, үзенә бердәнбергә әверелде. Ул кызны кочарга, иркәләргә, назларга мохтаҗлыгын тойды. Бу кичереш алар өчен әлегә кадәр ят булган сәер, иң изге мизгелләр булдылар һәм икесенең дә күңелләрендә иң кадерле хатирә булып сакланып калдылар...

## 9

Ниһаять, җыен көне килеп җитте. Иртән иртүк каравыл өе янындагы мәйданга халык агыла башлады. Монда әле таягына таянып атларга хәлләреннән килә алган коргаксыган авыл картларыннан башлап борын аслары юеш бала-чагаларга кадәр җыелды. Капка төпләрендә бергә җыелышып әңгәмә коручы, ихтыяҗлары бердәй булган кешеләр бер төркемгә, икенчеләре икенче, өченче төркемгә оешып утырдылар.

Халык җыелып беткәч, староста Җәгъфәрсадыйк, Сафи мулла, Локман һәм тагын берничә авыл куштаны басмачага күтәрелделәр. Ак сакаллы бер абзый алар алдына килеп басты, таягына ике куллап таянды һәм бөтен халыкка ишетелерлек итеп кычкырып җибәрде:

— Монда җыелган мир — миңа бирегез җир!

Бу кеше малай чагында ук авылдан чыгып киткән, ата-аналары әллә кайчан үлеп беткән, монда бер туганы да калмаган Сәмигулла карт иде. Читтә йөрү авылда сирәк була торган күренеш булганга, бу элекке авыл кешесенә җир бүленеп бирелергә тиешме-юкмы, аны беркем дә белми иде. Җыенда иң беренче нәүбәттә шушы сорауны хәл итәргә булдылар.

— Сәмигулла, әйт әле, син авылдан кайчан, ни сәбәптән чыгып киттен соң? — дип сорады аңардан староста.

— Ни дип, яхшырак тормыш өмет итеп инде. Читекче мин. Казанда читек тегеп көн күрдем.

— Алайса ник кире кайттың?

— Картайдым. Күзләр күрмәс булды. Инде хәзер эшемне рәтләп эшли алмагач, хуҗага да кирәгем калмады.

— Бала-чагаларың бармы соң?

— Без карчыгым белән икәү генә. Балаларыбыз булмады.

— Карчыгың ни атлы?

Бу гади генә сораугa Сәмигулла карт җавап бирә алмады. Шул хәтле күп сорауга җавап бирү аны алҗыткан, ул фикерләү сәләтен югалткан иде инде. Җавап бирмәгәнгә гаҗәпләнүдән җыен гөжләп куйды. Кызык ясарга уйлапмы, староста бу картка тагын эндәште:

— Сәмигулла, бар әле, кайтып карчыгыңның исемен-атын белеп кил. Ансыз синең гозереңне хәл итеп булмый...

Картның өенә, дөресрәге, үзләре фатирга урнашкан Маһитап карчыкка кайтып килүдән башка чара калмады. Аның белән ияртеп бер малайны да җибәрделәр. Өенә кайтып җитү белән үк карт ишегалдында күренгән карчыгына ярып салды:

— Сәмига, син ни атлы?

Ул җыенга яңадан әйләнеп килгәндә аның үтенече хәл ителгән, ярты имана җир бирергә карар кылынган иде инде, җыен хәзер һәркемне озак еллар борчыган төп мәсьәләгә күчкән — җирне ничә елдан соң яңадан бүлү турында сүз алып бара иде.

Үзләре төркеменнән Мостафа әйтергә тиеш булганга, аңа сүз бирелде:

— Җәмәгать! Ун елга бер тапкыр җир бүлү һич дөрес түгел. Менә минем улыма хәзер сигез тула. Ул җирсез. Андый җирсез малайлар авылда байтак. Бу тәртипне үзгәртергә кирәк. Ник ике, я булмаса өч ел аркылы бүлмәскә җирне?

Староста ярдәмчесе Локман аның сүзен бүлде:

— Быел малаең иманага керә бит инде. Тагын улларың булыр иде, хатының юк.

— Әнә, Кәли, Бикмөхәммәт абзый, Вафа, Зыяларның икешәр-өчәр малайлары бар. Барысы да җирсезләр. Әйттерәсең килә бугай синең, Локман абзый. Атаң үлгәнгә ничә ел узганны үзең дә оныткансың инде, ә иманасын син чәчәсең. Бу тәртип сезнең ишеләргә файда гына ул. Ә халык интегеп яши.

Шул рәвешле каты сүзләр әйтешеп, ызгышып-бәхәсләшеп, озак тарткалаша торгач, җир бүлүне биш ел саен яңабаштан карап чыгарга булдылар.

Тагын бер четерекле мәсьәлә бар иде. Ул да булса — уйсу җирләр. Андый җирләрне махсус исәпкә алып, яңабаштан бүлү турында сөйләшергә кирәк иде. Бу уйсулыкларда җир арышлар башакка сикерә башлаганда гына өлгерә. Андый җирләргә күп вакыт тары да чәчеп булмый, киндер, җитен чәчсәң генә. Ә кайберләренә шалкан чәчәргә генә кала, ә шалкан белән генә яшәп булмый. Ниһаять, җыен бу мәсьәләне дә ничек кирәк алай ерып чыкты.

Яңа староста сайлау турысында сүз чыкмады. Бу мәсьәлә гаять зур

вакыйга булып, аны олыстан килгән берәр түрә белән тылмач катнашында гына хәл итәргә мөмкин иде. Ә олыс бу мәсьәләне староста үзенә ошамаган сурәттә, яисә ул вафат булган очракларда гына күтәрә торган иде. Авыл старостасы Җәгъфәрсадыйк кырыктан яңа узган таза кеше иде әле. Олыс түрәләре каршында ул, авыл кешеләренә карата үзенең рәхимсезлеген күрсәтеп, имана салымын вакытында җыеп тапшыра баруы һәм кирәк кешеләргә ришвәт бирә белүе белән урынында нык утыра иде.

Тагын бер мәсьәлә староста ярдәмчесе Локман турында иде. Ул үзенең тупаслыгы, кешеләргә ярдәм кулы сузасы урынга, алардан көлү, халык алдында кайберләрен рисвай итүе белән авыл кешеләрен үзенә каршы куйган, туйдырган бер адәм иде. Аның абруе бер очрактан соң бигрәк тә түбән төшкән иде. Гаделсезлекне яратмаучан һәм тиз тоя торган кешеләр алдында алдашуы белән бөтен авылны нәфрәтләндергән иде ул.

Эш болай булды. Түбән очтагы Галиулладан Локманның өч пот арыш аласы бар иде. Арышны жил капка төбенә алып чыккач, Локманга Җәләлетдин очрады. Үзе күтәреп кайтасы килмичә, бу кешедән илттерәсе килде аның. Йомыш кушуының хәйләсен дә уйлап тапты:

— Җәләлетдин, кара әле, менә бу өч пот арышны аркаңа күтәреп минем өйгә илтә алсаң, мин сиңа бүләк бирәм.

— Өч потны күтәреп илтүнең ние бар аның? Син аны үзең дә алып кайта аласың, — диде Җәләлетдин гамьсез генә.

— Күтәреп илтүнең дә бер шарты бар, мин күтәрсәм, аркадан шуып төшә барган саен төзәтеп, янадан күтәребрәк куярга тиеш булам. Ә син, бер аркаңа салган килеш, бер дә җайламыйча илт.

— Һы, бүләгең нәрсә соң? — дип җанлана төште тегесе.

Моны тыңлап торган Галиулла алдында Локман кызып ук китте:

— Бер бәрән бирәм.

Болар артыннан, кызыксынып, югары очка Галиулла да иярде. Бу кызыкны күзәтә-күзәтә, юлда очраган тагын берничә кеше кушылды. Җәләлетдин, чыннан да, капчыкны яңадан күтәреп җайламыйча-нитмичә генә, җиңел адымнары белән атлый бирде. Менә Локманның өе дә күренде. Инде оттырганын чамалаган Локман арттан килде дә капчыкны аска тарта башлады. Җәләлетдин бара бирде. Алай да җиңә алмагач, Локман капчыкка ике куллап ябышты. Тегесе атлавында булды. Арыш хуҗасы капчыкка асылынгач кына ул аны кулыннан ычкындырды. Хәер, алар капка төбенә килеп җиткәннәр иде инде.

— Оттырдың, — дип, канәгатьләнгән белдерде Локман.

— Хәрәмләштең, иблис! — Җәләлетдин әлеге капчыкны бер кулы белән күтәрде дә, болгап торып капка янына гына корылган туры әүеслек түбәсенә тондырды һәм артына да карамыйча өенә таба атлады. Салам белән аз-маз япкан, астына чикләвек чыбыклары гына түшәлгән лапас түбәсе җимерелеп төште һәм капчык салам-кибәк тузанына күмелде. Кетәккә кунган тавыклар чыр-чу килеп, түбә тишегеннән очып чыктылар да, бар хәлләренә кытаклый-кытаклый, тирә-якка сибелделәр.

— Менә дөрес эшләде! Җәләли менә шәп итте! Шул кирәк бу хәбескә, хәрәмләшмәскә яхшы булды, — дип таралыштылар кешеләр. Бу вакыйгадан соң Локман бөтен авыл алдында көлкегә калды. Моннан ары чәчелеп-сибелеп яткан берәр нәрсә күрсәләр: "Локман тавыклары кебек", — дип әйтә торган булдылар.

Менә шул Локманны алып ташларга, башка кешене куярга кирәк, диешеп, берничә кеше сүз кушса да, старостаны сайлау булмагач, ярдәмчесен дә алыштыру мәслихәт булмас, дип сөйләүчеләр, Локманны яклап чыгучылар булгач кына тынды халык.

Хәзер турыдан-туры җир бүлү мәсьәләсе калды. Бу иң мөһим эшне иртәгесен иртүк башларга булып, җыен таралышты.

Авыл ике мәчетле, ике мәхәлләле иде. Югары оч мәхәлләсенә караган кешеләргә җирне югары басудан, икенче мәхәллә кешеләренә түбән басудан бүләләр иде. Шуңа күрә, җирне үлчәү өчен дүрт-биш

кешедән торган ике төркем оештырылды. Моны, җир башына чыккач, мәхәллә кешеләре үзләре хәл итәләр. Җир бүлүчеләр һәрбер хуҗалыкның тамгасы сугылган йомычка, каен кисәге яки мәрәй башы кадәр генә таяк кисәге тутырган бүректән, я булмаса, каен тузыннан кул тыгып берсен алалар һәм тамга иясенә ничә имана җир тиеш булса, шуны үлчәп бирәләр иде.

Тамга ул — язу-сызу белмәгән кешеләрнең бердәнбер шәхси билгеләре. Тамга һәр хуҗалыкка борын-борын заманнардан, ата-бабаларыннан мирас булып килгән. Тамга ул — аларның имзалары, шәхси әйберләренә, әйтик, кычыткан капчыкларына кадәр сугыла торган билге.

Шунлыктан, җир бүлүчеләр төркеменә авылның, кимендә мәхәллә кешеләренең тамгаларын белүче, шул ук вакытта гадел, хәрәмләшмәүче кешеләрне сайлыйлар.

Мостафа да бу төркемгә билгеләнеп, аңа иң җаваплы вазифа йөкләнде. Ул тамгалы таяклар салынган бүрекне тотып йөрергә тиеш булды.

Яхшырак җиргә килеп җиткәч, халыкның дулкынлануы чиктән аша: үзенә эләгү ихтималын чамалап һәркем көтә, төркем-төркем шаулаша башлый. Үз тамгасы чыкмаганнар "аһ" итеп куя да тагын көтә башлый. Бүректән шобага таягын Мостафа үзе алырга тиеш. Ул, ничек тә булса хәйләләп, фәлән тамгалы таякны алырга да булдыра ала. Ләкин, үзенә шундый шик белән карамасыннар өчен, ул таякны йә берәр малайдан алдыра, йә берәр картка тәкъдим итә барды. Моннан файдаланырга теләүчеләрнең кайберләре, үз тамгасын бармак арасына кыстырган килеш бүреккә тыгылырга тырышып карады. Әмма Мостафа моңа ирек бирмәде. Күбрәк: "Ызандаш кешеңне үзең сайла", — дигән булып, инде өлеше чыккан кешедән алдырды таякларны. Шуңа күрә ризасызлык, тәртипсезлек тумады. Начаррак җир эләгүчеләргә дә үпкәләргә урын калмады.

Өлеш тигән хуҗалар һәрберсе җир башына көрәк белән кәзне ертып үзенең тамгасын сырлый кала килде.

## 10

Урал иркенлеген яхшы белүче Канзафар Хәмзәнең йорт-җирен ошатты. Юан имән бүрәнәләрдән салынган алты почмаклы бу йортта хуҗаның кунак бүлмәсе иркен, зур иде. Заманында сирәк булган паласлы такта идәнгә утызлап кеше тезелеп утырырлык. Аның белән янәшә җыйнак эш бүлмәсенә, кызлар ягына кагылмый гына, аш пешерү почмагына, җир идәнле аерым кер юу бүлмәсенең иркенлегенә игътибар итте кунак. Хезмәтчеләр тора торган йорт, аннан кала тагын бер кечерәк йортның да төп йорт белән бер ишегалдына карап торулары да күзенә чалынды.

Теләсә кемнең күз явын алырлык тагын бер мөлкәте бар иде Хәмзәнең. Ул да булса — алмагач бакчасы. Салкын Ырынбур далаларында мондый бакчалар булмаганга күрә, Канзафар аны исе китеп карап йөрде. Рәт-рәт тезелеп киткән алмагачларга, читән буйлап үсеп утыручы кура җиләкләренә, чикләвек куакларына, чия әрәмәлегенә кызыгып-сокланып туя алмады. Бакчада көшел-көшел яткан, тәмләре-төсләре белән берберсеннән аерылып торган алмалардан авыз итте.

Бакчаның аргы башында агып яткан тар инеш буендагы бүрәнәләр өстендә ике аягын кочаклаган, ияген тезләренә куйган килеш бер кыз бала утырганны күрде Канзафар. Кыз инеш аръягындагы урманга карап, нидер күзәтә иде булса кирәк, әтисе белән бу ят кешене күрмәде дә. Алар якынрак килгәч кенә сискәнеп китеп сикереп торды. Нәрсә турындадыр уйланып, хыялга бирелеп утыруын сиздергән чырае да тиз генә үзгәрмәде.

— Бу минем кызым Заһидә, — дип таныштырды Хәмзә. — Кызым, ник болай бер үзең генә сәерсенеп утырасың?

Заһидә ят кеше алдында унайсызланып калды. Гөнаһ эшләгәндә тотылган кеше кебек, битләре алсуланды. Озын аклы күлмәге өстенә күкрәгенә таккан хаситәсенең тәнкәләре чылтырап куйды. Муеныңдагы гәрәбә төймәләрен бармаклары белән тоткалаган арада озын җиңе эченнән көмеш беләзеге, бармагындагы йөзеге елтырап күренде. Ирексездән аяктан-аякка авышкан чакта, болай да матур кызның чибәрлеген арттырып, күлмәк итәге астыннан читек очлары күренеп калды. Канзафар тәҗрибәле күзләре белән бу өлгереп килгән кызның кемне дә булса көтеп торуын чамалаган кебек булды. Заһидәнең көмеш тавышы ишетелде:

— Әнә, агачларда тиеннәр уйнаша, шуны күзәтәм, әткәй...

— Минем кызым атларга гашыйк, — дип сүзгә кушылды Хәмзә, — аның яраткан Алмачуары бар. Үзе тешләк. Фәкать Заһидәне генә үз итә, башкаларны якын да җибәрми. Ул аңа атланып очуын күрсән, исең китәр. Бернинди егет куып җитә алмаслык.

Канзафарның башыннан бер уй йөгереп узды. Табигать кочагында үскән бу кыргый баланы үзенең улы Мортазага яучыласа, әйбәт буласы икән... Һәм ул шул ниятеннән Хәмзәнең кылларын тартып карарга булды.

Ул арада буш әрҗәләр төялгән арбалы атын җитәкләп бакчага Фәсхетдин килеп керде. Ул хуҗасы Хәмзә белән нинди дер ят кешенең инеш буеннан кайтып килүләрен күреп алган иде инде. Заһидәнең үзен көтеп торганын, тик Хәмзә бай белән теге кеше комачаулавын чамалады. Олылар алдында яшьләр сүз кушарга түгел, бер-берсенә карарга да оялдылар, әмма бер мизгелгә генә очрашкан күзләре барысын да әйтергә өлгерде, аларга артыгы кирәкми иде инде.

Тегеләр кереп киткәндә Фәсхетдин, авыз эченнән көнелле генә көйли-көйли, иртә таңнан базарга илтер өчен алмалар тутырып калды.

Икенде намазыннан соң Хәмзә морзаның туган-тумачалары җыелды, авыл старостасы да килде. Әңгәмә башлыча Урал-Җаек якларындагы тормыш-әхвәл, көнкүреш, гореф-гадәтләр турында барды. Мәчетләрнең торышы, урыслар белән татар-башкорт арасындагы мөнәсәбәтләргә дә кагылып уздылар. Канзафар, баштарак бу ят кешеләр арасында бераз тыелыбрак сөйләшсә дә, соңрак ачылып китте.

— Мондагы татарлар җиргә бәйләнгән. Салымны да җиргә бәйләп, имана пае итеп түлиләр икән. Безнең якларда салым җан башыннан билгеләнә. Һәр ир-атка башкортларга егерме бишәр тиеннән билгеләсәләр, типтәрләргә сиксәншәр тиен салалар. Типтәрләр — бу яклардан качып килгән татарлар. Алар җир җитмәүдән генә түгел, соңгы елларда куәтләнә барган көчләп чукындырудан да качып килүчеләр. Урнашыр өчен җир биреләр-бирүен үзләренә. Әмма ләкин аларга салым күбрәк салына. Аннан кала тагын мишәрләр бар. Алары патша хөкүмәтенә хезмәт иткәнгә күрә, салымнардан бөтенләй азат ителгәннәр.

Әңгәмәгә катнашып киткән табындашлар үзләре дә зарланырга керештеләр. Имеш, ерак түгел Наратбаш авылына берничә урыс руханилары килеп кергәннәр. Тылмач аркылы, ягъни үз динен саткан бер бәндә аркылы, авыл кешеләрен урыс диненә өндәргә тотынганнар, "тавык тәпие" — тәре таратырга керешкәннәр. Ул "тавык тәпие"н, имеш, тегәрҗепкә бәйләп, муенга тагып йөриләр икән. Урыс поплары авыл кешеләрен чукындырып, шул "тавык тәпиен" муеннарына аса икән. Бигрәк тә бала-чаганы алдалыйлар икән алар. Ничек дип, шул кәнфит-пәрәннек бирептер инде. Шулай да Наратбаш кешеләре җыелып, боларны кыйнап җибәргәннәр, ди. Андый җаһилләрдән Ходай үзе сакласын!

— Безнең якта көчләп чукындырулар юк, киресенчә, безнең сәүдәгәрләр өчен юл ачылып тора сыман әлегә, — дип сүзен дәвам итте Канзафар. Кунакның күзе Хәмзәдә иде. Ул сүзен еракланрак сукаларга булды.

— Урыслар сәүдә эшенә киң юл ачарга торалар. Аларның Урал-Ырынбур җирләренә чиктәш булган кыргыз-кайсак биләмәләренә дә өметләре зур. Шуннан Төркестанга, аннан ары фарсы җирләренә, Һиндстанга вә Кытайга каләр сәүдә юлларын җайга салу турында уйланалар.

Бу уңайдан сәүдә оештыру өчен, иң оста сәүдәгәрләр буларак, татар сәүдәгәрләрен җәлеп итүне хуп күрәләр.

Бу әңгәмә үзенең торган җирендә иркенләп сәүдә итүне урыс түрәләренең бик хупламауларын үз җилкәсендә татыган Хәмзә морза өчен бал кебек татлы булды. Бу нисбәттән ул кунагы Канзафарны өстәмә сораулар биреп байтак йөдәтте.

Икәү генә калгач, Канзафар Заһидә турында сүз кузгатты.

— Кызынны әйтәм әле, Хәмзә дус, чибәр генә булып җитлегеп килә икән. Үзе самими табигать баласына охшаган. Күзләре очкынланып тора. Бала акылы чыгып җитмәгән булса да, мин аңарда үзсүзлелек тә тойдым. Үзенә охшаган булса кирәк.

— Дөрес. Кызым табигать кочагында яшәде. Бердәнбер кызым, ул бернинди чикләнүләр күреп үсмәде. Кыз балага нинди ireклек тиеш булса, ул барысыннан файдаланды. Тиешенчә тәрбия алды, азынып-тузынып та йөрмәде.

— Гыйлем биргәнсездер бит?

— Абыстайга йөрде, укыттылар. Китапларны су урынына эчә. Әмма язу язарга үзем кушмадым. Кыз булып җитлеккәч, егетләргә хат яза калса, хурлыгыннан гүргә керерсең.

— Балаң әйбәт тәрбия алган икән алайса, — диде Канзафар.

— Белгәнебезчә әдәпле итеп тәрбияләдек, — диде Хәмзә кунагына.

— Күңелемә бер фикер килде әле, Хәмзә дус. Минем улым бар. Мортаза атлы. Аңа хәзер унтугыз тулды. Синең кызыңа, әйтүенчә, унбиш яшь. Әгәр аларны башлы-күзле итсәк дип әйтүем.

— Бик ерактан каердың әле син болай булгач, Канзафар дус. Кызны, вакыты җиткәч, кемгә булса да ярәшмичә булмас, анысы. Ходай тәгалә шулай язган. Бер насыйбы чыгып, аны вакытында урнаштыру бик мәслихәт. Шулай да улыгызны бер күреп сөйләшү кирәктер бит?

— Хак әйтәсең. Мортаза ул, дөресен әйткәндә, минем улым түгел. Аның турында сүз башланган икән, барсын да әйтеп бетерергә фарыздыр. Мин аны кыргыз-кайсак җирләренә кәрван белән баргач алып кайттым. Кәрванны озатып баручы бер башкорт улы иде ул. Атасы юлда вафат булгач, унике яшьлек кенә булса да, аннан ары юл күрсәтүче ул булды. Шуннан бирле үз улым кебек, миндә тора. Әледән-әле шул үзенең туган якларына минем малларым белән сәфәргә йөри. Һәр сәфәре уңышлы була. Үзе дин ягыннан да, тормыш ягыннан да мәгълүматлы бала.

Канзафар, бер елдан да озакка сузмыйча, улы Мортаза белән янә килеп чыгарга булды. Яшьләр бер-берсе белән танышкач, шәт ошашып та куярлар дип фикерләделәр. Хәмзә өчен иң әһәмиятлесе, иң кызыкканы булачак кияве белән бергә үз малларын төяп шул кыргыз якларына кәрван йөрү иде. Монда кысылып сәүдә итүгә караганда андагы сату-алу бик өметле, кызыктыргыч булып тоелды Хәмзәгә. Бу аның хыялы иде.

Сүзләрен сөйләшеп, уртак тел табып, сүз куешып, ике булачак кода бик җылы аерылыштылар.

Бу көннәрдән соң елга якын вакыт узды. Шул вакыт эчендә Заһидәгә әллә нәрсә булды да куйды. Ул уйчанланды, беркем белән сөйләшмәс булды. Алмачуарына атланып иртәдән кичкә кадәр берүзе югалып йөри торган көннәре дә булгалады. Җилбәзәк чагында тыярга кирәген белсә дә, үз күзе алдында тота алмады аны Хәмзә морза. Чираттагы алыш-биреш эшләре белән һаман базардан базарга йөрүендә булды.

Әйләнеп караса, Хәмзә дилбегәне ычкындыруга да күп калмаганын аңлады. Кеше арасында сүз чыккач кына. Турыдан-туры әйтмәсәләр дә, үзенең хезмәтчесе Фәсхетдин белән еш очрашуларын, бакча башындагы инеш буенда сәгатьләр буе сөйләшеп-көлешеп утыруларын, вакыт-вакыт атка атланып урманга чыгып йөрүләрен житкерделәр. Хәер, иптәш булсын өчен Фәсхетдингә кызын озатып йөрергә үзе кушты бит.

Хурлыкка калуың еракмыни болай була калса? Бердәнбер кызын үзенең атларын караучы малайга бирер өчен үстермәде ич ул!

Яшьтәшләре һәм аннан күп кечерәкләр иртә таңнан кичке караңгыга кадәр билләрен турайтмыйча һаман эштә булганда, Заһидә кызу урак өстендә дә иген кырларын атка атланып кына әйләнә бит. Шулай кадерләп үстергән кызың йолкыш Фәсхетдин белән бәйләнсен әле!

Шундый күңелсез уйлар уйлый-уйлый, Хәмзә Шомгаты базарына барып керде. Гадәтенчә, үзенең кибетенә сугылды. Ләкин кибет эчтән ябык иде. Якынрак килеп ишек аркылы колагын куеп тыңласа, анда кемнәрнеңдер сөйләшкән тавышларын ишетте.

— Фәсхи! — диде Хәмзәгә таныш тавыш. — Син хәзер егет кеше. Һәр алымыңны уйлап атларга вакыт.

— Габделхәй абзый, нишлим соң инде? Яратам бит мин ул кызны, — диде икенче тавыш. Монысы Фәсхетдин тавышы иде. —Ул да миңа кырын карамый...

— Син беләсеңме, энекәш, үзеңне нинди хәлгә дучар итүеңне? Морза кызы лабаса ул. Кая сузыласың, балакаем?!

— Ник, ике күңел бер теләктә булганнарга бергә булу языкмыни?

Хәмзә морза артык түзә алмады, бар көченә ишекне дөбердәтергә тотынды.

## 11

Фәсхетдин үсә төшкәч, Хәмзә бай аны бакчачылыктан алган иде.

— Малай, җитәр сиңа бакча тирәсендә хөрәсәнләнеп ятарга! — дигән иде ул. — Күзгә күренә торган эшкә тотынырга вакыт. Атыңны җик тә, олыс базарына, Габделхәй абзаңа алмалар төяп илт. Аннары бөтен кибетләргә дә товар ташырсың.

Озакламый Фәсхине тагын бер якка — Ялчеккә җибәрә башлады Хәмзә морза. Беренче тапкырында, Тәтештән биш-алты олау белән алып кайткан кызыл малның ике олавын төятте дә, егетне ияртеп, үзе дә юлга чыкты.

Иске Бола буена урнашкан Ялчек авылы гел чуашлардан гына тора икән. Алар барып кергән йорт хуҗасы Миклуша дәдәй Хәмзәнең яхшы танышы булып чыкты.

— Әйдәңес, хуш киләсес, Кәмсә агай, рәхим итегес, — дип, капкасын каерып ачты хуҗа һәм атларны үзе җитәкләп кертте.

— Ничек килеп чыгарга пултың, Кәмсә агай, хәпәр дә итмәдең? — арбадан төшкән Хәмзә белән ул ике куллап күреште. Аннары үзләренчә кемгәдер берничә сүз әйтте.

Өйдән башына кызыл шакмаклы яулыгын кыеклап бәйләгән, коңгырт шакмаклы, берничә рәт бәби итәкле озын күлмәк кигән бер хатын йөгереп чыкты:

— Аванни! — дип исәнләште ул, җитезлек белән атларны тугарырга кереште. Татар хатыннары кебек битен яшереп тормады. Фәсхетдингә монда бар да ят, таныш түгел иде.

Авыл урамнары, татар авыллары кебек яшел чирәмле, сиртмәле коелы булса да, йортларының тигезрәк утырулары белән аерылып торалар иде. Ишек аллары бәләкәй, ләкин өсте туры әүеслек белән ябып куелган. Урамда һәм бакча артындагы су буенда анда-монда таралып яткан пычраклыкта, тирестә эреле-ваклы дуңгызлар мыркылдаша иде.

Җир идәнле өй эчендә дә татар өеннән аермалар бар иде: мичләре башка төрлерәк итеп салынган, ишек катында бер яктан икенче якка сузылган зур сәндерә. Өй эче ниндидер ят ис белән тулган. Бу иснең тәмәкедән чыкканын Фәсхетдин Миклуша дәдәй төрепкәсен кабызгач кына аңлады.

Чуашларның киемнәре дә ят иде. Төрле төстәге шакмаклы киндер яулык, бәби итәкле күлмәк, бизәкле яки күп сандагы тәңкәләр тагылган күкрәкчәле алъяпкычларыннан тыш, һәрберсенең аякларында сарык

йонынннан юан итеп бәйләгән, өйдә дә тышта да киеп йөри торган озын оеклар. Алар ак, кара, сары, кызыл төсле божра-божра булып торалар. Хәтта чабаталары да урыс чабатасы булып, озын киндерәләрен сыйракларына тигез итеп әллә ничә кат чорнаганнар.

Хәмзә абзый белән Миклуша дәдәй каяндыр әйләнеп кайттылар. Бергәләп арбадагы алып килгән малларны бушаттылар. Алар урынына әрҗә-әрҗә колмак, күн, каеш, тимер-томыр төяп куйдылар. Иртәгесен иртүк кайтыр юлга чыктылар.

Моннан соң Миклуша дәдәйләргә Фәсхетдин көз буе йөрде. Ат дирбияләре илтте, аннан икмәк төяп кайта торган булды.

Ара-тирә, атасыннан калган йола буенча, Хәмзә морза Биеш урысларыннан яңа тотылган балык та ала иде. Урыслар балыкны атасына бушлай ташып торсалар, улы сатып алырга мәҗбүр иде инде.

Кышка исә Фәсхетдинне Хәмзә бай олыс кибетенә, Габделхәй абзасына ярдәмче итеп җибәрде. Анда ул базарны күзәтеп, нинди товар ни бәядә, кайсысы үтемлерәк булуын белеп торырга, Хәмзә байга хәбәр итеп, вакытында шуны базарга чыгару чараларын күрергә тиеш иде. Егеткә тырышып урыс телен өйрәнергә кирәк булды. Сатучы-асламчы булып йөргәндә үз товарын сатар өчен дә урыс теле кирәк иде.

Баштарак аны бу телгә абзасы Габделхәй өйрәтте. Аның белеме сайрак булса да, Фәсхетдин өчен ярап куйды. Тырышып өйрәнә торгач, үзе дә сизмәстән, кыска гына вакыт эчендә вата-җимерә урысча сөйләшә башлады. Сату әйберләренең бәяләрен яшьтән үк өйрәнү, хәтерендә калдыру мохтаҗлыгы, бәяләрне Хәмзә байга кайтып түкми-чәчми төгәл итеп әйтү зарурлыгы аның сәләтен шактый үстергән, хәтерен арттырган иде.

Урыслар белән тел арадашлыгы күп мөмкинлекләр ачты егеткә. Ул хәзер бу базарда гына түгел, башка якларда нинди малның, нинди товарның кайда ясалуын, кайдан нинди юллар белән кайтару мөмкинлекләрен өйрәнде.

Тик болар гына да аз иде әле. Аңа урысча укырга-язарга өйрәнү кирәк иде. Моны ничек өйрәнергә? Урыслардан таныш-белешләре дә бар инде хәзер югыйсә, тик алар арасында укый-яза белүчеләр юк иде.

Шулай уйланып йөргәндә Фәсхетдингә бер кеше белән танышырга туры килде. Ул кеше Дмитрий булып чыкты.

Табиб Дмитрийның олыска яңа гына килгән чагы икән. Аңа хасталарны карау, аларны дәвалау өчен күп вакыт өйләренә барып йөрергә кирәк. Шуңа күрә ул базарга ат алу нияте белән килеп чыккан иде. Фәсхетдин аңа ат сайлап алырга булышты. Шунда алар танышып киттеләр. Дмитрий кирәк булган очракларда тирә-яктагы татар авылларына чыгып йөрергә дә теләге юк түгелен аңлатты. Болар тиз арада аралашып киттеләр һәм бер-берсенә сабак та бирә башладылар. Дмитрий бик теләп татарча өйрәнергә тотынды, ә Фәсхетдин аңа өйрәткән татар сүзләрен урыс хәрефләре белән язарга кереште.

Бу ике яшь егетнең мәнфәгатьләре бердәй булганга, алар дуслашып өлгерделәр, бер-берсенә серләрен ачтылар. Дмитрий Богородское авылыннан икән. Табиблыкка укыганнан соң, үзе теләп ерак олыс авылына эшкә килгән. Телләрен белеп, татарларның көнкүрешен, гореф-гадәтләрен, тарихын өйрәнергә дә теләге бар икән үзенең.

Фәсхетдин исә үзе турында байтак мәгълүмат бирде. Тора-бара Заһидә турында да сөйләде.

Заһидә! Фәсхетдин кая барса да, нәрсә эшләсә дә, ни белән шөгыльләнсә дә, аны исеннән чыгармады. Заһидәнең сөйкемле йөзе, атлап йөрешләре, ияр өстендәге торышы күз алдында булды. Куллары, гәүдәсе хәрәкәтләнгән саен сизелер-сизелмәс чыңлап куйган хаситә тәңкәләренең көмеш тавышы колагында әледән-әле яңгырагандай була иде. Аюдан котылып, имән янында туктагач та аларның бер-берсенә омтылулары, назлanулары, кочаклашып, бик озак аерыла алмыйча иркәләнүдән тынычлык, юаныч табулары, шул ук вакытта әллә кайчаннан

бирле йөрәкләрендә яшеренеп килгән мәхәббәтләренең ирексездән тышка бәреп чыгуы аерым бер рәхәтлек биргән иде. Шул турыда уйлаган саен егетнең күңелен ләззәт, шатлык биләп ала иде.

Хәбәрләре белән Хәмзә бай янына кайткан саен Фәсхетдин Заһидәсе белән очрашу әмәлен эзләде, әмма очрашу күп вакытта тәтеми иде шул. Очрашкан чакта да бер-ике сүз алышудан, күзгә-күз карашып бер-береңне аңлашудан артмады.

Җитмәсә, соңгы вакытта егет Заһидәгә кагылышлы яман имеш-мимеш хәбәр ишетте. Узган көз килгән Ырынбур сәүдәгәре кызны үзенең улына алып китмәкче, янәсе. Бу җәйдә ул монда тагын килеп чыгасы, имеш. Бу хәбәр Фәсхетдиннең йөрәген парә-парә китерде, зиһенен чуалтты, кулыннан эшләре төште. Ул, төшенкелеккә бирелеп, үз-үзен кая куярга белми йөрде. Сөеклесенә атап алган көмеш чулпыларын ничә кайтып та тапшыра алмавын бәхетсезлеккә юрады, шик өстенә шөбһә өйде, йөрәге телгәләнде.

Әгәр кыз теге бай улына барырга риза булса? Ырынбур бае малае каршында кем ул Фәсхетдин? Гади ат караучы малае. Ә теге зур сәүдәгәр малае. Монда — гомер буе иртәдән кичкә хәтле билне турайта алмаслык эш. Анда — көн озын күңел ачу, сәхрәдә-сәйранда йөрү, башкаларны эшләтү. Монда — бәләкәй генә җир идәнле өйдә көне-төне төннекле мич тирәсендә кайнашу. Анда — башкалар әзерләп биргән күңелең теләгән аш-суны ашау, хакимлек итү. Монда... Уф...

Аптырагач, Фәсхи иртүк дусты Дмитрий янына китте. Бик төшенке кыяфәтен күрү белән Дмитрий дустының хәленә керешге. Гадәтенчә ачык чырай белән:

— Нәстә, дус, сөткә төшкян тычкан кибик настроение начар? — дип каршылады.

Фәсхи хәлне сөйләп биргәч, үзенең шиген дә әйткәч, Дмитрий уйга калды.

— Да, брат, синен хален серьезный, — дип кенә куйды.

Берникадәр уйлап утыргач, үзен кая куярга белми торган Фәсхигә карап торды да сайлап кына сүзен дәвам итте:

Сезнең, татарларнын, ничик але, умыкать девушку... э.э...

— Кыз урлаумы? Аны ябыштырып алу, диләр...

— Во-во! Урлау. Син аны урлап кит. Ул согласна булса, урлап кит.

— Урлап? Кая алып китим мин аны урлап?

— Бездә венчание булгач, ну, церковта жениха и невесту поп венчает, а татарда?

— Ә-ә, никах. Мулла никах укый. Шуннан соң алар ир белән хатын була.

Фәсхи җанлануыннан үзенең татарча сөйләшә башлавын абайламады:

— Алар никахтан соң ир белән хатын булалар. Аннары аларны беркем дә аера алмый. Шулаймы?

— Точно, Пасхи дус, шулай ит! Озак сузма. А куда алып китәсенне уйла. Мин пока мулланы белмим, извини.

Эченә жылы кергән Фәсхи ашыгып кибеткә Габделхәй абзасы янына китте. Тегесе кибетне ачкан гына иде әле. Дмитрийгә сөйләп биргән кебек, егет абзасына да үзенең кайгысын бәян итте. Киңәш сорады.

Бу көтелмәгән хәлдән Габделхәйнең бермәл теле тотлыгып торды. Аннары барып кибет ишеген эчтән бикләп куйды.

— И-и, бала, бала! Мин сине акыллы, төпле егет булып җитлегеп киләсең дип куанып йөрим тагын. Ә син чеп-чи юләр икәнсең!

— Ник алай дисең, абзый?

— Фәсхи! Син хәзер егет кеше. Һәр адымыңны уйлап атларга вакыт.

— Габделхәй абзый, нишлим соң инде, яратам бит мин ул кызны. Ул да миңа кырын карамый...

— Син беләсеңме, энекәш, үзеңне нинди хәлгә дучар итүеңне? Морза кызы лабаса ул! Кая сузыласың, балакаем?

— Ник, ике күңел бер теләктә булганнарга бергә булу язык-мыни?

Шул мизгелдә кибет ишеген тышкы яктан каты итеп дөбердәткән тавыш ишетелде. Сөйләшүчеләр тынып калдылар. Ишекне бертуктаусыз дөбердәтәләр иде. Кычкырган тавыш та ишетелде.

— Бу Хәмзә абзый үзе, бетте баш... — дип пышылдады Габделхәй һәм ишекне ачарга ашыкты.

Керә-керүгә үк Хәмзә коточкыч күзләре белән Фәсхетдинне эзләп тапты һәм камчысын биленнән тартып алды.

— Яратасыңмы, йолкыш, яратасыңмы? — ул егетне камчысы белән яра башлады. — Ә менә моны яратасыңмы? Мә, яратсаң, мә, мә!

Габделхәй арттан аны килеп тотмаса, Хәмзә күпме селтәнгән булыр иде, билгесез, тик камчысыз калгач та ул, еш-еш сулый-сулый, егетне сүгүен дәвам итте:

— Син эт җанны күпме кеше итәргә тырыштым мин, хәерче! Сиңа минем малым кирәк булдымы, йолкыш, эттән туган нәрсә! Эшләмичә баерга идеме исәбең, хәсис?

— Хәмзә абзый, тукта әле, сабыр ит азрак. Кызма әле ул кадәр. Тынычлан, — дип Габделхәй аны туктатмакчы булды. Тик аның сүзләре Хәмзәне кыздырды гына.

— Әллә кызымны азындырып та өлгердеңме, кабәхәт! Мин сине хәзер зинданга яптырам, себергә җибәрәм. Атаң-әнкәңне авылдан сөрәм. Сасы исегез дә калмасын кызым тирәсендә.

Габделхәй аны көч-хәл белән тынычландыра алды. Бер сүз әйтмичә, нәфрәтле күзләре белән курыкмыйча басып торучы Фәсхигә моннан чыгып торырга кушты. Тегесе урыныннан кузгалмады.

Азрак басыла төшкәч, Хәмзә бай Габделхәйгә дә берничә тозлы-борычлы сүз әйтте:

— Син монда кибет түгел, бүре оясы тотасың икән әле. Сиңа да җитешермен. Ишек аркылы бөтен сүзегезне ишетеп тордым мин. Кара син аны, "яратам", имеш. Шушы сәгатьтән минем күземә күренәсе булма, ахмак малай! Авылда да күрмим үзеңне. Юкса мин сине солдатка озатачакмын. Заһидә турында уйлавыңны да оныт. Кара син аны, кызымны аздырып минем малга хуҗа буласы килгән, эт коерыгы! Бар, хәзер үк ычкын минем кибетемнән! Мин сине җир тишегеннән эзләп табачакмын. Хәмзә морза диләр мине!

Ниһаять, Фәсхетдин урыныннан кузгалды. Ишек төбенә җитәрәк, ул борылып болай диде:

— Мин китәм, Хәмзә абзый, синең кибетеңнән башка да дөнья бетмәгән. Миңа биргән сабакларың өчен рәхмәт. Элеккесе өчен дә, бүгенгесе өчен дә. Насыйп булса, без очрашырбыз әле. Монда Габделхәй абзыйның да, әткәй белән әнкәйнең дә гаепләре юк. Алар гомерләре буена сиңа бил бөктеләр. Миңа синең малың кирәкми, тик минем күңелемә дә, Заһидә күңеленә дә син хуҗа түгел, була да алмассың.

## 12

Озакламый Хәмзә бай Канзафардан хәбәр алды. Ул монда бизмән — октябрь аенда килеп җитәргә чамалавын әйткән. Улы Мортаза да аның белән чыгачагын, туп-туры Хәмзә байның үзенә тукталырга уйлавын да әйтеп җибәргән.

Хәмзә бай олы кунакны каршылау өчен хәстәрлекләр күрә башлады. Иң элек: "Кунакны ни белән гаҗәпләндерим икән?" —дип уйлады ул. Капыл гына бирәр нәрсә уйлап тапмыйча изаланды. Канзафар башкорт арасында яши. Анда мал-туар, бездәге шикелле түгел, көтү-көтү булып утлап йөри, диләр. Чиксез далаларда үзенең генә ничә көтү кымыз бияләре бардыр. Аларда ат яки сарык көтүен бер-берсенә бүләк итү дә берни тормый торгандыр. Дәвәләр дә йөри икән анда. Казакъ җирләре белән

янәшә, берничә күнлек кенә юл икән аралары. Аларчарак итеп, ярыйсы гына бишбармак пешерүчеләр дә юк бит безнең хатын-кыз арасында. Ярый, аш-суны үзебезчә, мөселманнарча пешерерләр. Моңа безнең хатыннар оста. Әмма ни белән шаккаттырып була соң кунакны? Алма-чияне, җиләк-җимешне ул узган килүендә үк татып карады инде. Бернинди юньле-башлы фикердә туктала алмады бай. Ахырдан: "Ходай ничек тәкъдир иткән булса, шулай булыр", — дип, башка вак-төяк хәстәрләрен барларга керешге.

Кече атна көнне иртүк Хәмзә морза авыл мулласы Кәлимулланы чакыртты. Кәлимулла мулла, яшь булса да, авылда галим мулла абруен казанып өлгергән кеше иде инде. Ул үзе күп сөйләшмәс, дингә мөкиббән, кешеләргә киңәшен кызганмас бер кеше иде. Аның авыл халкы яраткан тагын бер гадәте бар —ул беркайчан да кыңгырлыкны сөймәс, кешегә, кем булуына карамастан, үз фикерен турыдан-туры әйтеп бирә торган иде.

Кәлимулла мулла Хәмзә бай өенә озакламый килеп тә житте. Дога кылынганнан соң, чәй янында әңгәмә башланды:

— Хәзрәт, минем синең белән киңәш итәсем килә. Аллаһы тәгалә язса, озакламый безгә Урал якларыннан кунаклар килер. Ул минем яхшы танышым, Канзафар атлы Ырынбур сәүдәгәре булыр. Ишеткәнсеңдер дип беләм, моннан бер ел элек ул монда бер-ике кичкә генә кереп тә чыккан иде. Хәзер, Алла теләсә, ул үзенең житкән улы Мортаза белән килер.

— Хәтеремдә, Хәмзә абзый. Аны укымышлы кеше дип әйткәннәр иде.

— Менә-менә! — дип дәвам итте Хәмзә, гүя үзе турында жылы сүз ишеткән сыман. — Хуш, андый кешене әйбәт итеп каршылау да лязымдыр. Башкортлар арасында башкортлашып баручы бик бай сәүдәгәр булыр ул. Аның көтү-көтү кымыз бияләре бар. Кымыз ясап, ерак-ерак жирләргә озата торган юллары бар. Тулаем әйткәндә, Канзафар бай бик дәрәжәле кеше. Үз форсатын кулдан ычкындырмас. Шуңа күрә бу зур кунакны үзенә тиң дәрәжәдә каршы алырга кирәк.

— Улы Мортаза белән килүенең берәр мәгънәсе бармы әллә?

— Дөрес, очраклы хәл түгелдер. Кызым Заһидәне улына яучыларга теләге бар сыман. Мин моны әлегә сиңа гына сер итеп әйтүем, хәзрәт. Башка кешегә житкерә күрмә берүк. Аларны ничек каршыларга, нинди сый-хөрмәт белән сыйларга, жыелачак мәжлесләргә кемнәрне чакырырга кирәк — шулар турында синең белән киңәшәсем килгәнгә чакырдым сине, хәзрәт.

Хәмзә байның үзе белән мондый рәвештә киңәш тотуы беренче тапкыр булганга, Кәлимулла мулла бермәлгә аптырашта калды. Ләкин үзенең гажәпләнүен сиздермәскә булды:

— Хәмзә абзый, кызыңны ярәшү турында миңа гына әйтүең дип хаталанасың. Имеш-мимеш хәбәр каян чыкканын мин белмим, әлбәттә, ләкин бу хәбәрне мин ишеткән идем инде. Кунакны каршы алу, кемнәрне чакыру турында киңәш соравыңа рәхмәт анысы. Тик сиңа, мөхтәрәм кешегә болар турында киңәш бирү артыктыр.

— Имеш-мимеш, дисеңме? Мин бит бу турыда жәмәгатемә дә әйткәнем юк. Каян белсеннәр?

— Халык зирәк бит ул, Хәмзә абзый. Ул сүз кунагың килеп китүгә үк халык арасына таралган иде инде. Аңа гына кәефең китмәсен. Ярый, хуш, Хәмзә абзый, болай булса, бик жаваплы эшкә, Аллаһы тәбарәкә вә тәгаләнең бик мәслихәт эшенә сарыфителергә торасыз икән. Ходай үзе жүн бирсен.

— Шулай да никах укуны сиңа тапшырырга ният.

— Никах уку бик жаваплы йола ул. Морза кадәр морза кызына никах уку минем кебек гади мулла эше түгелдер, ә дәрәжәле, тирә-якта абруйлы, шөһрәт казанган мөхтәрәм берәр хәзрәт укыса, кулайрак булыр иде. — Хәмзә абзый, ачуланма. Тирә-якта үзем белгән муллалардан Сафи хәзрәттән гайре мәгкуль булырдай кешене белмим.

— Хәзрәт, алайса, синең тәкъдимең белән килешермен...

— Хәмзә абзый, турысын әйткәндә, синең кызың Заһидә зиһенле кыз. Сылу да. Тик аның холкы үзенчәлекле. Ул булачак кияүен ошатырмы?

Аннан ары, туган якларын ташлап китәргә, башкорт далаларында яшәргә күнәрме? Бу турыда үзе белән аталарча алдан сөйләшеп куярга уйламыйсыңмы?

— Кыз бала атасының сүзеннән чыгарга тиеш түгел. Мин ни әйтсәм, шул булыр. Ата-бабаларыбыздан килгән гореф-гадәтне бозып, аның белән вакытыннан алда сүз катуның кирәге юк, — дип кырт кисте Хәмзә.

Алар икесе ике фикердә хушлаштылар. Хәмзә мулладан риза булмады. Тик ул үзенең тел төбен — кызы аша Ырынбур якларына үзенең дә барып урнашу, анда казакъ, ә бәлки Урта Азия белән дә киң сәүдә җәелдереп җибәрү хыялын ачып салмады.

Ә хәзрәт исә бу шикле никах уку вазифасын үз өстеннән төшерә алуына шатланды.

## 13

Ниһаять, көтелгән көн килеп җитте. Кунаклар Тәтештән пар атларда кичкырын килеп төштеләр. Җиңел арбада килгән бу кадерле кунакларны каршыларга Хәмзә бай үзе чыкты. Алар олылап берберсе белән күрешкәч, юынып, икенде намазы укыдылар. Ул арада табын өлгерде. Беренче сүз башы, әлбәттә, хәл-әхвәл сорашу, ничек килеп җитү турында булды. Юлчылар йончыган булганга күрә, сөйләшү өстән-өстән генә иде. Хәмзә Мортазаның басынкы буйлы, киң җилкәле, җәенке борынлы яшь егет булуын гына күрде, артыгын төпченеп, сораштырып тормады.

Иртәгесен кунаклар йокыдан ял итеп, көр күңел белән шактый соң тордылар. Алар килү хөрмәтенә буласы аш мәҗлесе өйлә чагына билгеләнгәнгә күрә, иртәнге чәйдән соңгы вакытны Хәмзәнең хуҗалыгы белән танышып йөрделәр. Хуҗалыкның күрке бакча иде, билгеле. Инешне, аннан ары урманны күзәттеләр. Бу якларга беренче тапкыр килеп чыккан Мортаза өчен болар бар да ят, кызык иде. Ул барыннан да бигрәк урманга сокланды.

— Алаен куркыс урман, гуй, — дип куйды.

— Урман белән танышырга өлгерерсең, улым, әлегә бу тирәне ныклабрак күзәт. Әнә, алма, чия агачлары нинди хозур, — дип, атасы аның күңелен башкага юнәлтте.

Бакча үзенең көзге бизәкләренә төренгән чак. Коры, сүлпән кояшлы әбиләр чуагы вакыты иде бу көннәр. Яфракларда күңелне рәхәтләндереп, күзгә ял бирә торган яшеллек беткән, алар авыраеп, калынаеп калган сыман. Өске яклары кызгылт көрән төскә кергән. Саргайганнары, киресенчә, югарып, җиңеләеп киткәннәр. Әз генә җил истеме, яфраклар менә-менә очып китәргә әзер булып, лепердәп торалар. Нәүбәте җиткәч, туган ботактан мәңгегә аерылып, кайсы тыныч кына, кайсы бер аска төшеп, бер өскә күтәрелеп очып китәләр, ә кайсылары бөтерчектәй бөтерелә-бөтерелә очарга мәҗбүрләр иде.

Алмагачларның кайберләрендә өлгергән алмалар кызарып торалар иде.

Кунаклар, шул алмалардан авыз итә-итә, алмагач төпләрен йомшартып йөрүче бер малай янына туктадылар. Ул Фәсхетдин урынына калган бакча караучы малай иде.

— Нәмәгә чоку кәрәк уны? — дип сорады Мортаза.

Бу татарча да түгел, ләкин аңлаешлы сүзләр малайга кызык булды, ахрысы, ул көлеп җибәрде. Хәмзә исә җитди генә җавап бирде:

— Көзен алмагачларга мул итеп су сибәргә кирәк. Тамырларына дым яхшы үтсен өчен тирәли казып чыгарга кирәк. Малай, син карабрак казы, тамырларына зыян китермә.

— Йир чокырга ярамый, гөнаһ ула, — диде Мортаза моңа каршы.

Малай бу егетнең сөйләменә һәм сүзләренең мәгънәсенә гаҗәпләнүдән авызын ачкан килеш басып торуында иде.

— Бүген казып бетер, иртәгә су ташып сибәрсең, — диде Хәмзә бай.

— Казакъ якларында жиргә көрәк тыгу чыннан да хәрам шөгыльгә санала, — дип аңлатты Канзафар.

Аш мәҗлесенә кунаклар җыелып беткәч, Кәлимулла мулла коръән укыганнан соң, табынга зур агач аштабагы белән итле токмач чыкты. Билгеле инде, сүз кунакка бирелде. Аларның ерак җирдән ничек, нинди юллар белән килүләре турында сорашудан башланды.

— Безнең торган җирдән ерак түгел Хәнифә юлы уза, — дип сүзен башлады Канзафар, — бөтен тирә-якта безнең сәфәр шул юлдан башлана.

— Хәнифә атлы авылмы ул?

— Юк. Аның риваяте болай. Башкортларның кыргыз-кайсаклар, ягъни казакълар белән элемтәләре борын-борыннан килгән. Бер-берсенә кунакка йөргәннәр, кызларын ярәшкәннәр, улларын башлы-күзле иткәннәр. Кайвакыт сугыш-талашсыз да булмаган, ләкин барыбер дуслык өстен чыккан.

Менә бервакыт Юлдыбай тирәсендә көн итүче башкорт старшинасы, үзенең кызын Актүбә тирәсендәге бер ыру башлыгы улына ярәшә. Бикәч кырында кияү ике елга хәтле кунак булу йоласы бар анда. Тик кияү җәйләвенә китәр чак кар эреп, ташу кузгалыр вакытка, хәмәл * аена туры килергә тиеш. Чөнки беренче бала атасы җәйләвендә туарга тиеш була. Башкортлар кияү белән Хәнифә атлы бу кызны зур кәрван белән озата баралар. Мондый юл өзек чакта, кәрванда күп санда атлар гына түгел, куй көтүләре дә булуын исәпкә алсаң, юл хәтәр була, билгеле. Ләкин үз далаларын яхшы белгән башкортлар аптырап калмыйлар, субүләр сыртларны үтә-үтә кәрванны даладан далага алып баралар. Озак, ләкин бер шиксез туп-туры алга баралар алар. Ике атналап баргач, бер җирдә ялга туктыйлар. Шунда Хәнифәнең кызы туа. Балага Сара дип исем кушалар. Шуннан бирле бу субүләр юл Хәнифә юлы дип атала башлый. Бала туган җирдә Сара җәйләве нигезләнә.

Канзафарның сүзе озын, вакыйгаларга бай булды. Ул зур кәрван оештырып, дөяләр-атларга йөк төяп, куйлар куып, кәрванны саклар өчен алайлар яллап, Таналык елгасыннан Хәнифә юлы буйлап Ирекле, Актүбәләр аша Сакмарның куәтле агымлы сайлыкларын узып, Зилаир елгаларын кичеп, Собханголга килеп җитүләрен, аннан инде кәрванны калдырып, малларны тапшырып, Өфегә, аннан Агыйдел, Чулман, Идел буйлап Тәтешкә килеп җитүләрен тәфсилләп сөйләп бирде.

Ул арада аштан соң каз итле тары бәлеше дә ашалды, ит белән бәрәңге дә чыгардылар.

— Бу нәмә бу? — дип әйтә куйды Мортаза. Ул кулына тавык йомыркасыннан кечерәк бер бөтен йомры бәрәңге тоткан иде. Канзафар да аның нәрсә икәнен белми икән. Табынында кунаклары искитәрлек ашамлык булуына гаять зур канәгатьлек белән Хәмзә бәрәңге турында горурланып берничә сүз әйтте:

— Бәрәңге бу. Аны бездә утыртырга кушалар. Күп кеше утыртып та карады, тик кайберләре агуланып үлгәнгә күрә, үстерергә курка башладылар.

— Агулымыни ул?

— Түгел. Белмичә сабагында үсә торган алмасын ашаучылар булган.Алмасы агулы икән. Ә бәрәңгесе җир астында үсә, тамырда. Шалкан кебек. Гәрәңкә кебек. Бәрәңгене җир алмасы дип тә әйтәләр, — Хәмзә аның агулы түгел икәнен күрсәткәндәй, кулы белән бер бәрәңге кисәген алды да кабып җибәрде. Аның артыннан башкалар да авыз иттеләр.

— Үзе тәмле соң! — диештеләр. Ерак кунаклар гына түгел, бәрәңгене беренче тапкыр татып караучы авылныкылар арасында да бар икән!

— Татлы тамыр, үстерергә кирәк моны, — диештеләр. Бу Хәмзәнең күңеленә бигрәк тә хуш килде.

— Язга бәрәңге сата калсаң, байтак табыш алып була лабаса!

Ашлар ашалып беткәч, чәй алдында әңгәмә тагын башкорт якларына әйләнеп кайтты.

*Хәмәл — март-апрель айлары.

— Сезнең якларда татарны чукындыра башлаганнан бирле анда һаман татарлар күчеп килә торалар. Араларында гаделләре дә, хәерсезләре дә очрап тора, кайбер юлбуарлар таларга, көтүләргә баскын ясарга да күп алмас. Урманнар булмаса да, авыллар сирәк урнашканга күрә, андый гамәл күп очракларда җәзасыз да кала.

— Урманнар булмагач, ул далаларда йорт-җирләрне нәрсәдән салалар соң?

— Йортларның күбесе агачтан түгел, саман кирпечтән өелә, түшәме шул ук түбә була. Җәйпәк түшәм өстенә камыш көлтәләре тезәләр яки камыштан кибәк ясап, аны балчык измәсе белән катнаштырып сылыйлар. Табигатьнең холкы да анда үзенчәлекле. Әле сәвер* аенда да кулләрдә боз була, кистереп ява торган бураннар була. Аларның берсе бишкунак бураны дип атала. Имеш, җылы кояшлы беркөнне биш гаилә, җиңел генә киенгән килеш, башка карьяга — авылга кунакка китәләр. Кире кайтканда котычкыч буран чыга. Алар барысы да катып үләләр. Шуннан бирле сәвер аенда була торган мондый буран бишкунак дип атала башлаган.

Ерак Уралдан ук килгән мондый кызыклы хәбәрләрне тыңлау авылда бикләнеп яткан кешеләр өчен күңелле яңалык булды.

Кунаклар таралышкач, Канзафар белән Хәмзә морза үзләре генә калдылар.

Канзафар кичекмәстән сәяхәтенең төп максатына керешәсе итте:

— Хәмзә дус, үзегезнең хәл-әхвәлләрегезне сорашырга һаман форсат җитми. Кызыгызны да күрә алганым юк. Барысы да элеккечә исән-иминнәрдер бит?

— Ходайның рәхмәте белән бар да элеккечә, Аллага шөкер! Кызым да исән-сау.

— Ялгышмасам, теге юлы бакчагызда бер яшь егет эшләп йөргәнен күргән идем. Хәзер башка малай. Егетне бүтән эшкә куйгансың, ахрысы?

— Куйган идем. Аннан да алырга туры килде әле.

— Нишләп алай? Миңа калса, төпле егеткә охшаган кебек иде ул.

Хәмзә морза Канзафарның Фәсхетдин турында болай төпченеп сорашуыннан хафага төште. Фәсхи белән кызы Заһидә арасындагы мөгамәлә турында нәрсә булса да ишетеп өлгермәгәндер бит? Ә Канзафар исә төп мәсьәләгә күчәр алдыннан фикер туплау өчен генә шундый вактөяк сорау биреп маташты.

— Инде килеп, безнең былтыр булган сөйләшүләргә әйләнеп кайтыйкмы дигән идем, Хәмзә дус?

— Сөйләшик соң, мин каршы түгел, — дип җавап бирде Хәмзә. Аның бу төксерәк җавабында кызын яучылаучы кода алдында азрак ялындыру әсәрмәте бар иде, шул ук вакытта бу әңгәмәдән үзенең ни көткәнен сиздермәскә дә тырышуы иде аның.

— Угылым Мортазаны менә хәзер үзең дә күрдең, тап-таза яшь егет. Безнең сәүдә эшендә маһирлыгы да бар. Ходай насыйп итеп, синең ярдәмеңдә Ырынбур-казакъ якларына икмәк озату чараларын күрсәк, кем белә, Мортаза белән казакълар ягына барып кайтырга да туры килүе бар.

Канзафарның бу сүзләренә исе китеп, үзенең монда гына түгел, ә бөтен тирә-якка атаклы бай сәүдәгәр булу мөмкинлеге ачыласын аңлап тәэсирләнгән Хәмзә, башына киткәнсыман, сүзсез калды.

Форсаттан файдаланырга кирәген сизеп, Канзафар сүзен дәвам итте:

— Безнең якларда, ягъни Акъяр-башкорт карьяларында ансыз булмый торган йола буенча, калымы да мул булыр. Ә бирнәсен инде үзегез карарсыз. Әгәр кызыңны Мортазага бирергә ризалыгың бар икән, без сөйләшкән сүзләр рас булыр.

— Кызым минем сүземнән чыкмас анысы, — дип җавап бирде Хәмзә.

— Алай да кызың үзе белән сөйләшсәң, ышанычлырак булыр иде, бәлки?

---

*Сәвер — май ае.

Бу сүзләр Хәмзәнең мин-минлегенә кагылды булса кирәк, ул горур кыяфәт белән:

— Мин атасы сүзеннән чыгардай бала тәрбияләмәдем, —диде.

— Ихтыярың, Хәмзә дус.

— Минем кызым, — Хәмзә кызыбрак китте, — шундый бала булыр — күзе күрмәс, колагы ишетмәс, теле сөйләшмәс булыр. Ул шундый килен булыр — аягы атламас, кулы сузылмас, күңеле бикле булыр.

Канзафар моның мәгънәсенә төшеним дип азапланырга талпынган арада, Хәмзә морза сүзләренең мәгънәсен ишекле-түрле йөри-йөри аңлатырга да керешге:

— Күзе күрмәс дигәнем — үзенә кирәкмәгән, кагылышлы булмаган һичнәрсә күзенә чалынмас дигән сүз. Колагы ишетмәс — үзенә әйткән сүзне тыңлавыннан ары кирәкмәгән, гайбәт сүзләрне колагына алмас, аларга саңгырау булыр. Теле сөйләмәс — аннан гайбәт сүзләр чыкмас, ызгыш-талаш кебек гадәтне белмәс. Аягы атламас — тиешсез җирләргә аяк басуын да килештермәс. Кулы эшләмәс — хәрәмгә кулы сузылмас, хәләл булмаган малга орынмас. Күңеле бикле — азгынлыкны имәс, үз хәләленнән гайре, кешегә дә, малга да нәфесе сузылмас...

## 14

Фәсхи, Хәмзә абзыйсы кибетеннән куып чыгаргач, нишләвен дә белмичә, урам буйлап каядыр атлады. Тирә-ягында ни барын абайламады, каршысына очраган кешеләрне күрмәде, барган юлының сикәлтәләрен сизмәде, тик аяклары гына, үзенә буйсынмастан, атладылар да атладылар. Абайламастан базар мәйданына килеп чыгып, андагы кешеләрнең һәрвакыттагыча гүләве колагына килеп кергәч кенә исенә килгәндәй булды.

Ярар, хуш, ул хәзер Хәмзә байның хезмәтчесе түгел. Ләкин яшәргә кирәк бит. Ул үзенә шөгыль табар табуын, тик менә картайган әтисе белән әнкәсен дә Хәмзә бай куып җибәрсә, эш харап. Шул фикер аның йөрәген әрнетеп куйды.

Бәлки, әле алай ук булмас та, Хәмзә бай ул сүзләрен ярсуы белән генә әйтеп салгандыр. Әткән-әнкәнне авылдан сөрәм, диделе? Сөрүен сөрә алмас анысы, тик үзендә тотмас, эшләреннән куып чыгарыр. Җитмәсә, үзләренең өйләре дә иске, сипләп куярга өлгерә алмады Фәсхи.

Хәзер Заһидә белән кешечә никахлашып өйләнешү турында уйларга да калмады. Андый бәхет Фәсхине читләтеп үтәсе булган, ана тәтемәслек хыял гына булган икән. Шундый төшенке уйлары белән ул бу олыста бердәнбер танышы, дусты дип әйтерлек Дмитрий торган йортка таба атлады. Аның вакыты да юктыр инде, хәзер авырулар кабул итә торган чагы.

Дмитрий йорты буенда шулай таптанып торганда капка ачылып китте һәм таныш атына утырган Дмитрий үзе килеп чыкты. Аның күрше авылга барырга чыгуы иде.

— О-о, Пасхи, вижу, настроение тагын начар синен. Айда, утыр, бирга барабыз, юлда поговорим, — дип, Дмитрий аны үзе белән алды.

Юлда Фәсхи Хәмзә белән булган хәлне дустына вагына-төягенә кадәр сөйләп бирде. Алар, татарчалы-урысчалы сөйләшсәләр дә, әйбәт аңлаштылар.

— Значит, син, как его, кайнатаннын камчысын татыдын, ә кызын не поцеловал даже, — дип көлде Дмитрий. Аннары җитди генә дәвам итте: — Карап торам, Пасхи, синен ярдам итарлек помощник калмаган. Мин сиңа помогу.

— Миңа хәзер беркем дә не поможет, — дип Фәсхи тирән көрсенеп куйды.

— Вот что, держи голову выше. Если Загида согласна, алып кит аны. Никах укыгыз и аннары прямо ко мне. Мин сизни в Богородское к моим родителям сам алып барам. Анда син эш табарсын.

Шулай итеп, Дмитрий төшенкелеккә бирелгән Фәсхинең күнелендә өмет чаткылары кабызды һәм аны Морзаларга озатып җибәрде.

Авылга кайткач та нинди дә булса гамәлгә, Заһидә белән аралашырга җай таба алмый интекте Фәсхи. Егерме елга якын бирелеп хезмәт иткән әти-әнисен дә Хәмзә бай куып чыгарган икән. Хәзер күп еллар ташландык булып торган өйләрен, аның тирәсен рәтләргә, тәртипкә китерергә кирәк иде. Әтисе бөтенләй югалып калган, һичнәрсәгә кулы ятмаслык халәттә иде. Фәсхи ялгызы тирән уйга баткан килеш, иренен кысып кына өй тирәсендә аркылыны буйга салып йөргән булды.

Ниһаять, Заһидәне яучыларга кодалар килгән дигән хәбәр кызның үзенә дә барып ирешкән. Үткән елда бу Ырынбур сәүдәгәре аны улына кодаларга килгән икән дигән хәбәргә кыз артык илтифат итмәгән иде. Килсәләр ни, моннан алда да яучылар килеләр иде ич. Хәмзә бай һәрвакыт килүчеләрнең кем икәнен, кияү булачак кешенең кем, нинди булуын әйтеп бирә яки алар белән таныштыра, кызының ризалыгын сорый. Кыскасы, яучыларга җавапны Заһидәнең үзеннән әйттерә торган иде, ә кызның җавабы бер генә булды: юк!

Бу кунаклар килгәнгә бер көн үтте, ике көн. Яучылар һаман аларда кунак булып яталар. Моның өстенә, әтисе әнкәсенә Заһидәгә күз-колак булырга, аны күздән ычкындырмаска кушкан. Туйга әзерләнергә боерган. Туй хәстәренә керешеп, тегене-моны әзерләргә әмер яудыра башлаган. Ә Заһидә белән үзе бернәрсә сөйләшми. Әнкәсенә дә өзеп сүз әйткәне юк. Элек тә бернинди хокукы булмаган әнкәсе хәзер дә тәгаен белми иде әле. Белсә, әйтер иде. Заһидәнең күңелен ниндидер билгесезлек биләде.

Ярый әле, аның якты йолдызы, сихри рәхәт дөньяга әйди белүче Фәсхетдине бар. Менә ул килер дә Заһидәнең барлык шикләрен юкка чыгарыр.

Заһидә шундый ярым хәсрәтле, ярым хыялый халәтендә уйланып утырган чакта аның янына күрше кызы Фәридә килеп керде. Ул шаян күңелле, авырлыкларга баш бирмәүчән зат буларак, башкаларга да төшенкелеккә ирек бирмәскә сәләтле кыз иде.

— Ай Аллам, нигә бик моңсу күренәсең, Заһидә апа? — дип тезеп китте ул килеп керү белән. — Әллә кияүгә киту дөньядан аерылу дип беләсеңме ул кадәр?

— Әллә ни булды миңа, Фәридә, һаман эчем поша, күңелем урынында түгел, — дип зарланды Заһидә.

— Әй, апакаем, булыр да. Күңелең сизәдер. Ник дисәң, атаң Фәсхетдин абыйны камчы белән ярган, эшеннән куып чыгарган икән бит.

— Ничек? — дип коелып төште Заһидә.

— Шулай менә. Шомгатыга баргач, Фәсхетдиннең бер урыс духтыры белән дуслашып йөрүен белгән. Мин каферләрне эштә тотмыйм, дип, камчы белән ярган да эшеннән куып чыгарган.

— Йа хода! Фәсхетдин хәзер кайда?

— Әллә син абайламыйча калдыңмы, ахирәт? Шомгатыдан кайту белән Фәсхетдиннең әти-әнисен дә куып чыгарды ич әткәң!

— Фәсхетдин кайда хәзер? — дип кабатлады Заһидә, төсе үзгәрүен сизмичә.

— Кайда булсын, авылга кайтты. Хәмзә абзый аны солдатка җибәрәм, дип тә әйтә икән.

— Әй, Фәридә, белсәң икән, нинди хәсрәтле хәбәр әйтүеңне! Малакачым, үтә минем бер гозеремне: күрештер мине Фәсхетдин белән!

Фәридә хатын-кызда булган хәйләлегеен җигеп, төшенкелеккә бирелгән Заһидәне тынычландырырга тырышты, ничек тә Фәсхетдин белән сөйләшергә, күрше апасының теләгән Фәсхетдингә җиткерергә булды.

Әлегә кадәр үз теләгенә ирешми калмаган Заһидә:

— Йа хода! Мине атам күрәләтә торып әллә кая, күз күрмәгән, колак ишетмәгән башкорт далаларына җибәрергә исәп тота икән ич! Туган йортымнан, таныш иген басуларыннан, яраткан урманымнан аерып,

очы-кырые күренмәгән япанга, күз әйләнмәс далаларга чыгарып җибәрмәкче. Йа, раббем, синең каршыңда нинди гөнаһларым бар соң минем? Бу бәладән котылу юлын күрсәт миңа, — дип ялварды ул.

Аннан ары, азрак тынычлана төшкәч, үз башына төшәчәк бу афәттән котылу юлларын эзләп уйланды. Аңа иң әүвәл, билгеле, Фәсхетдин белән очрашырга, аның белән киңәшергә кирәк иде. Кыз бала үзе генә ни эшли ала соң? Кыз бала ул, нинди генә чая булмасын, читлектәге кош. Аның ата-ана сүзеннән, теләгеннән, әмереннән читкә тайпылырга хакы юк. Татар хатыннарының язмышы шулай, күрәсең. Әнә бит, Якуб абыйсының хатыны Нажия җиңгәсе дә көне-төне терлек-туар арасыннан, сыерлар корсагы астыннан чыкканы юк, һаман сыер җилененә ябышып яшәгән көне. Ярый әле, бердәнбер кыз буларак, Заһидәне мондый кара эшләргә җәлеп итмәделәр. Теләсә — булышты, теләмәсә — үз җаен карый бирде. Әгәр башкорт далаларына барып чыгарга мәҗбүр итсәләр, гомереңдә үз кулың белән күрмәгән шөгыльгә — бия саварга, аннан кымыз ясарга кушсалар, нишләрсең? Атка атланып йөрү генә кызык. Аларны карый башласаң, йа раббем, үзең сакла!

Шулай үз-үзенә бикләнеп уйлана торгач, кул кушырып утырудан эш чыкмас, берәр нәрсә кылырга, җөрьәт итәргә кирәк дигән нәтиҗәгә килде.

Мунча ягу мәшәкатьләре һәрвакыт Нажия җиңгәсенә төшә торган иде. Заһидә үзе теләгән чакларда гына аңа ярдәм иткәли иде. Нажия җиңгәсенең чирләп торуыннан файдаланып, бүген мунча өлгертүнең бөтен мәшәкатен ул үз өстенә алды. Тергезеп җибәргәч тә, ташлар тирәсенә тезелгән иске казанга, чүлмәкләргә су ташыды. Төтенгә буыла-буыла суны бушата, утын өсти һәм тагын суга йөгерә торды. Юыныр өчен бакча артындагы инештән су ташыганда ул кемне дә булса очратуга өмет итмәде, һаман эшендә булды. Менә хәтсез вакыттан соң ишек алдында кешнәүче Алмачуарның тавышын ишетте. Аны кем алып чыккан икән, дип караса, чит бер егет атланганга риза булмыйча, атының чыгымлавын күрде. Абыйсы Якуб та үз атына атланып тора икән. Ат өстендә Урал ягы кунагы Мортаза үзе иде. Болай да бу егеткә дошманлык хисе белән янып йөрүче кыз үзенең Алмачуарына атлануын да күргәч, бөтенләй чыгырыннан чыкты. Ул тиз генә атының тезгененнән барып тотты:

— Төш минем атымнан! Минем ризалыктан башка атланырга хакың юк.

Хуҗасын күрү белән Алмачуар әкрен генә кешнәп куйды.

— Был һылыу минем бисәм буласакмы? — дип сорады Мортаза Заһидәнең абыйсы Якубтан. Алар каядыр барырга җыенганга охшаган иде.

Якуб:

— Сеңлем, син ачуланма. Бу — әткәй әмере. “Заһидәнең Алмачуарын буйсындыра алсаң, кызымны да иялэштерә алырсың”, — диде. Шуңа күрә Мортаза атыңа атланды, — дип, сеңлесен тынычландырырга тырышты.

Заһидә Алмачуары өстендәге егеткә җирәнеп карады да кинәт кычкырып җибәрде:

— Алмачуар, һоп-һоп!

Мортаза кинәт кушаяклап сикергән ат өстеннән аның арт саны аша җиргә мәтәлеп төште. Кыз аны мыскыллап кычкырып көлде дә, атын иркәли-иркәли, аранына алып кереп китте. Теге кысык күзле, җәйпәк борынлы егеткә атларының берсенә атланудан гайре чара калмады. Алар чыгып киткәнче Заһидә Алмачуары белән булашты.

Заһидә, бераз тынычлангач, чишмә суына бару сылтавы белән Фәридәне дә ияртте. Ике кыз парлашып, көянтә-чиләкләрен күтәреп, иркенләп сөйләшә-сөйләшә бардылар. Фәридә Фәсхетдин белән сөйләшеп өлгергән икән инде. Көтү кергән арада Фәсхинең Заһидәне чишмә буенда көтәчәген әйтте.

Заһидә, мунчасы өлгергәч тә, нәрсәгәдер вакытын сузды, уйланды, бар эшне дә юк итеп, мунча тирәсендә кайнашты. Ниһаять, өйгә кичке чәйгә дип, янә чишмәгә суга кузгалды. Алар янә Фәридә белән кит-

теләр.Көтү кергән арада чишмәгә суга баручылар аз булганга күрә, бу вакыт алар өчен иң кулай чак иде.

Фәсхи чишмә буенда ботакларын суга игән шомырт куагы төбендә Заһидәне көтеп утыра иде инде.

Заһидә — бай кызы. Борынгы ак сөяк морза нәселеннән. Хәмзәнең сәүдәгәрлеге дә үзенең җирләреннән җыеп алган икмәк сатудан башланган кәсеп. Аның ата-бабалары кайдадыр Чулман буйларында зур җәйләүләр тоткан кешеләр булганын да ишеткәне бар иде Фәсхетдиннең. Дөрес булса, тамырлары Туктамыш ханга барып тоташа, имеш. Заһидә әнә шундый затлы нәселдән. Ә Фәсхи аңа бөтен дөньясын онытып гашыйк булды. Хәзер аларны ни көтә? Әгәр Заһидә саубуллашу-хушлашу өчен генә чакырган булса? Әллә дә балачак дусты, бергә уйнап үскән малай белән, ә бәлки үзенең балачагы, үсмер чагы белән саубуллашуыдыр?... Кем белә, ә бәлки алай да түгелдер...

Фәсхинең өмет чаткылары бер сүнеп, бер кабынып торган арада Заһидә күренде. Ул килеп җиту белән, теге чакта аюдан котылгач сарылган кебек, Фәсхинең күкрәгенә капланды, тавышсыз гына елый башлады. Вакыт-вакыт сулкылдап куйды.

Егетнең шикләнүләре шунда ук юкка чыкты. Ул сөеклесенең аркасыннан, чәч толымнарыннан сыйпады. Ләкин иркәләнешеп торырга урыны да, вакыты да ул түгел иде. Чиләкләрен чыңгылдатып, аска таба Фәридә төшеп килә иде. Бу — суга килүчеләр булуын, очрашуны өзәргә кирәклеген аңлату булды.

— Инеш артындагы имән буенда көт мине. Озак чыкмый торсам да, көт. Ничек тә чыгарга тырышырмын, — дип пышылдады Заһидә һәм чишмәдән су тутырырга иелде.

## 15

Караңгы төшүгә Фәсхи сөйләшенгән имән янында тора иде инде. Озак көтте ул Заһидәсен, бөтен сабырлыгын җыеп көтте. Вакыт исәбен дә белмәде, күпме торганын да чамаламаслык хәлгә килде. Заһидә инеш аша түгел, ә урман ягыннан килеп чыкты. Җиңел генә Фәсхигә кагылды да:

— Әйдә, киттек! — диде.

Аптырап калган Фәсхи аның ниятен аңламады:

— Кая?

— Әйдә, калганын аннары сөйләшербез! — дип пышылдады кыз, каршы дәшәргә урын калдырмыйча. Фәсхине житәкләгән килеш житез адымнар белән урманга кереп китте. Алар озакламый бер аланга килеп чыктылар. Анда агачка бәйләнгән иярле ике ат тора иде. Хуҗасын сизеп, Алмачуар әкрен генә кешнәп куйды. Артык тавыш чыгарырга ярамаганны гүя ул да аңлый иде.

— Йә, хәзер әйт, кая юл тотабыз?

— Моннан тизрәк китәргә кирәк безгә. Аннан соң — никах, никахтан соң безне беркем дә аерып ала алмас!

Заһидәнең ниятен аңлап алган Фәсхи, тәвәккәлләп:

— Ялчеккә, Миклуша дәдәйгә барабыз, — диде. — Анда безне эзләргә берсенең дә уена кермәс. Ялчектән ерак түгел Батыр авылы бар. Аның мулласы безгә никах укыса, без гомергә бергә булырбыз, җанашым!

— Бисмилләһир-рахман ир-рахим, хәерле сәгатьтә, ярабби! — дип, алар атларына атландылар да алга омтылдылар.

Авылдан ераклашкач та атларын кудылар да кудылар. Таң беленә башлагач кына бер уйсулыкта хәл алырга тукталдылар. Вакытында каты һәм кискен була белгән Заһидә хәзер җебеп төште. Фәсхинең күкрәгенә капланды да үксеп елап җибәрде. Кызны назлап-иркәләп тә туктатырлык түгел иде. Ниһаять, үткән берничә көн арада үз башыннан кичергәннәрен

күз яше аша чыгарып бераз жиңеләйгәч, Фәсхигә башкорт киявен күрүен, аны Алмачуары өстеннән егып төшерүен сөйләп алды. Атларның берсе алар аты икәнен дә әйтте.

— Якыным минем, канатым... — дип, Фәсхи Заһидәсен иркәләде, — Батыр авылы мулласыннан никах укыту белән Идел буена, минем дустым Дмитрийнең әти-әнисе авылына китәрбез. Алар безне сыендырырлар. Дмитрий шулай дигән иде.

Заһидә ризалыгын белдереп башын гына какты.

— Матурым, мин сиңа күптән инде чулпылар алган идем. Һаман сиңа бүләк итә алмый йөрдем. Очраша алмавыбызга да күп вакыт узды бит инде. Кил әле, кадерлем, үремнәреңә үзем тагыйм әле.

Шулай бер-берсен назлап, алар байтак вакыт кинәнделәр, ял иттеләр. Атлары да утлап, ял итеп алгач, тагын юлга кузгалырга булдылар. Якты төшеп житкәнче, көтү куганчы барып житәргә кирәк иде Ялчеккә.

Миклуша дәдәй, алар килеп кергәнгә аптырап калса да, үзен тиз кулга алды:

— Аванни! — дип сәламләде. Тиз генә ашарга-эчәргә әзерләтте. Яшьләрнең йончыганын күреп, аннан-моннан гына сорашкандай итеп утырды. Батыр авылына юл тотуларын төшенде. Бу яшьләрнең, качып китеп, никах укытасылары килүен аңлау алай катлаулы нәрсә түгел иде. Миклуша хатынына чуашчалап берничә сүз әйтте:

— Болар тикмәгә генә йөрмиләр. Атасы кызны башкорт баена ярәшергә уйлавын ишеткән идем, шуннан качып килүләре, ахрысы. Тиз генә Иванайны чакыр!

Иванай килеп кергәч, аны ишек алдына, аннан арт якка алып чыкты да тизлек белән Хәмзә байга чабарга кушты. Атын арткы ишектән алып чыгып иярләп бирде, Фәсхи белән Заһидәнең мондалыгын, кичекмәстән килеп житүләре кирәклеген хәбәр итәргә боерды.

Яңадан кереп, берни дә сизенмәгән яшьләргә ял итеп алырга тәкъдим итте. Кызны хатыннар ягына почмакка, ә Фәсхигә сәндерәгә ятарга кушты:

— Атларга солы салдым, сес тә ял итегес, — дип тынычландырды ул аларны.

Сәндерәгә менеп, ярыкларындагы мыжлаган тараканнарга карап ята торгач, Фәсхи йоклап китүен дә сизмәде.

Сискәнеп уянып киткәндә көн шактый күтәрелгән иде инде. Урыннан торганда башы түшәмгә бәрелүгә дә игътибар итмәстән, ул сикереп төште һәм ишек алдына атылып чыкты. Чыннан да, кояш шактый күтәрелгән иде инде. Өй тирәсендә беркем дә күренмәде. Аранга күз салса, анда атлар да юк иде.

Фәсхинең эче жу-у итеп китте. Хыянәт! Егет тизрәк Заһидәне уятыр өчен өйгә атылды. Кыз башта берни аңламый торды. Атлар югын ишеткәч, ул да ишек алдына омтылды.

Ул арада бакча башыннан ашыкмыйча гына Миклуша дәдәйнең кайтып килүе күренде.

— Тордыгыс тамыни, кунаклар? — диде ул елмаеп.

— Атлар кайда, дәдәй? — дип каршы алды аны Фәсхи.

— Атларыгызны су эчәргә чипәртем, кәсер кайтып читәрләр, сес юыныгыс, ашап-эчеп алырсыс, ашыкмагыс, — диде Миклуша дәдәй тыныч кына һәм өенә юнәлде.

Фәсхинең шиге арткannан-арта барды. Ул Миклуша дәдәй кайткан якка атларын эзләргә йөгерде. Анда Иске Бола елгасы акканын белә иде ул.

Фәсхи китеп югалуга, дәдәй өйдән килеп чыкты да Заһидәне тотып алды. Аның ай-ваена карамыйчан, сөйрәп келәткә кертте һәм тыштан бозау кадәр йозак белән бикләп куйды. Үзе тагын юкка чыкты. Кыз күпме кычкырса да, аңа жавап бирүче булмады. Бу чуаш карты качып торуны кулай күрде бугай, чөнки Фәсхи белән очраша калса, яман булачагын белә иде ул. Шул ук вакытта, Хәмзә килеп житкәнче яшьләрне тоткарлап торырга да кирәк иде.

Атларын таба алмагач, гаҗиз булган Фәсхи йөгереп тагын кайтып керде.

— Заһидә! Заһидә!

— Фәсхи! Мин монда! Мине Миклуша бикләде! — дип, келәт ишеген эчтән дөбердәтергә кереште кыз.

Хәлнең өметсез икәне, дәдәйнең аларны алдавы ап-ачык иде. Нишләргә белмәгән Фәсхи беравык уйлап торды да келәт чатындагы бура башларына тотынып өскә үрмәләде. Салам түбәне ачты, астына түшәлгән кабыкны каерып ташлады һәм келәт эченә сикерде.

— Менә синең Миклуша дәдән. Дәдә түгел ул, сатлык җан! —дип Заһидә гаҗизлегеннән Фәсхинең яңагына чабып җибәрде.

— Хәзер сөйләнеп торырга вакыт юк, әйдә, тизрәк чыгып ычкыныйк моннан! — дип, Фәсхи кызны түбәдәге тишеккә әйдәде.

Көч-хәл белән келәттән чыгып, алар бакча буйлап елгага таба йөгерделәр. Авылдан исән-сау котылуларына шатланып, урман кырыйлап кына Батыр авылына ашыктылар.

## 16

Иванай Хәмзәләргә килеп җиткәндә, кызның һәм ике атның юкка чыкканын анда беләләр иде инде. Фәсхетдиннең өенә барып, аның да өйдә юклыгын ачыклагач, аларның төнлә качып китүләренә шик калмады.

Төрле якка атлар чаптырды Хәмзә. Беренче нәүбәттә, билгеле, Шомгатыга, Габделхәйгә улы Якубны җибәрде. Тегесе ул вакытта Хәмзәдән киткән, башка сәүдәгәр кибетендә сату итә иде. Ә Хәмзә кибете вакытлыча ябык торган чак булганга, Фәсхине аннан да, Габделхәй тирәсеннән дә эзләргә кушылды.

Җен ачулары чыкты Хәмзәнең. Ул бөтенесен аякка бастырды. Таякның юан башы хатынына эләкте. Ырынбур сәүдәгәре белән туганлашып зур сәүдә ачып җибәрергә торганда гына шундый хурлыкка кал әле. Ачуланмый түгел, үз кабыгыңнан сикереп чыгарсың!

Камчы белән ярып ташланган хатыны үкси-үкси елый иде. Улы Якубка да эләкми калмады. Ләкин аның җавабы кыска булды:

— Алар төнлә качкан. Мин кыз кешене кунарга яныма сала алмыйм ич инде! Минем үз хатыным бар. Әнә, Мортазаны атыннан егып төшергәндә нинди усал карады ул миңа, тез буыннарым калтырады.

Әгәр Хәмзә улына кул күтәрсә, Якуб та җавапсыз калмас иде, мөгаен.

Аның өстенә, кунакларның да бер атын урлап качканнар бит, җирбитләр!

Канзафар да дөньяда булмаган бу искиткеч хәлдән югалып калган иде. Хәмзә белән туганлашу үзенә зур файда китерәчәк иде бит! Ниятләре эшкә ашмавы кызганыч хәл, әлбәттә. Ләкин нихәл итәсең?

Әйтергә кирәк, Мортазаның башкорт илендә ярәшкән кызы бар иде инде. Атасы белән килешенгән, ягъни кызның колагы тешләнгән иде. Калымга кыз атасына бер дөя дә биргәннәр иде. Туй алдыннан бер көтү куй түләргә генә калган иде. Ләкин, кызга унике яшь тулмыйча, туй уздыруны кичектереп торырга сөйләшенгән иде. Әгәр бу татар кызын алып китсәләр, аларга ул кадәр калым түләргә дә кирәкми, аның өстенә, гаять табыш вәгъдә иткән икмәк белән сәүдәне җайлаштыру да өметле кәсеп булачак иде. Ә ярәшелгән башкорт кызын тагын бер елдан икенче хатынлыкка алсалар, барысы да Канзафар уйлаганча барып чыгачак иде. Ләкин бу татар кызы аларның бөтен өметләрен җимереп ташлады, качып китте. Хәзер аны яучылаудан өмет өзәргә, бу уйдан туктап, кайтып китәргә генә кала. Мортазаның кызга кызыкмавын күреп торган Канзафарга бу фикергә килү җиңелрәк булды.

— Кыз матур, атай, тик ул минә ошамай, үз егете менән булһыннар, — дип, Мортаза атасының күнелен кайту ягына күндерде.

Кунакларының мондый ниятләрен белә калса, Хәмзә дә шул хәтле дуламас иде. Тик бу карарга килүләрен кунаклар әлегә сиздермәделәр. Вакыйганың ни белән бетәсе кызыксындырганга, сабыр итәргә булдылар.

Менә шулай Хәмзәнең яшен яшьнәтеп йөргән чагында Миклушадан хәбәр килеп житте. Кызын тотып алып кайтырга Хәмзә үзе җыенды. Кызык күрер өчен аңа Мортаза да иярде. Авыл яшьләреннән староста Җамалетдинның улы Шиһабетдин алынды. Өчәүләп атка атландылар да Иванай артыннан Ялчеккә чаптылар. Кайтып житсә Якубка да алар артыннан барырга кушылды.

Ике-өч сәгать үтмәде, жан-фәрманга чабып, алар Миклушаларга килеп життеләр. Миклуша аларны каршы алуын алды, ләкин яшьләрнең кайда булуларын әйтә алмады. Яшереп куйган жиреннән атларын гына алып кайтып тоттырды. Үзенең ничек атларны яшерүен, Заһидәне келәткә бикләп куюын сөйләп бирде. Аннары түбәдәге тишеккә күрсәтте:

— Пүре кепек, түпәне тишеп качканнар...

— Абау, бер-берһен яратусы кешеәрдер. Мин аларны кисерер инем, — дип сокланды Мортаза.

— Һе, кияү имеш! — дип сукранды Хәмзә киная белән һәм хужага борылды:

— Җәяүләп алар кая китә алырлар?

— Пелмим тә инде, Хәмсә апсый. Алар никах укытып өлгермәгән пит әле...

— Моннан муллалы авыл еракмы?

— Патыр авылы. Егерме чакрым. Пасхи пелә ул авылны.

Качкыннарны куучылар атларын алмаштырып, Миклуша белән Иванайны да ияртеп Батыр авылына юнәлделәр.

Бу вакытта гашыйкларның, тамаклары ач булуга карамастан, арганнарын да сизмичә, шул авылга ашыгулары иде. Баштарак артка, як-якка карый-карый сакланып барсалар да, бара-бара шикләре югалды шикелле. Авылның мәчет манарасы күренүгә шундый шатландылар ки, гүя бөтен жиһанда кайгы-җәнҗаллар, гаделсезлекләр бөтенләй юк, бары тик алар бәхете генә бар, алар өчен генә кояш нур сибә иде.

Ә Хәмзәнекеләр артларыннан бастырып куа иде инде. Куучыларны алар якынлашкач кына күреп алдылар. Кая да булса йөгерергә яки посып калырга да соң иде. Егет белән кыз юл уртасында бер-берсе белән житәкләшкән килеш катып калдылар.

Кушаяклап чаптырып килгән мәлгә Хәмзә Фәсхигә камчысы белән берне сыдырды. Тагын кизәнгән арада, ачы кычкырып, араларына Заһидә килеп керде:

— Әткәй, тиясе булма! — Ләкин бер күтәрелгән камчы бар хәлгә Заһидәнең үзенә килеп эләкте. Ул куырылып төште. Шул мизгелдә Фәсхи камчының очын кулына эләктереп алды да бөтен көченә үзенә таба йолкыды. Беләзегенә киелгән каеш элмәккә ияреп, камчы артыннан Хәмзә дә атыннан егылып төште.

— Заһидә, атлан тизрәк, кач, мин аны тоткарлыйм! — дип кычкырды Фәсхи.

— Юк, син... — дип, Заһидә әүмәкләшкән атасы белән Фәсхи арасына ташланды.

Ул арада Шиһабетдин белән Иванай Фәсхине бөгәрләп жиргә салдылар һәм кулларын бәйләп тә куйдылар. Кабат Фәсхигә ташлана башлаган Хәмзәне Мортаза килеп тотты:

— Һабыр-һабыр, атай, ярар имәс.

Барысы да, хәлләре бетеп, авыр сулый-сулый, бермәл бер-берсенә карашып тордылар.

— Син ник катып калдың? Синең дә камчың бар ич! — дип, Заһидә Мортазага борылды.

— Һылыу, мин һинә һокланам. Һин арысландай һугыштың. — Мортаза чыннан да кызның кыюлыгына, житезлегенә гажәпләнде. — Мен атына, арыганһың, мин йәйәү кайтаем, — дип тәкъдим итте ул Заһидәгә.

Ләкин Хәмзә аяусыз иде. Шулай да Алмачуарның тезгенен үз ияренә таккач риза булды ул моңа. Фәсхине, куллары бәйләнгән килеш, Шиһабетдин артына икенче кеше итеп атландырдылар.

Кәрван атлатып кына кайтыр юлга төште. Берсе дә сүз дәшмәде. Заһидәнең сыны каткан, ул нәрсә дә булса әйтергә, хәтта еларга да булдыра алмый иде. Фәсхи исә йөрәге көюенә, хурлыкны күтәрә алмаслык гарьлегенә һәм үзенең көчсезлегенә сызланып барды. Вакыт-вакыт ул ыңгырашып куйгалады. Сөмсез җанлы Шиһабетдин, чөй өстенә тукмак буларак, аны үртәргә керешге:

— Нәрсә, Фәсхетдин, кыз ычкынды диген, ә? Хәмзә абзыйның байлыгы да фью-ю, сәнәк арасыннан җил очкан кебек, сызып кына калды алайса?

Фәсхи дәшмәде. Тегесе аның саен кыюлана төште:

— Бикәч куенына керү урынына сине солдатка озатырлар инде. Сөйгәнеңне Мортазага биреп җибәрерләр...

— Замолчи, сволочь! Бу сүзләрең өчен син бер җавап бирерсең, — дип кычкырды Фәсхи һәм җаен китереп, башы белән тегенең янбашына төртте. Тегесе атыннан очып төшә язды һәм куркуыннан кычкырып җибәрде:

— Хәмзә абзый, мин аның белән кайтмыйм, ул сугыша!

Бу арада арба җиккән Якуб та якынлашып килә иде инде. Арбага күчеп утыргач та Фәсхи җаен туры китереп, Миклушага эндәште:

— Дәдәй, мин сине бу хәтле сатлык җан булырсың дип уйламаган идем. Вөҗданың таламасмы үзеңне?

— Ни пит, Пасхи, алай ярамас пит, кысны урлау ясык пула... — дип буталды чуаш карты.

— Кара аны, картлык көнендә җавабын бирергә туры килмәсен.

— Тынычлан, Фәсхетдин, артык үртәлмә әле, — дип тынычландырырга тырышты аны Якуб. — Мин бөтенләй өметсез үк димәс идем әле сезнең хәлегезне.

Миклушаларга кайтып атларны ял иттерделәр, үзләре дә ашап-эчтеләр һәм яңадан кайтыр якка кузгалдылар.

Кайтып керү белән Фәсхетдинне келәткә бикләп куйдылар. Хәмзә Заһидәне кәҗәнкәдән чыгармаска кушты. Шунда ук старостага хәбәр итте.

Ул арада Мортаза белән Канзафар арасында сүз булды. Егет үзенең күргәннәрен сөйләп бирде. Ул урманнар, сулар, чәчкән иген кырлары белән чикләнгән мондагы мохитне башта ук күңеле белән өнәмәгән иде. Монда аны, аны гына түгел, башкаларны да кысалар, чиклиләр төсле тоелды. Заһидә белән Фәсхетдингә карата бу шулай булып чыкты да. Дала кешесенең иркәле күңеле урман арасына сыймас була икән шул.

Хәмзә камчысын күтәргәч тә, бу егет белән кызның бер-берсен яклауларын сокланып күз алдына китерде Мортаза. Ул аларга бәхет теләде, атасын да шул фикергә кушылырга әйдәде. Изге теләкләрен теләп, юлга кузгалырга өндәде.

Ләкин Канзафарның фикере башкачарак иде. Дала кешесе түгел иде шул ул, шуңа күрә Мортазаны аңламады.

Ниһаять, Канзафар китәргә җыенгач, Хәмзә белән саубуллашасы итте. Болай да кызын буйсындыра алмавына, атасының теләгенә каршы килеп, тирә-якта ишетелмәгән, адәм баласының башына да килмәслек юләрлеккә баруына, шул йолкыш Фәсхи белән качарга җыенуына ачуы чигенә житкән Хәмзәгә бу хәбәр башына күсәк белән суккандай булды. Ул югалып калды. Акны-караны аермас хәлгә килде. Канзафарга кайтарып сүз дәшә алмады. Канзафар исә, аның бәгырен телүен дәвам итте:

— Синең кызың нинди әле? Күзе күрмәс, колагы ишетмәс, теле сөйләшмәс, аягы атламас, кулы эшләмәс, күңеле ябык, диденме? —

Хәмзәнең үз сүзләрен кабатлады ул мәсхәрә белән. — Бәс, шулай икән, андый кызың үзенә булсын, мина андый килен дә, улыма андый бичә дә кирәк имәс.

Хәмзәнең җавабы юк иде. Башын иеп, ул капкадан килеп керүче Җамалетдин старостага таба атлады. Хәзер аның бөтен ачуы Фәсхетдиннән үч алса гына басылса басылыр инде.

Старостаны авыл телендә Җамай дип кенә йөртәләр иде. Хәмзә дә:

— Җамай, бездә ниләр булганын беләсең инде, — дип сүз башлады. Бу эт малае Фәсхине кулга алырга, төрмәдә черетергә кирәк.

— Тукта әле, Хәмзә абзый, син бик кызгансың бугай. Салкын кан белән хәл итәргә кирәк монда. Төрмәгә утыртыр өчен аның гаебе булырга тиеш.

— Минем ниятләремне чәлпәрәмә китереп, кызымны котыртып алып китүеннән, бөтен кеше каршында хур итүеннән артыграк гаеп бармы?

— Буй җиткән кызны урлап, башлы-күзле булу бер аннан гына башланмаган бит. Кыз риза булып, үзе егет белән киткән икән, моның гаебе юк.

Староста кыз урлау сәбәбе белән булмаса, башка сәбәпләр табып булса да, Фәсхине төрмәгә озата алырлык җай карар иде анысы, тик олыс түрәләре каршында аннары уңайсыз хәлдә калуың бар. Аның авылында җинаять булган, староста үз авылында тәртип урнаштыра алмый дигән яманаты чыгачак аның, шуңа күрә бу вакыйганы зурга җибәрмәү ягында иде ул.

— Мин сине законнарны белә торган кеше дип йөри илем, — дип, Хәмзә һаман аңа бәйләнде, — ат урлау да гаеп түгелме?

— Кем атын урлаган соң ул?

— Ике атны. Берсе Алмачуар, икенчесе Ырынбур кунагының аты.

— Ул атлар өендә бит инде хәзер.

— Алайса, олыстан урәтникны үзем чакыртам, — диде Хәмзә, ачуыннан үзен кая куярга белмичә. — Мин аны үзем төрмәгә утыртам!

Хәмзә чыннан да урәтниккә кеше җибәртте. Карак тотылды, килеп алып китсеннәр, дип әйтергә кушты.

Бу әңгәмәне Якуб белән Мортаза да ишетеп тордылар.

— Егет кызганыч, — дип куйды Мортаза һәм старостага эндәште. — Ул атны урламады. Мин аны үзем биреп тордым.

Бу соңгы сүзләр урамнан узып баручыларга ачык капка аркылы ишетелеп калды...

## 17

Быелгы ел Мостафалар өчен уңайлы булды. Ике иманаы да чәчеп үстергәч, уңыш искитәрлек үк булмаса да, элекке елларга караганда артыграк иде. Элек бер иманага егерме биш-егерме җиде пот ала торган булса, быел Мостафа чама белән алтмыш биш поттан артык уңыш алды. Күршесе Гайнулла абзасы белән Гайнижамал абыстасының да җирләрен беррәттән эшкәрттеләр. Язмыш бер ягы белән баш түбәсенә китереп сукса, икенче яктан иркенрәк сулыш алырга да мөмкинлек бирә икән.

Озын кышкы кичләрдә Гайнулла абзый белән Мостафа кайсы җиргә нәрсә чәчәргә, ничек сукаларга, тырмаларга кирәген кабат-кабат киңәштеләр, сөйләштеләр.

Яз житкәч, Мостафаның атлы кешеләргә урман кисешүе бәрабәренә атларын алып торып, сукаладылар. Чәчәр алдыннан кырга барысы да килделәр. Гайнулла абзый тубалын көйләде. Мостафа агач тешле тырмасын тагын бер кат карап чыкты. Галимҗан чыбык-чабык җыйды, учак тергезергә булышты. Гайнижамал абыстай өйдән алып килгән ярмадан ботка пешерергә куйды, йомыркаларын хәстәрләде. Кечкенә Фатиха аңа ярдәм итеп, дөресрәге, комачаулап йөрде.

Беренче чиратта каты итеп йомыркаларны пешерделәр. Тубалга бодай тутыргач, арасына пешкән йомыркаларны яшерделәр.

Дога кылып, бодайны чәчәргә керештеләр. Тубал артыннан Фатиха белән Галимҗан бөртекләр белән бергә чәчелгән йомыркаларны җыеп йөрделәр. Алар җыелып беткәч, Мостафа җирне тырмаларга, шулай итеп бөртекләрне җиргә күмәргә кереште. Аннары Гайнулланы — Мостафа, Мостафаны Галимҗан алмаштырды. Шулай кул алмаш бергәләп, гөрләшә-гөрләшә, җирне чәчеп-тырмалап бетерделәр. Соңыннан җир башына кадәр Мостафа буш тубалын, теләкләр тели-тели, тәгәрәтеп чыкты. Уңыш мул булсын, янәсе.

Аннары җыйнаулашып җир башына утырдылар һәм тары боткасын тәмләп ашадылар. Менә йоланың иң кирәкле мизгеле килеп җитте. Фатиханың күзләрен йомдырып, пешкән йомыркаларның берсен алдырдылар һәм чәчкән җиргә кертеп җибәрделәр. Күзен йомып, ул җир буйлап барды да йомшак җиргә йомырканы күмеп куйды. Бу вакытта табын янындагылар дога кылып утырдылар. Күмелгән йомырка җир иясенә багышланды. Җир иясе мул уңыш үстерешергә, корылыктан, боз сугудан, кыраудан сакларга тиеш иде. Чәчкән икмәк тишелеп чыкканчы, үсеп өлгергәнче, аны урып-җыеп алып кайтканчы ниләр генә булып бетмәскә мөмкин?

Менә хәзер тормыш җайланып килә. Әнә Галимҗан кул арасына керә башлады. Фатиха да әкренләп өйрәнә башлар.

Шаһидәсенең генә булмавы әледән-әле йөрәген тырнап куя Мостафаның. Тик үлгән артыннан үлеп булмый, яшәргә кирәк. Яшәргә, димәк, башлы-күзле булырга кирәк. Аңа тол хатыннарны да, иреннән аерылып кайткан баласыз хатыннарны да тәкъдим итүчеләр булды булуын. Кызы Фатиха да: "Әнкәй кайчан кайта инде?" — дип теңкәгә тия. Ләкин Мостафаның күңеле берсенә дә тартылмады. Иң әүвәл, ятим ике балага ана булырдай кеше табылырмы? Галимҗан әнә, үсә төшкән саен үз эченә йомыла бара. Кай вакытта, бер дә юкка үпкәләп, ишек алды тәрәзәсенә каплана да сәгатьләр буе нидер уйланып утыра. Андый чакларда нишләтеп тә булмый аны, ни агыннан дәшми, ни карасыннан. Үги әнкәсе белән килешә алырмы? Фатихага ана җылысы бик кирәк тә бит, бала җанлы кеше туры килмәсә? Андый мисаллар дөньяда азмыни?

Әнә, Галиулла абзыйның сөйләгәне әле дә истә. Җәмәгате Фәхрикамал алты баласын калдырып вафат булган аның. Кече кызына тугыз гына ай чак. Галиулла абзый да, балаларын карарга бер яшь әнкә кирәк булганга күрә, өйләнгән. Әйтергә кирәк, иманасыз-нисез, яшәргә бернинди чыганаклары булмаган ялгыз хатыннар күп балалы тол ирләргә кияүгә чыгарга мәҗбүрләр. Ләкин алар арасында төрле холыклылары була шул. Галиулла абзыйның да яшь хатыны балалар өчен каты күңелле, рәхимсез булып чыга.

Берсендә кабат кайтып керүендә Галиулла ишек алдыннан ук кече кызының үкереп елавын ишетә. Инде артык түзә алмыйча, кызын куенына алып, үзе дә утырып елый һәм казыйга китә. Казыйга кызының күгәргән беләген, ертылган киндер күлмәген күрсәтә һәм өч тапкыр "талак" әйтеп, хатынын аталарына кайтарып җибәрә. Әнә, үги ана, үги кыз турында күпме әкиятләр бар. Берсе дә аларның тату яшәүләре турында түгел. Менә шундый хатыннан Ходай сакласын!

Икенче яктан караганда, тернәкләнеп килә торган тормышын алга алып барырдай, көнкүрешкә ямь бирердәй кеше бик кирәк. Әле тормышны җайлар, балаларын аякка бастырыр өчен бик күп хезмәт куясы бар. Берсен башкардым дисәң, икенче эш килеп чыга, аның артыннан өченчесе, аннан ары тагын...

Гайнулла абзый белән Гайнижамал абыстай да картаялар. Хәзер аларның үзләрен карарга вакыт. Карарга дип, ир-ат эшен, ягъни утын белән тәэмин итүне, аны ярып бирүне, бодаен-арпасын тегермәндә

тарттыруны һәм башка зур эшләрне үзенеке белән бер рәттән күптән башкара анысы Мостафа. Гайнижамал абыстай эш эшләгәндә Фатиха да кул арасына кергәли, кая калдырча әйләндереп шүрегә жеп чолгый, кая әвернә сүтеп йомгак ясый торган иде. Хәзер абыстай да эрләү-сугу эшләре белән сирәгрәк кайнаша башлады. Бетмәс-төкәнмәс хатын-кыз эшен тавык та чүпләп бетерерлек түгел.

Шундый уйлар башыннан йөгереп узды Мостафаның. Аның шулай башын ватып утыруына нокта куйгандай, Гайнулла абзый әйтә куйды:

— Мостафа, хәзер безнең бишебезгә өч имана жиребез бар. Ходай кушып, уңышын исән-сау жыеп алырга язган булса, берәр кырыкмыш тай алырга мөмкин булыр иде.

— Мин үзем дә шул турыда баш ватып йөрим, Гайнулла абзый.

Көз житү белән, ашлыгын сатып, жигү аты булмаса да, ике яшьлек кырыкмыш тай алырлык акча әзерләделәр. Ачлы-туклы яшәсәләр яшәрләр, әмма тай алырга бик кирәк иде. Имана паен түләгәннән соң, бер имана уңышы гына житмәс, билгеле. Ярый әле, Гайнулла абзый уңышы бар. Аның өстенә, быел бәрәңге утырттылар. Ул да өстәмә азык булыр. Ничектер яшәрләр әле, доньялар имин булсын.

Шул ният белән көннәрдән бер көнне Мостафа Галимжанны ияртеп Бәки базарына китте. Бу базар атнаның чәршәмбе көннәрендә жыела торган иде.

Бәки базары Балыклыдан ерак булганга күрә, алар киченнән Шомгаты олыс авылына тукталырга, анда кич кунарга чамалап, юлга төштән соң чыгып киттеләр. Мостафаның кич кунардай урыны — күптәнге танышы Габделхәй иде.

Алар кичкырын килеп кергәндә, Габделхәйнең кәефсез чагы туры килде. Тынычлыгың да югалырлык шул, сәүдә эшендә зур өметләр вәгъдә иткән сәләтле егет Фәсхетдин кыз аркасында үзенең бөтен язмышын, киләчәген челпәрәмә китерсен әле. Габделхәй Мостафага Хәмзә кызы Заһидәне Ырынбур ягыннан бер башкорт баеның улына яучыларга килүен, моны белеп алган үсүзле Заһидә яратып йөргән егете, Габделхәйнең туганы Фәсхетдин белән качып китүен, аларны тотып алып кайтуларын, хәзер егеткә йә төрмә, йә солдат хезмәте янавын сөйләп бирде.

— Кызга берни булмас анысы, чөнки ул Хәмзә кызы. Ә менә Фәсхетдин кызганыч. Иң аянычы шул, аны яклап берни дә эшләр хәл юк. Кичә генә әле Морзаларга олыс үрәтниге китте. Үрәтник бик кансыз кеше. Хәмзәнең ришвәтенә кызыгып, теләсә ни эшләргә сәләтле, — дип көрсенде Габделхәй.

Мостафа бу хәбәргә артык игътибар бирмәде. Кеше кайгысы иртә керә, кич чыга.

Мостафаның Бәкигә нинди ният белән баруын белгәч, Габделхәй дә базарга жыенды.

— Барыбер барасым бар, сезгә дә файдам тимәсме, — дип белдерде ул.

Базарны инде бер күргән Галимжанга ул бу юлы артык тәэсир итмәде. Шул ук гүләгән тавыш, шул ук ыгы-зыгы икән монда да. Аның бүген бар күңеле атларда иде. Тайларны карап, кайберсе янында туктап, сатулашучы атасы белән Габделхәй абзасыннан калмыйча ияреп йөрде. Олылар, ышанычлырак булсын дипме, әнкәсе туры бия янына бәйләгән озын йонлы, кара яллы, матур койрыклы ике яшьлек жирән бия кырыкмышны сайладылар. Габделхәй осталыгы беләнме, алай ук кыйбатка да алмадылар — нибары биш тәнкәгә сатты хужасы. Базар үзенең бәясен белә дип исәпләгән Мостафа исә хужа сораган бәяне бирергә дә әзер иде.

Шомгатыга кайтып житкәч тә, туктап тормастан, жәяүләп авылга ашыктылар. Өйләренә кайтырга, ишегалдында тайның йөрүен, йортны тулыландырып торуын тизрәк күрәселәре килә иде аларның.

Авылга кергәч, керәшеннәр урамыннан узарга өлгермәделәр, каршыга Сафиулла мулла очрады.

— Әссәламегаләйкүм, хәзрәт! — дип, Мостафа мулланы ерактан ук сәламләде.

— Вәгаләйкүм, Мостафа! Күрәм, кырыкмыш алып кайтып киләсең. Төкле тояклары белән бәрәкәтле туфрагыгызга басарга язсын Ходай. Үзегезгә зур ярдәмче булып үссен!

— Рәхмәт, хәзрәт, яхшы сүзләреңә, — дип, Мостафа куанычын яшерә алмыйча, мулланың сүзләренә шат булды.

— Мостафа, сине күрәсем килеп йөри идем әле, ярый очрадың. Бүген икенде намазыннан соң мәчеттә калыбрак тор. Ахшамга хәтле сөйләшеп алырбыз. Сиңа әйтәсе сүзләрем бар иде.

Икендедән соң Мостафа белән Сафиулла мулла мәчеттә икәү генә калдылар.

— Мостафа, син минем күз алдымда ятим калдың. Атаң Мөхәммәт абзый, урыны оҗмахта булсын, тырыш кеше иде. Анаң Мәрхәбә дә җор телле күңелле кеше булды. Мөнәҗәтләр әйтергә ярата торган иде. Син дә аларга охшаган булсаң, җиһанда үз урыныңны табарсың, Аллаһы теләсә. Менә күзәтеп торам да, син һаман муллыкка омтыласың. Балаларың турында кайгыртасың, аларга үзеңә тигән язмыш кагылмасын өчен бөтен көчеңне куясың. Күршең Гайнулла абзыйларны да үз атаң-анаң кебек карап тәрбияләвең бик күркәм эш. Шуны да әйтим, Мостафа, ат алып, имана паен түләп, урып-җыйган икмәгең дә бик аз калгандыр инде синең. Әгәр мохтаҗлыгың булса, тартынмыйча миңа кил, күпме кирәк, ярдәм итәрмен. Уйлама, киләсе көзгә түләрсең, Аллаһы боерса. Арттырып түгел, күпме алсаң, шулкадәр түләрсең. Йә булмаса, әнә минем имән бүрәнәләрем ята. Вакытың булганда ашыкмый гына мунча бурап бирерсең. Буш итмәм, разый булып калырсың.

Әлегә хәтле дәшми утырган Мостафа кышкы буш көннәрдә үзенә эш табылуга шатланып, рәхмәтләр әйтә башлаган иде, тик аны хәзрәт бүлдерде һәм сөйләвен дәвам итте:

— Атаң-анаңны искә төшерүем юкка түгелдер. Бабаң Әбүбәкер дә авылда хөрмәткә лаеклы кешеләрнең берсе иде. Әнә керәшен урамыннан чыгып киткәч, Аргы җәпле күлдән башланган ермак аның исемен йөртә. Гаярь кеше булмаса, бу ермакның өстендәге чытырманлыкны әрчеп, анда икмәк чәчә алмас иде бабаң. Шул җирдәге күл-сазлык сулары аксын өчен мондый озын ермак казый алмас иде. Кызганыч, шул уңдырышлы җирләрне керәшеннәргә бүлделәр. Димәк, син тәвәккәл нәселдән.

Мостафа, атасы-бабасы турында берникадәр мәгълүматлы булуга карамастан, мулланың бу сүзләрен гаҗәпләнеп тыңлап утырды. Аның бу сүзләре белән ни әйтергә теләвен ул һаман аңламый иде әле.

Хәзрәт дәвамында булды.

— Син хәзер фәкать үз көчең белән, үзеңнең тырышлыгың аркасында тормышыңны җайлап киләсең, тернәкләнә барасың. Алга бар, тавыклар арасында әтәч була бел. Сиңа әйтәсе килгән сүзләрем шул, Мостафа, инде башлы-күзле булырга да вакыт, җәмәгатең карусыз, эшчән иде, урыны оҗмахта булыр, Алла теләсә. Тик үлгән артыннан үлеп булмый, яшәргә кирәк. Менә сиңа кәләш кодалау турында икенче кабат әңгәмә корып алырбыз. Хәзер ахшамга да вакыт килеп җитә. Тәһарәт алыйк, булмаса.

## 18

Хәмзәнең кәефе бик яман иде. Ул ут йотар хәлгә килде. Килмәслек тә түгел шул. Кода буласы башкорт бае бөтен вәгъдәләрне юкка чыгарып, үз ягына кайтып китте. Кабынган өметләр өзелде. Барысына да кем гаепле соң? Әлбәттә, тиреслектә әүмәкләнеп үскән Фәсхетдин! Иң беренче нәүбәттә аны җәзага тартырга кирәк. Хибесханәгә аны, каторгага, Себергә!

Озакламый олыстан урәтник Дубов килеп төште. Юан гәүдәле, үзенең дәрәҗәсен белеп, башкаларга да күрсәтә ала торган комсыз бер бәндә иде ул. Әйтергә кирәк, урыслар арасында да төрле кешеләр була. Колонизатор урысларның күпчелеге башкисәр, үз илләрендә дә эшне сөймәгән, фәкать башкаларны талап яшәргә күнеккән катламыннан тора. Алар арасында иң зәһәр, иң аяусызлары жирле халыкларны зур түрә сыйфатында изәргә, әмәлен табып, мал-мөлкәтен тартып алу гына түгел, рухи өстенлекләрен даими рәвештә исбат итеп торырга, шул өстенлекләреннән ләззәт алып яшәргә тырышучылар иде. Урәтник Дубов шундыйларның берсе иде.

Килеп туктау белән ул, зур түрәләрчә, Хәмзә байның чыгып алуын көтеп алды. Тегесе аны каршы алырга күптән әзер иде инде. Кыңгыраулы ат белән тарантаска утырып килүче түрәне ул капкасын киң итеп ачып каршылады, атын житәкләп ишек алдына кертте. Тарантас болдыр буена килеп туктауга, яп-якты итеп юылган баскычтан жиргә, урәтникнең аяк астына намазлык кебек тар гына палас тәгәрәтте һәм кунагын шунда бастырды. Бу зур кунак белән аның тылмачын өйдә сый-хөрмәт көтеп тора иде инде.

Урәтник старостаны чакыртты:

— Синең авылыңда тәртип юк, староста! — дип башлады Дубов. — Кызларыгызны алдыйлар, урлап китәләр. Ат урлый башлаганнар әнә. Син нәрсә карыйсың? Халыкны тәртиптә тота алмаган староста — староста була аламы?

Бу шелтә Җамай старостаның авырткан жиренә кагылды. Аның теле тотлыкты. Тик ишетелер-ишетелмәс кенә итеп үзенең бар белгән урысча сүзен мыгырданып куйды:

— Так точно, господин урәтник!

— Әйт әле, быел авылдан солдатка каралырга тиеш кешеләр бармы?

— Так точно, господин урәтник, быел көз бер егетне жибәрдек, башка караласы кеше юк.

— Ярар, бар, жый жыеныңны. Минем халык белән сөйләшәсем килә.

Аннан Дубов келәттән Фәсхине чакырып кертергә кушты:

— Хо, кияү егете! Кыз куенында рәхәтме?

Фәсхинең, җавап кайтармыйча, горур кыяфәттә басып торуын күреп, урәтник дәвам итте:

— Йә, ник дәшмисең, кыз урлау рәхәт шөгыльме? Житмәсә, беррәттән ат урлап баерга да идеме исәбең? Беләсеңме, моның өчен сиңа нәрсә көтә? Каторга!

— Миңа хәзер барыбер, — дип көрсенеп куйды Фәсхи.

— Вот так? Я тебя сгною! Своих родителей помнить не будешь, гололобый!

Тылмач тәржемә итеп маташкан арада Фәсхи җавап биреп өлгерде:

— Не пугай, господин урядник, я тебя не боюсь!

— Ого! Ты и по-нашему калякаешь? Забавно. Парень, давай тогда к нам служить, а? Христианство примешь, а? Условия создадим.

Фәсхи урысча белүен сиздергәненә үкенеп куйды. Бу җаһил белән күбрәк сөйләшкән саен үзенә яманрак буласын тиз чамалады ул. Шуңа күрә, кабат дәшмәс булды. Урәтник күпме сөйләштерергә тырышса да, сүзсез басып тора бирде. Дубов аның болай эндәшми торуын үзенчә юрады. Бәлки аның белән аерым, икәүдән-икәү сөйләшергә кирәктер, дип уйлады ул. Шуңа күрә, соңрак сөйләшергә булып, егетне кире келәткә бикләргә боерды.

Җыенга халык күп җыйналды. Олыстан урәтник килгән, авылдан Фәсхетдинне һәм тагын берничә кешене солдатка жибәрергә тели икән, дигән хәбәр бик тиз арада таралган иде. Быел солдатка бер кешене жибәрделәр бит инде. Каралу вакыты да узды. Шуңа күрә, кабат беркем каралырга тиеш түгеллекне авыл яхшы белә һәм моңа каршы торырга

жыена иде. Чөнки, закон буенча, сиксән өч ярым хуҗалыктан бер солдат каралырга тиеш. Ә авыл сиксән йортлы гына.

Хәмзә белән урәтник Дубов тылмачын ияртеп килеп житкәч, халык бермәл гүләп алды. Каравыл өе алдындагы мәйданда ясап куйган басмачага менеп баскан Җамай староста халыкны тынычландырырга керешге:

— Җәмәгать! Тынычланыгыз, тыңлагыз, хәзер олыс үрәтниге гасподин Дубов сөйләр. Әйбәтләп тыңлагыз!

Кызмача Дубов басмачага менеп басуга, гадәттәгечә горур-тәкәббер кыяфәт белән башын артка ташлап, халыкка күз йөртеп чыкты да тамак төбе белән сөйли башлады:

— Гололобые, башкисәрләр, юлбасарлар сез! Бөек Галиҗәнаб патшабикәбез Елизавета Петровна хөкеменә, ул биргән ирекккә риза булмый, каршы барасызмы? Бу бит фетнә! Аның өчен сезне авылыгыз белән Себергә, сөргенгә җибәрергә кирәк.

Шул рәвешле үрәтник байтак җикеренде. Патшабикә исемен атагач һәм сөргенгә җибәрү белән янагач, халык бермәл куркып, тынып калды. Үрәтникнең буталчык-усал сүзләреннән шуны аңладылар: авылда карак һәм юлбасарлар бар икән. Аларны монда тотсаң, бөтен авылны үзләре артыннан ияртеп, бозып бетерәчәк икән. Ниһаять, сөйләп арган үрәтник туктап, тирләгән битен кулъяулыгы белән сөртергә тотынгач, Хәмзә морза сөйли башлады. Аның сүзләре үрәтникнекеннән күп аерылмаса да, ул ачыграк әйтүне кирәк тапты:

— Авылыбызда гомер-гомергә булмаган кыз урлаулар, аның белән бергә бирнә итеп ат урлаулар булмасын өчен, андый фетнә чыгаручы Фәсхетдинне зинданга яки солдатка олактырырга кирәк!

Халык хәзер генә эшнең нәрсәдә булуын аңлап җиткерде.

Шулвакыт таяклы кулын өскә күтәреп, Зыя карт сүз башлады:

— Гасподин үрәтник! Монда син авыл өстенә таккан гаеп нахактыр. Без патшабикә хакимлегенә буйсынабыз. Аңа каршы булып, берни дә эшләгәнебез юк. Кыз урлауга килсәк, Хәмзә энем, бу гаеп түгел, ата-бабаларыбыздан килә торган гадәт. Ат урлау турында да нахак сүз әйтәсең. Атны урлаучы юк. Үзенә килгән башкорт кунакларының яше старостага әйткән сүзләрен мин үз колакларым белән ишеттем. "Атны мин биреп тордым", диде ул. Җамалетдин, ник дәшми торасың? Хак сүзне яшереп калдыру — зур гөнаһ.

Моңа каршы Җамай староста, ык-мык итеп кенә, Зыя картның сүзләрен җөпләргә мәҗбүр булды.

— Димәк, — дип дәвам итте Зыя абзый, — Фәсхетдин гаепсез. Аны зинданга озатырлык бер сәбәп тә юк. Солдатка каралырга да тиеш түгел ул — ата-аналарын караучы бердәнбер бала. Закун буенча да алай тиеш түгел.

Зыя картның төпле җавабын тылмач аша тыңлап торган Дубовның түземлеге бетте. Ул ашыгып басмачадан төште һәм янәшәдә генә сөйләп торган карт янына килде.

— Ах, гололобый, син законны беләсең икән, мин сине түрәләрне ничек ихтирам итәргә өйрәтәм хәзер! — дип җикеренде ул һәм картның колагын бора башлады. Шунда бабайның түбәтәе башыннан төшеп китте. Картның кулы ирексездән үрәтниккә таба сузылды. Үрәтник, үзенә сузылганга чыгырыннан чыкты һәм аңа камчысы белән селтәп җибәрде.Аркасына төшкән камчы ачысыннан Зыя куырылып калды һәм ыңгырашып куйды.

Шулвакыт үрәтник белән аның тылмачын авыл кешеләре урап алдылар. Шау-шу, кычкырыш китте. Бу эш кая барып җиткән булыр иде, билгесез. Шул чакта басмачада Кәлимулла мулла пәйда булды. Менеп җитүгә, ул, басмача тактасына таягы белән бәрә-бәрә, халыкны үзенә каратырга тырышты. Кешеләр, абруйлы мулланың һәрвакыт акыллы сүзләрен тыңларга өйрәнгәнгә күрә, бу юлы да бер чишелеш табар, дип, артык узынып китүчеләрне тынычландырдылар. Хәзрәт әйтергә тели, дип, мәйданда тәртип урнашуга ирештеләр.

Тынып калган халык алдында Кәлимулла мулла үзенең гадәттәге тыныч тавышы белән сөйләргә тотынды:

— Җәмәгать! Сез үз-үзегезгә баз казыйсыз түгелме соң? Сабыррак эш йөртергә кирәк. Пәйгамбәребез дә сабырлыкны яраткан. Монда, күренеп тора, ялгышлык килеп чыкты. Урәтник кызу канлы кеше, ләкин аңа кул тидерү җинаять итеп бәяләнәчәк. Шуңа күрә сезнең кызулануыгыз урынсыз.

Кемнәрдер "мулла дөрес әйтә" дип шаулаша башладылар. Аларны икенчеләре тын булырга, тынлап торырга өндәделәр. Хәзрәт дәвамында булды:

— Солдатка каралырга тиешле яки хибесханәгә ябыласы берәр кеше була икән, господин урәтник, аны камчы белән исбат итмиләр. Бездә солдатка каралыр кеше бар икән, аның турында олыс старшинасының үзеннән фәрман булсын. Башкача без бу мәсьәләне бүген карамыйбыз.

Аның сүзләрен хуплап, халык тагын шаулап алды.

— Бу гауга чыгу, Хәмзә абзый, бары синең аркада гына булды. Гөнаһсыз кызның өметен өзүең генә җитмәгән, мөрәүвәтле Фәсхетдинне дә рисвай итмәкчесең. Минем теләгем шул: болганыш зурга китмәстән, хәзер үк урәтник олысына кайтып китсен. Бичара егетне өенә җибәр. Югыйсә, халык кызды. Үзенә дә яманлык кылып ташлаулары бар.

Мулланың бу сүзләрен бөтен җыен хуплавын күреп, урәтникнең кайтып китүдән башка чарасы калмады.

Әмма бу вакыйга авылга киләчәк афәтнең башы гына иде әле.

## 19

Тоткыннан котылган Фәсхетдинне иртәгесен үк Кәлимулла хәзрәт чакыртты.

Барып керүгә, Фәсхетдин хәзрәтнең үзгәргән, кырысланган булуын сизде. Аның элекке мөлаем йөзе, якты карашының эзе дә калмаган иде.

— Утыр әле, улым, синең белән бик җитди сүз бар. Беләм, синең хәзерге вакытта нинди халәттә икәнеңне яхшы аңлыйм, — диде хәзрәт. — Әмма якын итеп әйтәм, зиһенле шәкертем булганыңа күрә, синең язмышыңа битараф кала алмыйм. Хәлеңә керәсем, язмышыңны җиңеләйтерлек киңәш бирәсем килә.

— Мин нишләдем соң шул хәтле, хәзрәт? Ник минем башка шундый хәсрәт төште, гаебем нидә?

— Яшьрәк шул әле син, угылым, барын да аңлап бетермисең. Хәлең яман булса да, ул кадәр башыңны ташка орырлык эш юк шикелле әлегә. Андый михнәт килергә дә ерак түгел. Җыенда булган вакыйганы ишеткәнсеңдер. Авыл халкы сине солдат хезмәтеннән йолып калды калуын. Киләчәктә дә йолып кала алырмы?

— Нишлим соң инде, хәзрәт? Заһидәне югалтуым шушы микәнни?

— Заһидәңә бернәрсә булмас. Менә сине солдатка алып китүләре бар. Закун буенча син каралырга тиеш түгел. Мәгәр түрәләрнең закуннары үзләре кулында. Шуңа күрә берникадәр вакытка сиңа авылдан китеп торырга туры килер. Фәһемле егет үзең. Мөрәүвәтлегеңне күрсәт, кайда булса да берәр җирдә сыенып торырлык урының бармы?

— Олыста табиб Дмитрий дустым бар.

— Урысмы?

— Урыс.

— Ай-һай, ярдәмле-мәдәтле кеше булырмы?

— Мин аңа ышанам, хәзрәт.

— Теләгең, олан, тик гафил була күрмә. Авылдан чыкканда старостадан язу алырга онытма. Аның сиңа кирәк булуы бар. Юлда алдыңны-артыңны карабрак йөр. Хәмзә морза үчле кеше, артыңа төшмәсен. Урәтниктән саклан. Ярый, хуш, угылым, бер дога. Юлга чыгар алдыннан "Аятел-көрси" уку мәслихәт.

Шулай итеп, үзе дә күз алдына китерә алмастай билгесезлеккә чыгып китте Фәсхетдин. Аның уйлары һаман бер тирәдә иде.

Заһидәсе белән кабат күрешә алмас микәнни? Яраткан кызы белән бергә узган чакларны берәм-берәм исенә төшерде ул. Истәлекле имән төбендә чытырдатып кочаклаганда үзенә килеп терәлгән күкрәк алмаларының кызылыгын әле дә тойган кебек, үз күкрәген капшап алды хәтта. Чын күңеленнән яратмаган кыз үзе атлар барлап, аны качарга һәм никах укытырга өндәр идемени? Миклушаларда атларыннан колак каккач та җәяүләп барырга риза булды. Бары тик бергә булуларын гына теләде. Андый кызны ничек күңел түреннән чыгарып ташларга мөмкин булсын?

Шулай уйланып бара-бара, урман буена барып җитте Фәсхетдин. Монда юлдан аз гына читтәрәк, урман эчләбрәк барырга җайлырак иде. Кырдагы шикелле чокыр-чакыр буйлап бару аны ялыктырган иде инде. Хисләренә бирелеп барганда юлдан атын кушаяклап чаптырып узучы берәүне күреп алды. Моның кем булуына әһәмият биреп тормады, үз кирәгенә күрә юлдан кем генә узмас? Ә игътибар итәсе калган икән.

Атта чабып узучы Җамай староста улы Шиһабетдин иде. Ул Фәсхигә бик ачулы иде. Теге чакта урысчалап авызын томалаганнан бирле, үч алу хисе биләп алган иде үзен. Йолкыш булуына карамастан, бай кызына күңелен сузган бу аламадан үч алып, үзенең өстенлеген күрсәтәсе килә иде аның. Фәсхинең староста янына килүенең сәбәбен ачыклауга, Хәмзә байга барып, егетнең авылдан чыгып китәргә җыенуын әйтте. Тегесе аның кая китәчәген сагаларга кушты. Үзе дә күз-колак буласын белдерде.

Икенче көнне иртүк Фәсхинең авылдан чыгып, олыс юлына таба юнәлгәнен күрде Хәмзә. Аның Шомгатыга Габделхәй абзасына китеп баруын аңлады. Ул тиз генә Шиһабетдинне чакыртты. Ләкин тегесе өендә юк иде. Аны атасы күрше авылга су тегерменәнә җибәргән булып чыкты. Көтеп тә кайтмагач, Хәмзә тегермәнгә үзе китте. Шиһабетдингә олыска чабарга, урәтникне эзләп табарга һәм Фәсхине тотып зинданга ябарга кирәклеген әйтергә кушты. Үчле Шиһабетдингә он тарттыруга караганда мондый мажара ошыйрак төште. Шуңа күрә ул берсүзсез олыска чапты. Тик юлда Фәсхине очратмады. Барып җитү белән ул урәтникне эзләп тапты. Урәтникнең, билгеле, егетне кулдан ычкындырасы килми иде. Ул ике солдатны һәм Шиһабетдинне ияртеп, Габделхәй торган йортка китте. Габделхәй Фәсхинең тоткынлыктан авыл кешеләре тарафыннан коткарылуын, аның монда килергә чыгуын белми иде әле. Староста малаеның ат белән чаптырып килгәнен күргәч кенә нәрсәдер сизенде ул. "Фәсхине эзлиләр!" — дигән уй сызылып узды.

Бу атлы-кораллы кешеләргә ничек комачауларга белмәде Габделхәй, шулай да күпергә таба атлады. Ул елгага якынлашканда үзенең соңга калуына төшенде. Тегеләр Фәсхине тотканнар һәм олыс конторы янына урнашкан зинданга алып баралар иде инде.

Габделхәй бу хәлне читтән генә карап калырга мәҗбүр булды һәм, тиз генә ат җигеп, Морзалар авылына барып килергә булды.

Авылда беркем дә хәбәрдар түгел иде, билгеле. Фәезхан абзасы белән Фатыйма җиңгәсе Фәсхетдиннең Кәлимулла мулла киңәше белән "бәхет эзләргә" чыгып китүен генә әйтә алдылар. Фәсхине тотып, зинданга алып китүләрен Кәлимулла хәзрәткә дә җиткерделәр, аннары бергәләшеп староста өенә юнәлделәр. Староста үзенең бернәрсә дә белмәвен, малаен су тегерменәнә генә җибәрүен әйтте. Тегермәндәгеләр исә, Хәмзә бай килеп, Шиһабетдингә нәрсәдер әйткәннән соң, тегесе ашыгычлык белән атына атланып, каядыр китеп барганны сөйләделәр. Староста өе тирәсенә шактый кеше җыелып өлгергән иде. Алар Җамай алдаша, чын хәлне яшерә дип уйладылар. Әгәр мөһерен муенына такмаган булса, аны тәпәләп алырга да күп алмаслар иде. Мөһерле килеш кул сузсалар, бу хакимияткә каршы бару булыр иде. Шулай да старостаны олыска барырга, Фәсхинең язмышын ачыклап кайтырга мәҗбүр иттеләр.

Әмма Фәсхинең язмышы хәл ителгән иде инде.

# 20

Авылга олыс түрәләреннән берьюлы әллә ничә кеше килеп төште. Авыл халкы алар килгәнче үк таяк тыгып болгатылган кырмыска оясы кебек кайный башлаган иде. Шау-шуның башы, билгеле булганча, Фәсхетдинне зинданга япкан хәбәрдән башланды. Бер гөнаһсыз кешене ябып кую авылның үзенә дә зур афәт китерердәй кара хәбәр итеп фараз кылынды. Авылны киеренкелек, шом басты. Староста Җамай да олыска барып берни майтара алмыйча кайтты. Анда аны сүгеп кенә җибәрделәр. Шуңа күрә олыс түрәләре килеп төшүне халык сагаеп каршы алды.

Җыенда исправник сөйләде, тылмач тәрҗемә итеп торды. Иң әүвәл патша галиҗәнапләренең яңа указын игълан иттеләр. Бу указ буенча, авылдан бер атлы һәм ике атсыз — барысы өч кеше бер елга лашман хезмәтенә алынырга тиешле була икән. Башта халык берни дә аңламый торды. Чөнки лашман хезмәте турында алар имеш-мимештән ары хәбәрдар түгел иделәр. Бу төбәктә, гомумән, Тау ягында йомышлы татарлар булмаганга күрә, андый хезмәткә дучар ителүчеләр юк иде.

Дәшми торган җыенга тагын бер кабат аңлатырга туры килде. Шуннан соң гына бу шомлы хәбәр аңнарына барып житте. Шаулаша башладылар. Әмма мәйданның тирә-ягында биш-алты атлы казак халык өстенә ташланырга әзер торганда, шаулашып кына ни кырасың?

Шулвакыт басмачада кара җиләнле, озын коңгырт сакалы өстеннән муенына күркә тәпиеннән дә зуррак тәре таккан олыс побы пәйда булды. Поп халыкка караган килеш чукынып алды да саф татар телендә сөйләргә тотынды:

— Кешеләр! Христиан диненә күчүче авыллар патша хәзрәтләре рөхсәте белән урман кисү эшеннән азат ителәләр. Лашманга барасыгыз килмәсә, безнең дингә күчегез. Иң гадел, иң мәрхәмәтле дин — православие. Күрегез, әнә сездән ерак түгел Ялчек авылы белән чуаш Шәмәге безнең дингә күчәргә риза булдылар. Алар лашманга бармыйлар...

Поп сүзләрен әйтеп бетерергә өлгермәде, җыен уртасыннан тәкъбир әйткән тавыш ишетелде. Тәкъбирне күтәреп алып, бөтен мәйдан көйли башлады. Яшьрәк ирләр бердәм кузгалып, басмачага ташландылар һәм аны кешеләре белән бергә әйләндереп капладылар. Ат өстендәге урәтник Дубов, кылычын чыгарып болгый-болгый, якынрак торган кешеләргә селтәнә башлады. Шуннан соң солдатлар, камчылары белән кем эләксә шуны суктыра-суктыра, халык арасына кереп киттеләр һәм атлары белән таптатып, кыйнап, төркемне айкарга керештеләр. Китте тавыш, кычкырышелаш. Җитезрәкләре читән казыклары суырып алдылар да казакларга каршылык күрсәтә башладылар. Халыкны болай гына җинә алмаслыкны күреп, исправник бәрелешне туктатырга, казакларга үз тирәсендә тупланырга боерык бирде. Түрәләр, казаклар чолганышында чигенә-чигенә, атларына утырып, тизрәк авылдан чыгып китү җаен карадылар.

Өстенлек үзләрендә калудан шаукымланган бер төркем аларны таштыр, кантардыр атып, авыл башына кадәр эзәрлекләп барды.

Әмма бу кыска бәрелеш фаҗиганың башы гына иде әле.

Империянең 1751 елгы ундүртенче июнь указы белән лашман хезмәтенә йомышлы татарларны, шул исәптән морзалар белән ясаклы татарларны да тартырга боерылган иде. Шул ният белән килделәр дә инде олыс түрәләре авылга. Ләкин указ буенча бу эшкә христиан динен тотмаучыларны гына алырга тиешләр иде. Бу көтелмәгән хәл иң элек Хәмзәне аптырашта калдырды. Ничек инде алай? Аның Биеш авылына җир бирү бәрабәренә атасына бирелгән мөһерле кагәзе бар. Анда алар нәселе мондый эшләрдән мәңгелеккә азат ителәләр дип язылган. Яңа указ белән бу хокук юкка чыгарыла микәнни? Ышанмыйча, өяз каласы Тәтешкә дә барып кайтты Хәмзә, ләкин анда да каефен кырып җибәрделәр. Буйсынмый чара калмады. Бәс, шулай икән, ул бу эшкә үз

теләге белән катнашырга, кемгә дә булса ат бирергә әзер икәнен белдерде.

Бер атнадан соң авылга солдатлар килеп төштеләр. Алар өяз каласы Тәтештән махсус чакыртылган иделәр. Килү белән солдатлар ун йорттан берәр сарык суйдылар, ашарга-эчәргә әзерләттеләр. Буйсынмаган авылларны акылга утырту өчен махсус рәвештә күп санда җибәрелеп, бу обжор команда үзенең кара эшенә керешге. Кешеләр берәм-берәм каравыл өенә чакыртылып, камчы белән суктырыла башладылар. Шул ук вакытта лашман эшенә җибәреләселәрне билгеләделәр.

Исемлекнең башына Фәсхетдинне язып куйдылар. Картайган атасы-анасы булу сәбәпле, аны закон буенча солдатка яки лашман эшенә җибәрергә тиеш түгелләр иде. Ләкин моның белән исәпләшүче булмады. Фәсхетдингә Хәмзәнең атын бирергә булдылар, чөнки атлылар озаграк хезмәт итәргә тиеш иделәр.

Солдатлар хатын-кызларга да күз ата башладылар. Инсафлы әдәпле татар хатыннары өчен бу солдатларның, аулак урын туры китереп, кочаклаулары, узганда-барганда авызын-битен яшергән яулыкларын тартып алу, яланбаш калдыру, кабыргаларына, күкрәкләренә сузылулары чиктән ашкан зур гөнаһ, акылга сыймаслык бер бозыклык иде. Шуңа күрә, кызларны, яшь киленнәрне караңгы кабу белән ындыр артларыннан, юлсыз җирләрдән генә күрше авылларга танышларына, туганнарына илтеп яшерә тордылар.

Хәмзә өенә әфисәр урнашты. Хәзер аның капка төбендә үк каравылда көне-төне алмаш-тилмәш солдатлар торды. Кемгә булса да керергә-чыгарга мөмкинлек калмады. Заһидәнең Фәсхетдин белән хәбәрләшерлек күршесе Фәридә дә авылдан чыгып тайган иде.

Хәмзә теләсә-теләмәсә дә әфисәрне, аның ярдәмчеләрен, аның янына килүчеләрне ашатып-эчертеп торырга мәҗбүр булды. Үзенең усаллыгыннан авылга килгән бу бәланең шулкадәр афәткә әйләнәсен күз алдына китермәгән иде Хәмзә. Ләкин ул хәзер дә явыз ниятеннән кире кайтмады. Киресенчә, Фәсхетдинне лашман эшенә озатуларына кинәнде генә. Шуның өчен дә өендәге әфисәргә сый-хөрмәтне кызганмады ул. Өстәвенә, үзенә бил бөкмәгән, күп чакларда туры сүзләре белән комачаулаучы Әхмәтзыя, Әхмәтсафа кебек ил картларының да уларын җибәртүгә ирешге. Җәгъфәрсадыйк староста белән бергәләп әфисәргә аларны яздырды.

Карчыгы ишек аша Хәмзәгә дәшкәч кенә ашларны гүрничәгә хуҗа үзе алып керә торган иде. Әфисәргә бу гадәт ошамады.

— Ник ашны үзең ташыйсың, сезнең хатын-кызларыгыз юкмы әллә? — дип көлде ул, мәсхәрәле итеп.

Шуннан соң Хәмзә табынга ашларны ташырга кызы Заһидәгә боерды. Фәсхетдин белән булып узган мажаралардан соң хәсрәтеннән яман сулыгып, йөзе агарынып калган Заһидәне элегрәк белгән якыннары кызгансалар да, ул үзенең сылулыгын югалтмаган иде. Бу сылуны күргәч, аның басынкылыгын бөтен татар кызларына хас бер сыйфатка юрады әфисәр. Әмма күзе төшкән иде кызга, шуңа күрә, гел аны чакырта башлады.

Берсендә, Хәмзә нindидер йомыш белән ишегалдына чыгып киткәч, әфисәр тиз генә Заһидәне кочаклап алды. Кыз елан тизлеге белән аның кочагыннан шуып чыкты һәм кайнар ашлы табагын атып бәрде. Әфисәрнең киеме буялды, куллары, боты пеште. Әфисәр исенә килеп өлгергәнче, Заһидә гүрничәдән чыгып тайган иде инде.

Моннан соң Заһидә әфисәргә хезмәт итүдән каттый рәвештә баш тартты. Түрә каршында һәрвакыт яхшы булырга тырышкан Хәмзәгә буйсынмаучан кызы бик күп бимаза китерә түгелме соң? Ачуыннан: “Нинди алама булса да, тиз арада берәрсенә кияүгә бирергә кирәк”, — дип күңеленә беркетеп куйды ул.

## 21

Ниһаять, лашманчыларны жыеп бетереп, обжор командасы китеп барды. Авыл алардан соң ничектер тынып, монсуланып калды. Кешеләр бер-берсенә эндәшмәс булдылар. Лашманчыларны башка авыллардан да алып жибәрү турындагы хәбәрләр генә аларның күңелләренә әзме-күпме жиңеллек китерде. Бер без генә түгел икән, ил белән икән бу бәла, диештеләр.

Хәмзә морза кызын урнаштыру уенда булды. Элек яучы жибәргән кешеләрнең кылларын читләтеп тә, турыдан-туры да тарткалап карады. Ләкин яучы жибәрерлек кияү-егетләр кайсы инде башлы-күзле булганнар, кайсы Хәмзә белән туганлашырга теләмәүләрен белгерттеләр. Фәсхетдин белән телгә кергән Заһидә хәзер алар күзаллдында "тубалы тузган" яисә сазаган кызлар исәбендә иде инде. Аны яучылап килүче башкалар да күренмәде. Шулай вакыт уза торды. Тагын көз житте. Бу әбиләр чуагы килеп житкән көннәр иде, ягъни бизмән ае* башланган көннәр иде.

Көннәрнең берендә Хәмзә морза күрше Балыклы авылы мулласы Сафиулла хәзрәтне очратты. Шомгаты базарында булды бу хәл.

Дога кылып, чәйгә утырганнан соң, Сафиулла мулла әңгәмәнең тезгенен үз кулына алды:

— Күптәннән бирле синең белән күрешеп, бер әңгәмә корып алырга теләп йөри идем, Хәмзә энем. Сиңа үпкәм дә бар иде. Менә, ходай кушып, сөйләшеп алырга да жай чыкты.

— Беләм, хәзрәт, ни әйтергә теләгәнеңне сизеп торам. Авылыбызга килгән афәтне гел миннән генә күрәләр. Мотлака, Фәсхетдинне урынына утырту гына иде ниятем. Күрәсең, әллә нинди лашман хезмәте уйлап чыгардылар. Анысына да мин гаепле түгел бит инде.

— Бәла үзе генә йөрми шул ул. Бәла килә-килә, артыннан куа килә. Лашман афәте сезнең авылга гына килмәде, ул безгә дә, башка авылларга да килде. Вә ләкин сездәге кебек обжор командасы килмәде, шуңа кыласы гамәлеңне алданрак уйларга кирәк иде, энем.

Сафиулла мулла беравык тын алды да дәшмичә, күзләрен аска төбәп утырган Хәмзәгә карап сүзен дәвам итте:

— Урыс кавеме ничек эшләргә белә ул. Татарлар арасында аз гына үзара талашны да файдаланырга тырыша, шул чакта тыгыла, үзенең куәтен сиздерергә әзер тора. Янәсе, күрегез, безгә итагатьсез кешеләргә карата без ничек рәхимсез була беләбез. Ә син авыл кешеләрен шундый тәшвишкә салуың белән каферләрнең күңелләрен ачтың, аларның кәефләрен күтәрдең.

Сафиулла мулланың бу кадәр каты һәм йөзгә бәреп әйткән сүзләреннән соң, Хәмзә байга карышып торыр әмәл калмады.

— Хәмзә энем, — дип дәвам итте мулла, — кызың да үзең кебек кырыс-усал холыклы булырга охшаган. Әлеге Фәсхетдин белән качуы да тәкъдирендә язылган булгандыр инде. Узган эшкә салават, аңа кайтмыш юк. Алдагыны уйларга кирәк. Кызыңны кияүгә бирергәдер бит ниятең? Хәер, бу синең эш. Күңел уйларыңны ачып саласың килмәсә, ихтыярың. Ярдәм итә алмаммы дип кенә соравым.

Һаман дәшми утыручы Хәмзә ачылып китте:

— Мин үзем дә шул турыда кем белән киңәшим дип йөрүем иде, хәзрәт. Баланы кичекмәстән урнаштырырга кирәк анысы. Ярлы-ябагайга, кара халыкка бирмәскә иде ниятем. Хәзер күренә, яучы жибәрергә атлыгып торучылар юк шикелле.

— Мин дә шулайрак ишеткән идем шул. Моннан ары исәбең ничегрәк эш итәргә инде?

— Рәтле-жайлы кеше булса, кем дә ярар дип уйлап куям хәзер.

— Безнең Балыклыда бер егет бар-барын. Әйбәт кеше үзе. Тырыш.

*Бизмән ае — 22 сентябрьдән башлана.

Атасыз-анасыз яшьли калып кына ярлылар исәбендә йөри. Нәселе яхшы. Аны бәлки беләсең дә булыр — Мостафа атлы.

— Мостафа? Соң, хәзрәт, шул үзсүзле йолкышка кыз бирергә син мине кем дип белдең? Минем морза нәселеннән булуымны оныттыңмыни? Аның ике баласы бар. Җәгъфәрсадыйк старостаның кызын алмыйча шул көнгә калды ич ул.

— Дөрес әйтәсең, Хәмзә энем. Тик ул старостаның гарип кызын алмавының икенче ягын да уйла: димәк, Мостафа горур кеше. Авырлыктан курыкмый. Үз акылы белән көн күрә. Синең кызыңны алса да, малыңа ымсынмас ул. Фәкать үз көченә ышанып яши торган кеше. Менә әле юк хәлен бар итеп, күптән түгел өч яшьлек тай алып кайтты. Бер елдан үз жирен үз аты белән сукалап чәчәр. Өстәвенә, күршесе Гайнулла абзыйларга тернәк булып тора. Бәгъзе кеше үз ата-аналарын да алай тәрбия кылмас. Кыскасы, уйла, энем. Кызыңны бөтенләй бәхетсез итәсең килмәсә, минем тәкъдимемә риза булырсың.

## 22

Фәсхетдиннәрне Шомгатыда ике көн тоттылар. Ул арада олысның башка авылларыннан да лашманчылар җыелды. Ниһаять, гаять зур, еракка сузылган олаулар юлга кузгалдылар. Фәсхетдин Әхмәтсафа улы Галләметдин һәм Әхмәтзыя абзый улы Шәйхетдин белән бергә урнашты. Башкалар да шулай берләшкәннәр иде.

Коры, кояшлы иртәдә атлар бер-бер артлы тезелешеп, ашыкмыйча гына алга атладылар. Кичен кырау төшкәнлектән, иртә белән аеруча салкынча иде. Саргаеп кипкән үлән сабакларын, камыл башларын сырып алган ак сыкылар яңа чыккан кояш нурлары астында ялтырап озата бардылар.

Арбалары артыннан җәяүләп баручы лашманчыларның күңелләре төшенке иде. Аңлашыла ки, аларны күрмәгән-күнекмәгән лашман эше борчый: кая барып керерләр дә, нинди ерәк эш булыр? Авыл кешеләренә урман кисү таныш булса да, бик күпләрне куркыта.

Элек-электән килгән "лашман" дигән сүз үзе дә куркыныч сала торган ят сүз. Лашманчы — тишек чабаталы, иң актык, җәмгыятьтән төшеп калган, йортсыз-җирсез бер буйдак, качкын, карак яисә кеше күз алдында иң түбән сыйфаттагы бәндә итеп кабул ителә иде. Синең лашманчы икәнеңне белә калсалар, сөйләшергә дә теләмиләр, тизрәк яныңнан таярга тырышалар. Лашман сүзе дә ят немец теленнән килгән "лашмасман", ягъни "урман кисүче кеше" мәгънәсен аңлатуны беркем белми дә, бу турыда уйламый да.

Әчке кичерешләргә килгәндә, Фәсхетдиннең хәле барысыннан да авыррак иде. Нигә соң аның язмышы тормышка аяк басмас борын шулай булып чыкты? Морза кызын яратканга гынамы? Кыз үзе дә ярата лабаса аны. Шулай булгач, нинди гөнаһлары бар? Ник аларны шулай ерткычларча аердылар? Ни өчен бу дөньяга яратылган кешегә үз теләген, өметен тормышка ашырырга ирек бирмиләр?

Заһидә үзен ничек хис итә икән хәзер, бичара? Нәрсәләр уйлый икән? Морза нәселе, аксөяк зат булуы белән кара халыкка өстен карарга, аларны санга сукмаска икәнлеген Заһидәгә ана сөте белән бергә сеңдерделәр, әлбәттә. Шулай да ул Фәсхетдинне яратты. Бу аның яшьлек омтылышы, яшьлек ялгышы гына булмагандыр бит?

Әй бу ялгышлыклар! Нишләп кенә соң мәчет манарасы да күренеп торган Батыр авылына барып житмәделәр алар? Бигрәк ваемсыз булдылар шул. Инде кавышу насыйп булмас микәнни? Алдыңа килеп баскан бәхетне дә кулдан ычкындырган егет егетмени инде ул?

Вакыт-вакыт бу вакыйгалар аның белән түгел, ә кемдер башка кеше башыннан үткән шикелле тоелды Фәсхетдингә. Әмма күңелендәге

хәсрәт төене туктаусыз тынгысызлап торды. Ичмаса, авылга кайткач та, Заһидә белән очрашырга жай чыкмады. Дөресрәге, ана да, Заһидәгә дә ирек бирмәделәр.

Шул ук вакытта, хәзер ялгыз калган карт ата-анасының исәнлеге, ярдәмгә мохтаж чакларында үзләренә терәк булырдай бердәнбер улларының шундый язмышка дучар булуы егетнең жанын теткәләде.

Үз уйларыннан айнып, тирә-юньгә күз салырга өлгермәде Фәсхи, юлдашлары Галләметдин белән Шәйхетдиннен үзенә карата тискәре мөгаләмәләрен тоеп өлгерде. Авылда төп крәстиян эшеннән, ягъни чәчеп-урып яшәүдән аерылган сукбай булуы белән генә түгел, ристан булып танылуы белән дә алардан аерылган иде Фәсхи. Шуңа күрә бу ике егет, аннан шүрләп кенә калмыйча, түбәнсетеп тә карыйлар кебек тоелды.

— Нинди матур көз, егетләр, чикләвек, балан, миләш жыеп урман хозурында йөрүе үзе ни тора! — дип куйды ул, дәшми баручы иптәшләренә сүз катып.

— Урманга барабыз бит инде, жыеп тик йөрерсең, — дип жавап бирде Шәйхетдин дорфа гына.

— Бәлки әле безне дә сыйларсың. Анда безгә, урман кисүчеләргә, норма дигән нәрсә бар, диләр. Ә сиңа, атлыга, норма юк икән. Булса да, атың үзеннеке түгел, тартыр әле.

— Егетләр, без барыбыз да бер камыт кигән кешеләр хәзер. Бергә оешып торсак, әйбәтрәк булыр. Әйдәгез, шул хакта сөйләшик әле.

— Ниен сөйләшәсең анын? Без урман кисүче, син ташучы. Ат белән күп нәрсә эшләп була. Чабата читеккә тиңләшми.

Шулай дорфа сөйләшүче иптәшләре белән Фәсхи артык сүз куертып торуны кирәксез тапты, тагын үз сагышларына чумды.

Ул арада алдагы олауларның берсе белән бер вакыйга булып алды. Баксаң, кайсыдыр ачык авызның алгы тәгәрмәченең чәкүшкәсе төшеп калган икән. Тәртәсенең тәже ычкынган һәм тәгәрмәче төшеп кала язган. Кәрванның алдыннан да, артыннан да саклап баручы солдатларның жикеренүеннән соң, тиз арада яңадан тәртип урнашты.

Бу вакыйга төш житәрәк булганга күрә, атларны ашатырга һәм ял итәргә әмер булды.

Әле оешырга өлгермәгән лашманчылар һәркайсы үз капчыгыннан ашарга утыргач, күрше арбадан бер олырак кеше тавышы ишетелде:

— Әй, егетләр, менә чишмәдән су алып килдем. Кирәк булса, агызып алыгыз!

Фәсхетдин жамаягын тотып шул якка китте.

— Әссәламегаләйкем, юлдашлар, — диде ул, жиргә кырын яткан өч кеше янына чүмәшеп.

— Вәгаләйкүм әссәлам! — берсе Фәсхигә утырырга ишарәләде. — Кайсы авылдан буласың инде, юлдаш? Ат башындамы, әллә жәяүлеме үзең?

Бу кеше үзе Үтәмеш авылыннан Мәүләтша булып чыкты. Ачык чырайлы, сөйләшергә маһир Мәүләтша көр күңелле кеше икән. — Әнә теге ермакта чишмә булмый калмас дип барган идем, рас булып чыкты. Бер казан су алып кайттым, син дә кирәк хәтле алып эч, иптәшләреңне дә чакыр. Өчегез дә бер авылданмы? Авылдашлар белән бергә булу күңеллерәк ул. Менә мин авылдан бер үзем генә туры килдем. Авыл кечкенә безнең, утызлап кына йорт. Шулай да менә күрше авыл Урсактан килүчеләр белән таныштым. Алар белән бергәрәк булырга исәп. Яшь кешеләргә киңәшем дә ярап куяр, шәт.

— Бу лашман эшенә сине ничек жибәрергә булдылар соң, Мәүләтша абзый? Яшең дә олы күренә.

— И-и, Фәсхетдин! Авылда һәр кеше үз урынында. Артык кеше юк. Әйтүләре буенча, беркем бу эштән читтә кала алмый. Баш исән булса, ике ай озын гомер түгел, мин әйләнеп кайткач, башкалары китәргә тиеш булырлар бит барыбер. Менә урак бетте, икмәкләр жыелды, Аллага

шөкер! Өйдә әвен сугарлык, терлекләрне карарлык кешеләр бар. Хур булмабыз, ходай насыйп итсә.

— Карале, кем, Фәсхетдин, син Морзалар авылыннан, диден түгелме соң? Онытып торам икән әле. Анда сездә обжор командасы булган икән ич. Хәмзә морза чакырып китерғән, диделәр. Аның кызы бер ярлы егеткә ябышып чыккан да, качып бару юлларында тотып алганнар икән. Шул хәбәрләр дөресме? Болар дөрес була калса, мин сезнең авыл кешеләре арасында булуымны теләмәс идем. Хәмзә морзагызны әйтәм әле, андый кеше белән каберен якын булмасын. Аллам гына сакласын, ярабби!

## 23

Заһидә беркемне дә күрмәс, беркем белән дә сөйләшмәс булды. Бер көнне Хәмзә морза кызын үзенә чакырып алды да аңа ташланды:

— Йә, сөйрәлчек, әйт, атаңны нинди хурлыкка калдырганыңны беләсеңме син?

Заһидә дәшмәде. Ул инде елаудан узган иде. Атасы дәвам итте:

— Бөтен тирә-якка яман атың чыкты. Ата-ана сүзеннән узмыйча, атаң ничек теләсә, шулай буласын белә торып та, шул йолкыш каракка ияреп киткән бәдбәхетне хәзер кем алсын? Бөтен тирә-якны үз кулында биетеп тоткан атаңның теләгенә каршы барырга ничек йөрәгең житте? Мин сине хәзер балам дип тормам, өемнән куып чыгарырга да күп алмам. Әйдә, йөр шунда хәер эстәп!

Хәмзә кызганнан кыза барды. Кызының җавапсыз басып торуы аның ачуын кабарта гына иде. "Әткәй, минем язмышым синең кулыңда, мине нишләтсәң дә иркеңдә, тәкъдирем шулайдыр инде", дигән җавап ишетсә, әллә дә бераз йомшарыр иде Хәмзә, ләкин кыз тәкәббер рәвештә басып торуында булды, буйсынырга теләген сиздерергә ашыкмады.

Тынлата алмагач, ачуыннан нишләргә белмәгән атасы камчысын тартып алды, аны болгап, кычкырынырга ук тотынды:

— Әлегә кадәр белмәсәң, бел: гомеремдә минем үземнекен кылмый калганым юк әле. Сине хәерчегә бирсәм бирәм, ә ул ристанны, лашманчыны гомереңдә бер тапкыр да күрмәссең! Морза икәнен онытма атаңның!

— Үз кызыңның шулай ук морза нәселеннән икәнен онытма! — диде Заһидә тыныч кына. — Мин үз язмышымны үзем кайгыртырмын. Ярар, әткәй, соңгы хәерчегә чыксам чыгармын, синең өеңдә артык кашык булып яшәмәм! Фәсхетдингә насыйп булмаганмын икән, башка кешене бәхетле итәргә тырышырмын! Әмма синең кеше талап җыйган байлыгыңа кызыкмам!

Бу сүзләрен бик тыныч тавыш белән әйтте Заһидә, Хәмзә бермәл югалып калды. Кызы гурничәдән чыгып киткәч тә, исенә килә алмыйча шактый вакыты үтте.

Әнкәсенә дә үпкәсе зур иде Заһидәнең. Гомере буе кол булып, иренә каршы сүз әйтү түгел, гел аның кубызына биеп кенә яшәде әнкәсе. Кызының йөрәгенә тоз салуын абайламыйча, ул да бер көйне көйләде:

— Балам, кызым, элек яучылар агылып торса, хәзер сине искә алучы да юк. Киресенчә, атаң үзе хәбәр салган кешеләр дә төрле сәбәп табалар, аралашырга атлыгып тормыйлар. Атаң сине иркәләп үстерде, үзең дә беләсең, башкаларга кушкан кебек, сине эшкә дә җикмәде. Бүләген-күчтәнәчен кызганмады. Бөтен кызлардан, тирә-як мулла-ахун, урыс түрәләренең кызлары-хатыннарыннан артык бизәндерде, киендерде. Ә син, рәхмәт яудырасы урынга, аны рисвай иттең, — дип сөйләнә иде әнкәсе.

Бу ихтыярсыз, җебегән әнкәсенең тел төбен яхшы аңлый иде Заһидә. Әнкәсенең тормыш ирегә дигән төшенчәне белмәве бер дә гаҗәп түгел, ә бары көлке һәм кызганыч кына иде.

Әнкәсе әнкәсе инде, ул өлкән буын кешесе. Аның халәте аңлашыла.

Менә абыйсы Якуб тагын. Ни үзен, һи хатыны Нажия җингине яклый белми. Гомерләре шул өй эшенә чумган булыр. Бер тапкыр аягүрә басып, кояш, ай, йолдызларның галәмдә барлыкларын кызыксынып караганнары бармы икән бу бичараларның?

Заһидә белгән барлык кешеләр арасында берләнбер аерылып торган кеше — ул да булса Фәсхетдин иде...

Ләкин егет Заһидәгә ышанычлы терәк була алмады. Бөтен эшне җайлап, башкарып чыгабыз дип торганда гына Ялчек чуашына тозакка килеп егылырга нигә кирәк булды инде? Чәйнәп каптырганны йота алмаган бәндә булып чыкты. Шунын нәтиҗәсенең әче җимешен икесе дә татыйлар хәзер. Зинданга да саксызлыгы аркасында гына эләкте. Лашман хезмәтен ифрат авыр хезмәт, диләр. Ходай ярдәм бирсен үзенә. Исән-сау кайтсын иде инде. И-и, Фәсхетдин, Фәсхетдин! Ходай түземлек белән сабырлык кына бирсен инде. Хәер, әнә атасы нәрсә ди бит: гомереңдә бер тапкыр да күрмәссең аны, ди. Шулай ук булыр микәнни? Шулай булса да, Фәсхетдингә исәнлек, иминлек бир, ходаем! Син, Фәсхетдин, ичмасам, ир кеше, тормышыңны җайлый белерсең, шәт. Менә миңа нишләргә хәзер? Башны элмәккә тыгаргамы? Юк-юк! Аллам сакласын! Кәфер уйларымнан арындыр, ярлыка мине. Атам йортында артык кашык булып яшәгәнче, ярлы-ябагайга чыгып, үз көненне үзен күреп яшәвең артыграк. Тик бу кичерешләремне аңлаучы бәндәсе генә насыйп булса иде. Йа, раббем, үзең хәерле кыл. Тәкъдирен шулай булгач, язмыштан узмыш юк шул инде...

## 24

Лашманчылар кич кунарга тукталдылар. Атларын-арбаларын берберсе янына түгәрәкләп куеп, үзләре барлы-юклы азыкларын тәгам итеп мәж килгән ыгы-зыгыдан соң, арбаларындагы печән арасына чумып, йокларга яттылар. Җылы өйләргә таралып ял итәргә теләмәгән ат хуҗаларын, ыгы-зыгыдан файдаланып, атларын урлап качу очраклары булгалый дигән хәбәр шикләндерде бугай. Көзге аяз төн үзенең сиздерерлек суыгы белән рәтләп йоклатмады да үзләрен, тик барыбер алар атларының кырт-кырт итеп солы ашаган тавышларын тыңлап ята бирделәр.

Иртәгесен иртүк лашманчыларны Каратай урманына алып киттеләр. Анда барып житкәч, яңа килүчеләрне элегрәк монда эшләгән лашманчылардан калган зимләнкәләргә кертеп урнаштырдылар. Җиргә ярым уелып ясалган, кара мунча сыман, ләкин мунчадан күпкә зур зимләнкәләрдә һәркем үз ятагын җайларга, ишеген-тәрәзәсен көйләргә тиеш иде. Көннең калган өлеше шул шөгыль белән үтте. Кемнең балта тотуга осталыгы бар, шуларның тәҗрибәсе ярап куйды монда.

Иртәгесен эш башланып китте. Монда элегрәк киселгән агачлар байтак җыелган икән. Арбаның алдын гына калдырып, өстенә ботаклардан арындырган дүртәр сажинлы бүрәнәләрнең юан башын кучәргә салып бәйләргә һәм аны Идел ярына сөйрәтеп барырга кирәк икән. Ара ерак, егерме чакрымнан артык. Таулы-чокырлы юлдан барып кайтканчы көн уза да китә. Әгәр кичennән төяп куйсаң, иртәрәк кузгалырга да була, ләкин алай өлгерү авырга килә. Көне буе җәяүләп кырык чакрым араны узу да нык ардыра. Шул арада атка азык әзерләргә дә кирәк бит әле. Үзенә һәм җәяүле иптәшләренә дә ашамлык алып кайтырга кирәк.

Урман кисүчеләр исә пар-пар булып, йөз еллык имәннәрне балтапычкы белән кисеп егарга, ботаклардан арчырга, аларны дүртәр сажин итеп туракларга, төяп китәргә җайлы ачык җиргә кәүсәләрне тәгәрәтеп өяргә тиеш иделәр. Монда агач басу куркынычыннан, башка бәла-казадан аеруча сакланырга туры килә. Шуңа күрә һәр парны бер-берсеннән шактый ерак арага куеп йөрүче махсус дисәтник бар иде. Ул эшләгән эшне дә кабул итә, норма тутыруны да тикшереп тора иде. Гадәттә

дисәтник итеп урысларны куялар һәм аны ришвәт биреп тә үз файдаңа аударырга, ягъни үтәлмәгән норманы үтәлде, дип яздыру мөмкин түгел иде.

Көннәр шулай үтә торды. Лашманчылар әкренләп йончый, арый башладылар. Монда авыруларга да бернинди ташлама юк иде. Бер зимләнкәдә бергә торучы егермеләп кеше ике-өч төркемгә бүленеп бергә аш пешерергә күнектеләр. Араларында авыру-фәлән була калса, аны кизү итеп калдыра алалар иде. Ләкин ул авыру өчен алар үзләре эшләргә, норманы аның өчен дә үтәргә тиешләр иде.

Киң күңелле кеше иде Мәүләтша. Үзе һәрвакыт ачык чырайлы, арган-талчыккан чакларда да кеше күңелен күтәрә белә торган адәм.

Көннәрдән бер көнне яңгыр катыш җепшек кар яуды, җил чыкты. Лашманчылар эшли торган мәйданда, урман сирәгәеп калгангамы, ачы җил үзен сиздерә иде. Туңып-күшегеп кайтучылар аннан-моннан капкалап, юеш киемнәрен ничек әлакте шулай киптерергә элделәр дә, һәрберсе тизрәк ятакларына аву ягын карадылар. Шулвакытта янып торган мичкә утын өсти-өсти, Мәүләтша үзенең көр тавышы белән сөйли башлады:

— Җәмәгать, исемә төште әле. Минем белән бер кызыклы хәл булып алган иде. Яшь чакларда ниләр булып бетми. Шулай берчакны Сәрия атлы бер кызга күзем төште бит, малай. Ул гәүдәсенең гүзәллеге, буеның зифалыгы, кулларына күз иярмәслек җитезлеге — барысы да килешеп тора инде менә үзенә. Күзәтәм мин моны. Җаен туры китереп сөйләшергә чакырдым. Ризалашты бит.

Зимләнкәдә арырак урнашкан кешеләр берәм-берәм торып, киптерергә элеп куйган киемнәрен җайлаштыру сылтавы белән мич янынарак елыштылар. Мәүләтшаның берара дәшми торуы да тыңлаучыларны кызыксындырды булса кирәк, алар хикәяненең ни белән бетәсен көттеләр.

— Караңгы төшкәч, читән коймалары аша сикереп төштем дә киртә коймасына тереләгән килеш көтеп торам. Менә берзаман өйдән кемдер чыкты. Ә-һә, мин әйтәм, чыктыңмы, былбылым! Баксаң, бу Сәрия чалымы түгел, аның әнкәсенә охшаган. Ул миннән ике генә адым кала туктады да, комганын җиргә куеп чүмәште һәм чыптырдата башлады. Тавышланып һава да чыгарды. Минем үтереп көләсем килә, көчкә түзеп торам. Карчык эшен бетергәч, әгүзе-бисмилласын әйтеп, тәһарәт алды. Мин артык түзеп тора алмадым, пырхылдап җибәрдем, куе үлән арасына тәгәрәдем.

Мәүләтша бераз тын алып, тыңлаучыларга хәйләле күзен йөртеп чыкканнан соң, хикәясен сөйләп бетерде:

— Шуннан соңмы? Шуннан соң минем үз хәлем хәл иде. Теге куе үлән арасы кычыткканлык булып чыкты. Бөтен җиремне кычыткан каклаганга түзмичә, тизрәк аннан чыгып ычкынырга ашыктым. Хәтеремдә, Сәриянең әнкәсе каравыл салып өенә йөгерде бугай. Аннары кулына сәнәк тотып, атасы минем арттан куа чыккан иде, тик яшь кеше, җитмәсә кычыткан да каклагач, кем куып тотсын соң инде?

— Шуннан соң Сәрия белән арагыз өзелмәдеме соң?

— Өзелде. Насыйбы ул булмагандыр инде. Ни хикмәт менә, җәмәгать, үз йомышын һәркем башкара анысы. Әмма, әнкәсе минем алда хәҗәтен үтәгәч, никтер кызыннан күңелем кайтты. Шулай да була икән ул. Хәер, кызлар барысы да бер бит алар, холыклары гына әйбәт булсын. Хәләл җефетем Бибигаян белән тезне тезгә, йөзне йөзгә куеп дигәндәй, утыз биш ел гомер иттек. Өч бала үстердек. Оныкларыбыз бар, Алланың биргәненә шөкер!

## 25

Вакыйгалар Сафиулла мулла фараз иткәнчәрәк барды. Хәмзәнең үзе янына тагын килеп чыгасын ул алдан ук чамалаган иде инде. Үзе заман агышына битараф булып күренсә дә, Сафиулла мулла заманча фикер йөртә, һәр вакыйганы тикшерә, нәтиҗә чыгара ала торган шәхес

иде. Хәмзә морзага карата да аның үз фикере әзер иде. Әйтергә кирәк, тирә-якны тетрәтеп торткан хан заманнарында шул ханнарның иң якын араннары токымы булган Хәмзә морзаның язмышы хәл ителгән иде инде. Монда, билгеле, башлыча урыс сәясәте нәтиҗәсендәге заман үзгәреше төп роль уйнады. Иң куәтле зыян-зарар Хәмзәнең атасы Хәкимҗан морза заманына туры килде. Аның җирләренә урнашкан Биеш урыслары хәзер морзаның кем икәнен дә белмиләр. Ә вакытында алар Хәкимҗан морзаның кул астына, аңа хезмәт итәргә дип килеп урнашканнар иде. Хәкимҗан морза үзе дә ихтыярсыз кеше булып чыкты. Тормышның давыллы дулкыннарына каршы көрәшә алмады. Хатынының фаҗигале үлеменнән соң тиз бирешге. Хәмзә исә, нык холыклы кеше булса да, бабаларының элекке абруен торгызу түгел, үзенең хәзерге дәрәҗәсен дә саклап кала алмаячак иде. Үзе күпме талпынса да, аның хыялын тормышка ашыручысы, дәвам итүчесе, аңа булышучысы юк. Улы Якуб, бабасыннан да йомшаграк табигатьле булганлыктан, токымының дәрәҗәсен саклап бару сәләтенә ия була алмаячак иде. Кызы Заһидә атасы кебек көчле, нык ихтыярлы кыз. Ләкин ул, хатын-кыз буларак, морза токымын дәвам итүче түгел. Бәлки аларны абыйсы Якуб белән урыннарын алмаштырасы булган да бит, әмма ходай тәгалә башкача тәкъдирләгән шул. Шуна күрә, Хәмзәгә хәзер, гади крәстиән баласы дип кимсенмичә, кызын шул гади крәстиәнгә тапшырасы гына кала. Мостафадан да кулай кеше юктыр, дип фикер йөртте Сафиулла хәзрәт. Ике бала атасы булган тол иргә кыз кешенең кияүгә чыгуы гадәти хәл булганга күрә, мондый вак-төяккә әһәмият биреп торуның кирәге бармы икән?

Хәмзә килеп кергәч, Сафиулла мулла аны тиешенчә олылап, ихтирам белән кабул кылды. Бер-берсен элек тә яхшы аңлап килгәнлектән, мәсьәләне кичекмәстән хәл итәргә булдылар.

Ике-өч көн үтүгә Сафиулла хәзрәт белән Мостафа җомга көн иртән иртүк Морзалар авылына юл тоттылар.

Барып кергәндә, Хәмзә кунакларны каршы алырга әзер иде инде. Дога кылып, чәй янына утыруга, тәкәнең башыннан тотарга күнеккән Сафиулла хәзрәт кызны чакырырга кушты. Хәмзә исә, кызым минем сүземнән чыкмаячак, дип маташса да, мулла үз сүзендә торды. Заһидә алар алдына чыгар алдыннан, Хәмзәнең тәкәббер кыяфәтен күзәтеп торучы Мостафа сүз кушарга булды:

— Хәмзә абзый, мин алдан кисәтеп куярга тиешмен: кызың Заһидә минем белән никахлашырга риза булмый икән, аңа да, сиңа да бернинди үпкә белдерергә исәбем юк. Әгәр дә риза була калса, үзем булдыра алган хәтле тыныч тормышта яшәвен тәэмин итәрмен. Моны мин үз өстемә тулысы белән алам.

— Мостафа энем, кызны чакырып карыйк, аның карашын белергә кирәк, — дип сүзгә кушылды Сафиулла хәзрәт.

Заһидә сулыга төшкән йөзен яулык чите белән яртылаш каплаган килеш ишек катына чыгып басты. Аның күзләре, билгеле, иң беренче нәүбәттә Мостафаны капшап алдылар. Озынча түгәрәк битле, хәтфә түбәтәй астында киң маңгае, кара кашы, озын керфеге, икегә аерылып торган киң иякле йөзе бер күз сирпүдә үк чалынды Заһидәгә. Моның өстенә, Мостафаның соры күзләре ниндидер акыллылык балкытып тора иде шикелле.

"Бу агай начар бәндәгә охшамаган, ләкин Фәсхине оныта алырмынмы икән соң?" — Заһидәнең беренче уе шул булды.

"Курыкма, матурым, — диде шикелле Мостафа җавабында шул ук соры күзләре белән, — мин беркайчан да синең үткәнеңә кагылам. Син үз иркеңдә булырсың".

"Әгәр мин үз иркемдә тора алмасам, синең ир горурлыгыңны җимереп ташласам?"

— "Хафаланма, син ир кадерен кадерли белә торган кешегә охшагансың. Хыянәт итү — ул безнең мөселман халкына хас нәрсә түгел".

Аннары кыз Мостафаның күзләрендә: "Минем ике балам бар бит, син аларга мәрхәмәтле ана була алырсыңмы икән?" — дигән ялварулы карашын, алар турында хафалануын тойды.

"Тыныч бул" — диде Заһидә һәм үзенең карашын аска төшерде. Берничә мизгелдә күзгә-күз карашып, шулай аңлашып алулары Хәмзә морза белән Сафи муллага сизелмәгәндер дә, бәлки, әмма бу берничә мизгел ике йөрәк өчен җитәрлек вакыт булды.

Ул арада Сафиулла хәзрәт, үзенең төп вазифасын үтәү рәвешендә озын гына вәгазь укырга кирәк тапты:

— Кызым Заһидә, улым Мостафа, икегезнең дә, игътибар белән тыңлавыгызны сорыйм. Без, кызым, сине ошбу Мостафага димләргә дип килдек. Ишетүем, белгәнем буенча, кызым, туп-турысын әйтергә кирәк, синең ниятең башкачарак булган икән. Бу омтылышыңны гаепкә алмастан, фәкать аны үз мәнфәгатеңне үзең яклый алырдай дәрәҗәгә ирешкән кыз алымы дип бәһалар идем мин. Ләкин, үткән эшкә салават дигәндәй, хәзер үз көнеңне үзең күрер вакыт җиткән. Шуңа күрә, атаң-анаң һәм үзең белән сөйләшмәстән, аларның вә үзеңнең ризалыгың алмастан борын, кызым, синең җавабыңны ишетүдән элек, мин Мостафа турында, аның көнкүреше, гамәле турында берничә сүз әйтергә мәҗбүрмен.

Бу һиммәтле сүзләреннән соң хәзрәт, читкәрәк китеп булса да, никах турында үзенең фикерен бәян итәргә кирәк тапты:

— Никах ул, балалар, ир белән хатынның икәү бергә кушылып тора башлауларына гына сәбәп түгел, ә тормыш барышында туган авырлыкларда бер-береңә ярдәмче терәк булуга ант итү тантанасы дип тә санала. Язмышлары бер-берсенә йөкләтелә...

Аерым әйтергә кирәк, тормышның иң мәшәкатьле, иң авыр йөге ирләр өстенә йөкләнгән. Мостафа углым, әгәр шул вазифаларны үтәрлек булсаң гына, син үзеңне никахка керергә лаеклы дип исәпли аласың. Ләкин никахлы хатынга да бик зур бурычлар йөкләнә. Ул тормыш-көнкүреш җиһазларын, әсбабларын иреннән сорарга хаклы булуы белән бергә, булганына шөкерана кылырга, өйдәге мәхәббәтне, көнкүрешне булдырырга, учагын тәртиптә сакларга тиеш...

Ир белән хатынга үзләренең ата-аналарына карата мәрхәмәтлекләрен саклау, ярдәмчел булу лазем...

Бала тәрбияләү авыр, мәшәкатьле вә татлы эш. Адәм баласының тормыш мәйданында тоткан дан вә мәртәбәләрнең яисә түбәнчелекнең башы — аңа әдәп-әхлак яки начарлык нигезе салган ата-анадыр, аларның тәрбия җимешедер...

Ата — тормыш авырлыгын үз җилкәсендә күтәреп, җимешен сыйфатлы итеп үстерүче бакчачы. Шуңа күрә дә ата-ананы рәнҗетмәү, аларның ризалыгын алу, картаймыш көннәрендә тәрбия кылу — балалар вазифасы...

Кеше күңеле башка кеше күңеленә ачкыч ул. Бөтен вакыйгалар кешенең карашыннан башлана. Карарга ярамый торган нәрсәләргә күзләр йомык булырга тиеш. Күрсәтергә ярамаган әгъзалар томаланган булсын. Шәригать хәтта колак алкалары күренеп йөрүне дә мәслихәт итми...

Шундый озын нәсихәттән соң, Заһидәне күндерергә күп кирәк булмады, тиешенчә никах мәҗлесе, аннары зур булмаган туй тантанасы үтте һәм яшьләрне авылларына, Балыклыга озаттылар.

Бу — 1751 елның кырлач ае булып, декабрь ахырлары җитеп килә иде инде.

## 26

Бер ай да эшләп өлгермәделәр, бәхетсезлек килеп чыкты. Кем белән диген әле — бөтенесен рухландырып торучы Мәүләтша абзый белән. Каратай урманы калын урман ул. Аның хәтта эре-эре имәннәре дә Иделнең уң як ярында сирәк булган сөзәк итәгенә кадәр җәелеп үскәннәр.

Монда бәян ителә торган вакыйгалар вакытында лашманчылар тарафыннан ул урман киселә барып, Иделдән гаять ераклашкан, Сөйки тауларына кадәр барып житкән иде инде. Әле үрле, әле сыртлавыклы тау араларында урман кисү аеруча игътибарлы булуны таләп итә. Хикмәт шунда ки, агачның күбрәк ботаклы, авыррак ягы башлыча кояш ягына караган булса, кояшсыз билдәү астырларында аның кәүсәсе үк кире якка авышып үсәргә мөмкин. Ә озын агачларны екканда алар, жиргә бөтен кәүсәләре белән килеп төшмичә, күрше агачка тәрәлеп, ярым егылган хәлдә калу куркынычы бар. Шул рәвештә бер агач егылмыйча калып, аның өстенә икенчеләре дә өстәлсә, эш бөтенләй харап булуы мөмкин.

Агачның егылу юнәлешен гадәттә дисәтник билгели. Аннары кисүчеләр бу юнәлешнең каршы ягын озын-озын колгалар белән терәтәләр һәм кисәргә керешәләр.

Бу очракта шулай булып чыкты да. Мәһабәт юан бер имәнне екканда ул, авырлыгы белән алдан билгеләнгән юнәлешкә аумыйча, икенче якка егылды һәм киң ботаклары белән күрше имәнгә терәлеп калды. Ул арада дисәтник килеп чыкты. Үзенең гаебен аклар өченме, ул урманчыларны аты-юлы белән озаклап сүккәннән соң, икенче агачны да шул юнәлешкә каратып кисәргә кушты. Янәсе, икенче агач үзенең авырлыгы белән беренчесен дә аударырга тиеш иде. Бу — тыелган ысул булса да, лашманчылар карыша алмадылар. Ләкин икенче имән дә терәлеп калды. Хәзер егылмаган агач башына менеп, тоткарлап торучы ботакларын кисеп төшерүдән башка әмәл калмады. Бу бик хәтәр эш иде. Ботаклардан арындырырга дисәтник берничә таза егетне куйды. Арада иң тәжрибәле диптер инде, Мәүләтшаны да билгеләде. Мәүләтша агачка менеп эшләүчеләргә астан киңәшләр биреп торды. Ярым ауган килеш терәлеп калган ботакларны арчыйсы бар, ә ул ботаклар гаять юан, йорт бүрәнәләреннән һич калышмыйлар. Аларга сузылыр өчен башта терәлмәгән ботакларны кисәргә кирәк. Берничә егет шуларны ботарлый торгач, терәлеп торучы имәннәр урыннарыннан авышып, куркыныч тудырып тордылар.

Мәүләтшага ботак кисүчеләрнең барысын да күреп-күзәтеп, агачларга якынрак ачык жирдә торып, әйтеп тору кирәк иде. Шул ният белән ул тагын да якынрак килеп, ике егеттән кала башкаларына саклык белән генә төшәргә кушты. Әмма шул мизгелдә ярым егылган имәннәр шатырдый-шатырдый гөрселдәп жиргә аудылар. Зилзилә үзенең юлында очраган һәрбер нәрсәне очырып алып киткән кебек, хәзер дә эрелеваклы агач ботаклары тирә-якка сибелде. Берара монда тоташ гүләүдән гайре бер тавыш та ишетелерлек түгел иде. Гарасат тынгач та кешеләр бу котычкыч урынга якынлашырга куркып тордылар.

Өем астында өч кеше, шул исәптән Мәүләтша да, һәлак булдылар. Тагын өч кеше гарипләнеп калды.

Бу бәхетсез очракны түрәләр ничек бәяләгәннәрдер, лашманчыларга караңгы иде. Шул ук дисәтник, шул ук мылтыклы солдатлар үз урыннарында йөри бирделәр. Аларның лашманчыларга карата тагын да зәһәррәк кыйланышларын исәпкә алмаганда, барысы да элеккечә дәвам итте. Әйтерсең, бәхетсезлек булмады, өч кеше дөнья куеп, тагын өч кеше гарипләнеп калмады.

Фәсхинең эше һаман агач ташу булды. Көн саен унбиш потлап бүрәнә илтергә кирәк. Кайбер көнне — авыррак, кайсында — жинелрәк. Шул ук егерме-егерме биш чакрым ара. Ул ай буена эшләп алган унбер тәнкә акчасының алты тәңкәсен атына һәм үзенә алган азык өчен тотып кала килделәр. Калган акчасы күчәрдер-тәртәдер, тәгәрмәчтер, дирбиядер сатып алуга китеп бетә язды. Базар бәясе белән таныш кеше булганга күрә, ул мондагы бәяләрнең гаять югары булуын тиз чамалады. Ләкин берни эшләр хәл юк, лашманчыларның башка чаралары юк иде.

Егерме чакрым араны үткәндә ниләр генә уйланылмый? Баштагы мәлдә Мәүләтша абзый аның башыннан чыкмады. Бигрәк тә кеше хәленә керә белгән, шаян-мәзәк сүзләре белән теләсә кемнең күңелен күтәрергә

сәләтле, тормыш сөючән кеше иде шул, мәрхүм. Исәпләсәң, урыс хезмәтендә күпме кеше ятып калды икән? Әле тагын күпмесе һәлак булыр...

Бу агачлардан кораблар ясалуын, шул корабларда урыслар Идел буйлап диңгезгә, шул диңгез ярларында яшәгән халыкларны яуларга баруын, Фәсхинең үзенә генә сер итеп, шул ук Мәүләтша абзый сөйләгән иде.

Әнә, Каратай кешеләре, үзләрен мукшы дип йөрүчеләр, лашман хезмәтенә җиккәч, урыс динен кабул иткәннәр. Шуның бәрабәренә лашман хезмәтеннән азат ителгәннәр. Ләкин моның белән аларның тормышлары җиңеләйгәнме икән соң? Фәсхинең күзәтүе буенча, юктыр. Чөнки алар, лашманчылар кебек үк, Фәсхиләр ташыган агачларны суга тәгәрәтәләр, билдән-күкрәктән суда сал бәйлиләр, шунда ук агачларга кысылып имгәнәләр, һәлак булалар. Бәлки аларга күбрәк түлиләр булыр, әмма аларның йончылган йөзләренә карап, рәхәт яшиләр дигән уй башка да керми.

Вакыт-вакыт, күбрәк зимләнкә тирәсендә, авылдашлары Галләметдин белән Шәйхетдин очраштыралар. Алар да көннән-көн йончыла, бетәшә баралар. Элекке кәпрәюләре юк инде, куыклары шиңгән. Бер очрашуында Шәйхетдин Фәсхигә мөрәҗәгать итеп:

— Фәсхетдин абый, авылдан хәбәр-хәтер алганың юкмы? — дип сорады.

— Мин үзем сездән сорашмакчы идем әле, сез дә хәбәрдар түгелмени?

— Татар Шәмәгеннән Шәвәли кайтырга тиеш, ул безнең авылга сугылыр инде. Бер-ике сүзләп хат язасыңмы әллә?

— Кем ул, ничек кайта, кайчан?

— Озакламый кайтам, диде. Ул монда ярты ел икән инде.

— Сез аны еш күрәсезме?

— Ул бездән ерак түгел, аргы зимләнкәләрдә тора. Без урнашкач, якташларын эзләп үзе килгән иде.

Хат язу чыннан да әйбәт фикер иде. Ләкин кәгазен-каләмен кайдан табасың аның?

Буш кайткан уңайда Фәсхи, әйләнечрәк булса да, кайбер авылларга керә, утынга яраклы ботаклар калдыра, аны икмәккә яисә йомыркага алмаштыра ала, җаен таба иде. Чираттагы керүендә ул бер кешедән кәгазь-каләм әзерләп куюын сорады. Аннары хат язды, җавап көтеп язмады ул, ә үзенең һәм авылдашларының хәлен белдереп язды.

Фәсхетдиннең хат яза белүе лашманчыларга кулай булды. Хат яздыру үзенә күрә ниндидер өмет, ябагай көннәрендә яңалык өсти иде.

Баксаң, лашманчылар үзләренең туганнары белән әледән-әле элемтәдә торалар икән ич! Йә авылдашлары, йә күрше авылныкылар, нәүбәтләре җитеп, бөтенләйгә кайтып китәләр, алар урынына яңа кешеләр килә, яисә, Мәүләтша абзыйның мәетен Урсак егете кайтарган кебек, бәхетсезлеккә очрап һәлак булган, йә гарипләнгән кешеләрне авылларына кайтаручылар була. Алар артыннан якташлары әти-әниләренә, туган-тумачаларына үзләренең исән-саулыгын белдереп хәбәр җибәрәләр, яңа килгәннәр белән сирәк булса да күчтәнәч алалар икән. Ләкин теллəп җибәргән хәбәргә караганда хат юллавы барысының да күңеленә хушрак килде. Әле бер авылдан, әле икенчесеннән хат яздырып җибәрүчеләр байтак булды. Язды Фәсхи, карышып тормады. Мондый үтенеч белән килүчеләр арасында төрле кешеләр очрый иде. Бер яшь егет, мәсәлән, үзенең юк кына маясыннан каклаган каз боты алып килде. — Фәсхи абый, миңа да бер хат яз әле, — диде ул тотлыга-тотлыга. — Мин әйтеп торырмын, син яз!

— Йә, әйт, алайса, нәрсә языйм?

— Менәтерәк, әнием Шәмсенурга иң әүвәл күп сәлам диген. Аннары Фәхрия әбигә әйт, май җибәрсен. Кечкенә сеңлем Раузателҗиһанга чуклы сәлам яз.

— Тукта әле, энекәш, хатка башта барысына да сәлам юллыйлар.

Чуклы сәлам димиләр, ә чук-чук сәлам дип әйтәләр. Ул күп-күп сәлам дигән сүзне аңлата. Майдыр-фәләндер ише гозеренне аннары гына әйтерсең.

— Юк-юк, абый, барысын да мин әйткәнчә яз. Юкса, Фәхрия бирәсе килмәс, ул бик саран карчык, берүк башта ук яз.

— Ярар, яздым, энекәш. Кем артыннан, кая җибәрәсең хатыңны?

— Кем артыннан, дип, язгансың икән, үзең илтеп кайтасындыр инде аны, абый. Безнең Мөрәле авылы моннан алай ук ерак түгел ич. Үзем дә илтеп кайтыр идем дә, җибәрмиләр генә.

## 27

Шулай итеп, Заһидә кияүгә чыгып куйды. Үзенең балачагын, яшьлеген, яшьлегендәге кайнар мәхәббәтен, мәхәббәте белән бергә Фәсхетдинне йөрәгенең иң ерак бер почмагына яшерергә мәҗбүр булды.

Заһидәне барыннан бигрәк, бала сабырсызлыгы белән Мостафаның нәни кызы Фатиха көтте. Әтисенең мулла бабайның кара айгырына утырып, әнкәсен алып кайтырга китүен ишетү белән бөтен тынычлыгын югалтып, зарыгып көтте бала. Ул урамга бер чыкты, бер керде, аш-су әзерләп йөрүче Гайнимҗамал әбисен аптыратып бетерде.

Мостафа яшь хатыны белән кайтып кергәндә каршы алучы да иң беренче Фатиха булды:

— Әнкәй! — дип, туктар-туктамас чанага ташланды кызчык, йөгереп килгән уңайга чана үрәчәсенә күкрәге белән бәрелүен дә сизмәде, ике кулын сузып, Заһидәгә омтылды. Тегесе баланы сузылып кочагына алды, шуннан соң гына җиргә төште.

— Әнкәй, ник болай озак кайтмыйча тордың? Мин сине бик-бик сагынып көттем бит.

— Вакытым булмады шул, кызым, эшем бик күп булды, — дип акланды җавабында Заһидә, кызны сөя-сөя.

— Әнкәй, инде син бер дә, бер дә китмә, яме? — дип иркәләнде бала.

— Ярар, кызым, ярар, бер дә китмәм.

Бу күренешне күзәтеп торучыларга, бигрәк тә Мостафага ямансу булды. Алар күзләренә ирексездән бәреп чыккан яшьләрен яшерер өчен әледән-әле йөзләрен читкә бордылар. Заһидәнең кызчык белән чын күңелләннән мәш килүен карап тору тынычлык бирә, өмет тә кабыза иде.

Фатиха әнкәсенә үзенең әтисе бүләк иткән агач курчагын, ат ябагасыннан ясаган тупчыгын, чуерташларын, кабырчыктан тезгән муен төймәләрен күрсәтеп мактанды. Кулына тоттырган алмага ифрат та куанды, әмма әнкәсен үз яныннан җибәрмәде, йокларга да аның белән генә ятарга риза булды. Ара-тирә сискәнеп, әнкәсенең йомшак, кайнар күкрәген тойгач, аркасыннан кагып иркәләгәч кенә тынычланып, йокыга талды.

Иртәгесен кияү мунчасы ягылды. Мунча чоланына кереп утыру белән Мостафа Заһидәгә сүз какты:

— Кил, син дә утыр әле, Заһидә, башта бер әйбәтләп сөйләшеп алыйк.

Болай да ир кеше белән гомерендә беренче тапкыр мунча керү йоласыннан оялып торган Заһидә иренә якынайды.

— Минем сиңа сүзем шул, Заһидә: без әле яшь башламаган. Алдагысын ничек хәл итсәк, шулай булыр, берсенә дә соң түгел. Минем язмышым, балаларым язмышы, үзеңнеке дә синең үз кулыңда. Әгәр, тормыш башлап җибәрсәк тә, яшь алмабыз дип икеләнсәң, әллә дә мине гади ярлы крәстиән дип уйлап, морза кадәр морза кызы булгач, миңа ярәшкәнгә кимсенерлек булсаң, бәлки башлап җибәрмәү хәерлерәк булыр.

— Әйтәсе сүзең шул гынамы?

— Шул гына түгел. Мин синнән олырак булсам да, яшәр өчен көчем-куәтем бар, Аллага шөкер. Сине ошатсам да, яратып өлгерсәм дә, тормышка ачык күз белән карарга күнеккән мин. Син, ике балам өстенә килеп, үз җилкәңә икеләтә күбрәк мәшәкать аласың, шуңа күрә мин сине алдан кисәтеп куярга тиешмен. Әгәр дә башламыйк дисең икән, минем сиңа үпкәм булмас. Яши башламыйча аерылабыз икән, мин гаепне үз өстемә алырга риза.

— Әй, юләрем минем! Юк-бар хәсрәтләр уйлап, башыңны катырма әле, сиңа әйтәм. Әйдә, чишеник, булмаса.

Заһидә шулай сөйләнә-сөйләнә Мостафаның читекләрен салдырырга кереште.

Тормыш шулай җай гына үз агымында бара бирде. Хатынының Фатиханы үз итүе, кызының да "әнкәм" дип өзелеп торуы Мостафаны бик тә куандырды. Тик менә Галимҗанның гына әнкәсенә бик исе китмәде. Күбрәк вакытын ишегалдында, ат янында булырга тырышты. Үзләрендә эш бетсә, Гайнулла бабаларында кайнашты.

Җирән бияләре матур булып үсте аларның. Галимҗан һәрвакыт аның янында булганга күрә, ат аны кешнәп көтеп ала, үзен иркәләүне, чистартуны ярата, ялын, койрыгын тараганда рәхәтләнеп тора иде. Галимҗан әкрен-әкрен атның сыртына кулын сала, аннан күкрәге белән ята торгач, атлана да башлады. Өч яшьлек тай хәзер атланып йөрерлек ат булып өлгерде. Гайнулла абзый белән Мостафа киләсе язга аны сабанга җигәргә мөмкин булыр дип уйлыйлар иде инде.

## 28

Урман шаулавы күңелгә һәрвакыт ниндидер шомлылык китерә. Урман эче җилсез, тыныч булса да, өстә — баш очында һәрвакыт диярлек тоташ гүләгән тавыш ишетелеп тора. Әйтерсең, сиңа әле килеп житмәгән, ләкин менә килеп җитәр, бөтереп алыр һәм андагы мәхшәрнең нәкъ уртасына китереп тыгар сыман ниндидер илаһи көч бар. Бу гүләү беравык тынып торгандай була да аннары яңа көч белән куәтлерәк шауларга тотына.

Ә урман авызында, лашманчылар зур агачларны екකач сирәкләнеп калган кишәрлекләрдә мондый гүләү юк диярлек. Сирәк агачлар арасында уйнаган үтәли җил, юнәлешен үзгәртеп, әле бер, әле икенче яктан китереп бәрә, җирдә яткан кар бөртекләрен өереп ала да биткә сибә, муенга китереп тутыра, җиң очларына керә.

Бүген җил бигрәк тә ачы иде шикелле. Әллә Фәсхигә генә шулай тоелдымы? Алай дисәң, башкалар да йә яннары белән борылып атлыйлар, йә битләрен бияләйләре белән капларга тырышалар.

Кышкы юлга төшеп, арбаларын чанага алыштыргач, урман ташучыларга әлегә илтә алмаган иң юан имәннәрне ташырга кирәк иде. Бу дүртәр сажинлы агачларның авырлыгы егерме-егерме биш потлап булганга күрә, бер чанага мичәүләп ике ат җигелә һәм аны ике йөкче илтә иде. Мондый гаять катлаулы, хәвефле эш аерым сак булуны таләп итә.

Шундый юан имәннәрне алып барган чагында юлның кыйгач бер җирендә олаучылардан берсенең чанасы ауды. Агачның түмәрле башын үрәчәсез чанага салгач та, аны аркан белән бәйләп, кат-кат беркетәләр һәм боргычлап куялар. Бу олауның боргыч борысы нечкәрәк булган, ул сынган һәм аркан бушаган булып чыкты. Шуңа күрә, чана барышында бүрәнә урыныннан авышкан, берьякка кыйшайган һәм юл кыйгачында чананы аударган иде.

Бер табанын күтәреп кырын яткан чананы янадан бастырыр өчен зур көч кирәк иде. Мондый вакытларда бер-бер артлы тезелгән олаучылар бергә җыелышалар һәм кумәкләшеп чананы янадан урынына бастыралар. Аннары агачны күтәреп чанага салалар. Андый очракларда, элек-электән

килгән гадәт буенча, лашманчылар гына түгел, аларга каршы очраучы бөтенләй ят кешеләр дә ярдәмгә киләләр.

Бу юлы да шулай булып чыкты. Юан имәннең арканын чишеп, күмәк көч белән казыклар ярдәмендә аны янадан чанага салып маташканда, каршыга килүче бер көрмәле чана килеп туктады. Аннан яшь кенә урыс төште һәм сүзсез генә лашманчыларга ярдәм итәргә кереште. Бүрәнәне күтәргәндә бу урыс, төркемнән көчен бер итәр өчен, фәрман да салды:

— А-ну-у, взяли!

Бу тавыш Фәсхигә таныш тоелса да, аның кем икәнен абайламады ул. Бүрәнәне чанага салгач та олаучы урыс, аны үзенчә бер алым белән бәйләп бирде, казыкларның юан башыннан борыслар кисте һәм ике яктан боргычлап куйды.

Фәсхи башын күтәреп караса, теге урысның китмичә үзен күзәтеп торуын чамалады. Таныш иде аның йөзе, тик киеме белән генә ят кешегә охшаган иде. Тегесе дә бермәл карап торганнан соң:

— Пасхи, ты ли это? — дип аны кочаклап алды.

— Митри, синме бу? — дип, Фәсхи дә аны каты итеп кочагына кысты.

Бу очрашу җыелышып торган лашманчылар өчен гаҗәп күренеш булды. Зур якалы озын бөрмәле тун, бүре тиресеннән тегелгән колакчын бүрек, аякларына җылы кара киез итек кигән бу урыс белән башына мескен бүрек кигән, юан итеп сарык йонынннан бәйләнгән шарф чорнаган, якасыз кыска бишмәт өстеннән зәңгәрсу эзәр бәйләгән, сырган чалбарлы һәм тула оек белән чабата кигән лашманчы татарның, әле урысча, әле татарча сөйләшә-сөйләшә, кат-кат кочаклашулары күбесе өчен гомердә күрмәгән-ишетмәгән могҗиза иде. Урысларның татар кешесе белән ерактан торып, тәкәббер мөгамәлә итүләренә күнегеп беткән лашманчылар күз алдында ничек шулай бертуганнар кебек күрешергә мөмкин? Лашманчыларның башына сыймас хәл иде бу.

Ике дус исә, тирәдәге кешеләргә әһәмият бирмәстән, берничә сүз белән бер-берсенең хәлен белештеләр. Тиз арада тагын очрашырга сүз куешып, икесе ике якка кузгалдылар.

Урыс белән очрашу вакыйгасы лашманчылар арасында төрле гайбәт тудырды. Берәүләре элек тә Фәсхинең чын крәстиән түгел, ә афәткә дучар ителгән мулла малае яки берәр татар түрәсенең нинди дер сәбәпләр аркасында өеннән куылган улы дип фикер йөртсәләр, икенчеләре урыс малае, тик, татар марҗасыннан туганга күрә, атасы кабул итмәгән бер бәндә дип уйладылар. Һәрхәлдә, Фәсхетдин, күбесе надан авыл крәстияннәренең фикерләвенчә, нинди дер аңлашылмый торган аерым бер кеше иде. Теге урыс белән очрашудан соң, Фәсхи бөтенләй серле кеше булып китте: аңа карата, бер яктан, ихтирам артса, икенче яктан, бигрәк тә якыннан аралашырга туры килгән кешеләр тарафыннан читләтү дә артты. Хәзер аны бик күпләр күреп, тагын да күбрәкләр ишетеп белә иде инде.

Берничә көннән соң кичке караңгы төшәр алдыннан Дмитрий Фәсхине зимләнкәсеннән эзләп тапты. Ул аны кантурга алып китте.

Дмитрийның тормышы Фәсхи белән аерылганнан бирле шактый үзгәргән булып чыкты. Аны, татар телен белгәнгә күрә, лашманчыларга табиб итеп билгеләгәннәр икән. Бу эштә ул әле бер ай чамасы гына булып, лашманчылар белән танышып йөри икән.

Дмитрий һәрвакыттагыча ачык чырайлы, шат күңелле иде. Фәсхине чәй белән сыйлый-сыйлый, ул һаман үз мәшәкатьләрен сөйләвендә булды:

— Мина зур участок бирдиләр, ун точка. Тетюшеводан алып до Теньков. Кругом урман кисалар. Кругом несчастные случаи, агач баса. Мин тиеш контролировать безопасность работы. Мескен татарлар куп калечатся. Условиелар юк. Татарлар неграмотный, кубрагы молодежь. Безопасные приемы работы не знают. Курсатучылар юк, показывать некому.

Дәшми генә тыңлап утырган Фәсхигә карап, сүзен бүлеп туктадып калды.

— Постой, мин хаман о себе да о себе. Син ничек яшисен? Эш авырмы? Айда, син хазер силә, рассказывай! Как дома? Твои старики, то есть атан-анан исяннармы? Давай, силя как другу, — диде ул Фәсхинең иңбашына кулын салып.

Фәсхи башта теләр-теләмәс, аннан ачылып китеп лашман тормышын тасвирлап бирде. Әлеге хәвефләрнең монда да булуын ачынып сөйләде.

— Шул килеш кенә барса, бу хезмәткә түзеп булыр иде, —дип нәтиҗә ясады ул үзенчә. — Тик минә өйдә калган картларның хәлен белә алмау эчне пошыра. Исәннәрме алар, хасталармы, бер хәбәр дә ишеткәнем юк. Аннары Заһидәнең язмышы да миңа билгесез.

Фәсхинең ярым сораулы бу сүзләренә җавап биреп тормастан, Дмитрий үзе сорады:

— Син монда тагын купмы эшлярга тиеш?

— Күпме дип... язга хәтле инде...

— Вот что, Пасхи, мина кучер полагается. Мин буду ходатайствовать. Сине кучер итармын. Эшен авыр булмас. Тиешле акчан алырсын. Расходларын булмас. Ата-аналарын турында белешербез. Совсем авылына кайтара алмыйм, извини, не в моих силах.

Дмитрий әйтәсе хәбәренең иң аянычлысын ахырга калдырган икән. Фәсхине озатырга чыккач кына, аның күзенә туры карамыйча, күңелсез тавыш белән әйтеп куйды:

— Невестан турында... Заһиданы оныт инде. Атасы аны ике балалы бер ирга кияуга бирде.

## 29

Моннан ары, киләбе чуалган кебек, Хәмзә морзаның тормышы өзлексез бутала барды. Иң элек, көне-төне авыр хезмәтне күтәрә алмыйча, килене Нажия хасталанып китте. Фәсхетдиннең атасы Фәезхан картны карчыгы Фатыйма белән бергә куып җибәргәннән соң, үзенә генә калган авыр хезмәт сындырды Нажияне. Хәмзәнең авыр холкын белгән авыл кешеләре аңа эшләргә бик атлыгып тормадылар. Башка авыллардан да хезмәтчеләр яллап карады Хәмзә. Тик алар да, ач тамагым, тыныч колагым, дигән кебек, озак тормыйлар, китә баралар иде. Терлекләрне карарга улы Якубка яисә еш кына үзенә туры килә иде. Бетмәстөкәнмәс йорт эшләренә кереп баткач, сату-алу кәсебе дә артка кала башлады, сатарга алган малы келәтләрендә ята бирде. Ә бу инде файда китерү түгел, аның кесәсенә зыян сала иде.

Көннәрдән бер көнне улы Якуб тик торганнан чәпченеп китте. Чанага тирес төягән чагында ул кулындагы сәнәген ачу белән тиреслеккә кадады да ныклы тавыш белән әйтеп куйды:

— Әткәй, җитәр миңа корт кебек тирестә казынып ятырга! Мине башка чыгар!

— Нәрсә?

— Гомерем буе бер кирәкмәгәнгә бил бөгеп, бөкре чыгарып яшәгәнче, үз көнемне үзем күрим, ичмасам. Әнә, көне-төне эштән арынмаганга күрә, җәмәгатем бала таба алмаслык хәлгә килде. Хәзер менә урынга ук егылды. Җитәр, әткәй!

— Син үз урыныңны белеп саташасыңмы, әллә белмичәме? Бу хуҗалыкны кемгә калыр дип уйлыйсың син? Синең үзеңә түгелмени? Син минем бердәнбер варисым икәнлегеңне яхшы беләсең. Рәхәтенә чыдый алмыйсын.

— Рә-әхә-әт, — дип сузды Якуб, — рәхәт булса, Заһидә дә ике балалы иргә китеп бармас иде әле. Түзәргә чамасы калмаганга күрә, өйдән чыгып ычкынды ул. Бик рәхәт икән, әнә, Мостафа кияүеңне чакыр. Ул мал-мөлкәткә мохтаҗ кеше. Кинәнсен әйдә!

— Кирәк икән, ал тагын бер хатын. Балалы да булырсың, өйдә

хезмәтче дә булыр. Яшь чагында ике хатын күп түгел ул.

— Сиңа шул бушлай эшләүче кирәк. Сиңа мал булсын, бүтәннәрнең башыннан йөрергә, аларны бөгәргә кеше булсын. Җан азыгы да бар дөньяда. Ә сиңа ул ят нәрсә, син мал өчен кызың белән мине генә түгел, үз җаныңны сатарга да риза.

Шул сүзләрен тезә-тезә, Якуб капкадан ук чыгып китте.

Хәмзә уйга калды. Бу тормыш ник аңа арты белән әйләнергә тора соң әле? Кая төртелмә, һаман артка бара түгелме?

Ләкин Хәмзәне тиз генә сындырырмын димә. Морза ич ул. Уйлый торгач, чыннан да кияве Мостафа белән сөйләшеп карарга булды.

Мостафаның ярлы гына өендә тынычлык, уртак фикер хөкем сөрә иде булса кирәк. Көтмәгәндә килеп кергән Хәмзәне кияве дә, кызы да ачык чырай белән каршы алдылар. Чәй янында утырганда уллары Галимҗан гына, дәшми-тынмый киенеп, ишек алдына чыгып китте. Кызлары почмак якта утырды бугай, шулай ук башка-күзгә күренмәде. Димәк, инсафлы балалар. Бераз утырганнан соң, Хәмзә мәртәбәле генә аларның тормышлары белән кызыксынган булды. Ашау-эчү якларын, утын-печәннәре барлыгын белеште:

— Барысы да җайланып килә бугай сезнең, балалар, — дигән булды ул. — Тик минә йортыгыз кечерәк шул. Монда дүрт кеше яшәрлек түгел. Әллә, мин әйтәм, кияү, улыңны миңа биреп җибәрәсеңме? Беләсез, торыр урын иркен. Бала атлар тирәсендә кайнашырга ярата бугай. Атлар, сыерларны карап торыр. Хәленнән килгән кадәр олыларга ярдәм итәр. Ашатырмын, киендерермен үзен. Хур булмас. Кеше арасында "морза хезмәтчесе" дигән аты таралыр.

Мостафа бу сүзләрне ишетү белән ялт итеп Заһидәгә карап куйды. Заһидә исә, атасының кирәк чагында йомшак сөйләп катыга утырта торган гадәтен белгәнгә күрә, бер мизгел генә елмаеп куйды да ире өчен үзе җавап бирде:

— Әткәй, сиңа биреп җибәрерлек артык балабыз юк безнең. Галимҗан үзебезгә дә бик кирәк. Тыштагы бөтен эшләрне ул башкарып килә. Аты белән аны аерсаң, Галимҗанга көн бетте дип уйла инде.

— Мин синнән сорамадым бит әле, кызым.

— Бабай, кызың Заһидә мин уйлаган сүзләрне әйтте. Чит-ят авылга биреп җибәрергә иртә әле малайга. Ул чыныгып өлгермәгән бала. Авыр хезмәткә иртәрәк. Әнә, әнкәләре әлиф өйрәтеп маташа үзләренә. Икесе дә тартылалар. Үзебезгә артык бала түгел. Без аны сиңа бирмәбез инде, бабай, күңеленә авырга алма берүк.

Икенче зур бәла һич көтелмәгән яктан килеп чыкты. Көн язга таба әйләнә башлаганда гына олысның земский нәчәлниге господин Садовников чакыртты. Яхшы мөгаләмә күрсәтеп, ул морза белән озак кына сөйләшеп утырды. Хәмзәнең күпме җире барын, анда нәрсәләр чәчүен сорашты. Бәрәңге уңышы белән кызыксынды. Беррәттән, Чирмешән елгасы ярны ашап, күпме җирне әрәм итүе турында сүз кузгалды. Бу зур булмаган елга чуаш урманнарыннан башланып, үзенә тагын берничә инешне кушканнан соң, таудан үзәнгә агып төшүендә Зөягә кояр алдыннан шактый зыян китерә торган елга иде. Язгы ташу вакытында булмасын яки җәен еш була торган яшенле яңгырлардан соңмы, Чирмешән кинәт ташып китүчән һәм вакыты-вакыты белән, ярларына сыеша алмыйча, үзенең болганчык суларын басу-кырларга да җәеп җибәрә иде. Андый чакларда ярлары ишелү, чәчкән иген кырларына зур зыян салуы элек-электән килә торган табигый афәт иде.

Земский нәчәлник Садовников бу хәлне шактый белеп сөйләште. Морзаны берничә дә мәҗбүр итмәстән, билгән җирләрен кабат үлчәп чыгарга, ягъни ревизия ясарга тәкъдим итте. Мондый мөһим һәм мәшәкатьле эшнең Хәмзә файдасына булырга тиеш икәнлеген Садовников әфәнде аерым басым ясап җөпләргә тырышты. Янәсе, Чирмешән елгасы тирәсендәге ташкын басып китәрлек җирләрне һәм яр буе кишәрлекләрне

исәптән чыгарырга һәм шул әмәл белән җир өчен ясак яки имана паен түләүне киметергә мөмкинлекне әйтте. Хәмзә исә бу кармакка эләкте дә, җир ясагын түләмәс өчен ул рәхәтләнеп риза булды һәм шул турыда язылган кәгазьгә кул да куйды.

Әмма бу мәкерле әңгәмәнең нәтиҗәсе соңрак билгеле булды. Иманага керми калган җирләр яр буйлап кына түгел, ә елганың түбән ягында шактый уңдырышлы ясмык, солы, киндер чәчә торган өлешен дә тәшкил итте. Хәмзә бу кадәр җирен тартып алуга каршы торып маташса да, аңа үзе кул куйган язуны гына күрсәттеләр. Үзең риза булдың, янәсе. Аның буйсынмый чарасы калмады. Бу алдауның мәкерлеге тагын да соңрак ачыкланды.

Карлар эреп, җир кибә башлаган көннәрнең берсендә Чирмешәннең нәкъ тигезлеккә төшкән урынында ниндидер кешеләр пәйда булдылар. Алар олау-олау бүрәнә, такта ташыдылар. Тиз арада берничә йорт салып куйдылар. Йортларның уртасында чиркәү калкып чыкты. Анда бер дистәдән артык урыслар килеп утырды. Алар барысы да кара сукнодан төгелгән хөлләгә охшаш киемнән, барысы да Биеш урыслары кебек, озын көрән сакаллы, җирән чәчле иделәр. Кара киемнәре, баксаң, кара сукно тышлы тун икән. Шуңа күрә аларны кара тунлылар дип атадылар. Торган җирләре Каратун* дип атала башлады.

Каратунлылар монда килеп урнашкач, халык арасында төрле имеш-мимешләр таралды. Хәмзә морза өчен иң көенечлесе, аның абруена сугучы имеш-мимешләрдән берсе бигрәк гарьлекле булды. Янәсе, ул урысларга сатылган. Сатылып кына калмаган,ә аларның динен яшерен рәвештә кабул иткән дә, аны тирә-як авылларга таратыр өчен бу каратунлыларны үз җиренә чакырып китергән. Озакламый ул мөэмин-мөселманнарга ачыктан-ачык урыс диненә күчәргә кушачак икән. Үтечле кешеләрнең бурычларын, әгәр урыс диненә күчсәләр, бөтенләйгә кичерә икән. Ә күчмәсәләр, икеләтә түләтергә җыена икән. Шуңа күрә берничә бурычлы кеше, яз кытлыгына карамастан, үтечләрен түләделәр дә. Урыс диненә күчәргә кыстамсын гына!

Урыс даирәләре христиан диненә күчәргә өндәп атасы Хәкимҗанны да, аннары Хәмзәне дә күпме үгетләделәр, югыйсә. Күчкән очракта биләгән җирләрен, аңа өстәп тагын фәлән хәтле җир бирү белән дә кызыктырып карадылар. Ләкин Хәмзә морза, атасы кебек үк, мондый түбәнчелеккә төшүдән ерак иде. Каратунлыларның килеп урнашулары, урысларның мондый сәясәте халык алдында Хәмзә аркасында булды дигән хәбәр таралуы аны гаҗизгә калдырды.

## 30

Дмитрийның Заһидә турындагы ямьсез хәбәреннән югалып калды Фәсхи. Зимләнкәсенә ничек кайтып житкәнен дә сизмәде. Кайтып житкәч, баганага сөялеп, аңына килә алмыйча озак басып торды. Фикере буталган иде аның. Юньләп бернәрсә дә уйларга хәленнән килмәде. Бары тик Батыр авылына тузанлы юлдан житәкләшеп атлаулары гына күз алдына килеп басты.

Иртәгәсен дә, аннан соңгы көннәрдә дә йомшак камыр кебек тот-рыксыз йөрде, ярый әле мичәүле икенче атның хуҗасы — яшь егет Габбас аның хәлен аңлап, юан-юан иманнарне ташыганда бөтен мәшәкать-ләрне үз җилкәсенә алды.

Тора-бара тынычланды кебек Фәсхи. Үз-үзен юатыр өченме, моңая белмәүче, һәр вакыйгадан кызык таба белгән мәрхүм Мәүләтша абзыйның

*Морзалар, Биеш, Каратун авыллары атамаларының килеп чыгышы турындагы риваятьләр тарихи чыганакларга нигезләнеп түгел, әдәби әсәр таләбенә буйсынып кына бәян ителделәр. *Автор искәрмәсе.*

сүзләрен исенә төшерде. Насыйбы ул булмагандыр инде, дигән иде бутай ул. Кызлар барысы да бер бит алар, холыклары гына әйбәт булсын, дигән иде. Аңа да насыйбы чыгар әле, баш исәнлеге кирәк. Фәсхи, тынычлана төшсә дә, Заһидәне оныта алмады, әлбәттә.

Дмитрий сүзендә торды. Ике атна да үтмәде, Фәсхи хәзер аның күчеры булып хезмәт итә башлады. Аның эше Хәмзә морза биреп җибәргән ат белән бергә Дмитрий атын да караудан, ул юлга чыккан чакларында ат башында булу, ягъни аны озатып йөрүдән гыйбарәт иде. Дмитрий аталарында Богородскоеда торганлыктан, Фәсхине дә шунда урнаштырды. Бу зур булмаган агач йортның ишек алдында тагын да кечерәк бер өй булып, алар аны заманча итеп, флигель дип атыйлар иде. Бу флигельдә, Фәсхидән кала, хуҗаларның терлекләрен карау, өй тирәсен җыештыру, мич ягу кебек вазифаларны үтәүче Николай атлы, көрәк сакаллы, гаять аз сүзле бер кеше яши иде. Фәсхине шул урыс янына урнаштырдылар. Ә хуҗалар үзләре, аларда пешекче хезмәтен үтәүче хатын да ачык чырайлылар, кунакчыл юмарт кешеләр булып чыктылар. Дмитрийның атасы Иван абзый Тәтеш өязенә караган Богородское олысының нотариал кантурын тотучы, заманча белемле бер мещан иде.

Нотариал кантурның төрле кәгазь-васикаларны рәсмиләштерә торган бер урын икәнен Фәсхи соңрак аңлады.

Шулай да лашманчыларга дисәтниклар һәм башка урыслар кимсетеп караган шикелле, монда да шундыйрак хәл сөрә иде. Шуңа күрә, Фәсхи алар белән артык аралашырга атлыгып тормады. Гәрчә, моның кирәге дә юк иде.

Дмитрий белән Фәсхигә атнасына ике-өч тапкыр, табибның үз теләге белән дә, чакыру буенча да юлга чыгарга туры килә иде. Чакыру килгәндә бик тиз арада юлга чыгасы булса, Фәсхи көрмәле чанага ике кара алашаны җигеп чыга торган иде. Җизле-чуклы эшлеяле, татарчалап өске ягын алга каратып җиккән, шөлдермәле дугалы пар ат кар буранын туздырып, көрмәле чанада берәр авыл аша узып киткәндә юлда очраган кешеләр туктап юл биреп, ә урыс авылларында зур түрәләрне генә хөрмәт иткән кебек бүрекләрен салып озатып калалар иде. Зур түрәләрчә, шундый купшы пар ат белән килеп туктагач, йортның яки идарәнең хуҗалары Дмитрийны ирексездән ихтирам белән каршы алырга мәҗбүр булалар. Яшь табибка бу бик ошый иде булса кирәк, вакыт-вакыт ул Фәсхигә буран уйнатып чаптырырга куша иде.

Ләкин Дмитрийның эше дә җитди иде шул. Ул барган һәрбер урында диярлек фаҗига, гарипләнү, җитешсезлек, ачлык, авыру, мохтаҗлык хөкем сөрә иде.

Юл йөргәндә калын көрт аша чыга алмыйча, атын туарып җиккәндә яисә өзелгән тәртә бавын җайлаганда битләрен-кулларын өшеткән тәҗрибәсез яшь егетләр бик еш очрап тордылар.

Берсендә табибны, бик тиз килеп җитсен, дип, Тәмте урманның Бүре чокырына чакырдылар. Анда гадәттән тыш хәл булып алган иде. Каяндыр монда килеп эләккән чирмеш лашманчыларының бер төркеме, күбрәк яшьләре, бу авыр хезмәтне башкарганчы, урыс динен кабул итәргә дә өйгә кайтып китәргә дип шаулый башлаганнар. Бу сүз чирмешчә оста сөйли белә торган бер урыс руханиеның боларны үгетләвеннән башланган икән. Ни татарча, ни урысча белмәгән чирмешләргә үз телләрендә матур итеп сөйләүче бу кара киемле кешенең юма теле күңелләренә хуш килгән. Олыраклары исә мондый адымнардан тыйлыгып торырга өндәгәннәр. Ике арадагы ызгыш-бәхәс сугышка ук барып җиткән. Ике көн буена эшкә чыкмый талашкан егетләрне бастырыр өчен солдатлар килгән. Үзара бергәләшкәндә яраланган лашманчыларга солдатлар кыйнап тынычландырылганнары да өстәлгән.

Фәсхиләр килеп җиткәндә бу чирмешләр кайсы кайда ыңгырашып яталар иде. Аларны кичекмәстән дәваларга, яраларын бәйләргә кирәк булды. Бу эшкә азмы-күпме кулы ята башлаган Фәсхигә бер түземсез

малай туры килде. Анының ыңгырашулы сүзләрен аңламаган Фәсхи олырак бер чирмештән сорарга булды:

— Әйт әле, агай, нәрсә кычкыра бу малай?

Тегесе татарча белә икән:

— Кайда сезнең попларыгыз? Хәзер үк чукынам да кайтып китәм, ди ул. Барыбер үләргә, ди. Урыс булсам да, чирмеш булсам да, җир астына бер тигез итеп күмәләр, ди.

Түземнәре беткән бу кешеләр чыннан да кызганыч иде. Фәсхи тагын сорады:

— Өендә ата-анасы бардыр бит. Урыс диненә күчеп кайткач, алар ни әйтерләр?

— Син мөселман кешесе, аңлашып бетмисең, — диде теге кеше. — Без чирмешләр — үзебез урман кешеләре. Безнең аллабыз — урман агачлары. Шуңа күрә, урманга барып гыйбадәт кылырга, аллабызны ризалатырга, аннан кирәк нәрсәбезне сорарга безгә җиңелрәк. Урыс дине тормышка җиңеллек китерсә, юри-марый гына ул дингә күчсәк тә ярый шул. Урманга барып гыйбадәт кылучыларны кем саклап бетерсен? Әллә алласы янына бара ул, әллә гөмбә, җиләк-җимеш җыярга?

Әмма урыс диненә күчү дә тиз түгел икән. "Тавык тәпие" — тәрене үбеп муеныңа тагу, өстеңә "изге су" бөркү — бер эш, анын артыннан "Отче наш" догасын күңелдән ятларга кирәк икән. Ят телдәге бу доганы өйрәнү чеп-чи надан кешеләргә бик җиңел түгелдер.

Бу чирмешләрне чын күңеленнән кызганды Фәсхи. Шундый ук авырлыклар кичерүче татар мөселманнарының күңелләренә үз диненнән ваз кичү турында уй кермәвенә сөенде дә ул.

Икенче җан тетрәткеч хәл татарлар белән булды. Ниндидер сәбәптән бер төркем лашманчыларга ашамлык китерми башлаганнар. Атна буе ач торгач, тәвәккәлләп, тора торган зимлянкаләреннән шактый ерак урнашкан урыс авылына барып чыкканнар. Барып, ашамлыкка алмаштыру өчен утын да төяганнәр. Ләкин, бәхетсезлеккә, урысларның, ниндидер дини бәйрәм көннәренә туры килгәннәр. Бәйрәм сәбәпле эчеп исергән урыслар утыннарын бушаттырганнар, ә ашамлыкны үз диннәренә инансалар гына вәгъдә иткәннәр. Ач кешенең ачуы яман дигәндәй, киткән талаш, сугыш... Кыйналып, яраланып беткән лашманчыларны богаулап, каядыр Себер ягына озаттылар. Бер каторгадан ул мескеннәр икенче — гомерлек каторгага китеп бардылар.

## 31

Фәсхетдиннең әти-әнисенә язган хаты кулдан кулга күчеп, ниһаять, авылга килеп җитте. Үлем түшәгендә яткан Фәезхан картның кулына китереп тоттыргач, ул җанланып киткәндәй булды, күзләренә нур инде. Укый белмәсә дә, хат аңа җан тынычлыгы бирде булса кирәк, һаман аны кулында тотты, ара-тирә сыйпаштырып куйды. Инде теленнән язган булуына карамастан, нәрсәдер әйтергә омтылды. Бөтенләй хәлсезләнгән карт янына ясин чыгарга мәзинне чакырдылар. Ул арада авыру җан тәслим кылды. Бердәнбер газиз улының нәрсә язганын да белә алмыйча, дөньядан китеп барды. Мәетне күмү мәшәкатьләре белән хат тагын укылмыйча калды. Аны әрвахның өче узгач кына укыдылар.

Хатында Фәсхетдин, барысына да тәфсилләп сәлам язганнан соң, үзенең исән-саулыгын, әкренләп эшләп йөрүен белдереп, әти-әнисе өчен кайгыруын, алар өчен җаны көюе турында күбрәк язган иде. Бер-ике сүз белән ул авылдашлары Шәйхетдин белән Галләметдиннең дә исән-саулыкларын белгерткән. Шуннан артыгын язмаган булса да, тегеләр Фәсхетдин турында шактый зур коткы тараттылар. Алар, җәяүле лашманчылар булганга күрә, Фәсхетдиннең хатыннан иртәрәк кайтып төштеләр. Кайтыр алдыннан Фәсхинең урыс табибын йөртү эшенә күчүен белеп өлгергәннәр иде. Бу

хәбәрне алар Фәсхи урысларга сатылган икән, урыс динен кабул иткән, аларга хезмәткә күчкән, шул табиб белән бергәләп башкаларны да урыс диненә өндәп йөри башлаган итеп тасвирладылар. Тәмте урманында эшләүче чирмешләрне дә, имеш, ул котырткан, дип сөйләп йөрделәр. Шул чирмешләр урыс диненә күчеп кайтып киткәннән соң, алар урынына да татарларны җибәрәчәкләр, имеш...

Бу хәбәрләрдән авыл кешеләренең күнелендә Фәсхетдингә карата нәфрәт хисе урнашып калды.

Язгы ташу китү белән үк юлга чыгарга ашыкты Фәсхи. Арбасына үзе хәстәрләгән үрәчәсез чанасын да салып, җир кипмәгәнгә карамастан, Дмитрийнең азрак сабыр итәргә кирәк дигән киңәшен дә тынламыйча, күңеле нәрсәдер сизгәндәй, авылына ашыкты ул.

Юлда очраган вак елга-инешләрне аты белән уза алса да, Шомгатыга кайтып житкәч, күпере сүтелгән, ә яңа күпер сугарга әле иртәрәк булган Зөя елгасы аша үтәргә мөмкин булмаганга күрә, атын Хәмзә морза кибетчесендә калдырырга булды. Көн соңарган иде инде, шуңа күрә абзасы Габделхәй өендә кунарга туры килде аңа.

Атасы Фәезханның вафат булуы турында абзасы әйтте. Бу кайгылы хәбәр Фәсхинең башына тукмак белән суккан кебек тәэсир итте. Мескен атасы, гомере буе тирес арасында хезмәт итеп, бер рәхәт күрмичә дөньядан китеп барды. Үзенә ни мал, ни картлык көненә мая туплый алмады. Иң аяныч — берләнбер улы атасының соңгы сулышында авызына су да сала алмады, гүргә дә индерә алмады.

— Әй, әткәй, әткәй... — дип көенде Фәсхетдин.

— Артык кайгырма инде, энекәш, — дип юатырга тырышты аны Габделхәй. — Алай ук синсез китеп бармаган ул. Язган хатың килеп җиткән. Атаң шул хатны кулында тоткан килеш җан биргән.

— Әнкәй ни хәлдә икән соң, бичара әнкәй...

— Фатыйма абыстай сырхау инде. Күзләре дә начар күрә башлады...

— Бу лашман эше минем бөтен ниятләремне юкка чыгарды шул. Кайгы артыннан кайгыны, бәхетсезлекне ходай биреп кенә тора. Заһидәдән башланган иде...

— Әллә Заһидә турында беләсеңме?

— Беләм. Анысын Митри әйтте...

— Заһидәдән димә, Фәсхи, үзеңнән диген. Ул кыз белән бәйләнешмәгән булсагыз, әллә дә юлың башкача булган булыр иде. Заһидәнең кияүгә чыгуын гаепкә алма берүк! — дип дәвам итте Габделхәй. — Хәмзә морза аңа шундый түзеп тора алмаслык тормыш ясады ки, кызның башка түзәр хәле калмады. Атасы йортында бер көн, бер сәгать тору да аның өчен гүр газабыннан да авыррак булгандыр.

Ярты ел чамасы читтә үткәргән гомерен куып тотардай булып, Фәсхетдин иртүк ашыгып юлга чыкты. Туган авылына килеп кергәч, аңа урамда берничә кеше очрады. Алар белән Фәсхи коры гына исәнләште, һаман өенә ашыкты. Тегеләре дә аны туктатып тормадылар. Хәтта кайберәүләре күрмәмешкә салынып, башка якка борылдылар яисә өйләренә кереп китәргә ашыктылар. Ләкин егет бер нәрсә дә сизмәде. Сизсә дә әһәмият биреп тормас иде.

Өенә килеп керү белән сәкедә ятып торучы әнкәсен күрде:

— Әнкәй, әнкәй! Хәлең ничек, әнкәй?

Карчык яткан килеш кенә күзләрен ачты, тик берни дә күрмәде булса кирәк, үзалдына сөйләнеп куйды:

— Йа, ходаем, әллә бу дөньяда миңа әнкәй дип эндәшүче кеше бар инде. Әллә төшемә генә керәме?

— Әнкәй, төшең түгел бу, өнең. Яхшылап кара әле. Мин бу, улың Фәсхетдин. Синең янына кайттым, әнкәй.

— Улым, синме бу? Чыннан да Фәсхетдин улыммы? Әй, ходаем, бу фани дөньяда сине дә күрәсе бар икән, — дип, әнисе урыныннан торып утырды, улының кулларын, битен, муенын сыпырды.

— Әнкәй, хәлең ничек соң, әллә авырыйсыңмы?

— Атаң үлгәннән бирле саулыкка туя алмыйм шул әле, балам. Әллә дә син кайткач савыгып китәрмен. И, улым, сине күрү шатлыклары атаңа гына насыйп булмаган икән. И-и, көтте, бичара, ул сине, и көтте. Килгән хатыңны кулына тоттыргач та шундый шатланды үзе, шундый куанды...

Озак күрешми торган ана белән улның сүзләре күп иде. Болай гына утырып та, Фәсхетдин әзерләгән аш-чәй янында да, карчыкка күз-колак булып торган күршеләре Фәрхинур абыстай белән дә һаман сөйләштеләр алар. Ата-анасы каршындагы бердәнбер бурычын үти алмавына — аларга картаймышлы көннәрендә игелек күрсәтергә хәленнән килмәвенә Фәсхетдин ачынып утырса, Фатыйма карчыкны улы кайту шатлыгы биләп алган иде. Алар һаман сөйләштеләр дә сөйләштеләр. Үткән тормышларын да искә төшерделәр. Ләкин һәр икесе дә телгә алып сөйләргә теләмәгән фикерләре дә башларыннан чыкмады. Беренчесе Заһидә турында иде. Бу турыда сүз кузгатмаска, улын артык борчымаска, авырткан җиргә кагылмаска Фатыйма карчыкның зирәклеге җитә иде әле. Икенче сорау аның тел очында әвәләнеп торса да, улыннан сорарга базмады. Фәсхетдин урыска сатылган, урыс динен кабул иткән икән дигән хәбәр карчыкка да килеп ирешкән иде. Битен-муенын сыйпаштыруы да, беррәттән, муенына таккан тәресе юкмы икәнен аныклау иде. Берни тапмаса да, бу турыда сүз кузгатырга курыкты карчык. Күрше Фәрхинур абыстайның һәм башка күршеләрнең лашман хезмәте турында сорашмауларына бераз гаҗәпләнде Фәсхетдин, ләкин сәбәбенең асылын белмәде.

Кайтуының өченче көнендә Фәсхетдин үзенең остазы Кәлимулла мулланы күреп сөйләшергә һәм киңәш итәргә дип китте.

Мулла абзый аны чамадан тыш коры кабул итте:

— Урыс диненә сатылган дигән хәбәр дөрескә килә шикелле. Кайтканыңа кайчан, мәчеткә бер намазга да аяк басканың юк.

— Нинди урыс диненә, хәзрәт? Мин сиңа ихтирам йөзеннән күрешергә-киңәшергә дип килүем, ә син мине әллә ничек каршы аласың!

— Фәһемле адәмгә санап, мин сине искә алган саен борчылып йөрим. Ә син анда урыска сатылган, урыс диненә күчкән, башкаларны да үгетләп йөрисең, диләр. Шул дөрес булса, ниң битең белән остазың каршына килеп бастың да, җитмәсә, берни булмагандай каршы сүз әйтергә җөрьәт итәсең!

— Мулла абзый, нindидер нахак бәла тагарга җыенасың түгелме миңа? Мондый мәкруһ эш минем башыма да килгәне юк. Бу нинди гайбәт тагын, йә Аллам!

Кәлимулла мулла йомшарды булса кирәк, ул Фәсхетдиннең лашманда ни күргәннәрен башыннан ахырына кадәр сөйләтте.

Ике аңлы кеше мәсьәләнең асылына тиз төшенделәр. Бөтен гаепләүнең башы юлдашлары Шәйхетдин белән Галләметдингә барып тоташуы билгеле булды.

Димәк, алар белән Фәсхинең очрашасы бар әле. Ләкин бу очрашу гаепсезгә гаепле булып калган Фәсхи кузаллавынча булмады.

## 32

Язгы чәчү дә килеп җитте. Җир кипкәч, көннәрнең берсендә, Гайнулла карт белән Мостафа үзләренең җирләрен карап кайтырга булдылар. Авылдан чыгуга аларны җылы кояш астында дәртләнеп сайраган тургай тавышлары каршылады, җанланган җирдән тонык кына рәшә булып пар күтәрелә иде. Таягына таянган Гайнулла абзый бермәл талгын искән җилгә йөзен куеп, башыннан бүреген салган көе бу манзарага мөкиббән китеп карап торды да:

— Нинди хуш исле бу язгы җир исе! — дип куйды.

Инде уҗымнар да яшелләнеп күтәрелеп килә икән. Юл кырый-

ларында, чалуларда яшел печән-үләннәр калкынган. Әйе, кыр эшләренә тотынырга вакыт.

Иртәгесен үк эш башланды. Көзеннән каты сука үткәрелгән йомшак җирне янадан сөрү җинел иде. Кышын килешү буенча Сафиулла мулла алашасы белән өч имана җирен тиз сукалап бетерде Мостафа. Җирне чәчкәч, тырмалап чыгарга үзләренен Җирәннәре дә булдыра ала. Бу эшне баштан-аяк Галимҗан башкарды.

Чәчү беткәч, Галимҗан дусты Гыйззәтулла белән ат сакларга йөри башлады. Гыйззәтулла Мостафаның туганнан туганы Шәфигулла улы булып, ике малай үзләрен белгәннән бирле дуслар иде.

Шәфигулла ятим үскән Мостафага караганда шактый хәлле яшәде. Чөнки аларның өч имана җирләре бар. Атасы, ягъни Мостафаның атасы Мөхәммәт белән бертуган Ногман абзый моннан бер ел гына вафат булганга күрә, анын иманасы өстенә Галимҗаннан ике яшькә олырак булган Гыйззәтулла туган елында ук иманага кергән иде.

Көнозын йорт эшләреннән бушамаган малайлар, билгеле, төннәрен ат саклаганда йоклап та киткәлиләр. Икәүләшеп яки өчәү-дүртәү бергә ат саклаулар бик күптәннән килә торган гадәт ул. Малайларның җыелышып төнгегә чыгулары, бердән, күнелле булса, икенче яктан, берсе уяу торганда, атларга күз-колак булганда, икенчеләренә черем итеп алу өчен дә җайлы иде, чөнки ходай сакласын, атларны урлап китүләре дә ихтимал. Балалар ат сакларга җәй буе диярлек йөриләр. Һәр төркемнең үзләре сайлаган чалулары, уйсулыклары бар. Аларга монда һәр куак, камышлык, дүмгәк, аулак урыннардагы үрдәк, тәкәрлек оялары таныш. Алар фәлән куак төбендәгеояда ничә йомырка барын, әнкәләре кайчан баса башлаган, кайчан бәбкәләре борыннарга тиеш, кайчан ничә бәбкә чыккан — барысын да белеп торалар. Тик ояларны туздыру, йомыркаларын алу гадәтләре юк.

Сусыл яшел үләнгә тиенгән атлар кышкы азык кытлыгыннан арынала, көрәеп, матурланып китәләр, кышкы ябагаларын коеп бетерәләр.

Ат сакларга күптәннән оешкан бер төркем булып йөрү гадәте абыйларыннан, хәтта аталарыннан бирле килергә мөмкин. Шуңа күрәдерме, Галимҗан белән Гыйззәтулла андый төркемнәргә кушылмадылар. Аларга аеруча сак булырга туры килә, чөнки алар икәүдән-икәү генә, аннары ат караклары яшь атларга кызыгучан икән. Күпме уяу булырга тырышсалар да, йокламый түзеп торуы малайларга авыр, бигрәк тә таң алдыннан үтереп йокы килә.

Караңгы төннәрнең берсендә кечерәк сазлыкта әкрен генә шаулаган камышлар ничектер икенче төрлерәк кыштырдаган кебек булды. Кыштырдый да туктый, кыштырдый да туктый. Кеше яки зур җанвар йөргән кебек. Малайлар, шикләнеп, атларына менеп атланулары булды, камышлыктан бер кеше килеп чыкты һәм боларның артыннан кычкырып калды:

— Бәхетегез, малайлар, сизеп өлгердегез!

Бу вакыйгадан соң алар ике атна буе төнгегә чыкмадылар. Әмма ат саклау әнә шул шомлылыгы белән кызыктыра да бит. Күрәселәре булгандыр инде, әтиләрен күндереп, тагын чыга башладылар. Тик хәзер алар башка урын, шактый ерактагы калын камышлы зур Акбулат күле тирәсен сайладылар.

Киләсе бәла килми торып, аннан котылып булмый икән шул. Таң алдыннан гына йокыга китеп барган малайлар уянсалар, атларыннан җилләр искән иде инде.

Ул төнне Мостафа начар йоклады. Таң атар-атмас урыныннан сикереп торды да хатынына эндәште:

— Заһидә, тор әле. Атларны урладылар, ахрысы. Кайда минем оекчабаталарым? Тизрәк бир.

— Тукта әле, сиңа әйтәм, әллә төшләнәсеңме? Берни дә юктыр. Ник шулай кабаланасың?

— Аңлатып торырга вакыт юк. Китер тизрәк. Малайлар белән дә берәр хәл була калса...

Мостафа туганы Шәфигулланы да уятып, аның киенгәнен көтеп торганда таң да атты. Алар авыл башына чыкканда, кулларына йөгәннәрен тоткан малайлар елый-елый кайтып та җиттеләр. Дүртәүләп кире барып, эзләп карасалар да, файдасыз булды: атлар юк иде. Аларның куе камышлар арасына алып кереп киткән эзләре генә калган иде.

Нишләргә белмичә, Мостафаларның ишегалдына кайтып утырдылар. Төсләре киткән малайлардан кат-кат сораштылар. Аларның йоклап калганнары ачык иде. Ачуыннан үзен-үзе белештермәгән Шәфигулла Гыйззәтуллага сугып җибәрде. Бер кырыйдарак кайгырып торган Заһидә атылып, Галимҗанны кочаклап алды. Аңа да эләкмәсен, дип курыкты ул.

— Сиңа әйтәм, балага тимә! Тәкъдирдән узмыш юк, диләр. Ходай язгандыр инде, сабыр итәргә кирәк, — дип тынычландырырга тырышты Мостафаны хатыны.

Уйлаша торгач, бер карарга килделәр. Тирә-якта, ат караклары белән яшерен эш йөртүчеләр дип яман аты чыккан Шәмбалыкчы кешеләрен атыйлар иде. Мостафаның анда Габдулла исемле танышы, белгән кешесе бар иде. Берәр файдалы киңәш бирмәсме дип, аның янына барып карарга булдылар.

Юлга чыккач та сүз һаман атлар тирәсендә барды. Инде бер ат карагыннан котылгач, тагын төнге ашатуга җибәрергә рөхсәт итүләрен бер-берсенә аудардылар, бәхәсләшеп киттеләр. Шәфигулла кызып ук китте: — Тумарка тәре, белмәсәң бел: безнең башка бу бәла синең җәмәгатең аркасында гына төште.

— Ничек инде минем хатыным аркасында?

— Әнә, Морзаларның Фәсхие качкын булып киткән, диләр. Заһидәнең сиңа кияүгә чыкканына үч итеп урлады ул безнең атларны. Ул бит аның яратып йөргән кызы булган.

Мостафа эсселе-суыклы булды.

— Булмас, Шәпи! Фәсхинең авылларыннан чыгып качуын мин дә ишеттем ишетүен анысы. Тик ул алай үчле кеше түгелдер.

— Ул булмыйча, кем булсын? Әлегә хәтле безнең авылдан ат урлаганнары булмадымы? Булмады. Фәсхигә хәзер качып йөрер өчен ат кирәкме? Кирәк. Ул булмыйча, кем булсын?

— Карап карарбыз. Күңелем сизә, ул булмас.

Шәмбалыкчыга җитеп, Габдулланың өен эзләп таптылар. Ишегалдына чакырып чыгаргач, күрешеп, хәл-әхвәл сораштылар һәм үзләренең кайгыларын сөйләп бирделәр. Габдулла атларның нинди төстә, ничә яшьтә, айгырмы, бияме икәнлеген төпченеп сорашты.

— Ә-һем, — дип хәйләкәр генә елмаеп куйды Габдулла һәм боларга сынаулы караш ташлады. — Мин күргән атлар чыннан да сезнекеләргә охшаган шикелле.

Мостафаның эченә җылы керде:

— Йә-йә! Кайда күрдең? — дип, түземсезләнеп сорады ул.

— Аларны кичә куып китерделәр. Тик менә... — Габдулла тагын сынаулы караш ташлады, — тик менә атларыгызны йолып алыр өчен сездән бишәр тәңкә акча кирәк булыр. Мин бу четерекле эшкә, Мостафа яхшы таныш булганга күрә, сезне кызганудан гына алынырга риза.

Шул чагында Шәфигулла кызып китте:

— Әле син шулаймыни? Атларны урлап китүең җитмәгән, алар өчен ярты ат бәясен түләтәсең килә! Мин сине хәзер староста алып килеп, зинданга озаттырам! Ярлы кешеләрне бөтенләй ыштансыз калдырырга телисеңме? Барып чыкмас бу эшең!

Шәфигулла пырлап чыгып китмәкче иде, Габдулла үзе һөҗүмгә күчте:

— Нәрсә, мине ат урлауда гаепләргә телисезме? Мине ат карагы итмәкчесезме? Башта сез мине тотыгыз әле. Әнә, тентегез, табыгыз атларыгызны!

Ачуы чыккан Габдулла янәшәдәге алачыкның саламнарын бастырып куйган бер бастырыкны алды да кизәнергә үк тотынды.

— Барыгыз, хәзер үк чыгып китегез! Юкса, башыгызны ярам!

Шул арада ул Шәфигулла белән Мостафаның сыртларына берикене кундырып та алды.

— Ычкыныгыз, барыгыз! Хәзер үк! Йә сугып үтерермен!

Крәстиән хуҗалыгына ат хәтле ат югалту иң зур бәлаләрнен берсе булуы турында әйтеп тә торасы юк. Кайгыларыннан кара янып, кичен генә кайтып кергәндә, Мостафаны тагын бер шомлык көтеп тора иде. Ул чыгып китүгә Галимҗан да күздән югалган, һаман кайтып кергәне юк икән. Кайгысыннан һәм атының урлануына үзен гаепләүдән куркып качкан да, кайда да булса яшеренеп ятадыр, дип уйладылар. Караңгы төшкәч, Шәфигуллаларга барып карадылар. Малай анда да юк иде. Гыйззәтулла дустының кайда икәнен белмәде. Чөй өстенә тукмак шикелле, бер бәлагә икенчесе өстәлде.

Мостафалар төне буе керфек какмадылар. Заһидә:

— Әллә этиләргә барып белешергәме? Галимҗан шунда китмәдеме икән? — дигән иде дә, Мостафа риза булмады. — Элегрәк бармаганны, башка бәла килгәч кенә барып йөрмәбез, Галимҗан да анда бармас, — диде.

— Шулай шул, атасы. Баш исән булсын. Менә Галимҗан үзен-үзе харап итеп ташламаса гына ярар иде инде, ходаем...

Арган, пычранып беткән Галимҗан өченче көнне кич кенә өенә кайтып ауды. Бик йончыган булса да, аның күңеле күтәренке, күзләрендә нур балкый иде.

— Әткәй, атлар табылыр сыман, эзләренә төштем бугай, — диде ул кайтып керү белән.

— Улым, аллага шөкер, исән-сау икәнсең әле, әйдә чишен, юын тизрәк, — дип, Заһидә Галимҗан тирәсендә бөтерелергә тотынды.

Икенче көнендә Галимҗан Шәмбалыкчы авылындагы кырый бер йортның абзары артында печән чүмәләсенә күмелеп йокларга булган. Атка дип, кесәсендә йөрткән арпа ипие кыерчыгын чеметкәләп ашап бетергәнен үзе дә сизми калган ул. Арып йокыга талгач, кемнәрнеңдер сөйләшкәне колагына кергән. Уянып, тынлый торгач, кемнәрнеңдер ниндидер атлар турында сүз алып барганнарын чамалаган. Тегеләр "Улак чишмәсе" дип тә әйткәннәр. Иртәгесен көтү куганда Галимҗан бер карчыктан Улак чишмәсе юлын белештереп, урманга кереп киткән, ләкин адашкан. Ничек кирәк алай юл табып, урманнан чыккач, авылга әйләнеп кайткан.

Малаеның кыюлыгына гаҗәпләнгән әтисенең ирексездән күңеле тулды. Галимҗан йокыга китәр алдыннан:

— Иртәгә иртүк барыйк, әткәй, йәме? Мине дә алып барырсың... — диде.

— Ярар, улым, ярар. Йокла тынычлап...

Иртәгесен алар шул ук Габдуллага барып керделәр. Хуҗа каядыр җыена иде булса кирәк, ишегалдында җигүле ат тора иде.

— Әллә кайчан үзең генә килмичә, ниндидер акылсызны ияртеп йөрисең, — дип каршы алды ул Мостафаны.

Мостафа үзенең гозерен кабатлагач һәм малаеннан ишеткән сүзләрне әйтеп биргәч, Габдулла икеләнеп калды:

— Атларыгыз чыннан да Улак чишмәсе буенда бура эчендә торалар иде. Моңа инде өч көн узды. Хәзер андамы икән соң алар? Алып китеп өлгермәгәйләре. Мин урманга юкә каезларга җыенган идем. Әйдә, утырыгыз, шул җайдан әйләник алайса.

Юлда барганда Мостафа бу атлар вакыйгасына Фәсхетдиннең катнашы булуы-булмавы турында сорашты.

— Фәсхиме? Морзалардан, теге Каратун урысын үтергән Фәсхиме? Ю-ук, туган, аннан шикләнеп, гөнаһлы була күрмә. Тирә-яктагы урыс түрәләренә генә тынгы бирмәячәк ул. Озакламый үзең дә ишетерсең әле, — диде Габдулла.

Урманның мәһабәт яшеллегенә дә, кошлар сайравына да, хәтта

көн уртасына житеп килә торган көләч кояшның биек агач араларыннан ялтырап төшкән нур көлтәләренә дә игътибар итмәде Галимжан. Ул зурларның әңгәмәләренә дә колак салмады. Аның бар теләге — тизрәк теге бура янына барып житеп, үзенең яраткан жирән биясен табу иде.

Ләкин, бер килмәсә, авызыңа капкан ипине дә карга тартып алыр, диләр. Атлар юк иде. Бура өстенә менеп карасалар да, печән калдыклары белән ат тизәкләреннән гайре бернәрсә күрмәделәр.

— Бәхетең чамалы икән, Мостафа, — дип көрсенде Габдулла да. — Бүген иртә белән генә алып киткәннәр, әнә тизәкләре дә кипмәгән.

Мостафаның, аннан да бигрәк Галимжанның өметсезлеккә төшкән йөзләрен күреп, өстәп куйды:

— Жаныңны телгәләмә, тынычлан. Аларны эзләү хәзер файдасыз. Атларыгызны чуаш ягына куганнардыр. Ә синең, энекәш, гомереңдә әллә нихәтле атың булыр әле, башыңны югарырак тот!

Мескен Галимжан бура өстендә күз яшьләренә буылып озак утырды. Аннан да хәсрәтле кеше булдымы икән бу чакта?

## 33

Язгы чәчү тәмамланыр алдыннан гына Фәсхетдиннең әнкәсе Фатыйма карчык вафат булды. Бәхетсез Фәсхи кайты артыннан кайгы килеп кенә торуына, тормыш тәгәрмәченең һаман артка таба тәгәрәвенә үзе дә күнегеп килә шикелле иде инде. Әнкәсен жирләгәннән соң, аның нинди юл сайлаячагын беркем, шул исәптән, үзе дә аныклап әйтә алмас иде. Ләкин, ни генә булмасын, кеше үзенчә фикерли, ходай үзенекен тәкъдирли.

Көннәрдән бер көнне авылга Каратуннан өч кеше килеп керде. Карагруһлар жиләне кигән бу өч рухани Фәсхи йортын сорашып таптылар һәм ачык өйгә юнәлделәр. Фәсхи өйдә юкка исләре китмәде бугай аларның, керү белән үз эшләренә керештеләр. Алар “Фәсхи урыс диненә күчте” дигән гайбәтне ишеткәннәр, шуңа күрә, торган йортын христианлаштыруда аңа ярдәм итәргә ашыктылар. Фәсхи ярдәмендә авылның башка кешеләрен дә үз диннәренә тарту иде, ахрысы, теләкләре.

Иң башта алар өйнең түр почмагына путаллы рәсемле сары калай икона элеп куйдылар. Икона бусагасына шәм яндырып утырттылар. Калын тавышлары белән үзләренең догаларын укыдылар. Укына-укына, өйнең барлык почмакларына пумала белән “изге су” бөркеделәр. Фәсхи кайтып керсә, аны христиан диненә кабул итү тантанасына алар әзер иде инде.

Ләкин йорт хужасы белән очрашу көтелмәгәнчә килеп чыкты. Фәсхи кайтып керү белән бу чакырылмаган кунакларга кычкырып жибәрде:

— Кто вам позволил? Уходите вон отсюда!

Руханиларның берсе Фәсхигә муенына тагар өчен әзерләп куйган “тавык тәпие”н — тәресен сузды, икенче кулы белән чукындырырга тотынды, калын тавыш белән үзенчә нindидер дога укый башлады.

Ачуы кабарып чыккан Фәсхи руханиның кулыннан эләктереп алды да, селтәп, ишектән тышка атып бәрде. Икенчесен дә шулай ук типкәләп чыгарып жибәрде. Өченче рухани, озын жиләненең чабуларына бутала-бутала, Фәсхинең йодрыгын көтеп тормыйча, ачык тәрәзәдән үзе чыгып качарга ашыкты. Аның артыннан чатка эленгән икона да чыгып очты.

Әмма руханилар ишек алдында тиз искә-аңга килделәр, өчәүләп бер Фәсхине генә жиңүләренә ышандылар бугай, аңа ябырылдылар. Ләкин Фәсхи, ачуын көчле йодрыкларына туплап, тегеләрнең әле берсен, әле икенчесен селтәп жибәрә торды. Арадан берсе көчлерәк иде булса кирәк, аунап яткан утын пүләнен күтәреп, Фәсхи өстенә килә башлады. Моны күрү белән Фәсхи читән казыгын суырып алды да аның башына шундый ярсулык белән китереп сукты ки, тегесе көлтә кебек гөрселдәп жиргә

ауды. Калган икесе тизрәк качу ягын карадылар. Ул арада көтелмәгән шау-шуга халык җыела башлады.

Ишек алдында егылып яткан урысның җан биргәне мәгълүм булды. Бу хәл Фәсхи башына көтелмәгән тагын бер бәла китерде. Кеше үтерү иң зур җинаять булып санала, үтерүчене гомерлек каторга көтә. Ә инде урыс руханиен "изге" эше өчен үтерү — икеләтә авыр җинаять, үтерүчене үлем җәзасы көткәне һәркемгә ачык. Фәсхинең бу бәладән котылу юлы хәзер бер генә калды — качкынлыкка китү. Бүген булмаса, иртәгә үзен кулга алырга киләчәкләрен ул яхшы чамалады. Шуңа күрә, качар өчен юлга хәстәрләнә башлады. Әйтергә кирәк, ул югалып калмады, кабаланмады, салкын канлы булды, аек акыл белән эш итте. Булган барлык кием-салымын җыйды, беренче мәлгә ашамлыклар әзерләде. Авылда бердәнбер якын кеше булып калган Кәлимулла хәзрәт белән саубуллашып китәргә, фатиха алырга кирәк иде дә, дип уйлады ул. Ләкин аңа сүз булуы бар. Аннары, вакыт та калмады бугай. Менә-менә аның артыннан килеп җитүләре бар.

Шулай уйлап йөргән арада Кәлимулла мулла үзе килеп керде. Аның кушуы буенча, үлгән урысны каравыл өенә илтеп салган иделәр. Икәү генә калгач, хәзрәт Фәсхетдингә карап, беравык тынсыз утырды.

— Нинди бәлагә тарыкканыңны аңлыйсың булыр инде, балакаем. Хәзер нишләргә уйлыйсың?

— Шундый хәлгә дучар иткәннәр икән, хәзрәт, мин дә тез чүгәргә тормыйм. Үчемне алмый торып, аларга тынычлык булмас.

— Алла диген, Фәсхетдин! Аллаһы тәгаләгә тапшыр. Ул берәр фәһемгә этәрмичә калмас, Аллаһы боерса.

— И-и, хәзрәт-хәзрәт! Син акыллы кеше ләбаса. Аллага үз язмышымны тапшырып, кул кушырып утырсам, мине алып китәчәкләр дә үлемгә хөкем итеп куячаклар. Ә минем әле яшисем килә.

— Хакимияткә кул сузып булмый, Фәсхетдин. Ул сине эһ тә итмәс, хәзер сытар. Аңа каршы бару мөрәүвәтлек түгел. Ә фидаилык — үзеңне корбан итү генә.

— Ә мин туган көнемнән бирле фидаи түгелмени соң? Бала чагымнан бирле әткәй-әнкәй белән беррәттән кешегә хезмәт иттем. Хезмәтем өчен нәрсә алдым? Кыз белән яратыштык — ул миңа тыелган гамәл икән. Үземә тиеш булмаса да, кеше өчен лашман хезмәтен үтәргә мәҗбүр иттеләр. Шуның аркасында, картаймыш көннәрендә газиз атам-анамны кешечә тәрбияләп күмәргә дә хокуксыз булып чыктым. Инде килеп, миннән сорамый-нитми минем җаным, күңелем белән идарә итмәкче булдылар, үз теләгемне түгел, башкалар теләгән үтәргә мәҗбүр итмәкчеләр. Йә, минем ни гаебем бар? Шулай булгач, гаделсезлек корбаны булмыйча, мин кем соң? Аныклап әйтә аласыңмы, хәзрәт?

— Әйе, язмыш сиңа артыграк каныкты шул. Ни әйтергә дә белмәссең. Тик алдан ук исеңдә тот, олан, ут белән уйныйсың. Алар сине, утка килгән күбәләк кебек, бик тиз юк итәрләр.

— Аңа хәтле мин дә аларның үзләрен шул ут эчендә ыслармын әле. Менә халыкны бер хафадан коткардым инде, хәзер урыс динен тагар өчен авылга тиз генә аяк басмаслар.

— Хак әйтәсең. Озакламый килеп җитүләре бар. Синең ниятең, кая китүең миннән чыкмас, олан. Бер генә теләгем бар: сак була күр. Сак акыл белән эш ит. Миннән сиңа фатиха!

Кәлимулла мулла китү белән ике пүнәтәй ияртеп староста килде. Ләкин Фәсхетдин өендә юк иде инде.

Иртәгесен иртүк килгән солдатлар, күпме эзләмәсеннәр, аның эзен дә таба алмадылар. Шул ук көнне Хәмзә морзаның абзарыннан аты, Заһидә яраткан Алмачуар юкка чыкканы билгеле булды.

## 34

Хәмзәнең тормышы һаман артка тәгәри барды. Кызын биргәннән бирле өйдән ямь китте, җансызлык, битарафлык, сүлпәнлек хөкем сөрә башлады.

Хәтта төп терәге, беренче ярдәмчесе, варисы Якуб та әллә нишләде. Соңгы вакытларда бигрәк сүлпәнләнде. "Хәл юк" дип зарлана башлады. Әллә авырый инде? Әгәр билгеле бер эш кушмасаң, үзе башлап тотынмас булды. Күптәннән авырып яткан хатыны Нәҗия янында чыкмый калган көннәре ешайды. Хәмзәнең кабат-кабат икенче хатын алырга кыставына кул гына селти торган булды.

Кем өчен тырыша соң Хәмзә? Морзалык дәрәҗәсен кемгә калдырып китәр? Яше дә шактый инде хәзер. Илледән узып киткәч, тагын өйләнмәс бит инде? Җегәрлеге бар әле аның барын, эшен дә җиренә житкереп башкару сәләте югалмаган. Сүзе дә үтә, кешеләр дә тыңлыйлар үзен. Олыс түрәләре каршында да абруе житәрлек. Тик барыбер тормышында нәрсәдер житешми, иртәгәсе көн ниндидер шом алып килер төсле эчне пошыра. Күңелне бимазалый торган бу "нәрсә" шул ук морза нәселен кем дәвам итәр дигән мәсьәлә түгелме соң?

Тукта, Заһидәнең баласы булырга мөмкин бит! Ярлы крәстиян Мостафа баласы булса да, Хәмзә морзаның оныгы да була ич! Бәс, шулай икән, морза тамыры корымаячак, токым дәвам итәчәк дигән сүз. Бу турыда уйлаганда Хәмзә кызы Заһидәгә карата артык коры булуын, аны ирексездән диярлек ярлы кешегә кияүгә бирүен исенә төшерде. Бирмәгән дә булыр иде, ләкин әнә кеше үтерүче лашманчы Фәсхи белән бәйләнеп ачуны китерде шул. Аларның тагын качып китмәүләренә ышаныч юк иде.

Заһидәләрнең атларын урлаган хәбәр дә ишетелде. Ярлы-ябагайга ат урлату зур бәла инде. Хәмзә аларга Заһидә яраткан Алмачуарны бирер генә иде, аны әлеге качкын Фәсхи урлап китте, катил! Әгәр Заһидә малай тапса, башка берәр ат бүләк итәр Хәмзә. Ә хәзергә атсыз яшәсәләр дә ярап торыр.Андый зур бүләккә лаек булырга да кирәк.

Арышлар өлгерер алдыннан Хәмзә, ниһаять, юлга кузгалды. Үзенә артык игътибар итмәсеннәр өчен, җәяүләп кенә барырга булды. Әйе, быел да икмәкләр буйга матур үстеләр. Җигүле атның дугасы күренмәслек, арышлар буйлы булдылар. Тик башаклары кыскарак күренә. Саламы булыр, ә арышы чамалы булыр кебек. Башакка сикерә башлаганнан бирле яңгыр булмады. Шуңа күрә, дым җитмәде.

Заһидә өйдә үзе генә иде. Хәмзә бу юлы йомшак телле булды:

— Кызым, мин бу арада күп уйлана торган булып киттем әле. Әллә картаям инде. Синең мондый тормышың да эчемне пошыра. Әллә, мин әйтәм, берәр төрле ярдәм итимме үзегезгә? Атыгызны да урлаганнар икән.

— Мин бүгенге тормышымнан канәгать, әткәй. Безгә бернинди ярдәм кирәкми. Үзебезгә килгән бәлане үзебез күтәрербез, Алла боерса.

— Алай димә, кызым. Менә озакламый урак өсте килеп җитәр. Көлтә ташырга булса да, бер атны алып торырсыз. Ишеткәнсеңдер, Алмачуарны да Фәсхи качкын урлап качты бит әле. Аны сиңа гына биреп җибәргән булсам, әйбәтрәк буласы икән.

— Әллә Фәсхи абый урлаган аны, әллә кем? Урлаган — бер гөнаһлы булса, урлаткан — йөз гөнаһлы, диләр.

— Ул булмыйча, кем булсын? Сезнең атны да, безнекен дә ул гына урлады. Сиңа үч итеп урлады ул аларны, катил!

— Кирәкми, әткәй. Син үзегез турында сөйләр идең. Әнкәй нихәлләрдә анда? Авырмыймы, исән-саумы?

— Әнкәңә ни булсын соң? Аш-су тирәсендә кайнаша һаман. Ыңгыр-шыңгыр чаклары да булгалый инде.

— Нәҗия җингинең хәле ничек?

— Ул һаман урын өстендә. Анысы шулай. Тик менә абыең авырыксына башлады.

— Нишләп алай?

— Үпкә авыруына охшаган. Ютәлли. Кымыз эчсә, әллә дә үтеп китәр иде. Менә шул Канзафар килене булып китсән... Аларда кымыз дәрьясы, югыйсә. Ходай насыйп итмәде шул.

— Мин монда яшәвемә шөкерана кылып бетә алмыйм. Ярый әле, шул кыргый якларга китеп әләгүдән ходай саклаган. Монда мин барына да, югына да үзем хужа.

— Бер барып чыгар иден. Әнкәңне, абыеңны күреп китәрсен. Кайчан киләсең, әйт. Тарантаслы ат җибәрермен.

— Үз җаем белән барып чыгармын әле, алайса, — дип җавап кайтарды Заһидә.

Хәмзә китәр алдыннан тагын сүз кушты:

— Миңа бер оныкк табар иден ичмаса. Тамыр корый бит. Морза нәселен кем дәвам итәр? Беләсең, абыеңның балалары юк.

Заһидә кызарып китте. Буенда бар иде аның. Ләкин бу турыда атасына әйтәме соң?

Кызын күрүенә үзенчә канәгать булып, ашыга-ашыга кайтып барышында, һич көтмәгәндә арышлар арасыннан Фәсхи килеп чыкмасынмы?

— Хәмзә абзый, кая ашыгасың болай? Тукта, бер сөйләшеп алыйк әле.

— Фәсхи? Фәсхетдин... Ничек, нишләп болай йөрисең?

— Мин ничек йөрсәм дә ярый. Менә син ник болай җәяү йөрисең? Морза кешегә килешми.

— Ат белән булсам, талап алыр идеңмени? Болай да Алмачуарны алып киттең бит инде. Кызым Заһидәләрнең дә атын, юк, ике атны куып киттең. Шулар җитмимени?

— Их, Хәмзә абзый, Хәмзә абзый... Син мине беркайчан да кешегә санамадың. Хәзер дә шулай икәнсең. Кирәк булса, урыс түрәләренең атлары да бетмәгән миңа.

Сабырлыгын югалта төшкән Фәсхи, күбрәк куркыту өчен булса кирәк, тула оегы эченнән пычагын тартып чыгарды.

— Фәсхетдин, калдыр, әллә ниләр әйтеп ташладым бугай, — Хәмзә пычакны күрү белән куркуга төште.

— Курыкма, морза! Мин сине суярга җыенмыйм. Әткәй-әнкәйне ялангач калдырып куып чыгарган кешене хәл итәргә кирәк иде дә... Ярар инде, кызың хакына... Ә менә малаең урынына лашманда хезмәт иткән өчен паемны түләгәнең юк әле. Мин, кеше хакы дип, шул авыр хезмәттән дә атыңны арбасы-дирбиясе белән алып кайтып үзеңә тапшырдым. Үз акчама алган чананы да өстәп кайтардым. Синең миңа уникe тәңкә бурычың бар. Хәзер бәхилләшәбезме, әллә икенче күрешкәч бирерсеңме?

Хәмзәнең Фәсхи белән кабат очрашасы килми иде, билгеле. Ләкин янында андый акчасы юк иде.

— Фәсхетдин, ни бит, янымда акчам юк шул. Шул хәтле зур акча...

— Алайса, сал җиләнеңне, морза! Минем белән очрашуыңның бер истәлеге калсын!

## 35

Теге шомлы көннең кичендә Кәлимулла мулла киткәч үк, Фәсхи бакча артлап кына әрәмәлеккә элдерде. Куаклар арасына барып кергәч, ирексездән артына борылып, шактый вакыт карап торды.

Туган йорт! Әткәсе-әнкәсе яшәгән, аны иркәләп үстергән йорт! Күңелдә гомер буена саклана торган хатирәле вакыйгалар саклаган йорт! Шул нигезендә Фәсхетдингә кешеләрчә яшәргә туры килмәде, ата-бабаларның дәвамын туктатып калдырырга мәҗбүр ул хәзер.

Эңгер-меңгердә ул үзләренең ишегалдына өч кеше кергәнне шәйләде.

Тегеләр өйгә кереп чыктылар, абзарны тикшерделәр, бакча ягында пәйда булдылар. Аларның Фәсхине эзләүләре аңлашыла иде.

Үзенең улын хәзер дошман итеп, аны ирексезләп куып чыгарган авылына соңгы кабат карады Фәсхи һәм әрәмәлек аша урманга, билгесезлеккә таба атлады.

Күпме баргандыр, артыннан ат пошкырган, авызлык тимере зеңгелдәгән тавыш ишетелде. Фәсхи юл кырыендагы бер агач артына ышыкланып, атлыны көтеп алды.

Бу атлы тәҗрибәсез кеше иде булса кирәк, гамьсез генә атын әйдәвендә булды. Искәрмәстән тезгеннән тотып алгач, бу кеше кычкырып җибәрде.

— Әкрен... — диде Фәсхи пышылдап. — Үзең ат урлыйсың, үзең урманны ярып кычкырасың.

— Куркыттың пит, апсый, — диде тегесе, чуаш иде булса кирәк.

— Атны алай кумыйлар аны, йә, төш әле атыңнан!

Фәсхи атны авызлыклады, күшилендәге сөлгесен ертып, тоякларын бәйләде һәм аны җитәкләп кенә барырга кушты. Арттан куа килсәләр, тавыш-тын ишетелмәсен. Үзе алданрак китте.

Озакламый ай калыкты. Аларга юлдан урман эченә керергә туры килде. Ай яктысында Фәсхи атны танып алды. Бу Алмачуар иде. — Син Хәмзә морзаның атын урлагансың ич, егет?

Бу яшь егетнең кыяфәте дә таныш тоелды.

— Тукта, тукта! Син үзең дә Ялчек малае түгелме соң?

— Та-та! Син Пасхи апсый пит! Миклуша дәдәйгә кыс урлап килгән.

Фәсхи исенә төшерде: бу егет Ялчек чуашы Миклушаның хезмәтчесе Иванай иде. Тик әлегә төпченеп торырга вакыт юк. Фәсхи Иванайның кая баруын сорашты. Иванай да качкынлыкта йөри икән хәзер. Алар урманда өч кеше икән.

Качкыннар урнашкан җиргә иртә белән генә барып җиттеләр алар. Иванайның ике иптәшенең берсе тормышка җайлашмаган, солдат хезмәтеннән качып ятучы татар шәкерте булса, икенчесе, тупасрак бер чуаш — ярыйсы гына аучы икән.

Болар ашау-эчү хәстәреннән башка берәр нәрсә майтарырга сәләтле түгелләр иде. Хәтта яшеренеп яткан җирләре юлларга якын булуы да аларның ышанычсыз урынга урнашуларын күрсәтә иде. Димәк, тынычрак урын табарга кирәк. Тиз генә арада алар шулай эшләделәр дә. Зимләнкә казыдылар. Алмачуарга куе агачлар астында киртә әзерләделәр. Тегеләр атны суеп ашарга ниятләсәләр дә, Фәсхи моңа ирек бирмәде.

Теге чуаш Ычтапан чираттагы аудан куркып кайтып керде. Ул үзләреннән өч-дүрт чакрым гына аралыкта өч кешенең ат суеп маташканнарын күргән икән. Фәсхи белән икәүләшеп шунда барып чыктылар.

Бер язмыштагы кешеләр бер-берсе белән тиз таныштылар. Тегеләр дүртәү икән. Дүртесенең дә Фәсхинекенә охшаган дүрт язмыш. Алар, ышанычлырак дип, Фәсхиләр торган урынга килделәр һәм тагын бер зимләнкә казып керделәр. Аларны кору, җиһазлау буенча Фәсхинең тәҗрибәсе бар иде инде.

Бу яңа дүрт кеше тәвәккәлрәк халык иде. Бигрәк тә кыю йөрәкле Искәндәр ошады Фәсхигә. Ул авылның кешеләрен нахакка кыерсыткан өчен олыс үрәтнигын кыйнаган икән. Шуңа күрә, күрәләтә зинданга китмәс өчен монда качып йөри. Урыс түрәләреннән үч алу теләге белән ул Фәсхи кебек бер фикердә иде.

Озакламый Шәмбалыкчы белән Ялчек арасында байларны, сәүдәгәрләрне талау очраклары ишетелә башлады. Фәсхи белән Искәндәр каршы булуга карамастан, төнгегә алып чыккан атларны урлау да ешайды. Бу кәсепкә бигрәк тә Тимерша оста иде. Ул ике атналап шул кәсебенә чыгып китмәсә, үзен үзе кая куярга белми йөри, анда бәрелә, монда сугыла, ләкин чыгып китә һәм атна-ун көннән ат ияртеп кайта иде. Шулай итеп, Тимерша һәрберсен атлы итте. Ләкин ул урлаган атларын монда

тотмый, әллә кайларга илтеп, башка атларга алмаштыра иде. Алмачуарның тарихын ишеткәч, аны да алыштырып кайтты.

Кайбер урлаган атларын ул сатып та җибәрә икән. Акчасын каядыр яшереп куя. "Кара көнгә" , янәсе. Моннан да кара көн нинди буласын үзе күз алдына китерә алмас иде. Мостафаларның атларын да шушы Тимерша урлаган иде. Аларны Канаш ягына ук илтеп сатты. Фәсхиләр моны белми дә калдылар.

Тимерша базарларны да еш алыштыра иде. Берсендә Бәки базарына барып чыкты. Мәгълүм ки, бу терлек базары иде. Тимершаның йомышы — чуаш ягыннан урланган атын сату иде. Малын мактап торган арада аның күзе бер кешегә төште. Иш ишен таба, җир тишеген таба, дигәндәй, бу кешенең ниятен тиз аңлады Тимерша. Тегенең нияте — берәр атка атланып качарга иде булса кирәк. Ул сатучылар белән сатулаша, үз бәясен әйтә, чын арадашчылар кебек тешләрен карый, бәкәлләрен капшый. Әмма һаман бер айгыр тирәсендә күбрәк булыша иде.

Күзәтә торгач, Тимерша аның шул айгырга сикереп атлануын, халык чыр-чу күтәреп шаулашкан арада базардан чыгып качарга чамалавын күрде.

Тавыш, кычкырыш китте. Ләкин тиз арада каракны бożра эченә тулгап алдылар. Тимерша аты белән бożрадан читтәрәк калган иде. Ул тиз генә теге айгырга ташланды, аның башына сузылган арада каракка:

— Әнә минем атым. Атланып ычкын тизрәк! — дип пышылдады.

Тегесе Тимершаны аңлап, айгыр өстеннән тәгәрәп төште дә халык арасына кереп юк булды. Шул арада:

— Рәхмәт, агай. Тәмтегә кил! — дип әйтеп узды.

Тимерша базар халкы күз алдында айгырны коткаручы кыю кеше булып калды, айгыр хуҗасыннан бүләк алды.

Тәмтедә ул теге кешене тиз эзләп тапты. Әнәс атлы бу карак Тимершадан да елгыррак бәндә иде, ахры. Аның монда, Идел буенда әшнәләре дә булуын, үзләре Иделнең аръягына да чыгып йөрүләрен сөйләде. Ләкин соңгы вакытларда боларны рәхимсез эзәрлекли башлаганнар икән. Ул шуннан зарланып алды.

Тимершаның башына бер кыю фикер килде:

— Кара әле, Әнәс дус. Безнең төркемдә шәп кенә ике егет бар. Әгәр без көчләрне берләштерсәк, сезне эзәрлекләүче солдатларны кызык итә алабыз бит!

Үз кешеләре белән киңәшеп карарга булдылар.

Хәмзә морза белән очрашкан чагында, Фәсхинең шул йомыш белән Тимерша артыннан Тәмтегә баруы иде.

## 36

Мәчеттә җомга намазыннан соң чираттагы вәгазендә Кәлимулла мулла сүз йөртү яки гайбәт турында сөйләде:

— Пәйгамбәребез әйткән: дүрт кешенең намазы кабул булмас. Шулар арасында сүз йөртүче, яки гайбәтченең гамәле. Андый кеше гөнаһлылар арасында иң явыздыр. Сүз йөртүчене Аллаһы тәгалә кыямәт көненә хәтле ут белән газап кылыр һәм кыямәт көнендә газабы тагын да авыррак булыр. Кылган гамәлләренең савабы юкка чыгар. Гайбәт бик авыр нәрсә, гайбәт кеше үтерер. Безнең күз алдыбызда ук шундый гыйбрәтле вакыйга булмадымыни? Хәтерегездәдер, авылымыздан лашман хезмәтенә барып кайткан Әхмәтзыя абзый угылы белән Әхмәтсафа абзый угылы Шәйхетдин вә Галләметдин үзләре белән бергә барган Фәсхетдин турында нинди гайбәт тараттылар. Алар бичара Фәсхетдинне диненнән язган, урыс диненә күчкән дип чыгардылар. Яхшы кешеләрдән туган бу яман оланнарның гайбәтләренә ышанып, Каратундагы карагруһ руханилар килеп, Фәсхетдиннең өен тәреләре белән нәҗесләделәр. Аларның бу

гамәлләре бирсенең үлеме белән тәмамланды. Әлхасыйл, әлеге гайбәт аркасында кеше үтерелде, Фәсхетдин законсызга әверелде. Ул хәзер качып йөрергә, качкын булырга мәҗбүр.

Хәзер, җәмәгать, бу ике олан, гомерләре буенча Аллаһы тәгаләгә гыйбадәт кылып, бу авыр гөнаһларын ярлыкауга ирешә алырлармы икән? Ходай шулай тәкъдирләгән булсын.

Беләсез, җәмәгать, хәзер дә лашман хезмәтен үтәүче авылдашларыбыз бар. Аларга Аллаһыбыз мәдәт бирсен дип дога кылыйк. Бу өч көнлек җиһанда барыбызга да дуслык, татулык, бердәмлек кирәк...

Фәсхетдиннең качып китүе олыс түрәләре арасында ыгы-зыгы тудырды. Баштарак моңа артык әһәмият бирмәскә тырыштылар. Ат урлау, сәүдәгәрләрне талаулар ешайгач, бигрәк тә качкыннардан урысларның күп зыян күрүләре эшнең зурга китүен сөйли иде. Фәсхинең Морзалар авылыннан булуын искә төшерделәр. Нинди буйсынмас авыл булып чыкты соң әле бу Морзалар авылы? Бөтен яманлыкның башы һаман шул авылдан килеп чыга. Аларның усаллыкларын бастырыр өчен олыс нинди генә чаралар күрмәде. Җыен җыеп та сөйләштеләр. Лашман хезмәтенә бармас өчен, патша хәзрәтләренең әмерен үтәмәс өчен гауга куптаручы узынган авылга солдатлар да җибәреп тоттылар. Инде менә хәзер архиепископ фәрманын тормышка ашырыр өчен йөргән миссионерларны үтерүгә хәтле барып җиттеләр. Нинди авыл бу?!

Бу авыл — олыста хакимиятнең терәге булырдай бердәнбер морза Хәмзә авылы. Әллә морза булганга халкы шундыймы? Хәмзә морзаның хөкүмәткә каршы эшләрдәй астыртын гамәлләре юк-югын. Мәгәр, өрә белмәгән эт өенә кунак чакыра. Әллә морзаның артык тырышлыгы халыкны гаҗиз итәме? Шулай да аның белән кабат сөйләшергә, ярдәменнән тагын бер кат файдаланырга булдылар.

Морзаны шул ук яхшы танышы земский нәчәлник Садовников чакыртты. Бу юлы ул кырыс иде:

— Синең авылың олыста егермедән артык авыллар арасында иң җәнҗаллысы. Син олыста бердәнбер морза — шул авылда яшисең. Моны ничек аңларга?

— Качкынның кеше үтереп, атымны урлап китүенә мин гаепле түгел, гаспадин Садовников.

— Ә ул егет синең ялчың булган. Лашман хезмәтенә дә синең өчен барып кайткан. Кызыңны аңа бирмәгәнсең бирүен, ә атыңны биреп җибәрмәгәнсең дип кем әйтә ала?

— Минем иминлек булсын өчен тырышлыгым сезгә мәгълүм, гаспадин Садовников.

— Әгәр чынлап булышасың килә икән, шул качкынны тотарга ярдәм ит!

— Ничек итеп?

— Кешеләр ялла. Әнә, юлчыларны, сәүдәгәрләрне талаган, атлар урлаган хәбәрләр бар. Үзеңә дә сакланырга киңәш итәм. Качкынның сиңа үче бар, диләр. Йортыңны яндырып китүе бар..

Ниткән начар замана бу? Җанын-тәнен кызганмыйча хезмәт итүенә, түрәләр кушканча булсын өчен үз татарларына каты булуга карамастан, Хәмзәне ничек мыскыллыйлар, хәтта җинаяттә гаепләргә тырышалар түгелме соң?

Ярый әле, Фәсхи качкын белән очрашуын әйтмәде Хәмзә. Яшерен элемтәдә торасың, дип, яла ягарга да күп алмаслар. Уйлап карасаң, бар бәла шул бәдбәхет Фәсхи аркасында. Земский нәчәлник хаклы: ничек кенә булса да тотарга шул катилне!

Олыста тәртип сакларга тиешле җаваплы кеше урәтник Дубовка да каты эләкте. Аңа кичекмәстән Фәсхине тотып китерү бурычы йөкләнде. Моның өчен ул нинди чаралар күрергә кирәк икәнен үзе уйларга һәм эшкә ашырырлык тәкъдим кертергә тиеш булды.

Күңелен тынычландырыр өчен Дубов үзенең сәяркәсе янына Биешкә

китте. Анда кәеф-сафа корып алганнан соң, сөяркәсе киңәше белән старостаны күрергә булды.

Качкынны тотар өчен ярдәм кирәклеген аңлаган староста бу хәвефле йомышны үтәргә бик ашкынып тормавын сиздерде.

— Качкынны эзләргә берничә кеше таба алырбыз анысы, —диде ул. — Ләкин якын-тирәдәге җыен татар авыллары арасында без бер утрауда кебек кенә. Каракны эзләүчеләрнең үзләре тиз арада юлбасар булып китүләре бар. Болай да татарлар безнең белән аралашырга омтылып тормыйлар.

— Мондый очракта сезнең ярдәмегез булырга тиештер бит?

— Мин ярдәм итүдән баш тартмыйм. Башкалар белән киңәшеп карармын...

"Болардан ярдәм көтү — мәгънәсез эш булыр", — дип уйланып йөргәндә, Дубов кылт итеп староста Җамайның малаен исенә төшерде. Исеме ничек иде әле аның? Ә, әйе, Шигабутдин. Ну, авыр исемнәре бу татарларның, черт возьми!

Дубов иртәгәсен үк Шиһабетдинны олыска чакыртты. Кылын тартып карауга ук аның Фәсхигә дошманлыгы кимемәгәнен аңлады. Шуңа күрә, сүзен турыдан-туры ярып салды:

— Сиңа бер эш тапшырырга уйлыйбыз. Башкарып чыксаң, бөтен олыста атаклы кеше булырсың — олы бүләк алырсың.

— Нинди эш, господин урәтник? — бу хәйләкәрнең юмакай сүзләреннән Шиһабетдин үсенеп китте.

— Шул Пасхины тотарга кирәк.

— Фәсхине? Фәсхи качкынны? — егет торып ук басты. — Ю-ук, мин моны булдыра алмыйм.

— Тынычлан әле, Шигабутдин. Мин бит синең үзеңә генә тотарга кушмыйм. Булышуыңны гына сорыйм.

Сөйләшә торгач, егет риза булды. Хәтта, ат-ияр, кирәк-яракка акча бирсәләр, үз ишләрен бергә тупларга да ризалашты. Корал да сорап караган иде, тик аңа ышанып мылтык-кылыч бирмәячәкләренә тиз төшенде.

## 37

Фәсхи кеше-кара очрардай җирләрдә юлдан читкәрәк кереп, авылларны әйләнеп узды. Озакламый Бүре чокыры. Монда кайдадыр чирмеш лашманчыларының зимләнкәләре булырга тиеш. Тавыш-тын ишетелмәгәнне чамалап, егет алга атлады. Зимләнкәләрдә тынлык хөкем сөрә иде. Димәк, лашманчылар моннан киткәннәр. Урман сирәгәеп калган, ләкин вәграк агачлар байтак иде әле монда. Күптән түгел генә лашманчы булса да, ирекле вакытын исенә төшерә-төшерә, көенеп барды Фәсхи.

Тәмтегә барып җитәрәк, сулдагы үрдән бүрәнә тарттырып килүче лашманчылар очрады. Аларның берсенә ияреп, Фәсхи хәл-әхвәл сораша башлады. Бу лашманчының сөйләве буенча, хәлләре элеккедән үзгәрмәгән, һаман шул урман кисү, аны ташып яр буена өю, кешеләрне һаман агач басу очраклары...

Читләтеп сораштыра торгач, Фәсхи лашманчыларны шул ук Дмитрий дәвалап йөрүен белде. Ул авырулар белән татар телендә сөйләшә, хәлләренә керә икән. Күп нәрсәдән хәбәрдар һәм сүзгә юмарт бу лашманчы табибның кучеры булып бер лашман хезмәтен үтәүче эшләгәнен, аннары качкынга әйләнгәнен, шуның аркасында табибтан сорау алып интектерүләрен әйтеп бирде.

Шулай итеп, дусты Дмитрийнең әле дә шул эшендә эшләп йөрүе, Фәсхи аркасында күңелсезлеккә таруы да мәгълүм булды. Әмма, уфтанса да, дустына ярдәм итә алмый иде Фәсхи.

Каршыга бер төркем солдатлар очрады. Алар, юлны иңләп, саф-

саф рәткә тезелешеп, атлы лашманчыларны юл сабарга мәҗбүр итеп узып киттеләр.

— Соңгы вакытларда бу тирәдә солдатлар күбәеп киттеләр әле, — дип зарланды лашманчы, атын янадан юлга чыгара-чыгара, —ниндидер каракларны эзлиләр диме шунда.

Аңа булышучы Фәсхи сүзне куәтләп җибәрде:

— Монда лашман эше кайнап торган җирдә нинди карак булсын инде тагын?

— Бар, диләр шул. Урыс түрәләрен талыйлар икән. Атларын, толыпларын, акчаларын, башка әйберләрен алып калалар да үзләрен җәяү кайтарып җибәрәләр икән. Әле бездә дә зимләнкәләр буйлап тикшереп йөрделәр. Ят кешеләрне эзләүләре булгандыр инде.

Әнәс каракның ишләре чыннан да чая, үтә тәвәккәл кешеләр булып чыктылар. Ләкин, Фәсхинең күзенә ташланганынча, аларда оешканлык житеп бетми иде.

Сөйләшә торгач, алар Фәсхи фикере белән килештеләр, ягъни урысларның җәза отрядын яшерен урында көтеп каршы алырга һәм көтмәгәндә һөҗүм итәргә булдылар. Моның өчен Фәсхи карап үткән Бүре чокырындагы чирмеш зимләнкәләреннән дә иплерәк урын тапмадылар.

Отряд анда барып чыксын өчен, качкыннар шул тирәдә икән, дигән хәбәр таратырга булдылар. Бу уйдырманы гамәлгә ашыру авыр түгел иде. Шул тирәдән бер-ике ат урлап китсәләр, тирә-як авыл кешеләре Бүре чокырын солдатларга үзләре үк күрсәтәчәкләр иде. Аннары кайбер качакларның лашманчылар арасында танышлары, хәтта теләктәшләре дә бар икән. Ә лашманчылар исә теләсә нинди хәбәрне тиз тарата беләләр. Гомумән, Бүре чокырының элек-электән килгән яманаты бу юрама файдасына эшләргә тиеш иде.

Көннәрнең берсендә Тәмте олысыннан егермеләп атлы солдат кузгалды. Үз эшләре белән мәшгуль булган кешеләр иртән иртүк тыныч кына атлатып авылдан чыгып баручы бу төркемгә әлләни әһәмият бирмәделәр. Әмма көтеп, күзәтеп торучылар аларның ниятен тиз аңладылар. Икенче урамнан шул ук вакытта бер атлы Бүре чокырына чапты. Сөйләшенгән җиргә килеп житкәч, ул сызгырып җибәрде. Аңа каршы куаклар арасыннан икенче бер атлы килеп чыкты. Бу атлы хәбәрчегә, алга барып, тозакта көтеп торучыларны кисәтергә кушты. Үзе солдатларга каршы китте.

Җәза отряды пәйда булуга, атлы качкын бераз таптанып торды да артка борылып чапты. Моның солдатлардан куркып качуы аерым-ачык иде. Араларыннан ике солдат моны куа китте. Калганнары да атларын юырттырды. Качып баручы, куучылардан качып күздән югала алмыйча да, үзенә якын китермичә дә, урманга кергәнче күзгә күренеп барды. Куучылар мавыгып киттеләр. Хәзер бөтен отряд, аны-моны карамыйча, бу качакны эзәрлекләргә кереште.

Кинәт качак күздән югалды. Солдатлар бер урында таптанып, аның кайсы тарафка киткәнен чамалап торган арада барасы юлларын бикләп, бер агач ауды. Килгән юлларына кире борылып китәр юллары да икенче агач белән бүленде. Бер үк вакытта өсләренә дә ике агач ауды. Солдатлар күбесе агач астында калдылар. Ыгы-зыгы, ыңгыраш, илереп атлар кешнәгән, кешеләр кычкырган тавышлар яңгырады. Башларын, кулларын күтәрә алган солдатлар мылтыкларын җилкәләреннән ала алмыйча азапландылар. Кайбер өлгеррәкләре мылтыктан ата башладылар. Ләкин төрле яктан камалган солдатлар, ауган агачлардан зыян күрмәсәләр, аларга һөҗүм итүчеләр тарафыннан юк ителә — алар йә башларына төшкән күсәктән, йә сөңгедән егыла бардылар. Ярты сәгатьтән соң эш беткән иде инде. Җәза отряды тулысы белән һәлак булды. Беркем дә качып котыла алмады. Качкыннар исән калган атларны агачлар арасыннан аралап чыгардылар. Мылтык-коралларны җыеп алдылар. Бу — зур җиңү иде!

Ләкин качкыннарга монда озак торырга ярамый иде. Алдан сөйләшү буенча, алар төрлесе төрле якка таралыштылар.

Бу искиткеч кыю һөҗүмнән соң, тагын бер көтелмәгән афәт бөтен тирә-якны тетрәндерде. Бүре чокырындагы фаҗигадән соң ике көн үткәч, Каратун авылы янды. Кара төндә андагы йортларны һәм чиркәүне ут билэп алды. Йокыларыннан айнып җитмәгән руханилар ялангач көе өйләреннән йөгерешеп чыктылар. Янгын яктысында берничә кешенең каралты-кураларга ут төртеп йөрүләре күренде. Руханилар арасындагы берсе, теге вакытта иптәше һәлак булганнан соң Морзалардан качып котылганы, ут төртүчеләр арасыннан Фәсхине танып алды. Котлары очкан урыслар Биешкә таба сыпырттылар. Артларыннан мылтык тавышлары гына янгырап калды.

Көтелмәгән ике зур бәла өяз каласы Тәтешне генә түгел, Казанны да хафага салды. Бу һөҗүмнәрне бер генә түгел, ә яхшы коралланган күп санлы берничә төркем оештыра, бергә хәрәкәт итеп, алар башкара дип фаразладылар.

Берникадәр вакыттан соң, Каратундагы янгынны Фәсхи оештырган хәбәрне ишеткәч, аны тоткан өчен йөз тәнкә акча вәгъдә иттеләр.

Тәмте, Шомгаты һәм башка күрше олысларга даими гаскәр тараттылар. Солдатлар шикле чокыр-чакырларны, күл-елга буйларын, урман куелыкларын айкап йөри башладылар. Бу эшләр белән губерна түрәләре турыдан-туры җитәкчелек итеп тордылар. Өстәвенә, Фәсхи башы өчен йөз тәнкә акчалата бүләккә кызыккан авыл кешеләре дә табылды. Шулардан беренчеләрдән булып Шиһабетдип төркеме оешты. Ул Хәмзә хисабына ике ат сатып алды, Фәсхине тоткач, бу атлар сезгә кала дип ышандырды, Шәйхетдин белән Галләметдинне дә күндерде. Алар, гаскәриләр кебек, урман-сазлыкларны айкап йөрмәделәр, ә Фәсхинең барып чыгардай җирләре тирәсендәрәк йөрергә тырыштылар. Хәмзә абзый белән киңәшеп, андыйрак җирләрне исәпкә алдылар. Мәсәлән, Фәсхинең авылда туган йорты, ата-атасының кабере бар. Ул йортын-җирен сагынып, зиратка килеп, ата-анасына дога кылыр, дигән уй белән шул тирәдә күз-колак булуны мәгъкуль күрделәр. Аннары, аның авыл кырында ике имана җире бар. Авыл халкына урып-җыярга бирелгән бу җирдән Фәсхи чүмәләләрне кая да булса төяп китәргә җаен эзләр, чөнки аның да ашыйсы килә бит.

Акчалата бүләк Биеш урысларын да кызыктырды. Алар да яшьләрдән торган атлы төркем оештырып, кырларны күзәтеп йөрделәр.

Көннәр уза торды. Шиһабетдинның башына тагын бер фикер килде. Фәсхинең яшьтән яратып йөргән, урлап качканда тотылган һәм шуңа күрә кавыша алмаган мәгъшукасы Заһидә бар ич! Кайчан да булса, мөгаен, ул Заһидә янына барып чыгарга тиеш. Хәзер нәкъ урак өсте. Өйләренә барып чыгу килешми торган азгынлык булыр иде. Барса, Фәсхи кырга, бу хатынның урак урган җиренә барыр. Ире көлтә ташыган яисә башка йомыш белән китеп барган арада, Фәсхи форсаттан файдаланып калырга, Заһидәне күрергә тырышыр. Бу фикер Шиһабетдингә шулкадәр ошады ки, ул үзенең ишләре Шәйхетдин белән Галләметдинне дә ияртмәде. Йөз тәнкә бүләкне үзе генә алырга хыялланды.

Шундый өмет белән Шиһабетдин күбрәк Балыклы кырларында йөрде. Һәм ул бу фикерендә ялгышмады.

## 38

Янә дә сөмбелә* ае якынлашты. Арыш урагына төштеләр. Бу юлы Мостафаларның уракка чыгулары күңелсезрәк булды шул. Башкалар үз җирләренә бөтен гаиләләре белән арбага төялешеп, казан-савытларын салып, шау-шу килеп барган чакта, алар җәяү йөрергә мәҗбүр булдылар. Шул сәбәптән, хәзер инде авыр кузгала торган Гайнулла бабай белән карчыгы Гайниҗамал әби дә уракка бара алмадылар. Мостафа озакламый бала табар вакыты җитеп килә торган хәләл җефетен, инде

*Сөмбелә ае — 22 августтан башлана.

тулысы белән кулга кергән улы Галимҗанны, әле рәтләп булдыра алмаса да, булышырга атлыгып торучы кызы Фатиханы ияртеп барды һәм, Аллага тапшырып, уракны башлап җибәрде. Берничә көннән соң алар кул арбасы тартып йөри башладылар. Чүмәләгә куйган көлтәләрне алып кайтырга әллә ат була, әллә юк. Мостафа оста уракчы булса да, Заһидәнең җегәрлеге сүлпән иде шул. Уру осталыгы бар-барын, әмма аңа көн озын иелеп эшләү авыр булды. Галимҗан, эшен жиренә җиткереп башкарса да, көче сыеграк иде әле. Фатиха исә әнкәсенә көлтә бавы әзерләп тора, шулай ярдәм итә. Шулай да күнел биреп эшләделәр алар. Бары тик ирләр көлтә ташый башлагач кына эш сүрәнләнә төште.

Бер көнне, ничектер, Фатиха белән икәү генә калган Заһидә янына Җамай староста улы Шиһабетдин килеп чыкты. Үзе нишләп йөргәнен дә әйтмәде, Заһидәне үртәргә кереште. Әйтерсең, шуның өчен генә килгән! Имеш, теге заманнарда башкаларның урак уруларын карап кына йөрүче морза кызы хәзер үзе, корсагы борынына җиткән килеш, урак ура. Берәр көннән соң тагын килеп чыкты бу юньсез. Үзе нишләп йөрүен әйтми, үзе мәсхәрәле елмая. Урмаган игеннәрне аты белән таптатып йөри шунда.

Заһидә шикләнә калды. Мостафага сөйләп биргәч, ире моңа каршы:

— Мөгаен, ул Фәсхине эзләп йөри булыр. Тәмтедә солдат командасын тар-мар иткәч, аннары Каратунны яндыргач, Фәсхине тырышып эзли башлаганнар. Әллә, мин әйтәм, өйдә генә утырасыңмы? Вакытың да күп калмаган...

— Вакытым бар әле минем. Уракны бетерәсе килә.

— Алайса, сак була күр. Эшләп өзлегә күрмә. Урып бетерербез, Аллаһы боерса. Көннәр дә матур тора әлегә.

Ике-өч көн үттеме-юкмы, Заһидә ерак түгел ниндидер ят тавыш ишетте. Алар бу юлы да Фатиха белән икәү генә иделәр.

— Әйдәле, кызым, утырып бер ял итик. Тегендә ниндидер ят тавыш ишетелгән кебек булды, хәерлегә генә булсын инде, — диде Заһидә. Кызы чүлмәк белән әйрән алып килгән арада үз-үзенә сөйләнеп куйды:

— Әллә нигә күңелем тыныч түгел. Фәсхи абый килеп чыгар кебек, артымнан тотып алыр кебек...

— Минем турыда начар уйлыйсың бугай, Заһидә! — чүмәләнең икенче ягыннан атын җитәкләгән берәү килеп чыкты.

Заһидә күтәрелеп караса, бу кеше чыннан да Фәсхи иде.

— Аһ! — дип, Заһидә лып итеп җиргә утырды.

— Курыкма, Заһидә! Мин сиңа тияргә, зыян итәргә килмәдем. Ерак юлга кузгалганчы, сине күрәсем килде. Минем хәзер җир йөзендә беркемем дә калмады...

Азрак исенә килгән Заһидә:

— Фәсхи абый! Әй, Фәсхи абы-ый! — диюдән башка сүз әйтә алмады.

— Заһидә! Курыкма! Мин сиңа тимәм. Каушама да. Сине бер күрсәм, миңа шул җиткән. Безнең язмышыбыз шулай булган икән, берни эшләр хәл юк.

Заһидә, исенә килеп, күренеп торган корсагын яшерергә теләгәндәй, кулларын кушырды.

— Фәсхи абый, тәкъдир шулай булган, күрәсең. Миңа ачулана күрмә...

— Ачуланмыйм, Заһидә. Мин бүләк иткән чулпыларың янында булса, кайтарыр идең. Төсең итеп йөртермен.

— Фәсхи абый, чулпылар синең истәлегең, бердәнбер истәлегең...

— Алаймы? Мине исеңдә тотучы кеше дөньяда булганда мин яшим әле, димәк.

Аларның бер-берсенә әйтер сүзләре күп булса да, очрашкач әйтә алмадылар. Тик икесенең дә күзләре генә барын да аңлый, аңлаталар иде. Ул нурлы күзләрдә назлау да, уфтану да, бәхилләшү дә, хәтерләп калырга омтылу да, үкенү дә, яшьлек хатирәләрен искә алу да бар иде.

— Ярый, бәхетле бул! Үзеңне сакла! Әнә ирең килә...

Ул арада көлешә-көлешә, Мостафа белән Галимжан килеп җиттеләр.

— Фәсхи! Син ничек монда? Сине бөтен җирдән эзлиләр ич!

— Беләм. Минем башым йөз тәңкә тора, аны да беләм. Синең мине тотып бирергә ниятең юкмы соң?

— Юк, Фәсхи. Миңа хәрәм мал кирәкми.

— Әнә, мине тотучыларның берсе чалуда ята. Барып чишәрсең. Ярый, хушыгыз!

Фәсхи атын елгага таба чаптырды. Шуннан соң гына Мостафа чалуга атлады. Анда, чыннан да, аягы-кулы бәйләнгән Шиһабетдин кычкырып ята иде. Мостафаны күрү белән ул кычкырынырга тотынды:

— Фәсхи киттеме? Кая таба китте? Атны калдырмадымы?

— Мин беркемне күрмәдем. Тавышыңны ишетеп килүем...

— Ну-у, тагын очратсам, болай алданмас идем. Көтмәгәндә каршыма килеп чыкты, каһәр!

Аннары Шиһабетдин кичекмәстән авылга йөгерде. Балыклыга йөгереп кайту белән Җәгъфәрсадыйк старостадан ат алып, олыска чапты. Анда урятник Дубовка Фәсхи белән очрашуын сөйләп бирде. Билгеле, качкынның үзен бәйләп, ә атын алып китүе турында әйтмәде. Дубов белән Шиһабетдин чамалавы буенча, Фәсхи Ялчек урманына качарга тиеш иде. Тиз генә дистәгә якын атлы солдатлар шул якка ашыктылар. Әмма аларның тырышлыгы җил куу белән бер булды.

Фәсхи чыннан да Ялчек урманына кайтырга ниятләде. Ләкин ул башта, Зөя аша кире якка китеп, анда бер-ике көн уздырырга булды. Ул яшеренгән урман олысның үзе белән янәшәдә генә булганга күрә, аны моннан эзләргә беркемнең дә башына килмәс иде.

Урмандагы үзләренең торган җирләренә кайтып керсә, анда Фәсхиләрнең бөтен корылмалары җимерелгән, зимлянкәләр ишелгән иде. Бу сәер тынлык егетнең күңеленә шом салды.

Уйланып утыра-утыра, шактый вакыт узды. Кинәт саескан тавышы ишетелде. Фәсхи сагая калды. Саескан юкка четердәмәс, монда кемдер килә иде. Сак адымнар белән тирә-якка каранып кына килүче кеше Иванай булып чыкты. Фәсхи эндәшкәч тә, ул агачлар артына посты, кабат чакыргач кына Фәсхи янына килергә батырчылык итте.

Урманны кишәрлекләргә бүлеп тикшереп йөргәндә, моннан берничә көн элек кенә гаскәриләр бу зимлянкәләргә тап булганнар икән. Учак өчен коры-сары җыярга чыккан Иванай, зимлянкәләр тирәсендәге шаушуны ишетеп, агач башына менеп качкан. Калган качкыннарны богаулап, солдатлар үзләре белән алып киткәннәр. Качкыннарның нәкъ бергә җыелган чагы туры килгән икән. Бары Фәсхи белән ат карагы Тимерша гына булмаганнар. Хәзер Иванай бер инешнең текә яры астындагы бүре өнен зурайткан һәм шунда төн уздыра икән.

— Мин монда син күренмәссеңме, йә Тимирша апсый кайтмасмы дип көн дә килеп китәм, — дип хикәясен бетерде Иванай.

Фәсхи дә куркуга калды. Аларга кичекмәстән яңа урын эзләргә кирәк иде. Урыннан урынга күчеп,озак кына эзләнеп йөргәннән соң, зур бер сазлыклы күл уртасында утрау шәйләделәр. Тирә-ягы биек куе камыш белән уратып алынган бу утрауга кеше аягы басмаган кебек иде. Эзли торгач, алар саз суын ерып, анда керер юлны да таптылар. Шиһабетдиннан истәлек булып калган атны сазлык буенда калдырдылар да утрауга кереп урнаштылар. Эт оясы биеклегендә генә итеп камыштан шалаш ясадылар. Чәй кайнатыр һәм ашарга пешерер өчен ничектер исән калган бердәнбер чүлмәкләре бар иде. Утрауда чәйлек мәтрүшкә, гөлйөзем яфрагы, төрле тамыр-томыр кебекләр җитәрлек иде. Күл суы сасы, күңелне болгаткыч булса да, түзәргә мәҗбүр булдылар. Ашау ягы гына хөрти иде. Элекке маялары беткәч, тал чыбыгыннан нәрәтәләр үреп күлгә салдылар. Нәрәтәләргә кергән балык тансык аш булды.

Бу тирәләрдә атлы солдатларның еш пәйда булып торулары көндез генә түгел, төннәрен дә утраудан чыгу мөмкинлеген кискән иде. Качкын

егетләр чарасызлыктан арыды-ябыктылар, иң аянычы — үзләренең язмышларына битараф-ваемсыз була башладылар.

Әмма Ходай бар икән ул. Боларның монда качып ятуларын сизми калалармы соң? Якындагы авыл кешеләре күл эчендәге утрауга ике кеше кереп качканны берничә көннән соң ук сизеп алдылар. Моны беренче булып сазлык кырыенда утлап йөрүче ят ат сиздерде. Аннары утрауда тонык кына җемелдәгән учак утын да күзәткәләделәр.

Колактан-колакка яшертен хәбәр тарала башлагач, авылның зирәгрәк-кыюрак кешеләре утрауны карап чыгарга булдылар.

Бер кичнең эңгер-меңгерендә сазлыклы күл кырыенда җигүле ат пәйда булды. Арбадан дүрт кеше төште. Аларның икесе, туп-туры сазлык суын ерып, утрауга атлады. Якынрак килгәч, алар, ул-бу булмасын диптер инде, әкрен генә өн-аваз салдылар. Утрауга чыгып житкәч тә берникадәр көтеп тордылар. Аннары саклык белән утрау эченәрәк кереп, качкыннарны эзләргә керештеләр. Актык чиккә җитешә язган качкын егетләр, сөңгеләрен тотып, болар каршына килеп чыкканда, авыл кешеләре кире борылырга җыенганнар иде инде.

Озын сүзнең кыскасы, пычранып, бетләп, ябыгып беткән ике качкынны, озак сөйләшкән-киңәшкәннән соң, авылга алып кайттылар. Мунча ягып юындырдылар, чәч-сакалларын кырдылар, чиста күлмәк-ыштан кигездәләр, ашатып-эчерделәр. Аннары шул ук мунчада берничә көн ял итәргә куштылар.

Бу сазлыклы күл Мөрәле авылына караган булып чыкты. Фәсхи лашманда йөргәндә Мөрәледән дә лашманчылар булган икән. Аларның берсенә Фәсхинең хат язып биргәне ачыкланды. Игелек җирдә ятмый, диләр, хат яздыручы егет качкыннарга бигрәк тә игътибарлы булды.

## 39

Татар хатын-кызларының борынгыдан килгән гаҗәеп бер изге-саф сыйфаты бар. Бер кияүгә чыккан хатын башка ирләргә, кем булуларына карамастан, ир кеше итеп түгел, ә гади бер кеше дип карарга өйрәнгән.

Фәсхи белән очрашканда, Заһидәнең күңеленә дә ире Мостафага хыянәт итәрдәй, аның абруена тап төшерердәй фикер килмәде. Ул Фәсхине бары тик кайчандыр үзе якын иткән, яшьлек хатирәсендә тирән эз калдырган, ә хәзер инде читләшкән бер зат итеп кенә кабул итте. Фәсхи белән очрашуы аның күңеле өчен хәзер еракта калган яшьлек хатирәсен яңартты, гөнаһсыз балачагын искә алу гына иде.

Сизгер күңелле Мостафа да аларның бу очрашуларын нәкъ шулай аңлады. Шулай итеп, бу очрак ир белән хатын арасында сүзсез, дәгъвасыз узды.

Гадәти тормышлары да үз агымы белән барды аларның. Уллары тугач, өйдә мәшәкать артып китте. Ләкин бу мәшәкать, тынычсыз булса да, күңелле иде. Бигрәк тә Фатиха шатланды энесе тууга. Әгәр дә рөхсәт итсәләр, ул аны гел үзе генә карар, беркемгә дә бирмәс иде.

Көз җитеп, көннәр суыта башлагач, Мостафалар тагын ат алдылар. Быел иген уңышы күп булмаса да, ат алыр өчен аның бер өлешен сатарга туры килде. Ат бәясенең төп чыгымы Заһидәдән булды. Ул гәрәбә муенсаларын, көмеш беләзекләрен, йөзек, колак алкаларын салды. Әмма истәлекле чулпыларын үзендә калдырды.

Үз гомерендә ишегалларына икенче ат килеп кергәнгә шатланмады түгел, шатланды Галимҗан. Яңа атны баштанаяк караучы да ул булды. Әмма тай килеш алып үстергән җирән биягә булган мәхәббәтен оныта алмады, монысына андый зур куаныч күрсәтмәде.

Заһидә, үз тормышы көйле генә барса да, атасы Хәмзә өчен бик борчылды. Борчылмаслык та түгел иде шул. Озак авырып ятканнан соң, җиңгәсе Нажия үлеп китте. Аны җирләп ярты ел вакыт узмады, абыйсы

Якуб дөнья куйды. Үпкә авыруыннан ифрат дәрәҗәдә ябыгып, күләгәгә генә калган абыйсын бик кызганды Заһидә.

Вафат булгач, Якубның тәне озак суынмавын картлар бу мәет артыннан тагын үлем-җитем булмагае дип юрадылар. Шулай булып чыкты да: Нажиянең елын уздырып өлгермәделәр, күптән түгел гөрләп торган йорт өченче үлемне каршылады. Заһидәнең әнкәсе, гомере буе ничек күзгә чалынмыйча яшәгән булса, шулай тыныч кына җан тәслим кылды.

Хәмзә морза үзе дә күзгә күренеп картайды. Аның элекке эшлеклегенең, җегәрлегенең хәзер эзе дә калмаган иде инде. Бигрәк тә улы Якубны җирләгәннән соң биреште ул. Әле кайчан гына хезмәтчеләрен кан елатып, дер селкетеп торган хуҗа, тирә-яктагыларның үзен ирексездән ихтирам итүләренә күнеккән ил тоткасы, урыс хакимияте каршында зур абруйлы морза кинәт гомере буе үзе корган бинаны ташлап, кыргый япанга чыгып китүче дәрвишкә охшап калды Үзе дә аңлата алмастай битарафлык биләп алды аны. Шулай итеп, кайчан гына гаярь кеше бер мескенгә әйләнде дә куйды.

Заһидә әтисе янына килгәләп йөри башлады. Хәмзә морза инде кулга тотарлык булып үскән оныгын алдына алып сөя иде. Берданбер оныгы, морза исемен дәвам итәрлек варисы иде бу бала. Ләкин аны морза итеп тәрбияләр өчен Хәмзәнең көче дә, иң аянычы — никтер, теләге дә юк иде. Бу бала ничек крәстиән Мостафа улы булып туган, шулай ук крәстиән булып калырга тиеш иде.

Үзе исән чагында Хәмзәнең оныгына гомерлек истәлек булып калырдай бүләк бирәсе килде. Ат, сыер малы, хәтта шыңгырлап торган йорт салып бирсә дә — гомерлек бүләк була алмаслар. Нәрсә бүләк итәргә соң?

Хәмзәнең мәчеткә барганда таянып йөри торган таягы бар иде. Имән агачының төз кәүсәсеннән юнып ясалган сигез кырлы таяк. Оныгы тагын бер килгән чакны туры китереп, морза аңа әнә шул таякны тоттырды:

— Мә, улым, морза бабаңның бүләге булсын. Олыгайгач, мәчеткә таянып йөрерсең. Коръән укыганда мине дә искә алырсың...

Хәмзәнең җилкәсеннән тау төшкәндәй булды. Күпме азапланса да, гомере буена мондый изгелек кылганын хәтеренә төшерә алмады ул.

## 40

Мөрәле кешеләре качкыннарны ачлыктан коткарып кына калмадылар, ә качкынлыкта йөреп көн итеп булмаячагын да искәрттеләр. Бөтен нәрсәдән куркып, беркемгә күренмичә сазлыкта калтырап яту үзеңне тереләтә кабергә тыгу һәм мәгънәсезлек икәнен аңлады Фәсхи.

Бала-чагаларның "сазлыкка җен ияләшкән" дигән юк-бар сүзләре ишетелеп тә түрәләрне шиккә калдырырга, эзләнергә, шул түрәләрне айкарга иртәме-соңмы мәҗбүр итәчәк иде. Мунчада торып калу шулай ук мөмкин түгел Шуңа күрә, ике-өч көн ял иткәннән соң, качкыннар, авыл кешеләренең киңәше белән, Кайбыч урманнарына юл алдылар. Бер егет аларны иске кышлауга илтеп куйды.

Бактың исә, бу шул ук урманның дәвамы булып, тирә-яктагы авыллары башка олысныкы, кешеләре ят булуы белән күңелгә ятыш иде. Үзен танымауларыннан файдаланып, иң элек Фәсхи тирә-як кешеләре арасында болгануны күздә тотты. Илдә чыпчык үлми, үзләренә дә җай табылыр, дип уйлады. Шул ният белән ул киемнәрен алмаштырып, төрле сурәттә-асламчы, мосафир, хәтта саилче булып та йөрде.

Яраткан шөгыле базарларда арадашчы яисә алыпсатар булу иде. Алучы яки сатучы файдасына ярдәм иткәне өчен аңа тиешле бәясен дә түлиләр иде. Шуңа күрә, урман кышлавында Иванай белән икәү алар ашау-эчүгә кытлык күрмәделәр диярлек.

Берзаман Фәсхи Норлат базарында бер таныш кеше очратты. Тегесе дә аңа сынаулы караш ташлады. Ләкин шикләнерлек нәрсә юк, бу кеше

Тимерша иде. Алар, күзләре белән генә аңлашканнан соң, икесе ике урамнан, күз күреме ара калдырып, урман ягына китеп бардылар. Урманга житкәч, бер-берсенең кочагына ташландылар. Тимерша табылуга Иванай да бик шатланды. Тимерша үзе генә түгел икән. Берничә көннән ул Әнәс дигән иптәшен ияртеп кайтты. Фәсхиләрнен кыншлаулары ошады аларга. Әйе, Фәсхи урын сайлый белә иде.

Хәзер алар дүртәү булдылар. Бу инде, кирәк булса, эзәрлекләүчеләргә дә каршы тора алырлык көч иде. Шуның өстенә, Әнәс күп нәрсәдән хәбәрдар иде. Сәүдәгәрләрне, түрәләрне, байларны талау, ат урлау белән көн итүчеләрнең, кайда, кайчан, кемнәрне талаганнарын да белә иде ул. Тимерша белән икәүләшеп, җай чыкканда, үзләре дә шул кәсептә йөргәннәр икән.

Ләкин мондый юлбасарлык шөгыле Фәсхигә ошамады. Ул базарларда, төрле авылларда йөреп, халык арасында колактан-колакка ишетелә килгән кайбер хәбәрләрне күңеленә сеңдерә барды. Татар халкы яши торган төрле төбәкләрдә әледән-әле баш күтәрүчеләр булып тора, хәтта авылы-авылы белән күтәрелеп чыгалар икән. Халыкны изгән, гаҗиз иткән, вөҗданына кагылган сәбәпләрнең иң кискене урысларның ислам динен таптап, урыс диненә күчәргә мәҗбүр итүләрендә икән. Көчләп чукындыру! Фәсхи үзе дә бит шул чукындыру аркасында кеше үтерүчегә әйләнде, качкын булып китте. Болай гына ятып, халыкка килгән бу афәтне җиңеп чыгып булмас. Әнә, Фәсхинең туган ягында гына ничә урыс авылы бар хәзер.

Үч алыр өчен икенче юл да сайлап була-булуын. Әйтик, Самар, Сембер якларыннан ятап-ятап (этап-этап) ристаннар уза. Аларны Зөя каласы аша Казанга, аннан Себергә каторгага озата торалар. Богауланган бу ристаннар, утыздан алып йөзгә кадәр булып, көчле сак астында ашыкмыйча гына олы юлдан җәяү атлыйлар. Әгәр шул ристаннарны коткара калсаң?.. Тик моның өчен күп көч кирәк. Андый көчне каян табасың? Уфа-Җаек якларында бу елларда татар-башкортлар еш баш күтәрәләр дигән хәбәрләр йөри. Андагы аймаклардагы старшиналар үзләре баш булып йөриләр икән. Ә монда авыл старостасын кузгату түгел, муллаларны да селкетә алмыйсың. Ник шунда ярты авыллары керәшенгә әйләнмәсен, аларга барыбер...

Яз авыл кешеләренә үзенең бетмәс-төкәнмәс мәшәкатьләрен алып килә. Крәстиән халкы чираттагы кыр эшләре белән мәшгуль була. Базар халкы күзгә күренеп азая. Качкыннарга яшәү кыенлаша. Кайсы кайда — мунчаларда, туганнарының базларында, авылларыннан еракта туганнарында, танышларында кыш үткәргән качкыннар язгы эшләрдә катнашырга, үзләрен яшереп тоткан хуҗаларына бурычларын кайтарырга мәҗбүрләр. Өстәвенә, кышын тынып торган җәза отрядлары да үзләренең эшчәнлекләрен яңадан башлап җибәрәләр. Алар белән көтелмәгән җирләрдә очрашу куркынычы арта бара.

Качкыннардан, каракларлан берәр төркем оештыру гаять авыр, оешсалар да, аларның һәрберсенең үз аңы, үз фикере, үз юнәлеше бар. Оешкан, бер максатка омтылган, бергә хәрәкәт итәрлек көч туплап булмас кебек. Хәтта шактый тату гына бергә кыш чыккан ат караклары Тимерша белән Әнәс тә үз юлларына китеп бардылар. Фәсхи Иванай белән икәү генә торып калды. Уйлаша торгач, алар үз төбәкләренә, үз урманнарына кайтырга булдылар.

Фәсхи хәзер урыс авылларыннан килеп йөри торган попларга, руханиларга аркылы төшәргә, татар авылларында чукындырып йөрүләренә чик куярга булды. Аның белүенчә, Шомгатыдан ике атнага бер яки атна саен поп яисә аның яраннарының берсе Балыклы авылы керәшеннәренә килеп йөри иде. Гадәттә якшәмбе көннәрдә йөриләр алар.

Көннәрдән бер көнне, Балыклыга җитәрәк, текә ярлы күл буенда шундый бер попны очраттылар. Поп, аны-моны абайламыйча, тубыгына кадәр җиткән озын кара җиләнен җилфердәтеп килә иде.

— Куда путь держишь, батюшка? — дип сорады Фәсхи поптан, илтифатлы булырга тырышып. Ягьни, кая юл тотасың, янәсе.

Поп югалып калды, ыкы-мыкы мыгырданырга тотынды.

Урысча белүче бу татар егетенең Пасхи булуын төшенеп алган иде инде ул. Тиз генә озын җирән сакалын ике кулы белән учлап алды. Сакалын югалтудан да зуррак хурлык юк иде аның өчен.

Фәсхи Иванайга ым какты. Иванай попның чылбырлы көмеш тәресен салдырып алды, тирән кесәсендәге акчалы калтасын чыгарды. Сакалына тимәделәр. — Моннан ары авылда халыкны бозып йөрсән, исән калырмын дип көтмә, — диде Фәсхи. — Пошел вон!

Коты очкан поп кире борылып Шомгатыга чапты.

— Кара аны, туры өенә кайт! — дип кычкырып калды Фәсхи.

Поп күздән югалгач, Фәсхи белән Иванай туп-туры Балыклыга юл тоттылар. Авылга кереп барышта беренче урам керәшен урамы иде. Кырый йортлардан берсенең капка төбендә олы яшьтәге берәү очрады. Килеп сәлам алышкач, сөйләшеп киттеләр. Бу Миңнулла атлы кеше Шомгаты побы килүен көтә икән.

— Бик теләп, сагынып көтәсезмени аны?

— И-и, улым. Бичарадан ни чара көтәбез. Ул күренгәч, башкаларга хәбәр таратам. Безнекеләр чормаларыннан иконаларын алып төшәләр дә чатка эләләр. Поп киткәч, тагын чормага ташлыйлар.

— Алайса, урыс диненә хирыслык юк, дисең?

— Булу кая! Бичарадан мәҗбүр иттеләр. Имана пае түләүдән бушаттылар. Яхшы җир бирделәр. Шуңа алдандык инде.

— Мөселманлыкка кире кайтасыгыз киләме әллә?

— Килмәгән кая ул! Ник кучкәнебезгә үкенәбез.

— Абзый, алайса, син поп көтмә инде. Без ул побыгызны кире борып җибәрдек. Мин — Фәсхи качкын. Ишеткәнең бардыр.

Бу сүзләрне ишеткәч, Миңнулла бермәл югалып калды. Ләкин, урыска яраргa тырышып та, үз динен ташларга теләмичә, төрле хәйләләр корырга күнеккән бу карт чынлап шатланды:

— Әйдәгез, алайса, егетләр, попка дип әзерләгән сыебыз бар. Тамак ялгап алырсыз, ачыккансыздыр, — дип, аларны өенә алып кереп китте.

— Шул урыс диненнән ике атнага булса да йолып калуыгыз өчен мең рәхмәт сезгә! — дип, ул, шатлыгын эченә сыйдыра алмыйча, кунакларын сыйлавында булды. Фәсхиләр киткәндә күшилләренә ашамлыклар да тутырып җибәрде. Фәсхиләргә хәләл ризык иде бу.

Фәсхи дә бу эчкерсез картка ышанды. Кирәк булса-нитсә дип, очрашу урынын да билгеләделәр.

## 41

Әзсез югалды дип, тынычланып калган олыс түрәләре, Пасхи качкын тагын калкып чыккач, эзәрлекләүне яңадан башлап җибәрделәр. Аның башы өчен билгеләнгән йөз тәңкә акча ике йөзгә менде. Яңадан кырларны, урманнарны айкый башладылар. Фәсхинең тагын берничә попны өркетүе татарлар арасында миссионерлык эшен туктатып торырга мәҗбүр итте. Фәсхи, ике ел буе качкынлыкта йөреп, эз югалту, теләсә нинди җирдә яшеренү осталыгына өйрәнгән иде инде. Аның сизгерлеген, кайчан, кай тирәдән куркыныч көтәргә кирәклекне чамалавын карт бүренең сизгерлеге белән генә тиңләп булса булыр иде.

Фәсхи белән бергә йөргән егетнең Иванай булуын да ачыкладылар түрәләр.

Көннәрдән бер көнне, Балыклы авылы керәшене Миңнулла белән сүз кушканча, тәгәенләп куйган урында билгеле тамга пәйда булды. Җавап тамгасы калдырып, Фәсхи белән Иванай күзәтеп тордылар. Җавап тамгасына Миңнулла үзе килде. Икенче көнне үк пар атта Миңнулла белән Сафиулла мулла күренде. Тирә-як хәвефсез күренгәч, очрашучыларның мәкерсезлегенә ышангач кына болар янына чыкты Фәсхи. Алай да Миңнулла белән Иванайның икесен ике якка сакка куйдылар. Бер-берсе турында

берникадәр хәбәрдәр булганга күрә, Сафиулла мулла белән сүз озын булмады:

— Улым, сиңа моннан китәргә кирәк!

Фәсхинең аптырашлы карашын күреп, мулла дәвам итте:

— Әйе, улым, китәргә кирәк. Үзебезнең мөселман халкын урыс диненнән йолып калу — изге, могтәбәр эш. Бу гамәлең белән күп түрәләрне аякка бастырдың, борчуга салдың. Мөселман өммәтләрен шатландырдың, канатландырдың. Әнә, элек төртенүле дингә дучар ителгән Миңнулла да ничек дәртләнеп китте. Тик, монда Ырынбур, башкорт тарафындагы кебек баш күтәрүләр булмастыр.

— Хәзрәт, ник баш күтәрмәскә? Әнә, Морзаларда лашманга каршы чыктылар ич.

— Дөрес, улым. Лашман эше йомышлы татарлар белән морзалар җилкәсендә генә иде. Крәстиәннәр өстенә төшкәч, алар, разый булмыйча, чуалыш чыгардылар. Хәзер бу вәзгыятькә дә инсан күнекте инде. Ырынбур-Җаек якларында исә татар-башкорт җирләрен урыслар тартып ала башлаган, диләр. Анда шуңа баш күтәрәләр. Урыс диненә күчү җөмләсенә килсәк, безнең төбәк болай да каты тора, иншалла!

— Халыкны күтәреп булмасмыни, хәзрәт?

— Булмас, углым. Минем, фәһемләвем буенча, син фидаи бәндәсең. Кәлимулла хәзрәт тә шул фикердә. Синең яшьлегең, киләчәгең бар. Болай да син күпне күрдең, үз тормышыңны җайларга вакыт. Шуңа күрә, моннан ераккарак китеп, кешечә көненне күрә башла!

Бу әңгәмәдән соң Фәсхи тирән уйга калды. Тырышып карамады түгел, карады ул. Әмма теләгәненчә берәр төркем оештыра алмады. Китәргә, әллә кая еракка китеп көн күрә башларга кирәктер шул. Һөнәре бар, телләрдән мәхрүм түгел, Иванай ярдәмендә чуашча да шактый шома сөйләшә башлады.

Иванай... Бу мәхлук егет Фәсхи белән ияреп йөри-йөрүен. Ләкин Фәсхинең попларны өркетүе аңа ошап бетми. Чөнки аның бабаларыннан калган дин ул — урыс дине. Иванай үзен шул диндә дип исәпли.

Иванайның зур бер хыялы бар. Ул да булса, Миклуша дәдәйдән үч алу. Сеңлесе Палаша өчен үч аласы килә аның.

Алар — абыйлы-сеңелле ике ятим — кеше кулында үскәннәр. Бала чакларыннан бирле тамак хакына Миклуша дәдәйгә хезмәт иткәннәр. Палаша кыз булып җитәрәк, Миклуша аны бер карт чуашка кияүгә бирде. Карт булса да, түзгән булыр иде, бәлки, Палаша. Ләкин Миклуша аны зөфаф киченнән алдарак үзе тотып көчләгән. Бу хурлыкка түзә алмыйча, Иванайның бердәнбер яраткан сеңлесе Палаша бәкегә чумган.

Иванайның сеңлесе турындагы бу хикәятне елый-елый, кат-кат сөйләгәне бар. Миклуша йортын яндыру иде аның хыялы. Фәсхинең дә Миклушага үче бар иде. Шул Миклуша дәдәй Заһидә белән Фәсхине тоттырган иде бит.

Фәсхиләр Ялчеккә барырга чыкканда көн бозылып китте. Күктә кара болытлар өерелеп, яңгыр алып килергә җыеналар иде. Урманны караңгылык басты.

Иванай исә, ниһаять, күптәннән хыялланып йөргән теләге тормышка ашырылачагына шатлана-шатлана, җилләнеп алга атлады. Палашаның рухы куансын, аның үчен алам бит, дип сөенде ул.

Ялчеккә барып җитәрәк, ял итеп, тамак ялгап алырга, төнне көтәргә дип, юлдан читтәрәк бер инеш буенда туктарга булдылар. Бераздан юлдан кемнәрнеңдер килгәне ишетелде. Ярдан күтәрелеп, куе печән арасыннан күзәткән Фәсхи өч атлы кешенең Ялчеккә таба узып баруын күрде. Болар Фәсхигә таныш иде. Алдагысы — авылдаш Шиһабетдин. Калган икесе Шәйхетдин белән Галләметдин иде булса кирәк. Фәсхи аларның үзен эзләп йөрүләрен белә иде. "Әле һаман шул кәсепләрендә икән болар", — дип уйлады ул.

Төн урталарында Фәсхи белән Иванай Миклушаның каралты-курасына ут төрттеләр. Йорт түбәсе белән болдырына да ут салдылар. Ул арада озак җыенган яңгыр сибәләргә тотынды.

Куәтләнә барган янгынны күреп, яр астындагы тугайда, Миклуша йортының артында кич кунучы Шиһабетдин белән аның егетләре корган шалашларыннан йөгерешеп чыктылар да, утлап йөргән атларына атланып, янгын ягына чаптылар.

Үч алу шаукымыннан Иванай тәмам шашынган иде. Ул, Фәсхи күпме чакырса да, качып китәргә ашыкмады. Куәтләнә барган ялкын телләренә карап ләззәтләнә иде булса кирәк. Шул берничә мизгелгә сузылган вакыт аяныч-хәлиткеч булды.

Атлы егетләр, чаптырып, ишегалдына килеп керделәр дә ут салучыларга ташландылар. Башына төшкән чукмар Иванайны аягыннан екты. Фәсхи читкә сикереп, урамга чыгып өлгерде һәм капка баганасына сыенды. Бер атлы урамга чыгарга омтылганда, аның башына Фәсхинең күсәге төште һәм ул җиргә тәгәрәде. Фәсхи тиз генә егылган егетнең атына атланып, качу ягын карады. Аның артыннан берсе куа китте. Кычкыра-кычкыра куып баручы Шиһабетдин иде. Ул, шактый артка калса да, эзәрлекләвен дәвам итте. Сирәк кенә уйнаган елдырым яктысында бер-берсен күреп бардылар алар. Берсе тизрәк урманга җитәргә ашыкса, икенчесенең урманга кергәнче куып җитәсе килде.

Урманга кергәч тә куышу дәвам итте. Морзаларга ерак та калмады булса кирәк, бер аланга килеп чыктылар. Бу — теге вакытта Фәсхи белән Заһидәнә аю куган алан иде.

Эзәрлекләүче шактый якынлашты, ахрысы, берзаман мылтыктан ата башлады. Фәсхинең колак төбеннән выжылдап ядрәләр очып үтте. Әмма карангылык саклый иде әле, Фәсхигә тимәде. Ләкин шулай да Шиһабетдиннең бер атуы шактый төз булды, Фәсхинең калак сөягенә эләкте булса кирәк, сул кулы оеп, салынып төште. Фәсхи җиргә тәгәрәде.

Шиһабетдин аның янына килеп иелгәч, Фәсхи бар җегәрен җыеп, дошманның күкрәгенә пычагын батырды һәм һушыннан язды.

Фәсхи күпме яткандыр, аңына килгәндә көн яктырган, анардан бер-ике адымда Шиһабетдиннең үле гәүдәсе ята иде. Күтәрелә алмыйча, озак ятты Фәсхи, атларның китеп барганнарын абайлады. Алар авылга кайтсалар, авыл халкының егетләрне эзли чыгулары бар. Димәк, моннан тизрәк таярга кирәк. Фәсхи янгыр суы җыелган күлләвеккә иелде. Озаклап су эчкәч, хәл кергәндәй булды. Ул, көчен җыеп, аякка басты да урман эченә, куелыкка кереп чумды. Аңа ашыгырга кирәк иде. Кан күп киткәнгә күрә, тагын бер егылса, ул тора алмаячак. Агачларга тотына-тотына, һаман атлавында булды Фәсхи.

Кара әле, ялгызы гына түгел икән ич ул хәзер! Заһидә белән икәү атларын янәшә атлатып, рәхәтләнеп баралар икән. Ул да түгел, алар җитәкләшеп Батыр авылына юл тоталар, имеш. Кулларын-кулга тотышканнар да тузанлы юлдан атлый бирәләр. Авылның мәчет манарасында кояш нурлары уйный. Тукта, Заһидәнең чулпылары чылтырый түгелме? Үзе кайда соң әле ул, ник күренми? Ул да түгел, каяндыр Митри килеп чыкты да елмаеп:

— "Держи голову выше!" — диде.

Әйе, Фәсхигә ашыгырга кирәк иде. Ниһаять, кайтып җитте бугай. Әнә, ат исе, тирес исе аңкып торган газиз әтисе чүмәшкән дә, улының йөгереп килүен, кочагына кереп сыенуын кулларын җәеп көтеп тора...

— Хәзер, әткәй, хәзер...

Ботакларын киң итеп җәйгән истәлекле имән төбе коры, тыныч иде. Фәсхи шунда килеп егылганда янгыр да туктады бугай.

Ул да түгел, Сафиулла мулла тавышы яңгырады:

— Улым, сиңа моннан китәргә кирәк!

— Хәзер, хәзрәт, хәзер...

Фәсхетдиннең җаны тәненнән аерылган мизгелдә аның бер җире дә авыртмый, аңа җиңел, рәхәт иде.

# ШИГЪРИЯТ



## КҮПТӘНГЕ ДУСТЫБЫЗ, АВТОРЫБЫЗ

*Шамил Анак (Шамил Гомәр улы Мәхмүдов) исеме шигърият сөючеләргә яхшы таныш, дип уйлыйбыз. Илленче еллар азагында Назыйм Хикмәттән тәрҗемәләр белән күренгән һәм аның татарча китабын да чыгарган (бөек төрек шагыйре бу басмага мәгълүм кереш сүзен дә язды. Хәтерегезгә төшерәбез: "Татар теле — бөек шагыйрьләр теле..." ди ул анда.) иде ул. Ә инде 60 еллар башында шагыйрь урыс, башкорт, татар телләрендә үзенең дә шигырь китапларын чыгарып, укучыга танылып өлгерде. "Европа уртасыннан репортаж", "Прага дәфтәре", "Гади әйберләргә мәдхия" кебек китаплары тематик киңлек белән бергә, шигъри форманың үрекле булуы белән яңа, кызыклы эзләнүләргә дәлил булды. Соңрак ул үзенең күләмле сайланмасын да чыгарды ("Тыйнак табын", 1982). Кыскасы, шагыйрьнең 60-70 еллар татар шигырендә, әдәби процесста билгеле бер урын тотуы һәркемгә мәгълүмдер.*

*Өстәвенә, Ш. Анакның галимнәргә хас белемле, эрудицияле булуын, телләр белән иркен эш итүен, төрки дөньяда һәм дөнья әдәбиятында тирән "йөзүен" дә беләбез. Әнә шуңа күрә дә Тукаебызның 100 еллыгына аның әсәрләренең урысча юлга-юл фәнни һәм шигъри тәрҗемәләрен эшләүче фидакарь, милләтпәрвәр зат та — шул ук Шамил Анак булды.*

*Шамил Анак бүгенге көндә Башкортстанның Раевский поселогында яши. Быел аңа 70 яше тулуын искә алып каләмдәшебезне, күптәнге дустыбызны журнал укучыларыбыз исеменнән котлыйбыз һәм алар игътибарына шагыйрьнең төрле елларда язылган берничә шигырен тәкъдим итәбез.*

## Шамил Анак

### ҮТКӘННӘР АВАЗЫ

* * *

**Бар шундыйлар —**
**барам мин аларга**
**әйтерсең тар, тайгак басмадан;**
**икенчеләр —**
**таудай, дәрәҗәле,**
**күтәреләм сукмак-тасмадан.**

Бар шундыйлар —
туктап тормый узам,
әдәп саклап, мин тик баш кагам,
элек дуслар торган таныш өйдә
яши гүя хәзер башкалар...

* * *

Күпләр белән йөзгә йөз килештем,
бу дөньяда очрап-табышып.
Берәүләрдән ваз кичтем мин үзем,
бүтәннәрдән
алып китте еллар агышы.
Ләкин хәтерлим мин барысын да:
Кемне сагыш,
кемне үкенеч белән,
ләкин беркемне дә искә алмыйм
кинә, үч белән.

* * *

Иртә — ак дөньяга аяк баскан чак,
өйлә — тимер өзгән ирлек заманы,
Кичен хатирәләр килә, тын картаю,
ә төн — ял сәгате, гомер тәмамы.

Иртән — җир сөрәләр, орлык сибәләр,
тимер сугу, өй торгызу — өйлә гадәте,
кичен җырлап җәтмә сөйриләр судан,
Ә төн — ак догалар, сөю сәгате.

## Күлмәк

*Ире герман сугышында үлеп, тол калган күршебез Сабрия әби истәлегенә.*

Бала чакта: "Күлмәк!" — диде, елап-елап,
матур күлмәк керде кызның төшенә,
тик әйттеләр:
"Әнә апаң күлмәген ки,
ниндие дә ярый бала кешегә!"

Үсә төшкәч әйтер иде: "Уеннарга
чыгар идем, булса матур күлмәгем".
Әйтте ана:
"Кыз чагымда киндер кидем,
ситсыларның ни икәнен белмәдем".

Кыз утырып елады.

Җиткән кыз да булды, сораттылар үзен...
Әйтте ата:

"Мулла кызы диярсең!
Күлмәк, имеш, рәт юк быел, иген начар,
әнә, кияү китергәнне киярсең!"

Кияү матур күлмәк китерде.

Туй иттеләр,
өч көн үткәч, әйтте каенана:
"Утырмага килмәгәнсең, килешми,
матур күлмәк кенә киеп торсаң ялан,
килен эшен синме, минме — кем эшли?"
Китте аннан бала-чага бер-бер артлы.
Әйткән була иде мескен шаярып:

"Әйбәтен, ни, олыгайгач, ялда киярмен,
бала үстергәндә иске дә ярый..."

Ул-кызлары үсте.
Әйттеләр ул-кызлары:
"Олы булып, олы була белмисең,
карт башыңа һаман күлмәк сөйлисең,
бер аягың гүрдә күптән, бигайбә —
тәнең күренмәсә, җиткән, бик әйбәт!"

"Ярар инде, — диде, эндәшмәде, түзде,
җан биргәндә әйтте соңгы теләген:
— Исән чакта киялмәдем инде,
кәфенем булсын атагызның бүләге".

Сөйләштеләр ул-кызлары җеназада:
"Теге дөньяда, ни, күлмәк кирәкми,
җитмәгәнме шунда ситсы кәфен,
башкаларга анысы да әләкми".

Шулай җирләделәр дә...

Үз гомерендә тик бер тапкыр
матур күлмәк кия алды Сабрия.
Ләкин кәфенгә төргәч үзен,
гаҗәп мәһабәт ятты.
Тере чактагы кебек
сабыр иде йөзе.

## Буыннар чираты. Эз.

Нәкъ көзгечә, буыннар яфрак коя,
дулкын артыннан дулкын — килә чират:
яу чорында китә сөлектәй яшьләр,
яу соңында гомер уртасы ир-ат.

Читләп узмый чират беркемне дә,
үз вакытында яфрак коя һәр буын:
яу-чирләрдән имин калган картлар
бер дә бер көн эчәләр әҗәл суын.

* * *

Аера икән барыбер
безне мәңгелек сызык,
безнең өн тере калудан
безнең өчен ни кызык?

Тиеш мәллә яшәргә без,
йөрәккә сагыш төяп?
Янәсе, онтыла, диеп,
бу көндәлек вак-төяк?

Ник соң әле шулкадәрле
борчылабыз икән без? —
калыр дипме бездән соң да
күренерлек берәр эз?

* * *

Теләгем бар:
мин дөньядан киткәндә,
утыртылган булсын агачым,
яшәрсен ул, ярсын яфрак;
элеккечә юмарт булсын
бәрәкәтле бу туфрак —
сары гомер болыным белән янәшә
чәчәкләнсен яңа, матур гөлләр,
җир һәм аналарның карынында
бөреләнсен
мин белмәгән яңа гомерләр...
Һәм тыныч кына
кереп китеп камышлар эченә,
югалсын күздән
минем күңел кошым;
чумып мәңгелек суларына,
нурдай сүнсен әкрен генә
минем тере тавышым...



# Нәҗибә Әминева

## МӘҢГЕЛЕК ТЕЛӘГӘН ҖАНЫМ

* * *

“Гомер кыска, җан мәңгелек —
Кемдәдер кабатлана...”
Мәңгелек теләгән җаным
Шул сүздән канатлана.

“Җан — мәңгелек” дигән фикер,
Их, дөрес булсаң, димен —
Их, яңа гомерләремдә
Кош булып тусам, димен.

Кош булып яралгач, тургай
Шатлыктан шашкан әнә.
Җаны канатлы булгач, ул
Күккә үк ашкан әнә.

Канатлы җан, әйе, күктә
Биектә өзгәләнә.
(Түбәндә үрсәләнергә
язганмы безгә генә?)

Ник гел баш очымда сайрый,
Монысы ни соң тагын?
Сагынамы ул да җанының
Кемдәдер булган чагын?!

* * *

Үстердең бөек бәхетләр,
Зур эшләр өчен мине.
Әллә кем булып булмады,
Әнкәй, син кичер мине.

Тормышны алсуга буяп
Күрсәткән өчен —
Мине
(Мин сиңа элек сөйләгән
әкиятләр өчен инде),
Балам, син кичер мине...

* * *

Нигә күңелем бары моңсу эшләр,
Моңсу төсләр күрә?
Төшләремә кадәр — нигә болай
Моңсу төшләр керә?

"Гомерем соңы житә..."
Дигән моңсу
Уймы күңелемдә?
Юк,
Гомергә истә торган уйга
Инде күнегелгән...

Күнегелгән...
Артта, алда ни бар —
Күптән беләм, аңлыйм.
Миңа моңсу:
Дөньясыннан инде
Алдана да алмыйм...

* * *

Житмәгән дә кебек иде,
Жәй инде үтеп бара.
Тау битләре моңсу-сары,
Тау бите соргылт-кара.

Туфрагында мәңге-мәңге
Орлык шытмаган кебек,
Язгы үлән баш төртеп бер
Калкып чыкмаган кебек.

Май аенда зөбәржәттәй
Яшәрмәгән дә кебек.
... Гомеркәем үтеп бара —
Яшәлмәгән дә кебек.

## Була микән?

Каеннарның бөдрә чәчен
Йомшак жилләр үргәннәр.
Каеннар, жилләр — һәммәсе
Жанлы төскә кергәннәр.
Каеннар, жилләр жанын, чын,
Була микән күргәннәр?..

Килә гөл, үлән буласым,
Йә күбәләк буласым,
Күбәләк булып, чәчкәнең
Зәңгәренә кунасым.
Сокландырып эретә мине,
Сабый ясый бу ямьнәр..

Гүзәллек күргәч, йомшармый
Түзә микән бүтәннәр?..

Абау, бу каеннар, гөлләр,
Абау, бу җил, үләннәр...
Үләрмен күк..
Сокланудан
Була микән үлгәннәр?!

* * *

Чәчкәсез һәм нурсыз иде,
Әйтте: "И шыксыз гөл инде..."
Энәләре арасыннан
Кактус безгә йодрык төйде.

Яз җитүгә, чыдамады —
Йодрыкларын ачты беркөн.
Алсу чәчкәле гөл булып,
Балкып торып басты беркөн.

... Әллә йөрәк боз булмыймы,
Йә бер тоташ наз булмыймы,
Йодрык булып йомарланып,
Чәчкә булып язылмыймы?!

# ПУБЛИЦИСТИКА

Фәүзия
Бәйрәмова

# ТӘГӘРИ КИТТЕ ЙОМГАГЫМ...

*"Кабул ителгән Хаҗның бүләге — җәннәт".*
(Хәдис)

Бисмиллаһир-рахманир-рахим.

— Тәгәри китте йомгагым, күрмәдегезме, агайлар?

— Күрдек, күрдек, тау тишегенә кереп китте...

... Югалган йомгагын эзләп кара урманнарда тилмереп йөргән үги кыз турында мин балачагымда күп хикәятләр ишеттем. Еллар үтеп, үзем дә милләтнең бер үги баласы кебек кара урманнарда каңгырып, бәрелеп-сугылып йөргәндә, мин, гаҗизләнеп, үзалдыма шундый сорау куя идем:

— Тәгәри китте йомгагым, күрмәдегезме, агайлар?

Ягъни, уй йомгагым, гомер йомгагым тәгәрәпләр-тәгәрәпләр китте, болыннар, кара урманнар буенча тәгәрәде, язмышым буенча тәгәрәде, дөреслек эзләп тәгәрәде, ялганга һәм мәкергә тап булып, дөньяны ят итте, аннан бизде, читләште. Милләтнең бу ятим баласы көннәрдән бер көнне яшәүнең мәгънәсен югалтты...

— Тәгәри китте йомгагым, күрмәдегезме, агайлар?

Минем өзгәләнеп, чарасызланып биргән бу соравыма, агайлар булып, ЯЗМЫШ үзе җавап бирде:

— Күрдек, күрдек, тау тишегенә кереп китте...

Гомеремнең иң авыр, иң кимсетелгән, иң тибәрелгән вакытларында, үз-үземә һәм дөньяга ышанычым юкка чыгып барган бер шомлы мизгелдә, Аллаһы Тәгалә миңа хак юлны күрсәтте. Язмыш чуалткан җепләремнең очы, гомер йомгагымның башлангычы һәм ахыры, мин эзләгән һәм таба алмаган сорауларга җавап тау куышында булырга тиеш иде. Тау куышы — ул минем күңел дөньям, фәрештәләр аша иңгән җанымның сыенып урыны, иман нуры саклана торган яшерен һәм серле дөнья, бәндә белән Аллаһны тоташтыра торган иң кодрәтле, иң ышанычлы урын ул — тау куышы — кеше күңеле... Гомеремнең иң авыр вакытларында мин, Аллаһының рәхмәте белән, үз-үземә, үз күңелемә юл таптым, дөньяның явызлыкларына һәм бозыклыкларына каршы догаларым белән үз күңелемдә тау куышы кора алдым, шулай итеп, исән калдым. Үзем булып калдым. Бу дөньяда яшәүнең мәгънәсе Аллаһының ризалыгын алу өчен зур сынау икәнен аңладым, намаз һәм гыйбадәтнең, Аллаһы кушканча яшәүнең нинди зур бәхет һәм җаваплылык икәнен аңладым, кешене кешe иткән илаһи көчнең ИМАН булуын аңладым, бу дөньяда мөмкин кадәр изгелекләр һәм яхшылыклар эшләп калдырырга кирәклеген аңладым...

Мин хәзер башка милләттәшләремә дә шушы бәхетне телим, шуңа өндим, динебезнең ни дәрәҗәдә камиллеген, пакьлеген, гаделлеген һәр кешегә аңлатасым, шушы олы бәхетемне — **иманга кайту бәхетен** башкалар белән дә уртаклашасым килә...

Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте белән, миңа быел Хаҗ сәфәре кылу бәхете насыйп булды. Хаҗдан алган тәэсирләрем шул хәтле тетрәндергеч һәм көчле булды ки, мин әле шушы көнгә хәтле бу кадәр зур бәхетнең миңа насыйп булуына ышанып та бетә алмыйм. Анда күргәннәрне, анда кичергәннәрне язарга сүзләр җитми, шул хәтле илаһи һәм дәһшәтле манзараларны тасвирларга сүзләр көчсез, бәндә көчсез, каләм көчсез... Кәгъбәтулла өстендә яңгыраган төнге азан авазлары, миллионлаган мөселманнарның кәфенлеккә уралган әрвахлар сурәтендә Аллаһ йорты янына җыйналулары, Мәккә һәм Мәдинә шәһәрләрендә укылган намазлар, Пәйгамбәребез рухын саклаган кара мәрмәр таулар, бу күренешләр, бу авазлар, бу тәэсирләр гомеремнең ахырына кадәр мине озата барырлар, мәңге онытылмаслар, мәңге җуелмаслар...

Көче һәм сәламәтлеге җиткән һәр мөселманга гомерендә бер тапкыр Хаҗ гамәлен кылу фарыз, мәҗбүри. Ул — исламның төп шартлары булган биш фарызның берсе. Бу хакта Аллаһы Тәгалә безләргә менә нәрсә дип васыять итә: **"Дөреслектә кешеләргә Аллаһуга гыйбадәт кылган вакытларында юнәлү өчен салынган өйнең әүвәлгесе — Мәккәдәге Кәгъбәтуллаһтыр. Мәккә шәһәре кешеләр өчен мөбарәк, Кәгъбәтуллаһ — барча галәмнәр өчен һидаят билгесе. Ул Кәгъбәтуллаһта билгеле галәмәтләр бар, шулардан берсе — Ибраһим гәләйһиссәламнең ташка баткан ике аяк эзләредер. Анда кергән гаепле булса да, анда чагында хөкем ителүдән иминдер. Көче җиткән кешеләргә Аллаһуга гыйбадәт өчен Хаҗ кылу — фарыз. Берәү Хаҗның фарызлыгына ышанмаса, көче житеп тә Хаҗ кылмаса, зарары үзенә. Аллаһ бөтен галәмнәр мәхлугыннан мөстәгънидер, һичберсенең гамәленә мохтаҗ түгел, карышкан кешеләрне газап кылыр."** *("Гимран" сүрәсе, 96-97 аятьләр.*)*

Шуңа күрә, мөмкинлеге булып та, Хаҗга бармыйча, бу булган байлыкны дөнья малы артыннан кууга, өсте-өстенә коттеджлар һәм йортлар салдыруга, машиналар алмаштыруга, чит илләрдә, диңгез буйларында ял итүгә һәм башка шундый гамәлләргә сарыф иткән бәндәләр өсләренә зур гөнаһ алалар. Коръәндә әйтелгәннәргә һәм Пәйгамбәребез сөннәтенә, хәдисләренә бик җитди карарга кирәк, дин белән уйнарга, аны фани дөньяда карьера ясау өчен генә файдаланырга, динне сәнгатькә, җыр-биюгә, шигърияткә әйләндереп калдырырга ярамый, дин ул — гамәл, аны тотарга кирәк, ягъни, Коръәнчә, Аллаһы Тәгалә кушканча яшәргә кирәк. Һәрхәлдә, без мөселман, дип йөрүчеләргә булса да...

Хаҗ сәфәрендә мин беренче көнемнән көндәлек алып бардым. Минем милләттәшләремә мөмкин кадәр күбрәк мәгълүмат бирәсем килде, үзем күргәннәрне алар да күз алдына китерерлек итеп тасвирласым килде, мин кичергәннәрне алар да күңелләре аша кичерә алырлык тәэссоратлар, хис-тойгыларымны җиткерәсем килде. Әлбәттә, намаз-гыйбадәт араларында, тау-таш өсләрендә, ай яктыларында, самолет һәм автобусларда язылган бу көндәлегемә минем Хаҗда күргәннәрем һәм кичергәннәремнең барысы да кереп тә бетмәгәндер. Әмма, булган кадәресен, тәвәккәлләп, мин укучы ихтыярына тапшырасы иттем. Аллаһы Тәгалә бу эшемнән риза булсын иде. Телемне ялганнан, гамәлләремне харамнан сакласын иде. Амин.

*1998 елның 4 июне.*

---

* Коръән тәфсире. Казан. Татар. кит. нәшр. 1992 ел. 69-70 б. Алга таба аятьләр шушы чыганактан алына.

# Хаҗ көндәлеге

Бисмиллаһир-рахманир-рахим.

**1998 ел. 27 март.** Ниһаять, без күктә. Көне буе Казан аэропортында самолет көтеп ятканнан соң, без, Хаҗга баручылар, кыйблага таба очып киттек. Җомга, икенде, ахшам намазларын Казан аэропортының таш идәннәренә тезләнеп укыган идек, ястү намазын укырга самолетта әзерләнәбез.

Безгә дигән самолет, никтер, Уфадан килде, без "Башкортстан" авиалиниясе очкычында Хаҗ сәфәренә юлга чыктык. Мөселман татарлар өчен Казанның үзендә самолет табылмаган, күрәсең. Мәшәкатьле, әмма саваплы, изге юлыбыз башлана гына әле, алда әллә нинди тоткарлыклар, каршылыклар булуы мөмкин... Без Аллаһтан сабырлык, ныклы иман, ихласлык, саулык-сәламәтлек сорыйбыз...

Без бу самолетта Хаҗ сәфәренә 160 лап кеше очабыз. Күренеп тора — хатын-кызлар күбрәк. Бездән башка тагы 200 ләп кеше очачак икән, алар Корольнең кунаклары булачак, ди, гарәпләр Татарстанга, татар халкына шундый зур бүләк ясаганнар. Хаҗ сәфәренә лаек булган, тәкъва, хакыйкый мөселманнарга насыйп булсын иде бу бүләк... Безнең белән Хаҗ сәфәренә чыгучыларның күбрәге олы як — алтмыш белән җитмеш арасы. Шушындый озын юлга тәвәккәлләп сәфәр чыккан бу апа-абзыйларга карап, күңел тула. Артык җитди дә, балалар кебек беркатлы да күренәләр алар бүген. Хатын-кызларның күбесе мәчеттә үк ак күлмәкләрен киделәр, ирләр исә самолетта гына, Мәккәгә якынлашканда Хаҗ киеме — ихрамга бәгъләначаклар. Ә хәзергә — көньяк-көнчыгышка — кыйблага карап очабыз. Аста — төн. Ап-ак карга уралган татар авыллары безне тын гына, сабыр гына ерак юлга озатып кала... Раббым, бу кырларга, бу урманнарга, җандай газиз бу татар авылларына, калаларыбызга исән-имин әйләнеп кайтырга насыйп ит. Илдә калганнарга да имин тормышлар насыйп ит, Раббым Аллам!

Бергәләп, хаҗиларны Хаҗга озату догасын укыйбыз. Гүяки бу догабызга тын авылларыбызда безне тын гына озатып калган ата-аналарыбыз да кушыла, дин өчен көрәшеп шәһит киткән әби-бабаларыбыз рухы безне караңгы төннәрне аралап, озата бара, балаларыбыз, өмет белән мөлдерәп, безнең исән-сау илләргә әйләнеп кайтканны көтеп калалар...

*"Бисмиллаһир-рахманир-рахим. Аллаһым! Биргән саулыгыңа, биргән нигъмәтләреңә меңнәрчә мәртәбә шөкерләр булсын! Безне яраттың, кальбебезгә ислам нурын урнаштырдың, мактау булсын Сиңа. Кәгъбәне мөбарәк кылдың. Күңеле Аллаһны сөю белән янган Ибраһим Пәйгамбәрне анда урнаштырдың. Безләргә аңа зиярәт итүне фарыз кылдың, инде ул мөбарәк туфракларга кавышу, аңа тәваф итү, зәмзәмеңне эчү теләге белән юлларга чыгабыз. Бу Аллаһка, Мөхәммәдкә, Пәйгамбәребезгә карата булган ашкынуда Кәгъбәне, аңа күрмичә җаныбызны алма, йөзебезне Хаҗәри-әсвәдкә куюю өчен саулык бир. Кәгъбә тирәсендә фәрештәләр кебек әйләнергә көч һәм куәт бир, Сафа һәм Мәрва таулары арасында, Ибраһим Хәлилуллаһны искә алып, Мөхәммәд Пәйгамбәрнең юлында җаныбызны фида кылыйк. Аллаһым, гөнаһларыбыз гафу ителсен, йортыбызга яңа туган кебек пакь һәм гөнаһсыз кайтыйк. Эчебездәге шайтанны үтерик. Бөтен җаныбыз, тәнебез белән "Ләббәй кә ләһүмә ләббәйк", дип кычкырыйк. Мин Синең әмереңдә, Аллаһым, әмер ит.*

*Йа, Рабби! Синең сөюең белән юлларга чыктык. Исән-сау кайтып килүне, гаиләбез һәм дусларыбыз белән кавышуны насыйп ит, аларны да сау-сәламәт күрүне насыйп ит. Һәр мөэмин колыңа Кәгъбәне тәваф итәргә насыйп әйлә, Аллаһым!*

*Аллаһым! Синнән бу дөньяда һәм ахирәттә яхшылык телибез, гөнаһла-рыбызны кичер. Сөекле Пәйгамбәрләребезнең шәфәгатенә ирештер. Амин."*

Хаҗ сәфәренә юлга чыгучылар арасында авыл татарлары да бар, шәһәрнекеләр дә күп. Чүчинкә итек, җон оекбаш, галош киеп Хаҗ сәфәренә юнәлүче самими, ихлас авыл татарлары... Аларга бу хәтле чыгымнарны күтәрергә

балалары ярдәм иткәндер инде. Авыл татарлары, һәр җирдәге кебек, самолетта да тын гына, күбрәк читтән күзәтеп кенә утыралар. Безнең бу төркемдә дин әһелләре, исемле, билгеле кешеләр, язучы-галимнәр, интеллигенция юк дәрәҗәсендә аз. Биредә — үз хисапларына Хаҗ кылучы ихлас мөселманнар, гади, бөек кешеләр... Менә янәшәмдә генә Түбән Кама шәһәреннән Рисәлә апа утыра. Аның белән инде Казан аэропортында ук танышкан идем. Аягында чүпрәк итекләр, башына гади бүрек өстеннән шәл уранган, кулына бәләкәй арба тарткан бу өлкән яшьтәге апага мин инде анда ук игътибар иткән идем. Без сөйләшеп-танышып киттек. Рисәлә апа — ялгыз карчык, ул Хаҗга бару өчен 4 ел буе пенсия акчасын җыеп килгән, ә үзе өс-баш тегеп саткан акчага яшәгән. Бәрәңгесенә кадәр үзе белән төяп алып бара, Мәккәдә шәкертләргә бирермен, ди. Никадәр ихласлык, никадәр бөеклек бу татар хатыннарында!

Сатирә апа Мөлекова белән без Чаллыдан ук бер таксида килдек, хәзер дә урыннарыбыз бер-беребездән ерак түгел. Таксидан чыкканда сумкасын күтәрешергә теләгән идем, әмма ул күтәрерлек түгел иде. Ул анда шыплап кара ипи тутырган икән. "Мәккәдә кара ипи юк икән, — диде миңа Сатирә апа. — Шәкертләребезгә дип алып барам бу ипиләрне..." Бер караганда, ул шәкертләр бу апаның беркеме дә түгел бит, әмма алар — татар балалары, мөселманнар. Шушындый кешеләрне күргәч кенә мин милләтебезнең никадәр бөеклегенә, исәнлегенә янәдән ышана башлыйм. Ә ул ышаныч бик кирәк...

Шәһәр хатыннарының күбесе ап-актан киенгән. Аларда шундый пакьлек, ихласлык, җитдилек — алар җирдә без күреп өйрәнгән татар хатыннарына бөтенләй охшамаганнар. Бу кадәр дә нурны, бу кадәр дә чисталыкны күреп, җәннәттәге хатын-кызлар, хур кызлары, мөгаен, шушындыйрак кыяфәттә булалардыр, диеп уйладым. Йа, ходa, бөтен хатын-кызларыбыз шушылай киенсә, үзләрен шушылай тыйнак, инсафлы, горур тотса, без изге милләт булыр идек, безнең урыныбыз да җәннәтнең түрендә булыр иде...

Бу Хаҗ сәфәренә кайбер шәһәрләрдән төркем-төркем булып, бик зур әзерлек белән килгәннәр. Әлмәттән Наил хәзрәт җитәкчелегендә 27 кеше Хаҗ сәфәренә чыккан, алар гел бергә, киңәшләшәләр, ярдәмләшәләр... Түбән Камадан да егермегә якын кеше бергә тупланып юлга чыкканнар, аларны Түбән Камада тәкбирләр әйтеп, намазлар укып, Казанга хәтле зур автобус белән озатканнар. Ә без, Чаллылар, урык-сурык, аерым-аерым, таксилар тотып килдек. Аллага шөкер, әле ярый Чаллыда хатын-кызлар мәдрәсәләре бар, бу юлы да "Тәнзилә" мәдрәсәсе мөгаллимәләре Хаҗ сәфәренә бергәләшеп тәвәккәлләгәннәр. Чаллыдан без 12-13 кеше булырга тиешбез. Барчабыз да исән-сау әйләнеп кайтсак ярар иде инде...

Төне буе самолетта очтык. Берләшкән Гарәп Әмирлекләренә туктап, ягулык алдык, аннан тагы очып киттек. Ястү, витр намазларын самолетта укыдык. Безнең салонда гел хатын-кызлар гына диярлек, күрше салонда — ир-атлар. Ниһаять, ир-аттан аерыла, үз асылыбызга кайта башладык. Ир-атлар ул якта ак ихрамнарга төренәләр, бу якта хатын-кызлар тәһарәтләнә һәм киенә. Бергә булсак, без бер-беребезгә нинди уңайсызлыклар һәм авырлыклар тудырыр идек. Дин һәрберсен үз урынына куя... Беркем йокламый... Без инде Согуд Гарәбстаны өстеннән очабыз... Таң алды... Төн белән көннең кушылган һәм аерылган сагышлы бер мизгеле... Тәннәребездә һәм җаннарыбызда җинелчә калтырану, борчылу сизәбез... Йа, Раббым, безме бу? Без әзерме һәм лаекмы бу изге җирләргә аяк басарга, бу туфракларга йөз орырга, Пәйгамбәребез йөргән эзләрдән йөрергә, ул гыйбадәт кылган мәчетләрдә намаз укырга?

Менә без Җиддә аэропортына якынлашабыз. Ирләр кычкырып тәлбия әйтә башладылар, микрофоннан ул тәкбир авазлары белән аралашып бара. Көчле тәкбир тавышы самолет гүләвен дә, безнең дулкынлануны да, барлык шик-шөһбәләрне дә басып китә...

Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр!
Лә иләһә иллаллаһу!
Аллаһу әкбәр! Аллаһу әкбәр!

Таң яктысы кергәндә, Пәйгамбәребезнең туфрагына аяк бастык. Күзләребездә — яшь, телләребездә — дога...

Аллаһу әкбәр! Аллаһу әкбәр!

Үзебезне, әчкерсез догаларыбызны, изге ният һәм гамәлләребезне кабул итеп ал, Раббым! Хаж сәфәрләребез хәерле булсын!

Без таможня, паспорт контролен башкалардан аерым үттек. Гарәп ир-атлары дәшми генә безне төрле ишекләргә, төрле тәрәзәләргә озатып торалар. Хатын-кызлар — аерым, ирләр — аерым. Ник бер сүз, ыгы-зыгы, тавыш булсын. Күңелне шомландырып, тагы бер уй үтте — кыямәт көнендә дә шушылайрак булачак бит! Аллаһының фәрештәләре бер ишектән икенчесенә йөртәчәкләр, сорау алачаклар, төрле төркемнәргә бүләчәкләр. Кемгә — кайда... Кылган гамәлләренә, иман дәрәҗәнә карап... Хәтта бу чик буе ишекләрен дә шикле документ белән үтеп булмый, ә безнең күбебез гамәл кылмыйча гына җәннәт ишекләрен ачмакчы була. Хаж сәфәре Аллаһыдан безгә гыйбрәт өчен җибәрелгән могҗиза түгелме соң ул? Исән чакта гыйбрәт алыр өчен, чагыштырып карар һәм... әзерләнер өчен...

Безнең бер төркемебез паспорт контролен исән-имин үтте, ә бер төркемнең визасы юк булып чыкты. Чик буен имин генә үткән төркем аэропорт мәйданында калганнарыбызны көтә. Әле кояш чыкмаган. Шуңа күрә тиз-тиз иртәнге намазга әзерләнәбез...

**28 март.** Әле кояш чыкмаган. Җиддә аэропортында тәһарәт алырга да, хәтта госел коенырга да бөтен шартлар бар. Әзерләнеп, таш мәйданга намазлыкларыбызны җәеп, иртәнге намазны укыйбыз. Изге Хаж җирләрендә, Пәйгамбәребез туфрагында бу безнең беренче намазыбыз. Күзләрне яшь томалый. Кыйблага тезләнеп, мин дә Гарәбстанда беренче намазымны укыйм. Ата-анама, балаларыма, гаиләмә, туганнарыма иман, саулык-сәламәтлек сорыйм. Беренче догам — иң якыннарыма, Раббым, кабул итеп алсаң иде...

Визасыз кешеләрнең паспорт контроле үткәнен көтеп ятабыз. Инде өйлә намазы да җитеп килә. Көн эссе, 35 градуслар булыр. Яшьрәкләр чәй ташып тора, үзара танышабыз, аралашабыз. Безнең янга гына төрекләр дә килеп утырды, бераз сөйләшеп тә алдым. Араларында "Рефак" дини партиясе вәкилләре дә бар иде, алар белән Төркиядәге хәлләр, ислам диненә карата башланган басым турында борчылып сөйләшеп алдык. Янибызга гына үзбәкләр дә байракларын күтәреп кададылар, һәм үзбәк хаҗилары шул тирәгә туплана башлады. Кая карама төрле илләрнең байраклары. Монда байрак бик мөһим роль уйный, ул — бер-береңне эзләп табарга, тупланырга нык ярдәм итә.

Безнең Татарстан байрагы Габдулла хәзрәтнең әтисе Сафа абзый кулында. Ул аны Казаннан бирле үзе тотып килде, хәзер дә кулыннан төшерми. Абзый балалар кебек куанган, яктырып киткән...

Әле өлкән яшьтәге ике апа белән сөйләшеп утырам. Бу гаҗәеп чиста, тыныч, мөлаем апаларга мин Казан аэропортында ук игътибар иткән идем инде. Менә хәзер, Җиддә аэропортында, сөйләшеп тә киттек. Гадәттә, Хаҗга баручылар турында халык арасында төрле сүзләр йөри. Имеш, шулкадәр зур акчаларны бүгенге көндә табу мөмкин түгел (сүз мең ярым доллар турында бара), имеш, харам акчага да баручылар бар, тегесе дә монысы... Миңа язу өчен, бу гайбәтләрне өлешчә булса да тарату өчен бик җентекләп белергә, иплән кенә, кешеләрнең күңелләрен рәнҗетмичә генә, сораштырырга кирәк. Минем әңгәмәдәшләрем икесе дә Казан карчыклары булып чыктылар, яшьләре җитмешләр тирәсендә булыр. Апаларның берсе, Хаҗга барырга акча туплар

өчен, ел буе биш Вьетнам гаиләсенә хезмәт күрсәткән, ягъни, аларның яшь балаларын караган, шәһәр буенча йөгереп йөреп, кайсына сөт, кайсына башка ризык ташыган, асларын юган, чистарткан. Бу гаиләләр биргән акчаны тиенләп җыеп барган һәм менә хәзер Хаҗга килгән. Икенчесе исә дачасын сатып җибәреп, шуның акчасына Хаҗга килгән. Хаҗга бару өчен еллар буе ашау-эчүне, кием-салымны кысып, акча җыючылар да бар. Бу апалар белән сөйләшкәндә шуны да яхшы аңладым — ниятенә кергән кеше үз дигәненә барыбер ирешә. Иманы зәгыйфь кеше дин тотмас өчен сәбәп эзли, Алладан курыкканы Аллаһы Тәгаләгә юлларын эзли. Һәм таба. Җиддә аэропортында күгәрченнәр кебек тезелеп утырган татар карчыклары, татар апалары, бабайлар, ир уртасы кешеләр — шул юлга чыгучылар, шул юлны табучылар түгелмени?

Көтеп утыру озаккарак китте. Визасыз ябылып калган төркемне һаман чыгармыйлар. Анда күбрәк карт як, Рәшидә абыстай белән ире Гомәр абзый, Камил хәзрәтнең әнисе Камилә абыстай, тагы егермеләп кеше чик буенда тоткарланып калды. Җитмәсә, житәкчебез Габдулла хәзрәт үзе, тагы бер имамыбыз Наил хәзрәт тә алар арасында. Без иртәдән кичкә кадәр аларны көтеп таш мәйданда утырабыз, язмышлары турында берни белмибез һәм борчылабыз. Шул ук вакытта без аларны калдырып Мәккәгә дә китеп бара алмыйбыз, беренчедән, бу — юлдашларыбызны ярты юлда ташлап китү булса, икенчедән, Габдулла хәзрәттән башка безне Мәккәдә алдан сөйләшенгән урынга беркем дә алып бара алмый. Ә Габдулла хәзрәт безнең янга чыга алмый, дөресрәге чыга ала, әмма бер чыккач, инде ябылуда калган карт-карчыклар янына башка керә алмый. Монда аэропорт берьюлы меңләгән, хәтта миллионлаган кешене кабул итеп, уздырып тора, шуңа күрә тәртип бик нык, кырыс, монда син үзең түгел, синең өчен кәгазьләрең, документларың сөйләшә. Аларда әз генә төгәлсезлек булдымы — кире кайтарып җибәрергә дә күп сорамыйлар. Чөнки Хаҗ битлеге астында төрле шымчылар, террористлар, начар адәмнәр дә килергә мөмкин. Безнекеләрнең элегрәк шулай визасыз килеп, үтеп киткәннәре булган, бу юлы да шуңа ышаныбрак, тагы алдан кемнәр беләндер сөйләшеп, юлга чыкканнар. Ә хәзер, менә инде 10-15 сәгать, беркем дә ярдәм итәргә, аларны визасыз гына үткәреп җибәрергә теләми. Димәк, биредә "чолганышта" калган 60-70 яшьлек карт-карчыклар, Хаҗ өмете белән юлга чыгучы яшьләр, йә берәр самолет белән кире кайтып китәргә, йә көннәр, атналар буе виза көтеп ятарга тиеш булачаклар. Кайберләренең чит ил паспортларының срогы җәйге айларда чыга икән, шуңа күрә Мәскәүдә виза куймаганнар, Россия илчелеге Гарәбстанга килгәч, булышырга вәгъдә биргән. Ә биредә исә, күпме шылтыратып та, Россия илчелегеннән килеп тә карамадылар...


Шулай итеп, без юл башында ук икегә аерылдык, бер өлешебез аэропортта "бикләнеп" калды, икенче өлешебез чатнаган кояш астында мәйданда ята. Җитмәсә, үзбәкләр килеп, яткан урыныбыздан да куып чыгардылар, бу урын 700 үзбәк мөселманы өчен каралган икән, хәзер алар һавада, килеп төшешләренә аларга урнашырга мәйдан кирәк икән. Безне күләгәле тыныч урыныбыздан юл өстенә кысрыклап чыгардылар, хәзер инде таш өстендә, кеше аягы астында ятабыз. Халыкны, "Хаҗ сәфәре шулай газаплы була инде ул", дип тынычландыручылар да бар, "безнең оеша белмәгәнебезгә Хаҗның ни гаебе бар соң?" дип борчылучылар да күп. Халык арыды, кешеләрнең күңеле төшә башлады. Нидер эшләргә, сәфәребезнең башында ук килеп чыккан күнелсезлекләрне бетерергә ярдәм итәргә кирәк иде. "Син укыганрак, бераз йөре, ярдәм ит", дип, әби-бабайлар миңа да мөрәҗәгать иттеләр. Делегация кебек бер төркем төзеп, илчелекләргә, хәрбиләргә, аэропорт житәкчелегенә чыктык, ярты көн арлы-бирле йөрдек, сөйләшүләр алып бардык. Эчтә исә Габдулла хәзрәтләр үзләре дә хәрәкәттә булганнар, сөйләшүләр алып барганнар. Ниһаять, Аллаһы безгә ярдәм итте — юлларыбызны ачты — ахшам намазы алдыннан "әсир"ләребезгә виза куеп, "биктән" чыгардылар. Чыккач абыстайларның

беренче сүзе — "ник фетнә чыгарып йөрдегез?" булды. Мин телсез калдым, изгеләштергән сәфәрем, изгеләштергән юлдашларым, канатланып, күктә очуларым бер мизгел-гә бары да юкка чыкты — мин бередә дә усаллык белән очраштым. Минем елый-елый ашкынып Мәккәгә очкан җаным моны күтәрерлек хәлдә түгел иде... Мин врач бүлмәсендә, уколлар ясый башлагач кына аңыма киләм, йөрәгем янадан тибә башлый, әкрен генә күзләремне ачам. Аллаһы Тәгалә яраткан бәндәсен Хаҗ сәфәрендә авырулар белән сыный, диләр... Алда көткән барлык сынаулардан иманны югалтмыйча, кеше булып, көчле булып чыгарга язсын иде. Шушы хәтле дә җаваплы, шушы хәтле дә хикмәтле, шушы хәтле дә саваплы Хаҗ сәфәрен минем пакь тән һәм пакь җан белән, сәламәт килеш, үз аякларымда йөреп, хәере белән башкарып чыгасым килә. И, Раббым, көч-кодрәт бир арыган тәнемә һәм җаныма, кешеләрдән биздермә, аларны кичерә алырлык олы йөрәк бир, ихлас һәм ныклы иман бир...

Мине башта Мәккәгә "ашыгыч ярдәм" машинасында илтергә булганнар иде, риза булмадым, үзебезнекеләрдән аерыласым килмәде. Мәккәгә үземнең милләттәшләрем белән, үз аягым белән барып керәсем килде. Мина авыр вакытымда ярдәм иткән төрек табибларына рәхмәтләремне әйтеп, алар ярдәме белән автобуска утырдым, һәм без, бөтен төркемебез белән, Мәккәгә карап кузгалып киттек...

Җиддәдән Мәккәгә автобус белән киттек. Ике көн рәттән Казан һәм Җиддә аэропортларында ятып, төнне самолетта уздырып, халык бик арыган иде, алай да автобусларда тәкбир һәм тәлбия авазлары яңгырап торды. **"Ләббәйкә-лләһуммә ләббәйк, ләббәйкә лә шарикә ләкә ләббәйк, иннәл-хәмдә вән-нигъмәтә ләкә вәл-мульк лә шарикә ләк"**. "И Аллаһы Тәгалә, Синең нигъмәтеңне камил итагать илә кыйламын. Синең һич тиңдәшең юк. Дөреслектә барча мактау вә барча нигъмәт Сиңа гына хас. Вә хуҗалык та Сиңа гына. Синең һич тиңдәшең юк".

Төнге Мәккә безне янып торган утлары, гөрләп торган урамнары белән




каршы алды. Бу инде Пәйгамбәребез заманындагы Мәккә түгел. Мәккә тирәсендәге кырыс кара таулар гына бу җирләрнең гаять борынгы, тарихи изге җирләр икәнен искә төшереп, кисәтеп торалар...

Никадәр арыган булса да, төнге гумра Хаҗыбызны башкарырга ниятләдек, ягъни, бу төнне үк Кәгъбәтуллага барып, шунда гумра (кече) Хаҗ гамәлләрен башкарырга, дигән фикергә киллек. Әле безнең фарыз Хаҗыбыз Корбан бәйрәме алдыннан гына башланырга тиеш, шуңа күрә безнең кече Хаҗ гамәлләрен башкарырга да мөмкинлекләребез бар иде. Бу безгә фарыз Хаҗ гамәлләренә өйрәнә торырга да бик яхшы җай иде. Урнашкан йортыбызда ястү намазын укыдык та, тезелешеп, тәкбир әйтеп, Кәгъбәтуллага таба юнәлдек. Без урнашкан урам туры Кәгъбәтуллага илтә. Төнге сәгать бер белән ике арасы... Юлда безгә күп кенә хаҗилар очрый, берәүләр Кәгъбәтуллага бара, икенчеләре инде кайтып килә. Кәгъбәтулланы күрәсебезгә әле һаман күңел ышанып бетми. Без, татар хаҗилары, тәкбир әйтеп, ашкынып, шул якка — мәчет-Һарам ягына таба барабыз. Мәчетне әлегә биек, заманча йортлар каплап тора. Ул, дөньяның бөек бер могҗизасы кебек, кисәк кенә күренә икән...

Нәкъ шулай булды да. Кайсыдыр биек йортның артыннан кинәт кенә мәгърур, мәрмәр Һарам мәчете күренде. Кап-кара төн, ак мәрмәр мәчет, күккә төбәлгән очлы манаралар һәм кешеләр, кешеләр, кешеләр... Шушы Һарам мәчетенең ишек алдында, эчендә — Кәгъбәтулла, җәннәттән иңгән кара таш, Аллаһының сере, могҗизасы, хәбәре...

Һарам мәчетенең 45 капкасы бар икән. Без шуларның беренчесеннән-Габделгазиз капкасыннан эчкә керергә җыенабыз. Фарыз Хаҗга караганда, халык әле чагыштырмача азрак, әйтик, Корбан бәйрәме көннәрендә монда 3-5 миллион кеше берьюлы фарыз гамәлләр башкарса, хәзергә биредә миллионга якын кеше булыр. Ул да бик күп, ашыгып түгел, аяк атлап йөрергә дә мөмкинлек чикле. Без, шушы халык арасында адашмыйча, тапталмыйча, җиде тапкыр Кәгъбәтулланы әйләнергә тиешбез. Аннан соң, мәчет эченә үк



керәп калган Сафа һәм Мәрва таулары арасын җиде тапкыр урарга, нәфел намазларыбызны укырга һәм мәчет эчендә үк агып яткан зәмзәм суын авыз итәргә тиешбез. Шушының белән кече Хаҗ тәмам була, без инде фарыз Хаҗ гамәлләренә әзерләнә башларга тиешбез. Адашсаң, эзләп табу өчен, Мәккәгә килгәч тә беләкләребезгә гарәпчә язылган беләзекләр тактылар, муеннарыбызга кызыл тасмалар кидек. Монда һәр милләт, бер-берләрен таныр-табар өчен, киемнәренә берәр тамга таккан, күбесендә — дәүләт байраклары рәсеме. Бу яктан бигрәк тә төрекләр, Малайзия һәм Индонезия мөселманнары аерылып тора, аларга күз салу белән, тамгаларына карап, кайдан икәнлекләрен әйтергә була.

Аяк киемнәребезне салып, Һарам мәчетенә керәбез. Кем оекчан, кем яланаяк кала. Мәчеткә кергәндә кулда әйбер булырга тиеш түгел, без дә аяк киемнәребезне муеннарыбыздагы алдан әзерләнгән кечкенә капчыкларга салабыз. Салкын, ак мәрмәр идәннән бераз баруга... күз алдында кинәт кенә Кәгъбәтулла-кара таш пәйда булды. Мин "аһ" итеп куйдым. Кәгъбәтулла, Аллаһ йорты, җәннәттән ингән серле кара таш... Ничә йөз еллар бөтен дөньяның мөселманнары шушы кыйбла ягына карап гыйбадәт кылганнар. Кәгъбәтулла — Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кылу өчен җир йөзендә беренче салынган йорт, аны төзүне Аллаһы Тәгале Мөхәммәт галәйһиссәламнең ерак бабасы булган Ибраһим Пәйгамбәргә һәм аның улы Исмәгыйльгә тапшыра. Җәннәттән ингән кара таш үзе затлы ырнауга утыртылган, бу җәннәт ташын саклау өчен шакмак (куб) рәвешендә корылма ясалган, ул Коръән аятьләре язылган кара япма белән чорнатып алынган. Башта бу корылманың эче потлар (сыннар) белән тулган булган, хәтта мәҗүси гарәпләр дә бу урынның хикмәтле икәнен белгәннәр, табыну урыны итеп күктән шушы таш төшкән җирне сайлаганнар. Аларның да хаҗлары нәкъ безнеңчә булган — җиде тапкыр Кәгъбәтулланы тәваф кылганнар, ягъни, әйләнгәннәр, Сафа һәм Мәрва таулары арасында йөргәннәр, корбан чалганнар, тауларда Хаҗ кылганнар. Әмма бездән, мөселманнардан аермалы буларак, алар сыннарга табынганнар, сыннардан ярдәм көткәннәр, сыннары өчен корбан биргәннәр. Бу мәҗүсилеккә каршы беренче булып Ибраһим галәйһиссәлам күтәрелеп чыга, бер Аллага табынырга өнди. Бу хакта Коръәндә менә ничек әйтелә: **"Дәхи хәтерләгез, Ибраһимга Кәгъбәнең урынын бәян иттек, вә аңа әйттек: "Миңа һичнәрсәне тиңдәш итмәгел, вә минем өемне ягадан килеп тәваф итүчеләргә, вә анда торучыларга, вә намаз укучыларга пакълагыл, анда ислам диненә хыйлаф бер гамәл дә булмасын".** *("Хаҗ" сүрәсе, 26 аять.)*

Ислам дине көчәйгәч, потларны җимереп, биредә мөселманнар гыйбадәт кыла башлаганнар. Мөселманнар, кайда гына яшәсәләр дә, аларның карашлары, күңелләре Кәгъбәтуллага төбәлгән. Мөселман кешесе өчен бөтен юллар да Мәккәгә илтә, бөтен уйлар да Кәгъбәтуллага илтә...

Без Кәгъбәтулла тирәли әйләнә — тәваф кыла башлыйбыз. Әмма Кәгъбәтуллага якын килерлек түгел, без бик ерактан әйләнергә мәҗбүрбез. Таза-таза негрлар, елгыр индонезиялеләр әйләнгән саен кара ташка ныграк якынаялар, аңа куллары белән кагылу бәхетенә ирешәләр, үбәләр. Мин, әле генә каты авыру кичерү сәбәпле, ялгыз гына йөри алмыйм — мине биредә укучы Ирек исемле татар шәкерте җитәкләп йөртә. Халык дулкыны безне бер күтәреп, читкә чыгарып ташлый, бер Кәгъбәтуллага ук китереп тери. Кайбер урыннарда аяклар җиргә тими — халык ташкыны үзе этеп, күтәреп алып бара. Биредә егылырга ярамый, егылсаң, ташкын өстеннән чыгып китәчәк. Этү-төртү юк, кырыс бер тәртип, тыгыз бөҗра булып, бер-берләребезгә тотынып, Кәгъбәтулланы әйләнәбез. Җиде бөҗра, Аллаһка җиде тапкыр ялварып мөрәҗәгать итү. Аннан соң җиде тапкыр Сафа һәм Мәрва таулары арасын йөгереп-атлап уздык. Һәр әйләнүдә, тау башына менеп җиткәч, ин изге, иң эчкерсез теләкләребезне теләдек. Биредә теләгән бөтен теләкләр дә тормышка

аша, диләр. Шуна күрә беркем беркемне күрми, елап, ялварып, Аллаһыдан үзенә кирәкне сорый. Авыру кеше — сәламәтлек сорый, фәкыйрь кеше — бәрәкәт сорый, иман ныклыгы, ихласлык сорый, җәннәтләргә керерлек изге гамәлләр башкаруны сорый. Биредә, Сафа һәм Мәрва таулары арасында, анабыз Һаҗәр шулай яңа туган улы Исмәгыйльгә эчерергә су таба алмыйча, уттай кояш астында өзгәләнеп йөгергән, һәм Алланың рәхмәте белән, Исмәгыйль яткан урында су тибеп чыккан. Бу су — зәмзәм суы дип атала. Ул суның файдасы, составындагы нигъмәтләр турында әйтеп тә, язып та бетерерлек түгел. Бу су еллар буе сакланып та бозылмый, күпме эчеп тә туйдырмый, хәтта ашыйсы килү теләген дә бетерә. Зәмзәм суының составында көмеш бар, башка күп төрле файдалы матдәләр бар, дип әйтәләр, анысын галимнәр тәгаен беләләрдер. Һәм менә мин дә, беренче тапкыр, кипшергән иреннәремне зәмзәм суына тидерәм. Әйтерсең лә, балачагыма кайтам, йотылып-йотылып чишмә күзеннән шифа эчәм, һәр күзәнәгем терелә, җанлана, пакьләнә. Аннан зәмзәм суын уттай янган алҗыган йөземә, күзләремә тидерәм. Мин басып торган мәчет тә ап-ак, кешеләр дә ап-ак, дөнья да ап-ак... шушы аклык, пакьлек эчендә бу мәчеттә беренче намазымны укыйм... Минем белән бергә бу намазны шушы көнне тилмереп көтеп торган фәрештәләрем дә укый, бөтен нәселебезгә соңгы йөз елда беренче мәртәбә мин — **Әүхәди кызы Фәүзия** дөньяның иң изге мәчетендә, Кәгъбәтулла каршына тезләнеп, намаз укыйм... Миннән дога өмет итеп яткан әрвахлар рухына багышлап, атам-анама исәнлек сорап, балаларымның иманлы булуын теләп, милләтемнең дөрес юлга — ислам юлына чыгуын сорап, мин дөньяның Баш мәчетендә намаз укыйм... Төн әле үтмәгән, таң әле атмаган, догаларның иң кабул була торган чагы, Раббыбызның күк капусына, адәм балаларына иң якын чагы...

Иртәнге намазны да шушында, Һарам мәчетендә укыдык. Миллионлаган кеше берьюлы, бер җан булып, Раббыбыз каршында тезләндек. Беренче таңыбызны Мәккәдә, Аллаһы каршында тезләнеп каршы алдык...

**29 март**. Өйләгә кадәр ял иттек. Кайбер кешеләребезнең төнлә мәчет тирәсендә адашып калганнары билгеле булды. Моңа гаҗәпләнерлек тә түгел иде. Казан урамнарында да адашмыйча, кешегә тотынмыйча йөри алмаган авыл карт-карчыклары, 80-90 яшьлек бабайлар ничек төнлә, миллионлаган кеше арасында йөри белсеннәр дә, юлын тапсыннар, ди. Алай да Габдулла хәзрәт, Габдерәшит хәзрәт, биредә укучы шәкертләр халыкны бергә туплап, исән-сау йөртер өчен бөтен көчләрен куйдылар. Ә барыбер адашучылар, кайтмый калучылар бар. Рәшидә абыстайның ире Гомәр абзый бер тәүлеккә якын югалып торды, аннан китереп куйдылар. Берничә хатын адашып, төне буе без яшәгән йортны таба алмый йөргәннәр. Полиция ярдәме белән, соңрак алар да кайтты. Инде арабызда эсселектән чирләүчеләр дә күренә башлады. Һәрхәлдә, эсселек 30-35 градуслар гына булса да. Бу — аларның кышы дияргә була. Җәйләрен биредә эсселек 60-70 градуска җитә икән. Ходаның хикмәте, 29 март көнне көндез, 30 мартка каршы төндә көчле яңгыр яуды. Монда яңгырлар сирәк булганлыктан, без моны да Аллаһының бер хикмәте һәм бүләге итеп кабул иттек. Бүген беренче тапкыр яктыда гарәп җирләрен, Мәккә шәһәрен күрдек. Монда Пәйгамбәребез заманыннан Кәгъбәтулла һәм шәһәрне әйләндереп алган кара мәрмәр кыялар гына калган. Мәккә шәһәре бүгенге көндә заманча биек йортлардан, кунакханәләрдән, затлы кибет һәм чәйханәләрдән торган бер шәһәр. Мәккәдә малайлар өчен 12, кызлар өчен 28 урта мәктәп эшли икән. Болардан тыш малайлар өчен 148 башлангыч, 44 әзерлек мәктәбе бар икән, шулай ук кыз балалар өчен 18 башлангыч, 60 әзерлек мәктәбе эшли. Моннан тыш шәһәрдә кызлар өчен колледж (педагогия училищесы), Коръәнне яттан өйрәнү мәктәпләре, наданлыкны бетерү мәктәпләре, шәхси балалар бакчалары да эшләп килә икән. Мәгариф ягыннан Мәккә шәһәренең горурлыгы, ул —"Өм-Әль-Кора" университеты. Ул 1981

елда ачылган булган һәм аның Шәригать факультеты хәзер бөтен Согуд Гарәбстанында иң атаклылардан санала. Бу университетта, Шәригать белеменнән тыш, педагогика, гарәп теле, инженерлык, авыл хуҗалыгы һәм социаль фәннәр буенча да махсус факультетлар бар. Пәйгамбәребез "Кытайга барып булса да белем алыгыз" дигән, хәзер гарәпләргә белем алу буенча дөнья читенә дә китәргә кирәкми, киресенчә, бар дөньядан хакыйки белемгә омтылучылар бирегә килә. Бу университетта Татарстаннан да дистәләгән шәкертләрнең белем алуларын әйтеп узарга кирәк.

Бу зур университет каршында тагы берничә институт һәм фәнни-тикшеренү үзәкләре эшләп килә икән. Әйтик, гарәпчә сөйләшә белмәгәннәр өчен гарәп теле институты, инглиз теле институты (дөньясы өчен анысы да кирәк), мөселман өммәтен өйрәнү фәнни-тикшеренү институты, педагогика һәм психология буенча фәнни-тикшеренү институты, Хаҗ мәсьәләләре буенча фәнни-тикшеренү үзәге, ислам белеме буенча халыкара үзәк, ислам югары мәктәбе, инженерлык-политехника үзәге зур эшләр алып баралар. Шушындый ук көчле институтларның, университетларның, үзәкләрнең Мәдинә һәм Согуд Гарәбстанының башкаласы булган Эр-Рият шәһәрләрендә дә барлыгы һәм аларда бөтен дөньяның мөселманнары белем алганнарын әйтеп үтсәк, Пәйгамбәребезнең һәрдаим укырга, белем алырга өндәп сөйләгән сүзләре, васыяте тормышка ашып барганына ышанасын...

Мәккәлеләр сәламәтлеккә зур игътибар бирәләр икән. Әйтик, Мәккә шәһәренең үзендә 5 хастаханә, Хаҗ кылу урыннарында (таулар) тагы 6 хастаханә эшләп килә, болар, башлыча, Хаҗ кылучыларга ярдәм күрсәтә. Моннан тыш Мәккәдә 22, Хаҗ кылу урыннарында тагы 41 шифаханә бар икән. Халык медицинасы, төрле үләннәр белән дәвалану да киң таралган. Кая карама, анда үлән тамырлары, төрле төнәтмәләр, баш әйләндергеч исләр тараткан яфрак-чәчкәләр сатып утыралар. Хаҗга берничә тапкыр килгән кешеләр нәрсә эзләгәннәрен белеп эзлиләр, табалар, тәвәккәлләп алалар да. Безнекеләр күп-күп итеп зәгъфран, канәфер алдылар. Мин исә, Гарәбстанда укып кайткан кешеләр белән киңәшеп, "Рәхмәт" тавында үсә торган кара орлыктан ясалган кара сыекча дару алдым. Пәйгамбәребез бу үлән турында әйткән диләр: "Барлык чирләрдән дә дәва, әҗәлдән генә алып кала алмый", дип. Әмма, Мәккәдә беренче көннәрдән үк авырый башласак та, беркем дә бу даруны үзендә тикшереп карарга батырчылык итмәде.

**30 март**. Әйткәнемчә, төнлә көчле яңгыр явып үтте. Шуннан дәртләнеп, рухланып, без, берничә хатын-кыз, өйлә намазын укырга Һарам мәчетенә килгән идек, әмма эчкә уза алмадык — полиция кире борып торды. Чөнки мәчет эче инде халык белән шыгрым тулган иде. Намазыбызны чатнап торган кояш астында, мәчет каршындагы мәйданда ак мәрмәр өстендә укып кайттык. Анысына да бик куандык. Мәчетнең эченә түгел, янына да якын килерлек түгел. Халык һаман агыла да агыла. Инде мәчеткә алып килә торган зур урамнар гына түгел, кечкенә тыкрыклар да халык белән шыплап тулды. Намаз беткәч тә, шактый вакыт урыннарыбыздан кузгала, хәрәкәт итә алмый тордык — кайтыр якка таба аяк та атларлык түгел иде. Мәчеттән өйлә намазыннан чыгучылар урынына башкалары кереп тула торды, чөнки мәчеткә шушы намаз араларында кереп калмасаң, башкача якын килерлек түгел. Без исә урнашкан йортыбызга кайтырга булдык. Мин эсселектән тагы хәлсезләндем, һәм башкача көндезләрен бик йөрмәскә, Кәгъбәтуллага исә төннәрен генә килергә булдым.

Юл буенча карап кайтабыз — Мәккә кибетләре гөрли. Шәрык базарларына хас бер купшылык белән, бөтен нәрсә ялтырый, җемелди, уйнаклап тора. Монда караңгы-кара төсләрне, укасыз-чуксыз товарны өнәп бетермиләр, ахры, һәрхәлдә, кибет киштәләре, хәтта урамнар да затлыдан-затлы, купшыдан-купшы ялтыравыклы мал белән тулы. Чын ефәк дисеңме, алтын-көмеш дисеңме,

күз явын алырлык табак-савыт дисеңме — жаның ни тели. Безнекеләрнең бик азы гына кибетләр тирәсендә йөри — халыкта акча аз, әле ике атнага якын торасы бар. Аннан, бирелә укыган гыйлем кешеләр әйтеп тә куйдылар — фарыз Хаж гамәлләрен башкарганчы, кибетләр, сату-алу белән бик мавыкмаска, чөнки Хажының кабул булмавы бар. Дөресе дә шул инде, без бит монда меңәр чакрым юллар үтеп, кибетләрдә йөрер өчен килмәдек, безнең төп эшебез — гыйбадәт, намаз, зекер... Коръән уку, бер-беребезгә аңламаганнарны аңлату, вәгазь тыңлау...

Кичләрен җыелып вәгазь тыңлыйбыз. Барыбызны да таң калдырырлык вәгазьләрне Мәдинә шәһәрендә укучы татар шәкертләре сөйләде. Алар тумышлары белән Киров өлкәсеннән, ике ир туган, Хажга әниләре һәм апалары да килгән. Аллага шөкер, милләтебезгә менә дигән белемле, тәкъва дин әһелләре әзерләнеп кайтачак. Аларның динне аңлатулары, инанулары, яшәү рәвешләре бөтенләй икенче төрле — чын, тирән һәм ихлас. Бу яшь татар мөселманнарының турылыгы, дөреслеге башкаларга да бик нык тәэсир итә — алар янында гел кеше, гел сорау, гел аңлашу. Ничек сусаган безнең халык дөрес мәгълүматка, дөрес дингә, дөрес тормышка! Һәм аңа ирешергә дә мөмкин бит! Аның өчен, иң беренче чиратта, дин әһелләренең үзләренең дөрес, тәкъва, ихлас булулары кирәк, динне халыкка дөрес итеп, бозмыйча, үзләренә һәм түрәләргә яраклаштырмыйча аңлатулары кирәк, җитәкчеләрнең, олыларның, зыялыларның Коръән кушканча яши башлаулары кирәк. Ә без, тотабыз да, халык дибез, халыктан көтәбез, халыктан сорыйбыз. Халык кемнәрдән үрнәк алсын да, кайлардан килеп дөрес динне белсен һәм тотсын соң?..

Пәйгамбәребез дә башлаганда бер ялгызы булган бит. Шушы Мәккә шәһәрендә, Мәккә кяферләре арасында, барысы да котырып, тилереп потларга табынганда, ата — улны, ана — кызны белмәгән коточкыч бер бозык заманда — бер ялгызы, шушы кара тауларга чыгып китеп, яшәүнең мәгънәсе, дөньяның хуҗасы, Раббысы турында уйлана башлаган. Мәккә шәһәреннән ерак булмаган Һира тавында, мәгарәдә ураза тотып, уйланып утырганда, ул "Укы, әй, Мөхәммәт!" дигән тавыш ишетә. Бу хәл Милади белән 610 нчы елны була. Коръәннең беренче аяте шушында иңә, Мөхәммәт галәйһиссәламгә Пәйгамбәрлек килә. Аңа иң беренче булып хатыны Хәдичә ышана һәм иман китерә. Өч ел буе алар ислам динен яшерен генә тараталар, бу вакыт эчендә нибары утызлап кына кеше ислам динен кабул итә. Пәйгамбәребез Мәккәдә унөч ел буе тыныч юл белән исламны таратырга тырышып карый, әмма бик нык каршылыкларга очрый. Мәккә кяферләренең бозык гадәтләреннән аерыласылары һич килми, алар мөселманнарга зур явызлыклар күрсәтәләр, Пәйгамбәребезне үтерүләр белән яный башлыйлар. Пәйгамбәребезгә Аллаһы Тәгалә Һиҗрәт кылырга кирәклек турында аять индерә, ягъни, ислам динен саклап калу өчен, Мәккә мөселманнары 622 нче елда Мәдинә шәһәренә күчеп китәргә мәҗбүр булалар.

Пәйгамбәребез Мәдинәдә ун ел яши, анда мөселманлыкны киң җәелдерә, тарата. Шул ук вакытта Мәккәне дә исеннән чыгармый — тыныч юл белән исламга килмәгән, киресенчә, ислам диненә каршы явыз һәм пычрак эшләр алып барган Мәккә кяферләренә каршы берничә сугыш белән бара. Бу сугышлар тарихта Бәдер (624 ел), Ухуд ( 625), Хәндәк (627) сугышлары буларак билгеле. 630 елда исә Пәйгамбәребез мөселман гаскәре белән килеп, Мәккәне ала, Кәгъбәтулладан потларны чыгарып ташлыйлар, ислам дине зур тизлек белән дөньяга тарала башлый. 632 нче елда Пәйгамбәребез үзенең соңгы Хажын кыла, шушы Хаж вакытында Коръәннең дә соңгы аятьләре иңә... Шушы ук елны, 63 яшендә, Пәйгамбәребез Мәдинә шәһәрендә вафат була һәм шунда җирләнә...

Ислам дине — Аллаһының соңгы дине, Коръән — адәмнәргә дөрес юл күрсәтүче соңгы китап, Мөхәммәт галәйһиссәлам —соңгы Пәйгамбәр. Һәм

кыямәт көненә хәтле шулай булачак. Бүгенге көндә жир шарында 1 миллиардтан артык кеше ислам динен тота, бу — дөньяда яшәүче халыкларның чиреге, дүрттән бере дигән сүз. Монда, Мәккәдә исә, бөтен дөнья ислам диненә күчкән, бөтен дөнья кубарылып чыккан кебек тоела. Кемнәр генә юк ул Хажга килүчеләр арасында! Кап-кара негрлар, африкалылар, сары тәнле Океания халыклары, кечкенә генә малайзиялеләр, карага чорналган иранлылар, иракълылар, ерактан ук татарга охшап килгән туганлаш төрекләр, тагы әллә нинди көдрә башлы, елкылдап торган бакыр тәнле (бронза чоры) кавемнәр... Барысы да — мөселман, барысы да "Лә иләһә иллал-лаһу" ди, барысы да, безнең белән янәшә тезләнеп, намаз укый... Болгар бабаларыбызның безгә калдырган иң зур байлыгы, иң кыйммәтле бүләге, ядкяре шушы ислам дине булган икән. Шушына тагы бер кат инану өчен дә, үзенне бөек бер ташкынның — ислам ташкынының бер тамчысы итеп тою өчен дә Мәккәгә килергә, менә шушыларның барысын да үз күзләрең белән күрергә, йөрәгең аша үткәрергә кирәк булган икән...

**31 март**. ... Бүлмәдә адәм чыдамаслык бөркүлек. Кондиционерларны куйсаң, әбиләр чирли, тәрәзәне ачсаң, аннан бөркү һава гына керә, әбиләр исә ул жилдән дә куркалар, бөтен жир томаланган, ябылган. Без бер бүлмәдә ун хатын, 75 яшьтән 30 яшькә кадәр. Һәммәбездә аерым бер холык. Шулай пешеп, ярга ташланган балыклар кебек, идәндә ауныйбыз. Төнге сәгать бердә тордым да, болай идәндә газапланганчы, мәчеткә барып төн кунарга, дигән нияткә килдем. Миңа 75 яшьлек ике татар карчыгы да иярде. Ниятебез — төнге салкыннан файдаланып, тагы бер тапкыр Кәгъбәтулланы әйләнү, ике тау арасын үтү, гыйбадәт кылу, зәмзәм суын чыккан жирендә эчү. Әбиләр белән тәвәккәлләп халык дулкынына кушылдык. Инде әкренләп мин дә терелә, тернәкләнә башладым, әбиләрне дә үзем житәкләп, барлап йөрттем. Тәкбир һәм тәлбияләр әйтеп, дога һәм изге теләкләр белән, елый-елый жиде тапкыр Кәгъбәтулланы әйләндек. Таптамадылар, исән-имин килеш миллионлаган кеше арасыннан кыласы гамәлләребезне кылып читкә чыктык. Аннан жиде тапкыр Сафа һәм Мәрва таулары арасын урадык, теләкләр теләдек. Аннан зәмзәм суы эчеп, намаз укыдык. Иртәнге намазны Һарам мәчетенең түбәсендә укырбыз, дигән ниятебез бар иде, әбиләр белән түбәгә чыгу юлын эзләп киттек. Бормалы баскычлардан күтәрелә торгач, түбәгә дә менеп житкәнбез. Безнең бәхетебезгә, түбәдә әле кеше аз, хәтта намаз укырга да урын бар иде. Хәтта, дим, чөнки Һарам мәчетендә намаз укырга өч адым урын табу — иң зур мәсьәләләрнең берсе.

Без мәчетнең өченче катында — түбәсендә... Сәгать төнге өчләр тирәсе. Әллә кайдан гына салкынча жил исә башлады, әбиләр дә, үзем дә юка гына киенгән идек, дерелди үк башладык. Әмма моннан күчсәк, аска — жылыга төшсәк, без намаз укырга бөтенләй урын тапмаячакбыз. Мәчеттән чыгу турында уйларга да ярамый, ул чагында инде яңадан бөтенләй керә алмаячакбыз. Иң яхшысы — мәчеткә төннән кереп калу һәм иртә намазын Кәгъбәтулланың каршында, кара ташка юнәлеп уку. Бу әйтеп бетергесез зур савап, әйтеп бетергесез бәхет, мәртәбә. Без хәзер түбәсендә утырган бу мәчет — дөньядагы мәчетләрнең иң өстене, Баш мәчет, дип атала. Аннан кала дөньяда икенче шундый мәртәбәле мәчет — Пәйгамбәребезнең Мәдинә шәһәрендәге мәчете. Бу хакта Пәйгамбәребез үзенең бер хәдисендә болай ди: "Минем мәчетемдә укылган намаз башка мәчетләрдә (Баш мәчеттән кала) укылган 1000 намаздан хәерлерәк." Ә икенче бер хәдистә болай ди: "Мәккәдәге Баш мәчеттә укылган намаз минем мәчетемдә укылган намаздан 100 тапкыр хәерлерәк." Димәк, Һарам мәчетендә укылган һәр намаз, башкалардан 100 мең тапкыр хәерлерәк һәм саваплырак икән! Без, хаж кылучылар, моңа чын күңелдән ышанабыз, шул ышаныч безгә көч бирә, уттай кояштан да, боздай жилләрдән дә саклый, түзем, сабыр итә...

Шулай итеп, тыштан өшеп, эчтән дәртләнеп, иртәнге намазны көтәбез. Мәчет түбәсе — күзәтү өчен иң яхшы урын. Аста — миллионлаган кеше Кәгъбәтулла тирәсендә әйләнә. Кешеләр түгел, әйтерсең лә, дөнья үзе әйләнеп тора. Югарыдан караганда, бернинди тавыш, өн ишетелми. Нииндидер телсез дәһшәт, шомлы котылгысызлык кына сизелә. Әйтерсең лә, мәхшәр мәйданының бу дөньядагы кабатланышы. Телсез, өнсез булып, Аллаһының җәзасын көтү... Хаҗ сәфәрен Аллаһы Тәгалә безгә нәкъ менә ахирәт көнен искә төшерү, кисәтү өчен фарыз кылган кебек. Аллаһыдан фарыз булганы өчен, кеше бу дөньяда ук, мең газаплар күреп, таптала-изелә Кәгъбәтулла каршына — Мәхшәр мәйданына омтыла. Син кем генә булсаң да — даһимы син, бер мескенме, баймы син, бер фәкыйрьме, галимме, бер наданмы — Аллаһы каршында бу имтиханны үзең тотасың, тәвафны үзең кыласың, Кәгъбәтулланы үзең әйләнәсең, миллионнар арасында тузан бөртеге булып каласың. Мәхшәр мәйданында да шулай — бергә-бер калып, Аллаһы каршында кылган гамәлләребез өчен җавап тотачакбыз. И Раббым, бу дөньяда изге гамәлләрне күбрәк кылып, шулар исәбенә җәннәт бәхетләрен насыйп итсәң иде...

Урыныбыз, Аллаһының рәхмәте белән, үзебез дә сизмәстән, бик хикмәтле, иң хикмәтле урынга — Кәгъбәтулланың җәннәттән иңгән кара таш урнашкан почмагына туры килгән. Кичә кичтән Актаныштан Мөнәвир абзый нәкъ шушы урында намаз укуы турында бик кызыктырырлык, көнләшерлек итеп сөйләгән иде. Шул вакытта: "Ah, безгә дә шул бәхет туры килсә иде!" дип теләгән идем. Монда ихлас теләгән һәр теләк тормышка аша, диләр шул. Иртәнге сәгать дүрттә азан яңгырады, бу аста Кәгъбәтулланы тәваф кылучылар өчен туктый башларга кисәтү икән. Өстән карап торганда бу тукталыш бик кызыклы, хикмәтле күренә. Миллионлаган кеше, борып җибәргән сәгать шөрепләре кебек беренче азаннан соң акрынлап тукталуга җайлаша башлый. Башта иң кырый рәттәгеләр туктый — зекергә утыра, аннан — урталар, аннан Кәгъбәтуллага иң якын өлеш әкрен генә тукталып бетә. Бу хәл бер сәгатькә якын бара. Шулай итеп, халык божрасы, дөнья божрасы әкренләп, күз алдында сүтелә, т у к т а л у ы н а хәрәкәт итә башлый. Берзаман өстән карыйсың — уртада сыек кына берничә рәт калган, алар әле һаман гадәт, инерция буенча әйләнәләр, әмма бөтен тирә-як инде зекергә оеган, барысы да күктән бер аваз — Азан тавышын көтәләр. Менә, күкне ярып, бер аваз — Азан тавышы яңгырый. Хәрәкәт тәмам туктала, бәндәләр баскан урыннарында катып калалар. Унга да бара алмыйлар, сулга да бара алмыйлар... **"Бүген без аларның авызына мөһер суктык, шуның өчен алар куллары белән сөйләрләр һәм аяклары белән эшләгән эшләренә шаһитлык кылырлар. Әгәр теләсәк, аларның күзләрен томалап сукырайтыр идек, гадәтләре буенча ашыгып юлга чыгарлар, ләкин алар ничек күрсен? Әгәр теләсәк, без аларны торган урыннарында тораташ итеп катырыр идек, алар алга да, артка да китә алмаслар иде".** *("Ясин" сүрәсе, 65-67 аятьләр.)*

**1 апрель.** Бу көндәлегемә мин күбрәк көннәр турында түгел, төннәр турында язам. Чөнки көн артык эссе булганга, без күбрәк төннәрен генә Һарам мәчетенә барабыз. Әйткәнемчә, бу изге мәчет без яшәгән урамда, без анда җәяү генә йөрибез. Көндезләрен җыелып, намазларыбызны йорт ишек алдында укыйбыз. Бу да бик тәэсирле, үзәк өзгеч күренеш. Татар хаҗилары — ап-ак әбиләр, кырыс бабайлар, дингә әле яңа аяк баскан яшьрәк як — Мәккә шәһәрендә, Кәгъбәтулладан ерак түгел урында, саф-саф булып тезелеп, намаз укыйбыз! Иң яшебезгә —13 яшь, ул — Чаллыдан Флера исемле кыз бала. Алар бөтен гаиләләре белән Хаҗга килгәннәр — әнисе, апасы, әбисе, бабасы... Иң картыбыз — Чистайдан Габдулла бабай, аңа 91 яшь. Казаннан Рөстәм Шәфигуллин исемле егетебезгә — 14 яшь, ул — Казаннан, Коръән уку ярышында җиңеп чыккан өчен Хаҗга бару белән бүләкләнгән. Менә янәшәмдә генә Алабугадан Галимә ханым Харисова. Ул гомер буе табибә

булып эшләгән, кешеләрне дәвалаган. Соңгы елларда Галимә ханым дин буенча зур эшләр башкара — ул Алабугада кыз балаларга дин сабаклары бирә, Коръән уку буенча дәреслекләр язган кеше. Халкыбыз арасында кемнәр генә юк! Карап торырга гади генә кеше кебек, ә сөйләшә башласаң, күңелләреңдә әллә нинди энже-җәүһәрләр ялтырый, йөзләреннән нур агыла, бөтен торышларыннан аклык, пакьлек бөркелеп тора. Ислам дине кешене, бигрәк тә хатын-кызны шулай нурландыра, сабырландыра, сафландыра шул. Ирләр артына тезелешеп намаз укыган татар хатын-кызларына карап, менә тагы бер кат инанасың... Бу намазда — милләтебезнең үткәне һәм киләчәге. Мәккә урамында намазга тезләнгән татарларның йөзләре аеруча тыныч, моңлы, киемнәре ак, үзләре пакь, барысына да түзәләр, сабыр итәләр... Уттай кояшына да, йокысыз төннәргә дә... Бу төркем, мөгаен, халыкның үзеннән тупланган иң ихлас, иң гадел һәм соңгы Хаж төркемедер... Нигәдер, миңа шулай тоела. Бу 60-70 яшьлек карт-карчыкларны алга таба болай оештырып, кулларыннан җитәкләп йөртмәсләр инде. Заманалар үзгәрә, кырыслана, изге Хаж гамәлендә дә күп мәсьәләне акча һәм шәхси әшнәлек хәл итә башлады. Күбрәк татарларны бирегә китерәсе иде дә бит. Акчасы бары, беренче чиратта, мал җыя; акчасызы, Хажга түгел, авылына да кайта алмый. Әмма барысы да Аллаһ кулында, ничек биргән, шулай алырга да мөмкин — байлыгын да, сәламәтлеген дә, хәтта гомерне дә... Шуңа күрә көч-куәтең барында күбрәк изге гамәлләр кылып калырга кирәк...

Бу көннәрдә (төннәрдә) беренче тапкыр күктә яңа туган ай күрдем. Ул шул хәтле матур, үзе кечкенә, сызылыплар гына киткән көмеш алка кебек җыйнак... Ә Мәккәдә күк йөзе кара түгел икән бит. Күп кешеләр "күк монда кап-кара", диләр. Юк, күк монда зәңгәрсу-кара, ә шул каралык артыннан ниндидер яктылык, нур сирпеп тора кебек. Мәккә өстеннән кара төн пәрдәсен күтәрүгә, яп-якты нурлы күк йөзе ачылыр кебек. Күкне исә кара таулар терәп тора... Пәйгамбәребез заманыннан калган таулар... Алар шәһәр читендә генә түгел, шәһәр эчендә дә урыны-урыны белән калкып, тырпаеп торалар. Кыеп-кыеп алынган кара мәрмәр таулар... Кайсы гына якка борылсаң да, каршыңа киләләр дә басалар, киләләр дә басалар... Алар белән узыша-узыша Мәккә урамнарында егермешәр, утызар катлы йортлар үсә. Ә азан тавышы барысын да тигезли, нәрсә өчен яшәгәнне һәм яшәргә кирәклеген искә төшерә, шушы илаһи аваз каршында барысы да вак, кечкенә, әһәмиятсез булып кала...

Кәгъбәтулла ягыннан тагы азан тавышы яңгырый. Монысы инде — төнге намазга. Төн җитте исә, без тагы юлда, без тагы мәчеттә, без тагы Кәгъбәтулла янында. Бирелә үткәргән гомеребезнең бер генә минутын да бушка сарыф итәсебез килми. Намаз, зекер, дога, теләк. Көннәребез һәм төннәребез бары тик шушы юлда гына үтәргә тиеш.

Бу юлы Кәгъбәтулла каршына Рәшидә абыстайлар белән килдек, тәваф кыла башладык. Алланың рәхмәте, халык төркеме безне гел эчкә, Кәгъбәтуллага таба кысрыклый. Анда исә халык тагы да күбрәк, тагы да тыгыз, борылу түгел, кыймылдап та булмый, аста аягың гына тыпырдый, гәүдәне төркем үзе этеп алып бара кебек. Инде хәзер чыгам дисәң дә кырыйга чыгып булмый, халык дулкыны сине бөтереп-бөтереп бер урынга — кара ташка таба этәрә, үзе дә шунда омтыла. Миллионлаган кешенең өмете — җәннәт ташына орыну, аннан көч, күзгә күренмәгән энергия алу, алар шушының өчен меңәр чакрым юл үтеп, бирегә килгәннәр, төн йокыларын йокламыйча, Аллаһының форсатын көтәләр. Инде җәннәт ташына ук тотына алмыйлар икән, иңе-буе 15 метр булган, җәннәт ташы урнаштырылган ташка булса да орынып карыйсылары килә кешеләрнең. Дөресен әйтим, минем Кәгъбәтуллага орынып карау өметем зур түгел иде, менә, әле авырудан яңа савыгып килгән бер хатын-кызга, Аллаһы йортына ерактан гына карап, ерактан гына көч-кодрәт алу да җитә

иде. Аллаһының могҗизасы һәм рәхмәте чиксез киң бит — халык дулкыны мине әйләндерде, әйләндерде дә, кара ташка ук китереп бәрде. Күземне ачсам — каршымда бер метрлар тирәсе бушлык һәм... аннан соң Кәгъбәтулла үзе. Калганын төштәге, кинодагы, томан арасында кебек кенә хәтерлим. Әбиләргә, әйдәгез, дип кенә әйтеп өлгердем, аларны халык ташкыны инде бөтереп читкә алып ташлады һәм күздән югалтты. Мин Кәгъбәтулла каршында бер үзем калдым. Юк, анда кемнәрдер ташка капланып елый, кемнәрдер үбә, кемнәрдер тезләнеп намаз укырга тырыша... Алар мина, мин аларга комачауламыйм. Иң мөһиме — мин берүзем һәм җәннәт ташы каршында. Ташка кадәр өч адым бар. Мин аны әллә очып, әллә йөзеп үтәм — хәтерләмим. Җәннәт ташының кытыршы, салкын өстенә кулларымны куеп, Аллаһыдан иң кирәкле, иң газиз нәрсә — ихлас һәм ныклы иман сорадым, саулык-сәламәтлек сорадым, ярдәм-шәфәгатеннән ташламавын сорадым. Шул ук теләкләремне атам-анама, балаларыма, гаиләмә, туганнарыма да теләдем. Кәгъбәтуллага килеп орынуга, дөнья кинәт туктап, тынып калган кебек булды. Әйтерсең лә тирә-ягымда шушы мизгелгә килеп җитәр өчен ыргылган миллионлаган кеше дә юк, җәннәт ташына ябышып яткан башка хаҗилар да юк. Мин, инде башкалар да керсен, Аллаһының бу зур бәхетен башкалар да татысын дип, читкәрәк чыкмакчы идем, тыгыз божра мине тагы эчкә этеп кертте, тагы кара таш каршына китереп бастырды. Мин инде тынычлап, иркенләп, Аллаһыдан көч һәм гайрәт сорадым, файдалы гыйлемнәр алып аны милләттәшләрем белән дә уртаклашу бәхетен сорадым, халкыма иман, бәхет, бәрәкәт сорадым. Икенче бер мизгелдә инде халык ташкыны мине бөтереп алып, читкә — меннәр, миллионнар арасына алып аткан иде... Мәккә өстендә төн белән көн арасы иде, офыкларда таң сызыла башлаган серле бер мизгел иде...

**2 апрель.** Корбан бәйрәме көннәре җиткән саен, Мәккә урамнары кеше белән тула бара. Инде Мәккә шәһәре ябылган, башка беркемне дә кертмиләр икән, диләр. Быел Хаҗ кылучыларның саны 7 миллионга җитеп килә икән, дип сөйлиләр. Хәллерәкләр яхшы кунакханәләрдә ята, безнең кебек урта хәлләр — уртача шартларда яшибез, урамда, йорт араларында, мәчет ишеге төпләрендә дә кунучылар бар. Урамнарда йөрү көннән-көн тыгызлана, кыенлаша. Без дөньяда нәрсә барганын белмибез, бүлмәләребездә радио да, телевизор да юк, газеталарны укый белүче аз. Хәер, фани дөнья мәшакатьләре, сәясәт үзе үк китереп чыгарган ясалма ыгы-зыгылар безне биредә аз кызыксындыра. Без шулай бер халәттә яшибез ки, әйтерсең лә дөнья безне белми, без дөньяны белмибез. Вакытлыча булса да, барысы белән дә ара өзелгән. Без моның вакытлыча гына буласын беләбез, дөньялыкта дөньяныкын эшләп, көн итәргә, тормыш алып барырга кирәген дә беләбез. Әмма без, Мәккәдә, Хаҗда булса да, беразга булса да, башка тормыш белән яшибез, онытылып, онытыласыбыз килеп яшибез. Алай да кемнәрдер өйләренә шылтырата, Казанда буран икән, диләр, Чаллыда салкын икән, диләр... Монда — кырык градуслы эсселек, урамнар һәм кеше җыелган урыннар мәхшәрне хәтерләтә. Вакыты-вакыты белән атлап та, йөреп тә, тын алып та булмый. Бүлмәләрдә дә шушындый ук эсселек. Әмма, ни хикмәт, аңа карап, күңелебез төшми, кәефебез кырылмый, кем намазда, кем зекердә, кем мәчеттә, кем Коръән укый — рухыбыз сафлана, шушы хәтле зур бәхет каршында — Хаҗ бәхете каршында — барысы да вак нәрсәләр булып кала...

Илнең хөкүмәте хаҗиларга уңайлы булсын өчен барысын да эшли. Зәмзәм суын бушка күп-күп итеп бүлмәбезгә китереп торалар. Бушка, сәдакә итеп, төрле ризык, бүләк-мазар өләшәләр. Һавада, тәртип саклап, бер туктаусыз хәрби вертолетлар очып тора. Транспорт, такси кайда барасың килсә — шунда алып бара, әмма урамнарда халык күп булганга, барасы җиреңә җәяү тизрәк барып җитәсең. Гарәпләр үзләре бик эшләмиләр ахыры, кибет-ашханә тирәләрендә, авыррак эшләрдә күбесенчә төрекләр. Гарәпләр белән төрекләр

үзара бер-берләрен бик үк яратып бетермиләр. Бу низаг госманлы империясе вакытларыннан ук — төрекләрнең гарәпләрне басып алган чорларыннан ук килә. Гарәпләр төрекләрне моның өчен генә түгел, Ататөрек заманында диннән киткәннәре, динне бозганнары өчен дә гафу итә алмыйлар. Согуд Гарәбстаны үзе — ислам дәүләте, анда Конституция булып Коръән тора, барлык эшләр дә шәригать кануннары нигезендә алып барыла. Ә Төркиядә исә, бу гасырның егерменче елларыннан алып, дин дәүләттән аерылган. Гарәпләр — чиста, саф ислам ягында, Коръән кушканча яшәү ягында. Төрекләр исә ислам динен миллиләштереп, үз якларына борып, мистика, мәҗүсилек дәрәҗәсенә төшеп баралар. Әмма, ни генә булса да, бирегә Хажга килүчеләрнең ин зур күпчелеге — төрекләр. Ә менә Ираннан килүчеләрнең соңгы вакытта бөтенләй кимүен дә әйттеләр. Иранлылар хәтта шундый ширеккә барып житкәннәр ки, үзләрендә үк "Хаж кылу"ны оештыра башлаганнар, ягъни, мәчетләре, үзләре "изге" дип йөрткән урыннар тирәсендә тәваф кыла башлаганнар. Ә бу — бик зур гөнаһ, Коръән белән тыелган гөнаһ. Шул вакытта үзебезнең Болгарда мәктәп балаларының Кече Манараны тәваф кылып, ягъни, жиде тапкыр әйләнеп йөрүләре исемә төште. Мин аларны күпме генә туктатырга тырышып карасам да, мин китүгә, алар тагы шул эшләрен дәвам иттеләр. Кемдер шулай дип әйткән, имеш. Балалар бу гамәлне чын күңелдән, бирелеп, ислам дине шулай куша, дип алданып эшлиләр. Болгарга "изге сәфәрләр" оештыручылар, гаять дәрәҗәдә надан булулары сәбәпле, бу эшләрне белмиләр, тыймыйлар, туктатмыйлар...

**3 апрель.** Кичә төннән Һарам мәчетенә кереп кунган идек. Бүген жомга көн. Аллага шөкер, жомга көнне Кәгъбәтулла янында иртәнге намазны укып каршы алдык. Бу юлы мәчеткә Камил хәзрәт һәм аның якыннары белән килдек. Камил хәзрәтнең әнисе Камилә абыстай — Буа районыннан килгән. Бу апа гажәеп сабыр, тырыш, түзем булып чыкты. Килгәч тә эссе кагып авырды, аннан салкын тиде. Әмма шуңа да карамастан, 70 яшьлек бу авыл карчыгы уттай кояш астында, улына тотынып, Һира тавына менәргә, Пәйгамбәребезгә Коръәннең беренче аяте иңгән урыннарда булырга да үзендә көч тапты. Аның инде Хажга икенче тапкыр килүе икән, теге килүендә Һира тавына мена алмаган, бу юлы шуны ният итеп юлга чыккан. Без Камилә апа белән хәзер бүлмәдә дә янәшә ятабыз, чөнки мин, эссегә түзә алмый, беренче каттан икенчегә күчтем. Бу бүлмәдәге әбиләр кондиционер жибәргәнгә бик үк каршы килмиләр, монда көнен дә, төнен дә жиләс...

Иртәнге намазны мәчеттә укыдык та, кайтырга чыктык. Мәчет урамыннан йөрешле түгел — бер як иртәнге намаздан кайта, икенче як жомга намазына кереп калырга ашыга. Инде мәчетнең эченә керерлек түгел, яна килгән халык мәйданга урнаша.

Жомга намазын, жыелышып, йортның ишегалдында укыдык. Башка вакытта намаз укырга урын таба алмый интегә идек, бу юлы хәтта азан әйтеп, намаз укыганда да ир-атларыбыз калмаганлыгы билгеле булды — бөтенесе жомга намазына мәчеткә киткән. Без ишегалдында хатын-кызлар гына жыелып калганбыз, ә хатын-кызның азан әйтергә дә, имамлык кылырга да хакы юк. Хезмәтче гарәптән азан әйттереп, жомга намазы урнына гадәти өйлә намазы итеп, беркемгә дә оемыйча, һәрберебез аерым-аерым намаз укыды. Алай да, безнең янга бер абзый чыгып баскан икән. Ул — гажәеп ямьшшлы абзый. Гомер буе шахтада эшләгән һәм соңгы вакытта бик нык чирләп киткән. Аның үпкәсе дә юк, ашказаны да юк, йөрәге урынында да тимер клапан, кергәне дә, чыкканы да резин шланга аша. Ә шул кеше йөри, Хажга килгән! Инде икенче тапкыр килүе икән. Кем белә, бәлки соңгы тапкыр бу изге жирләрне күрәсе, бәхилләшәсе килгәндер, бәлки әле терелергә дә өмете бардыр, врачлар үлә, дигәч тә, шушы килеш сигез ел яшәгән бит инде. Бәлки шушы мөкатдәс жирләрдә мәңгегә ятып калырга да уйлагандыр, чөнки

Хажда вафат булган кешенең урыны җәннәттә була, диләр... Шушындый кешеләр дә, үргәмәләп диярлек Хаҗга чыккач, бүгенге ике аягында йөргән адәмнәргә иртәге көн турында уйлап, гыйбрәт алырга кирәк тә бит... Гыйбрәт алыр өчен дә күңел күзе кирәк шул...

Вакыт бардан файдаланып, урамнарда, халык арасында күргән күзәтүләремне гомумиләштерергә, бер нәтиҗә ясарга уйлыйм, дөресрәге, уйланам... Җир йөзендә I миллиардтан артык мөселман бар, дидек. Алар Азиядә дә, Африкада да, Европа илләрендә, дөньяның барлык кыйтгаларында. Әмма, күреп торабыз, бер мөселман иле икенчесен яратмый, хәтта Иран, Ирак, Кувейт кебек, үзара сугышып яталар. Төркия иң беренчеләрдән булып, мөселманнарның дошманы булган Израиль дәүләтен таныды, бөтен эшләрен аның белән киңәшеп алып бара. Ә Израиль үз җирләреннән мөселманнар яшәгән Сирия, Ливанны утка тотып ята, Фәлистин мөселманнарын чебен урынына кыра. Һәркем ислам динен үз ягына тарта, үзе өчен файдаланмакчы була. Мөселман булып йөргән фарсы иранлар бүген утка табына, төрекләр каберләргә табыналар, татарлар "изге чишмәләр" эзләп таба башладылар. Ә болар бит барысы да Коръәндә тыелган нәрсәләр! Заман ахырында исламда җитмеш фирка булыр, алардан бары берсе генә дөрес юлда булыр, диелгән. Халыкның дин мәсьәләсендә наданлыгы, Коръәнне белмәве, әби-баба гореф-гадәтләрен, төрле ырым-шырымнарны дин белән бутаулары төрле адашуларга, ялгыш юлдан китүгә, фетнәләргә китерергә мөмкин. Андый вакытта дөрес юлны табу өчен Коръән бар, Пәйгамбәребезнең Сөннәте бар,бары тик шулар буенча гына яшәргә омтылырга кирәк. Аллаһы Тәгалә бу хакта безгә менә нәрсә дип әйтә: **"Коръән белән күрсәткән бу юлым тәхкыйк сезнең өчен туры юлымдыр, шул туры юлга керегез! Вә мин күрсәткән юлдан башка юлга кермәгез, әгәр башка юлларга керсәгез, ул юллар сезне Аллаһ юлыннан аерыр. Аллаһ сезгә Коръән юлыннан барырга әмер кылды һәм башка юлдан китүдән тыйды, шаять Коръән юлыннан башка юлга китеп һәлак булудан сакланырсыз"** *("Әнгам" сурәсе, 153 аять.)*

Без үзебез шаһит булдык — Хаҗ кылу мөселманнарны берләштерә, сафландыра, уйландыра һәм үкендерә, мона кадәр, мин мөселман, дип, әмма туры юлдан читтәрәк йөргәннәрне дә туры юлга чыгара. Бер килгән кеше монда тагы килергә, кылып бетерә алмаган гамәлләрен кылырга, җанын чистарындырырга дип тагы Хаҗ кылырга ният итеп китә. Мин берничә тапкыр Хаҗ кылырга килгән кешеләрдән җентекләп шул хакта сораштым: "Хаҗ сәфәре бик авыр сәфәр, эсселек, кеше күп, иданнәрдә ауныйсыз (ауныйбыз), күбегез чирли, ничек шушыларны белгәннән соң да яңадан монда килә аласыз?" — дип әйттем. Миңа: "Авырлыклар барысы да кайтуга онытыла, күңелдә бары тик иң изге, иң кадерле, иң якты хисләр генә кала. Алар еллар буе истән чыкмый, бу җирләр, бу таулар, бу мәчетләр, Аллаһының йорты булган Кәгъбәтулла гел үзенә тартып, чакырып тора", — дип җавап бирделәр. Бу — ихлас җавап иде. Хәтта рәсми делегацияләр составында Хаҗга ясалма гына, кешегә ияреп кенә килеп китүчеләр дә гомерләренең ахырына кадәр бу җиргә яңадан бер әйләнеп кайтырга, тәүбәгә килеп, ихлас күңелдән Аллага ялварырга, Аллага сыенырга мәҗбүр булалар. Килеп тә, кылмыйча киткән Хаҗлары аларның гомер буе артларыннан йөриячәк, бугазларына басып, тәкәббер башларын аска идерәчәк, үкендерәчәк. Шуңа күрә Хаҗ гамәленә җиңел карарга ярамый, аның белән шаярырга, аңа бер туристик сәяхәт итеп кенә карарга ярамый! Ярамый! Ул чагында савап урынына күтәрә алмаслык гөнаһ җыеп китәргә мөмкинсең...

**4 апрель**. Бүген төшемдә очтым... Беренче тапкыр түшәм урынына болытларга сыенып очтым. Хәзергә болытлардан югары күтәрелә алмадым. Әмма инде бу очу өй түшәме биеклегендә генә түгел иде. Хикмәтен бер Аллаһ белүче...

Бераз авырып торам, бер жиргә дә бара алмадым. Идәндә язып утырам. Иртәгә бик җаваплы көн — фарыз Хаҗыбыз, олы Хаҗыбыз башлана. Менә кадәр күргәннәр-кичергәннәр олы эшкә әзерлек кенә булган... Иртәгә-зөлхиҗҗә аеның сигезенче көне — без, Мәккәне калдырып, биш көнгә тауларга китәргә тиеш булабыз. Без шушы көннәрдә Мина тавында, Гарәфәттә, Мөздәлифә тауларында булырга, янадан Минага кайтып, өч көн рәттән шайтанга таш атарга, аннан Мәккәгә кайтып Кәгъбәтулланы тәваф кылырга, Сафа һәм Мәрва тауларын йөгереп үтәргә тиеш булабыз... Корбан бәйрәме көнне корбан чалдырырга тиеш булабыз. Бу көннәрнең ни дәрәҗәдә авырлыгы, ни дәрәҗәдә җаваплылыгы турында безгә кат-кат кисәтәләр. Әзерләнәбез. Үзебез күтәрә алырлык кына әйберләр алабыз. Без тауларда җир өстенә җәймә җәеп, түбәсе чүпрәк белән генә капланган ачык чатырларда яшәргә, төн кунарга тиеш булабыз икән. Төннәр шактый суык була ди. Апалар мамык шәлләрен, пальто-бишмәтләрен үзләре белән алалар. Мин аска-өскә берәр җәймә алдым да, тәвәккәлләдем, ашарга да санап кына алдым, авыр күтәрә алмасымны беләм. Мин 14 көн ач торган кеше, 5 көнне ипи белән суда да чыгармын, иншаллаһ. Намазлык, икмәк, су, җәймә... Артык бернәрсә дә кирәкми. Күңелдә, гомумән, әйбер, дөнья кайгысы түгел, күңел тыпырчына, алгысый, тауларга дәшә, Пәйгамбәребез эзләре буенча йөрергә чакыра...

Төнлә беркем дә йокламады, барыбыз да чиратлап госел коендык, ирләр ак ихрамнарын, хатын-кызлар ак өс-башларын киделәр. Барыбыз да, сабыр гына, иртәнге намазны көтәбез...

*Ахыры киләсе санда*

---

## 1999 елның беренче яртысында "Казан утлары" журналы битләрендә дөнья күрәчәк чәчмә әсәрләр:

**З. Зәйнуллин.** Агыйделнең аръягында. *Роман.*
**Г. Ахунов**. Тимерхан атылган комиссарларны эзли. *Документаль повесть.*
**Р. Фәизов**. Тәңре хөкеме. *Фантастик повесть.*
**Ә. Галиев.** Чигенгәндә ура кычкырмыйлар. *Повесть.*
**Ә. Моталлапов**. Нигез. *Повесть.*

Редакция папкасында шулай ук **Р. Мингалим, Ф. Латыйфи, Р. Рахман, Ә. Гадел, Ф. Дунай** һәм башка язучыларның күләмле проза әсәрләре бар.

# "ӘЙДӘ, ХАЛЫККА ХЕЗМӘТКӘ!.."



*Татар халкының борынгы мәдәни мирасын барлаучы, тикшерүче, яңадан халыклар үзенә кайтаручы, сәнгать традицияләрен дәвам итүчеләр арасында Нәҗип Нәкъкаш дип исеме чыккан бер затлы зат бар. Әйе, Нәҗип әфәнде милләт өчен кирәкле һәм файдалы олы эшләр башкара: беренчедән, ул әдәбият галиме, текстолог буларак, архивлардан, сирәк кульъязмалар арасыннан энҗе-мәрҗәннәр табып, әдәби мирасыбызны барлый, текстологик яктан эшкәртә, ягъни без яшәгән буын җәмәгатьчелеге аңлый, укый алсын өчен, аларны хәзерге гамәли алфавитка күчерә, аңлатмалар яза, китап итеп чыгарырга әзерли. Ул күп белем, көч, тырышлык сорый торган мәшәкатьле, әмма игелекле эш башкара. Икенчедән, аның бөтен күңелен биреп, яратып эшли торган тагын бер шөгыле бар: ул, сәләтле рәссам буларак, соңгы 80 ел эчендә онытылуга дучар ителгән борынгы сәнгатебезнең бер төрен — гарәби каллиграфия сәнгатен тергезеп, яңартып җибәрүче. Нәҗип Нәкъкаш иҗат иткән гүзәл гарәби язулар, шәмаилләр менә 8-9 ел инде Җөмһүриятебездә чыгып килүче газета-журнал һәм альбом битләрен, музейларны, мәчетләрне, аерым кешеләрнең өй эчләрен бизи.*

*Ниятебез — укучыларны шушы сирәк һөнәр иясе, талантлы шәхес белән якыннанрак, тулырак таныштыру. Шәхеснең үзен һәм эшен аның үзеннән дә яхшы белүче юк, шуңа күрә без күбрәк Нәҗип әфәндедән үзен сөйләтергә булдык.*

*— Нәҗип әфәнде! Әңгәмәбезне традицион сораудан башлыйсыбыз килә: кем сез, кайдан сез, әдәбият фәненә ничек килдегез дә, сәнгатькә ничек кереп киттегез?*

— Мин үзем тумышым белән Мамадыш төбәгеннән, Чулманга коя торган ямьле Бүрсет елгасы буена урнашкан үрле-үзәнле, елга-чокырлы, бик күп чишмәләре булган борынгы Өчөйле (рәсми исеме Усали) авылыннан. Әтием Фәйзерахман һәм әнием Бибигайшә исемле колхозчылар гаиләсендә беренче бала булып 1948 елның август аенда дөньяга килгәнмен. Атам ягыннан булган бабаларым, Сөләймановлар нәселе игенче һәм һөнәрчеләр, балта осталары булганнар. Балта остасы булу өчен рәссамнардагы кебек "кул" белән "күз" арасында тыгыз бәйләнеш булу кирәк, шуңа күрә мин үземдәге рәсем ясау сәләтен нәселебездән киләдер дип уйлыйм. Әтием клуб яисә ферма мөдире булып эшләгәндә белдерүләр, плакатларны үзе яза иде. Элекке заманда фанердан эшләнгән чемоданнар бар иде бит. Бервакыт шундый чемодан белән яңа гына армиядән кайткан Мөбарәкҗан абый (әтинең энесе), капкачын ачып җибәрде дә, шуның өслегенә акварель белән үзенең портретын ясап куйды. Әгәр уку, тәрбия эләккән булса, алардан рәссамнар чыккан булыр иде, бәлки. Мин үзем дә рәссам булу өчен махсус белем алмадым. Кечкенәдән үк рәсем ясарга, матур язуны яраттым. Бишенче сыйныфтан башлап укуны тәмамлаганчы класс дивар газетасының бизәүче рәссамы булдым, мәктәп һәм авыл китапханәләрен бизәүдә катнаша идем. Урта мәктәпне тәмамлагач, "күп балалы атам-анам гаиләсенә булышыйм" дип, 7 ел үзем укып чыккан мәктәбемдә эшләргә туры килде. Сынлы сәнгать дәресләрен укыттым, түгәрәкләр алып бардым, шуның өчен сәнгатькә багышланган китаплар җыйдым, сынлы сәнгатькә кагылышлы

барлык журналларны алдыра идем. Шулар аша үзлегемнән өйрәнергә тырыштым. Шулай итеп, рәсем ясаудан мин һичкайчан өзелеп тормадым.

Үзем белән бергә эшли торган, электәге әдәбият һәм татар теле укытучым Мәрьям апа: "Нәҗип, бу сәләтләрең белән монда йомылып калма, сиңа укырга кирәк, укырга бар!" — дип кыстый торгач, ниһаять, 1974 елда 26 яшемдә университетның татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга барып кердем. Беренче курстан ук гарәп теле өйрәнә башладым. Кечкенәдән үк шул серле хәрефләрнең мәгънәләрен белергә омтыла идем. Университетта "Әдәби сүз" дивар газетасын бизәүдә күп көчемне куйдым. Профессор Хатыйп ага Госман сәләтле студентларга бик зур игътибар бирә торган шәхес иде. Дүртенче курста укыганда ул мине берничә егет белән бергә Бакый ага Урманчега каллиграфия өйрәнергә йөртте. Атаклы остадан 3 — 4 дәрес алып кала алдым, ул безне каләм тотарга, матур язуның кайбер серләренә өйрәтте.




*Татарстан Республикасы Югары Советы рәисе Фәрит Хәйрулла улы Мөхәммәтшин туграсы*

Борынгы әдәбият белән кызыксынуым гыйльми тикшеренүләргә — моңарчы өйрәнелмәгән урта гасырлар татар прозасын өйрәнүгә этәрде. Бу эштә иң беренче фәнни җитәкчеләрем Хатыйп абый Миңнегулов, Хатыйп ага Госманнар булды. Өченче курста укыганда ук Хатыйп ага миңа XVIII гасырдан сакланып калган зур күләмле хикәятләр җыентыгын тикшерүне тәкъдим итте. Шул китап хакында диплом эшемне якладым һәм кульязманы басмага әзерләү эшен Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында эшли башлагач та дәвам иттем.

Менә 18 ел инде шул фәннитикшеренү институтында эшлим. Төп гыйльми шөгылем — урта гасырлар татар прозасын өйрәнү, тикшерү һәм әдәби текстны басмага әзерләп, китаплар итеп чыгару. Нигездә мин кульязмалар буенча эшлим, хикәят, кыйсса,ләтыйфа, нәсыйхәт, гыйбрәт жанрларындагы чәчмә әсәрләрне гарәп хәрефеннән хәзер кулланыла торган алфавит хәрефләренә күчерәм, сүзлекләрен төзим, шәрехләр язам һәм аннан соң хәзерге әдәби телгә яраклаштырып, басма өчен әзерлим.

XIV йөздән башлап, XIX йөз ахырына кадәр Көнчыгыш әдәбиятларыннан татарларга гаҗәп күп хикәятләр үтеп кергән. Хикәят дигәннән, иң әүвәл Г. Тукайның мәшһүр "Туган тел"еннән шул юллар хәтергә килә:

Аннары төннәр буе әбкәм хикәят сөйләгән.

Чынлап та, ул хикәятләр шулкадәр күп булган ки, аларны көннәр-төннәр буе укып, сөйләп булган. Хикәят — язма әдәбият әсәре, хикәят жанры исә әкият белән хәзерге хикәя арасында торган үзенчәлекле жанр. Хикәятләрдә әкият хыялы, тылсымы белән бергә хикәя чынбарлыгы тыгыз үрелеп бирелә. Г. Тукай әлеге юллары белән безнең зур язма әдәбиятлы мәдәни милләт икәнебезне искәртеп тора.

Таҗиклар хикәятләрдән гыйбрәт торган "Җәмигыл хикәят" исеме

белән 5 том чыгардылар. Таҗик-фарсыларда булган хикәятләрнең барысы да диярлек бездә дә бар. Димәк, бездә дә рәхәтләнеп 5 том җыентык төзеп чыгарырга була. Шуны истә тотып, мин "Борынгы татар прозасы" дигән серияне төзи башладым. 1994 елда дөньяга чыккан 25 табаклы "Мәҗмүгыл хикәят" китабы сериянең беренчесе булды. Хәзерге вакытта тагын ике китап: "Маҗаралы хикәятләр" һәм "Гыйбрәтле хикәятләр" китаплары әзерләнеп бетеп килә. Ә бу көннәрдә исә мин хәзергә билгеле булган иң беренче чәчмә әсәр — Насретдин Рабгузыйның 1311 елда язылган "Кыйссас-ел әнбия", ягъни "Пәйгамбәрләр тарихы"ның текстын матбугатка әзерләү белән шөгыльләнәм. Әгәр дә гаҗәеп бай эчтәлекле бу дини-әдәби китапны хәзерге әдәби телдә бастырып чыгарып булса, мөселманнар өчен бу зур яңалык, кадерле бүләк булыр иде.

*— Нәҗип әфәнде! Белүебез буенча, дини-әдәби мирасны халыкка кайтаруда бу сезнең беренче генә эшегез түгел. Дини әдәбият үрнәкләрен газета-журналларда бирү, радио аша пропагандалау эшен күптәннән алып барасыз. Сез үзегез дин эшлеклесе, мәчет әһеле түгел, бу эшкә ничек кереп киттегез?*




*Шагыйрь Равил Фәйзуллин туграсы*



*Татарстанның халык артисты Айрат Арсланов туграсы*

— 80 елларның ахырында халыкка дин тотарга ирекләр бирелгәч, халык онытылган Ислам диненә кире кайта башлагач, хәзерге хәрефләр белән язылган җиңел аңлаешлы китаплар, белешмәләр кирәклеге сизелде. 1991 елда З. Шәфигуллин үзе төзи башлаган "Ислам . Белешмә сүзлек" китабына татар халкында популяр булган дини китаплар турында кыскача белешмәләр язарга тәкъдим иткән иде. "Бу минем өчен әлләни авыр эш булмас, алар турында инде әдәбият бардыр, шулардан җыеп алып, бер системага салып кына бирермен", — дип, җиңел генә уйлап, ризалык биргән идем. Әмма эшкә чынлап тотынгач, әдәбият тарихы китапларын актарып карагач, борынгы дини әдәбиятыбыз турында бөтенләй диярлек мәгълүматлар юклыгын белдем. Дөрестән дә, Совет власте елларында язылган әдәбият тарихларында ул әсәрләр турында сөйләп, мәгълүмат бирү кирәкмәс эш саналган, бары тик аларны сүгеп, тибеп үтү генә яраган. Шулай итеп, миңа турыдан-туры чыганакларга мөрәҗәгать итәргә туры килде, оятыма каршы, борынгы әдәбият белән эш итүче

саналсам да, мин аларның кайберләрен бөтенләй укымаганмын яки өстән-өстән генә белгәнмен икән. Минем алдымда яңа бер зур дөнья ачылды — гаҗәеп бай мәгънәле, мавыктыргыч, нәфис дини әдәбият дөньясы. Ул әсәрләрнең кайберләре турындагы иң тулы мәгълүматны, әдәби анализны Гали Рәхим белән Газиз Гобәйдуллин чыгарган "Татар әдәбияты тарихы"нда (Казан, 1923) таптым.

Үземнең белемнәремне шактый баеткан бу белешмәләрне язып тапшыргач, шулар нигезендә "Ватаным Татарстан" газетасында 1992 елда "Дини әдәби мирас" рубрикасын ачып җибәрдем һәм анда Әхмәт Ясәвинең "Диване хикмәт"еннән башлап 19 гасыр уртасы әсәре "Фазаилеш-шөһүр"гәчә булган иң популяр китаплар хакында белешмәләр һәм әсәрләрдән үрнәкләр биреп бардым. Аларның күбесе хәзерге алфавитта һәм хәзерге әдәби телдә чыккан иң беренче үрнәкләр булдылар. Мәсәлән, XIV йөз әсәре саналган "Кисекбаш" дастаны хакында Г. Тукай пародия рәвешендә язган "Печән базары, яхуд яңа Кисекбаш" аша өстән-өстән генә белгән халык аның борынгы үрнәге белән танышты. Ә "Фазаилеш-шөһүр" китабы исә халык арасында көтелмәгән популярлык казанды. Авторы Мамадыш төбәге Шәдче авылының имамы Җамалетдин Бикташи булган, әмма аның исеме күрсәтелмичә генә кат-кат күп тиражлар белән чыккан, кадими мәдрәсәләрдә беренче татарча уку китабы булган бу җыентыкның шактый өлешен башта "Ватаным Татарстан" газетасының "Әллүки" чыгарылышында биреп барган идек. Яңа гына дингә тартыла башлаган халык, бигрәк тә өлкән яшьтәге апалар аңа шунда ук игътибар иттеләр. Чөнки монда Ислам диненең төп кануннары, кайбер гадәтләре, әхлак кагыйдәләре җиңел тел белән, пәйгамбәрләр, изгеләр тормышыннан кыска хикәятләр аша эмоциональ рәвештә аңлатылган иде. Китап итеп бастырып чыгаруны сораучылар күп булгач, мин аның текстын әзерләп, бизәлешен дә үз кулым белән эшләп "Иман" нәшриятына тапшырган идем. Китап 25 мең тираж белән басылып чыкты һәм бик тиз арада сатылып та бетте. Китапның шундый популярлыгын тоеп һәм аның белән тиз арада өлләни хезмәт куймый гына акча эшләү мөмкинлеген күздә тотып, шул вакыттагы мөфти Г. Галиуллин миннән һәм "Иман" нәшриятыннан рөхсәт сорамыйча гына аны фототехник ысул белән күчертеп 1995 елның июлендә 50 мең тираж белән бастырып та чыгара. (Бу фактларны минем шикаятемә җавап рәвешендә җибәрелгән Татарстан интеллектуаль милекне саклау агентлыгы юристы җибәргән белешмәдән алдым.) Әлеге "Иман" нәшрияты да беренче тираж сатылып беткәч, "Фазаилеш-шөһүр, яки саваплы гамәлләр"не тагын берничә кат бастырып чыгарды. Наширләргә файдасы, миңа савабы калды. Шулай итеп, иске мәдрәсәнең бик гади, самими уку китабы булган, җәдитчеләр тарафыннан заманында сүгелгән бу китап Ислам диненә яңадан кайту чорында, XX йөзнең ахырында да популяр булды.

*— Элекке дини һәм әдәби мирасны яңадан халыкка кайтару сезнең эшчәнлекнең бер ягы. Без әле аның икенче ягын да, шулай ук борынгы мирас белән — бу юлы каллиграфия сәнгате белән бәйле эшчәнлегегезне беләбез. Сез борынгы традицияләрне тергезү-яңартуга зур тырышлык куясыз. Бездә әле каллиграфлар күп түгел, бармак белән генә санарлык. Сез исә каллиграфия сәнгатенең берничә төре белән берьюлы шөгыльләнәсез һәм һәр өлкәдә уңышларыгыз юк түгел. Шуңа күрә күп санлы укучылар, тамашачылар ул әсәрләрне көтеп алалар, яраталар. Сезнең "Нәкъкаш" дигән кушаматыгыз кызыклы, Такташ, Сәйдәш, Борнаш, Гаташлар кебек бик тә татарча яңгырый, гәрчә ул гарәп сүзе булса да. Кушаматны гадәттә шагыйрьләр, әдипләр ала, сез исә гыйльми хезмәтләрегездә*

*үзегезне "Н. Исмәгыйлев" дип күрсәтсәгез, сәнгать әсәрләрендә исә "Нәкъкаш" дип исемләнәсез. Ни өчен кушамат алдыгыз, аның мәгънәсе нидән гыйбарәт?*

— Бу псевдоним-кушаматны мин 1991 елдан башлап, "Мирас" журналында беренче эшләрем басыла башлагач та алдым. Беренчедән, Исмәгыйлев нык таралган фамилия, мине башка Исмәгыйльләр белән бутамасыннар, дидем. Икенчедән, минем бу шөгылем әдәбият белән турыдан-туры бәйләнгән. Хөрмәтле Рабит Батулла үзен "мин язучылар янында язучы, артистлар янында артист" дигән шикелле, мин дә галимнәр янында галим, рәссамнар янында рәссам. "Нәкъкаш" — гарәпчәдән тәрҗемә иткәндә иң беренче тар мәгънәсе "ташка уеп бизәк ясаучы, ташка язучы" дигәнне аңлата. Киңрәк мәгънәдә рәссам-график дигәнне белдерә. Шулай булгач, бу кушамат минем шөгылемә бик тә туры килеп, ябышып тора, дип уйлыйм. Соңрак, инде бу кушаматны үземә алгач, мин төрекләрдә бер язучының һәм гарәпләрдә бер каллиграфның Нәкъкаш кушаматын йөрткәнен белдем.



*Шагыйрь Рәдиф Гаташ туграсы*



*Әдәбият галиме Нил Юзиев туграсы*

*— Тагын бер традицион сорау: бу борынгы сәнгать белән сез кайчан, ни рәвешле шөгыльләнә башладыгыз?*

— Балачактан ук мине ул серле хәрефләр үзләренә тартып, күңелне әсәрләндереп тора иде. Әбидән калган Коръән кисәкләрендәге язулар, өни ягыннан булган күрше авылдагы бабайлар өендәге пыялага ясалган, нурланып, җемелдәп торган тылсымлы шәмаил минем хәтеремә мәңгегә уелып калды. Ул төсле шәмаилләрне безнең авылда Хәсәнша Әхмәтшин исемле бик укымышлы, бухгалтер булып эшләүче өлкән яшьтәге кеше ясый иде. Хәллерәк кешеләр үзләренең өйләрендә аның картиналарын булдыруны бурыч итеп куялар иде, шуның белән горурланалар иде. Ә гарәп хәрефләре белән чын-чынлап танышу, гарәп телен өйрәнү миңа шактый соң — Казан университетында укыганда насыйп булды. Тик ул чакта, 70 еллар ахырында, аның бу заман өчен шулкадәр кирәк булачагы хакында кем уйласын!.. Нәселдән килә торган табигать бүләге, Алланың рәхмәте — азмы-күпме рәссамлык сәләте булганга, гарәп хәрефләрен матур язарга өйрәнү әллә ни кыен булмады. Күбрәк мин үзлегемнән, элеккеге осталарның эшләрен күчерә-күчерә өйрәндем. Студентлык елларыннан

башлап 1989 елга кадәр бу сәнгать белән үзем өчен, үз күңелем өчен генә шөгыльләнә идем. 1989 елның җәендә Болгар дәүләтендә Ислам дине кабул итүнең 1100 еллыгына багышлап Казан шәһәренең күп музейларында күргәзмәләр оештырдылар. Шул вакытта минем үзем өчен генә иҗат ителгән уртача гына эшләремне дә экспозицияләргә куяр өчен кырып-себереп алып бетерделәр. Шул елларда бер-бер артлы яңа журналлар, газеталар чыга башлады. Халыкның бу сәнгатькә ихтыяҗын канәгатьләндерү йөзеннән алар миңа бер-бер артлы заказлар бирә башладылар. Минем шәмаил-миниатюраларым бигрәк тә "Мирас" журналына туры килеп, аның йөзенә әверелде һәм мин ул журнал белән даими хезмәттәшлек итә башладым. Хәзерге вакытка аның тышлыгында минем 30 дан артык эшем басылып чыкты.

*— Менә сезнең әүвәлге традицион шәмаилләргә якын булган эшләрегез дә, шулай ук алардан аерылып торган, үзегезгә генә хас булган, яңача әсәрләрегез дә бар. Бигрәк тә "Мирас" журналындагылар. Аларның үзенчәлеген, яңалыгын сез үзегез яхшырак аңлатып бирерсез, дип уйлыйм.*

— Традицион шәмаилләрдә гадәттә Коръәннән аятьләр, Мөхәммәд пәйгамбәрнең хәдисләре, Алланың бөек исемнәре; Мөхәммәд галәйһиссәламне данлаган сүзләр, аның сахабәләре Әбүбәкер, Гомәр, Госман, Галинең исемнәре; дүрт олуг фәрештә: Җәбраил, Газраил, Микаил, Исрафилнең исемнәре языла. Шулай ук, сирәгрәк булса да, атаклы һәм фарсы шагыйрьләренең Аллага, Мөхәммәд пәйгамбәргә, Ислам диненә багышланган хикмәтле юллары языла.

Мин исә үземнең шәмаил-миниатюраларымда Коръән аятьләре, пәйгамбәр хәдисләре белән бергә үзебезнең татар шагыйрьләренең дә шул эчтәлеккә туры килеп торган, аваздаш булган шигъри юлларын урнаштырам. Мәсәлән, Коръәндә (2 сүрә, 153 аять) сабыр итү турында шундый гыйбарә бар:

"Иннә Аллаһа мәга-сабирыйнә" ("Аллаһу Тәгалә сабырлар белән бергә").

Нәкъ шуңа туры килеп тора торган мәгънә Тукайның "Сөткә төшкән тычкан" шигырендә бар:

— И карындәш! Син кирәксә суга бат, йә сөткә бат —
Ит сабыр, күрсәт чыдамлык һәм дә ит гайрәт, сәбат!

Менә тагын Мөхәммәт пәйгамбәрнең хәдисе:

"Утлүбү-л-гыйльмә минә-л-мәһди иле-л-ләхди"
("Бишектән башлап ләхеткә кергәнче гыйлем өйрәнегез").

Тукайда да шул ук мәгънә:

— Өч наданга алмашынмас бер язу белгән кеше,
Мәгърифәт эстәр, ирәнмәс һич кеше булган кеше.

Гомумән, Коръән аятьләренә һәм хәдисләргә тәңгәл булган шигъри юлларны, хикмәтләрне Тукайдан еш табарга була. Шуннан соң да Тукайны бөек дими ни дисең!


Шәмаилләремнең үзенчәлекле икенче ягы — аларның ачык күренеп торган милли төсмере, татарчалыгы. Мин моны XX йөз башы типографик шәмаилләрдән һәм бүгенге башка авторларның эшләреннән аерып торган иң зур үзенчәлек дип саныйм. Бу төсләрнең кулланылышында, бизәкләрдә дә, композициядә дә күренә. Безнең халык ачык, якты, шатлыклы төсләрне, һәр детальнең аерым-ачык күренеп, беленеп торуын ярата. Мин шул таләпләргә аваздаш

булырга тырышам. Гәрчә, ул милли төсмер миндә үзеннән-үзе килеп чыга, чөнки ул миллилек минемканымда, җанымда һәм дөньяга карашымда.

*— Нәҗип әфәнде! Сез әле каллиграфия сәнгатенең онытылган, күпләр бөтенләй белми торган төре — тугра сәнгате белән дә шөгыльләнәсез. "Герб" сүзен алмаштырган "тугра" терминын да матбугатка, сөйләмгә кертеп җибәрүче дә, ялгышмасам, сез булдыгыз кебек.*

— Әйе, шулай туры килде. Җөмһүриятебезнең туграсын иҗат итү конкурсында мин дә катнашкан идем. Алтын Урда чорында ясалган чүлмәктәге гаҗәеп көчле, мегърур барсны үрнәк итеп алып, беренчеләрдән комиссиягә илтеп биргән идем. Ләкин үтә милли төсмерле булу сәбәпле комиссия минем туграмны халыкка күрсәтмәде... Аннары мин М. Бакиров идеясенә тәңгәлләштереп дәүләт тугралары ясаган идем. Шул мин ясаган сурәтләр белән аның мәкаләләре матбугатта күренде, тугра сүзе шул вакытта таралды.

Тугра — борынгы төрки сүз. Ул билге, тамга, шәхси герб дигәнне аңлата. Тамырында "ту", "туғ" дигән сүз ята. Гаскәри берләшмәнең, бүлекчәнең билгесе булган әләмне, байракны шул сүз белән атап йөрткәннәр. Әле язу кулланылмаган борынгы чорларда күчмә төркиләр гади генә сызыклардан торган бакыр, бронза, тимер тугралар белән кыздырып басып, далага көтүгә чыгарып җибәрәсе атларын тамгалый торган булганнар. Һәр кабиләнең, ыруның үз тамгасы булган. Атлар далада йөргәндә бергә кушылып зур табуннар хасил иткәндә, аларны шул сугылган тугралары буенча аера торган булганнар. Ә инде Ислам дине белән бергә гарәп хәрефләре кабул ителгәч, ханнар, солтаннарның фәрманнарда, хатларда, ярлыкларда аларның исемнәре үзенчәлекле матур монограммалар рәвешендә язылып куела торган булган. Шуны электән килгән төрки сүз белән "тугра" дип атаганнар. Ярлыкларны язучы, тамганы ясаучы хаттатларны исә туграчы, тугракеше дип атый торган булганнар.




*Язучы Флүс Латыйфи туграсы*



*Шагыйрь Наис Гамбәр туграсы*

Урыслардагы "клеймо"ны белдергән "тавро" сүзе нәкъ менә шул төрки сүздән алынган.

XIV гасыр ахырларында Төркиядә махсус тугра стиле формалаша, канунлаштырыла. Ул көчне, мегърурлыкны, җегәрне белдереп торучы мәһабәт бер композиция рәвешен ала.

Соңгы чорларда ханы, солтаны булган милли дәүләтебез юк ителгәч, ул тугралары укымышлы кешеләр, муллалар, сәүдәгәрләр үзләренең шәхси мөһерләре, китап билгеләре рәвешендә куллана башлаганнар. XIX гасыр ахырларында үзеңнең туграң сурәтләнгән

шәхси мөһерең булу мәдәнилек билгесе саналган. Безнең Казанда Берләштерелгән дәүләт музеенда 48 мөһердән торган бай һәм матур коллекция саклана.

Гарәп хәрефе матур сурәтле, сыгылмалы, сурәтләү мөмкинлекләре зур булган хәреф. Хыялың бай булса, аннан әллә нинди күп сурәтләр, бизәкләр ясап була. Мәсәлән, "Бисмилла" сүзен җиңел генә кош рәвешендә, яки кувшин рәвешендә язып була. Кешенең исеме, атасының исеме, нәсәбатыннан (фамилиясеннән) торган монограмманы да төрле сурәтләр рәвешендә язып була. Кайсыбер очракта аларга кешенең кайбер холык сыйфатларын да, профессиясен яки бер-бер мавыгуын да чагылдырып була. Мәсәлән, мин үземнең якташым, атаклы җырчы Мингол Галиевнең туграсын музыка билгесе "скрипка ачкычы" рәвешендә ясадым.

*— Бу туграларны хәзерге көндә дә гамәлгә, ягъни кулланылышка кертеп буламы соң?*

— Ник булмасын, бик була! Туграны үзеңнең визит карточкаңда, шәхси мөһереңдә, китап мөһерендә (экслибриста) кулланырга мөмкин. Мәсәлән, мәгълүм әдип Марсель Гали аны үзенең визит карточкасында да, үзенең юбилей кичәсенә чакыру билетында да кулланды.

Шулай ук аны үзеңнең гербың (туграң) итеп, пыялалы кысага урнаштырып, диварга эләргә була. Эшмәкәр Р. Һибәтуллин нәкъ шулай эшләде дә. Бөтен гаилә әгъзаларының исемен берләштереп уртак гаилә туграсы да ясарга була. Диварда эленеп торган мондый тугра бүлмәгә үзенчә бер экзотика, милли төсмер бирә, бизәп тора.

*— Нәҗип әфәнде! Дөресен әйтергә кирәк: бу гарәби каллиграфия сәнгате бу көндә һәркемгә дә әле аңлашылып җитми, сезнең картиналарны аңлау өчен иң элек гарәп хәрефен таный, укый белү сорала. Димәк, бу элитар сәнгать?*

— Мин моны алай ук димәс идем. Элитар сәнгать ул аерым бер катлау, бер төркем өчен генә хезмәт иткән сәнгать. Ә моны гарәп хәрефен таныган һәркем аңлый, укый ала — бае да, ярлысы да. Гарәп язуын, бабаларыбызның меңъеллык мирасын өйрәнү өчен берәүгә дә юл ябылмаган. Бүгенге заманда мәктәп-гимназияләрдә гарәп язуын өйрәнүче балалар һаман ишәя бара, димәк бу сәнгатьне аңлаучыларның да аудиториясе киңәя дигән сүз. Ә бит Алла сүзе, пәйгамбәр сүзе кергән шәмаилләрне гарәп язуын танымаган күп татар кешеләре өйләрендә тотканнар, алар аны динлелекнең, Аллага ышануның, татарлыкның символы итеп санаганнар, атеизмның һөҗүмнәре вакытында да өйләрендә саклаудан курыкмаганнар. Алар ата-бабаның ядкяре, реликвиясе булып, буыннан-буынга күчә барганнар, әле дә аларны һичкем йә сатарга, йә музейга илтеп тапшырырга җыенмый. Безнең музейларыбыздагы шәмаилләр бик авырлык белән генә җыелганнар.

— Рәссам-хаттат эшчәнлегенен тагын бер өлкәсен — матур язу сәнгате белән турыдан-туры бәйле китап бизәлеше белән шөгыльләнүен дә искә алып үтү кирәктер. Хәзерге көндә ул — 40 лап китап тышлыгының рәссамы. Ул бизәгән китаплар хәрефләренең ачыклыгы, төгәллеге, оригинальлеге белән, төсләренең ачык һәм якты булулары, чып-чын милли төсмерләре белән "менә бу татар китабы!" дип, әллә кайдан әйтеп торалар. Аның бизәлешендә чыннан "Мәҗмугыл-хикаят", "Фазаилеш-шөһер, яки савaплы гамәлләр" китаплары, Ф. Яруллинның өчтомлыгы, Ш. Зәбиров һәм Ф. Хуҗиәхмәтовалар инде менә 5 ел чыгарып килгән татар мөселман календарьләре, "Иман" нәшрияте чыгарган күптиражлы календарьләр, "Раннур" нәшрияты чыгарган "Ислам дине нигезләре" китабы үзләренең милли янгырашы, милли төсмерләре белән соңгы 80 елда

чит-ят халыкларның мәдәнияте тәэсиренә бирелеп, үз йөзен югалта башлаган татар халкының зәвыгын тәрбияләүдә, янадан формалаштыруда уңай йогынты ясыйлар.

Н. Нәкъкашның тагын да бер юнәлештәге игелекле эше игътибарга лаек, ул да булса — остаз буларак, шәкертләр тәрбияләү.

*— Нәҗип әфәнде! Сез кайда укытасыз һәм инде күпме шәкертегез бар?*

— Мене инде 6 ел мин Татар дәүләт гуманитар институтында каллиграфия дәресләре алып барам. Бу эш шушы яңа институт оешкан елны ук, хәзер шунда проректор булган Ф. Ә. Ганиева әйдәкләве белән башланган иде. Бу көнгә инде минем 400 ләп шәкертем бар, шулар арасыннан иң сәләтлеләре каллиграфия конкурсларында катнашып, алдынгы урыннарны яулап алдылар. Инде профессиональ дәрәҗәдә иҗат итүче шәкертем Ә. Хәлиуллина үзе каллиграфия дәресләрен укыта башлады. Аллага шөкер, без башлаган эш уңышлы гына бара.

*— Менә сезнең шәхси туграгызда очып баручы кош сурәтләнгән. Моның берәр символик мәгънәсе бармы?*

— Очып баручы кош сурәтеннән төрле мәгънә чыгарырга була. Үземчә мин моның белән очкан кош кебек тиз үтеп китүче фани дөньяны, шул вакыт, шул дөнья эчендәге үземне сурәтлидем. Менә шул очкан коштай тиз үтеп китүче гомердә эз калдырып, үзеңнән соң игелекле эшләр калдырып китәргә иде. Бу тугра минем шуңа омтылышымны аңлата.

*— Омтылышыгыз, максатыгыз изге икән, Нәҗип әфәнде. Шул изге юлда, халкыбызның мәдәни мирасын кире кайтаруда, шул эшчәнлегегезнең һәр ике тарәндә Сезгә иҗат уңышлары насыйп булсын. Һәм ихлас күңелдән "әйдә, халыкка хезмәткә!.." дибез.*

*Әңгәмәдәш —* **Наис ГАМБӘР.**

## Марс Шабаев

# ТУГАН ҖИРЕНЕҢ БАЛАСЫ ИДЕ...

Вакыт елгасы ага да ага...

Танылган татар язучысы, хикәяләр-повестьлар остасы Хәсән Сарьянның вафатына егерме ел тулды.

Безне Аяз Гыйләжев таныштырган иде.

Болай булды: 1960 елның май урталарында мине — Татарстан радиокомитетының әдәби-драматик тапшырулар мөхәррирен — Башкортстан радиокомитетына командировкага җибәрделәр.

Дөресен әйтим, бер дә барасым килеп бармадым мин Уфага. Юкса, беренче баруым, кызыксынуым да көчле — Уфа турында күп укылган, күп ишетелгән: анда Мәҗит Гафури, Габдулла Тукайлар сулышы бардыр кебек, анда Галимҗан Ибраһимов, Шәехзада Бабич, Хәсән Туфаннар укыган атаклы "Галия" мәдрәсәсе, анда күренекле әдипләр: Сәйфи Кудаш, Мостай Кәрим, Нажар Нәҗмиләр...

Аннары килеп, үз тиңнәрем — яшь башкорт язучылары белән танышып-күрешеп, дустанә элемтә-мөнәсәбәтләр урнаштырып кайтсаң, начар булмас иде булуын.

Әмма менә шул кызыксындырып-ымсындырып торган Уфага барасым килми иде. Бердән, вакытсыз: мин әле яңа гына яшь әти булган кеше — май башында гына улым Илшат туды. Икенчедән, әлегә бер танышым да булмаган чит-ят шәһәргә шулай кинәттән генә чыгып китү дә бераз шикләндерә иде.

Шулай аптырап-каңгырап дигәндәй йөргән көннәрнең берсендә мин ничектер "Совет әдәбияты" (хәзерге "Казан утлары") журналы редакциясенә барып керәсе иттем. Берәр йомышым булдымы, әллә болай гына — эш юктан гына сугылуым идеме — хәзер инде әйтә алмыйм.

Журналда эшләүче егетләр белән гәпләшеп-сөйләшеп утыра торгач, Уфа турында да сүз чыкты. Дөресрәге, сүзне үзем кузгаттым:

— Менә, Уфага барырга торам әле... — дидем.

Язу өстәленә иелә төшебрәк утырган Аяз Гыйләжев (ул журналның проза бүлеге мөхәррире иде), күзлек пыялаларын ялтыратып миңа таба борылды:

— Танышларың бармы соң Уфада? — дип сорады ул.

Узган кышта Мәскәү радиосында ун көнлек семинарда булып, Башкортстан радиосының мөхәррире Якуб Колмый белән танышкан идем танышуын. Ләкин Якуб Колмый, үзе бик әйбәт, ачык кеше булса да, безнең яшь араларында шактый аерма бар: ул инде фронтларны кичеп кайткан, олгаеп баручы ир уртасы кеше иде. Ә миңа әле, ни әйтсәң дә, егерме җиде генә тулып килә.

— Барыннан бигрәк, юграк шул... — дип көлемсерәдем мин.

Аяз сүзне җитди юнәлешкә борды:

— Сарьянны беләсеңме?

Хәсән Сарьянның әле ул вакытта Казан матбугатында булса, бермеикеме генә хикәясе чыккан булгандыр, шулай да исеме колакка кереп өлгергән иде инде.

— Ишетеп беләм, — дидем.

— Миннән сәлам тапшырырсын. Барып керсәң, куып чыгармас. — Аяз күзлеген салып, күп укудан җилсенгән күзләрен бармагы белән сыпырып алды. — Әйбәт егет ул Сарьян. Татар җанлы...

Минем бер дә күрмәгән-белмәгән кеше янына алай капыл гына барып керә торган гадәтем юк. Гомумән, мин кешеләр белән тиз генә аралашып китә алмыйм. Ачылып китәр өчен миңа бераз вакыт кирәк була. Үзенә күрә бер сынау срогы димме...

Нәрсә әйтергә белми аптырабрак торганымны шәйләп булса кирәк, Аяз кулы белән кискен бер хәрәкәт ясап алды:

— Тукта, парин, мин сиңа бер язу сырлап бирим булмаса! —диде.

Монысы ярый торган эш иде.

Аяз Гыйләҗев язганын кычкырып укый барды:

— Сарьян дус! Шабайны мине кабул кылгандай кабул кыл!

Бу кечкенә хат-рекомендациядә башка сүзләр дә бар иде, билгеле. Әмма минем өчен иң мөһиме әнә шул беренче ике җөмлә иде.

Уфага барып төшкәч, туп-туры Хәсән Сарьяннарга юл тоттым. Мине кем дә булса каршы алыр дигән өметем-уем юк иде. Алдан хәбәр дә бирмәгән идем. Алай да Татарстан радиокомитеты рәисе Михаил Филлипович Долгов хәбәр иттергән булган икән, тик ни өчендер, ул хакта миңа гына әйтергә вакыт тапмаган: кайсы вагонда икәнемне белмәсә дә, каршыларга Якуб Колмый төшкән булган. Ләкин ул мине таба алмаган. Монысы соңыннан ачыкланды.

Уфаның Тукай урамында — мәчет белән янәшә ишек алдындагы бер агач йортта яши икән Хәсән Сарьян. Артларында — биек яр астында бормаланып Агыйдел агып ята. Данлы Агыйдел!


*Хәсән Сарьян*

Бик ашкынып, күңел кытыкланып килдем килүен дә, Хәсән Сарьян өйдә юк булып чыкты. Ишекләрендә йозак иде. Кәтәргә булдым.

Тукай урамындагы йортларны караштыра-караштыра эзләнеп килгәндә, каршыма өч-дүрт яшьләр чамасындагы малаен җитәкләгән урта буйлы, әмма нык-таза бәдәнле, калын күзлекле бер кеше очраган иде. Минем як-ягыма карана-карана килүемне күрепме, якыная төшкәч, ул адымнарын акрынайтты. Мин дә, ул да бер-беребезгә текәлебрәк карап уздык шикелле. Узып китеп бераз баргач, артыма борылып карадым. Теге кеше, җитәкләгән малаен ашыктыра-ашыктыра, урамның икенче ягына чыгып бара иде.

Их, бу кыюлык җитмәүләр! Шунда аны туктатып: "Фәләненче йорт кай тирәдәрәк?" — дип сорыйсы гына калган бит. Күңел сизенгән иде бит югыйсә: Хәсән Сарьян үзе иде ич ул! Малаен балалар бакчасына илтә барышы булган икән аның.

Сарьян, шул иртәнге якта чыгып китүеннән, "Кызыл Таң", "Һәнәк" кебек газет-журнал редакцияләренә кергәләп йөри-йөри, көн урталарында гына кайтып керде булса кирәк. Һәрхәлдә, миңа шактый озак кәтәргә туры килде.

Ниһаять, кайтты Сарьян. Таныштык. Мин аңа Аяз Гыйләҗевның хат кисәген тоттырдым. Сарьян хатны бик игътибар белән укып чыкты:

— Ала-а-ай... — дип, сузып кына үзенчә бер нәтиҗә ясады шикелле. — Әйдәгез, өйгә керик алайса! — дип ишеген ачты.

Аның хәрәкәтләре сүлпән-салмак, тавышы да сүрән-салкын иде. Ул ниндидер тирән уйда иде төсле.

"Кояшы бик сүрән күренә әле моның..." — дип, күңелсезләнеп уйлап алдым мин. Аяз әйткәнчә, һич тә алай кочак җәеп каршы алырга ашыкмады мине Хәсән Сарьян. Мин инде берәр кунакханәгә яки турыдан-туры Башкортстан радиосына китеп бармаганыма үкенә дә башладым.

Ярар, ничек булса булды, мин шулай итеп Хәсән Сарьянның йорт бусагасын атлап кердем.

Сарьян кечерәк кенә ике бүлмәле агач йортта яши икән. Түр бүлмәдә, тәрәзә буенда — трибуна дип әйтимме, мөнбәрме —агачтан ясалган бер

нәрсә тора. Ул буялмаган-нитмәгән, кулдан эшләнгән, әмма бик пөхтә, зәвыклы иде.

Минем кызыксынуымны сизеп, Сарьян елмайгандай итте:

— Бу мөнбәр — минем эш өстәлем. Үзем ясадым, — диде. — Мин басып язам. — Бераздан өстәп куйды. — Хемингуэй кебек...

Безнең дә яшь чаклар иде шул әле. Сарьянга да нибары утыз гына тулып узган. Кемнәргәдер бөекләргә иярәсе, шуларга ни-нәрсә белән булса да охшарга тырышып йөргән чаклар...

Тамак ялгап, чәйләп алганнан соң, без Башкортстан радиокомитетына — командировкамның төп максаты булган җиргә киттек.

Бардык, кердек, таныштык.

— Оятлы иттең син мине, Шабай! — дип уңайсыз елмаеп каршылады Якуб Колмый. — Мәскәүдә кышкы киемнән идең бит. Бәлкем, шунлыктан бу хөббәңнән танымаганмындыр. Кунакханәгә дә сугылмагансың. Без сиңа урын алып куйган идек.

Бу юлы миңа уңайсызланырга туры килде. Кирәк бит, кешеләрне шул кадәр бимазаларга!

— Кара, ул хакта башыма да китермәдем бит, әй! — дидем.

Сүзгә Сарьян кушылды:

— Бернинди кунакханә юк! Ул минем кунагым, үземдә тора...

Менә сиңа сүрән-төксе Сарьян! Болай булгач, аның мине үзеннән җибәрәсе килми була түгелме соң?

Уфалыларның кунакчыллыгын барыбыз да яхшы беләбез. Ул хакта озын-озаклап сөйләп тору кирәкмидер. Мине дә менә — әле исеме-аты әдәбиятта рәтле-юньле күренмәгән бер кешене — зурлап, "татарның талантлы яшь шагыйре" дигән булып, кунактан-кунакка йөрттеләр. Якуб Колмыйда булдык, Әнгам Атнабаевта булдык, Денис Исламовта булдык... Хәтта Денис Исламовның, бераз утыра төшкәч: "Сез, егетләр, утыра торыгыз. Җитмәсә, кибет әнә теге почмакта гына. Мин футбол карап кайтыйм инде..." — дип, безне калдырып чыгып китүе һәм ике сәгатьтән соң кайтып керүенә кадәр күңелле бер вакыйга булып истә калган...

Шул берничә көн эчендә Хәсән Сарьян белән тәмам якынаеп беттек. Аның үзенең дә күңеле бик тулышып, эч серләрен кемгә түгәргә белми йөргән көннәре булган икән. "Мин сине шуңа күрә дә кунакханәгә җибәрмәдем", — диде ул. Ике арадагы салкынлык, шик-шөбһә бозлары эреп юкка чыкты.

Шик-шөбһә дигәннән...

Сарьянның шәхси тормышында бик тә авыр көннәр кичергән чагында барып төшкәнмен икән мин аларга. Булырсың да сүрән...

Хәсән Сарьянның эшсез калган, эш таба алмый каңгырып йөргән мәле икән аның. Башкорт дәүләт университетының филология бүлегендә татар теле тарихы һәм хәзерге татар теле буенча курслар алып барган ул. Ә менә хәзер эшсез... Редакцияләрдә дә "Һай, Сарьян!" дип, язганнарын бастырырга бик атлыгып тормыйлар икән. Кичәге дусларның кайберләре бүген аны бөтенләй күрмәмешкә үк салыналар, имеш. Юкса, бик әйбәт кенә язып, күтәрелеп барган чагы...

Сарьян эчендәгесен шулай ачып салгач, мин:

— Ничек алай килеп чыкты соң, Сарьян? Сәбәбе нәрсәдә? — дип сорап куйдым.

— Сәбәбе "Нокталы өтер"дә! — дип усал гына кисеп куйды Сарьян. — Әйдә, соңга калмагаек... — Ул, кулындагы чыбык кисәген бер якка ыргытып, урыныннан кузгалды.

Мин аның "Нокталы өтер" дигәненнән бер нәрсә дә аңламасам да, ары таба сораштырырга батырчылык итмәдем. Күңелемдә авыр бер хис калды: "Сарьян барын да әйтеп бетерми..."

Безнең бу сөйләшү Салават Юлаев һәйкәле янында булган иде.

Сарьян Уфаны әйбәт белә. Миңа күрсәтеп йөргәндә, теге яки бу бинаның тарихын да сөйләп бирә, атаклы кешеләре турында да тәфсилләп сөйли.

Менә әле бу юлы ул мине Уфаның ике заллы кинотеатрына алып бара. Шунда кинога билет алган идек. Сүзебезне бүлеп шунда ашыктык.

Кинотеатр фойэсында Сарьян мине бер егет белән таныштырды:

— Татарның Такташка алмаш булырлык яшь шагыйре Рәдиф Гаташ — Гатауллин булыр бу! — диде.

Уфада, гомумән, уенын-чынын бергә кушып, әнә шулай күтәренке-купшы итеп сөйләшергә ярата иделәр. Мин моны берничә мәртәбә сизгән идем.

Рәдиф Гатауллин дулкынланып торган коңгырт-кара чәчле, калын гына кашлы, ак чырайлы, күзлекле бер егет иде. Ул Башкорт дәүләт университетында укый икән.

Сарьян аңа:

— Казаннар белсен әле кемлегеңне! Йә, берәр шигырь укы әле, — диде.

Рәдиф аптырабрак калды:

— Шушындамы?

— Ә ни булган шушында булса?

Укыды Рәдиф Гатауллин шигырь. Тавышын баса төшеп укыса да, ялкынланып, кулларын бутый-бутый укыды ул. Сүз дә юк, егет чынлап та сәләтле иде.

— Шәп бит әй! — дип мактадым мин Рәдифне. — Казанга кил. Синдәй егетләр кирәк Казанга.

Артык уйлап-нитеп тормастан, шигырь тыңлап әсәрләнгәннән генә әйтелгән бу сүзләр Рәдиф Гатауллинның күңеленә бик тирән кереп калган икән. Берме-икеме ел үтүгә, ул инде Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга күчкән иде.

Хәсән Сарьян соңыннан еш кына:

— Син, Шабай, Уфадан берьюлы ике куян атып киткән идең: берсе — Рәдиф, берсе — мин, — дип шаяртып әйткәли иде.

"Икенче куян"ның — Хәсән Сарьянның Казанга күчүе мәсьәләсе әлеге дә баягы Салават Юлаев һәйкәле янындагы сөйләшүне, бүленә-бүленә, кайта-кайта дәвам итүебез нәтиҗәсендә булды шикелле.

Бер кичне Сарьян миңа, ачылып китеп, сатирик әсәреннән бер өзек укыды. "Чәмәт — фәннәр кандидаты" дип атала иде ул. Томана, надан бер карьеристның фәнгә үрмәләве бик усал тасвирланган иде анда. Укыганда икебез дә көлә-көлә укысак та, өзекне укып бетергәч, сүз җитди юнәлеш алды.

— Менә шушы "Нокталы өтер" минем өстән КГБга ике-өч әләк язды, — диде Сарьян күңелсезләнеп. — Имеш, мин — милләтче. Татар милләтчесе...

Коллегасы өстеннән донослар язучы ул адәм дә Башкорт дәүләт университетында укыта икән. Тел галиме, имеш. Соңыннан бу "Нокталы өтер", Уфага сыеша алмыйча, Казан ВУЗларының берсенә килеп сыенган иде. Хәзер юк инде, мәрхүм... Авыр туфрагы җиңел булсын...

— Хәзер нишләргә дә белгән юк... — дип сүзен дәвам итте Сарьян. — Ни эшкә кереп булмый, ни язганнарны басмыйлар... Әзмәвердәй ир башым белән хатын җилкәсендә утырам. Җитмәсә — бала... — ул ачынып кулын селтәп куйды. — Менә шулай, Шабай, минем хәлләр... Сиңа ачылдым, түгеп йөрмәссең, яме!

— Нинди түгү, ди, Сарьян! — Минем аңа чын күңелдән ярдәм итәсем килә иде. — Әгәр Казанга күчсәң...

— Казанга?.. — Сарьян күзлеген салып, аны сөрткәләп азапланды. Күрәсең, мондый тәкъдимне көтмәгән иде ул. — Кабул итәрләрме соң? Кара сакалың үзеңнән калмаса, нишләрсең?

— Син бер-ике елдан Аяз Гыйләҗев, Газиз Мөхәммәтшиннарны куып җитәчәксең, Сарьян! Әнә бит, язганнарың да байтак. Беренче китабың әзер дигән сүз.

— Шулай дисеңме? Ә гаилә? Ә фатир мәсьәләсе? Анда да тотырып куймаганнардыр...

— Җан биргәнгә җүн бирер әле. Кил, Сарьян! Башта үзең генә килергә була. Аяз бар, мин бар дигәндәй... Куып чыгармабыз...

— Сүздә җинел, Шабай! Тормыш башкачарак шул. Бә-ә-әк кырыс түтәй ул — тормыш...

Кече якта йоклап яткан баланың саташып ыңгырашуы ишетелде. Сарьянның хатыны Фирүзә ханым:

— Чү-чү, улым... Чү-чү... Мин монда... — дип, улы Рифкатьне тынычландырып юата башлады.

Сарьян башы белән шул якка ымлады:

— Әнә бит... "Паку" да бар бит әле...

"Паку" — үзе аерым бер тарих. Анысын Сарьян миңа беренче кичтә үк, улы Рифкатьне бакчадан алып кайтканда сөйләгән иде.

Рифкать яшь ярым-ике яшьләр чамасында чагында бик каты авырып китә. Күзгә күренеп сыза бала. Ашаудан кала. Табиблар да әллә ни ярдәм итә алмыйлар. Менә шундый авыр көннәрнең берендә, аптыраганнандыр инде, Сарьян сабыена радиолада музыка уйнатырга тотына. Тавышын басып, ишетелер-ишетелмәс кенә куеп уйната ул. Үзебезнең татар көйләрен, моңлы, озын көйләрне... Шуларны тыңлап ята-ята, сырхау бала изрәп йоклап китә... Бу хәл берничә мәртәбә кабатлана. Әле тел чыгып җитмәгән Рифкать үзе: "Паку... паку..." — дип, музыка сорый торган булып китә.

— Хикмәти хода! Килеште бит шул көй-моңнар — терелде балакаем... Паку... — дип йомгаклаган иде Сарьян сүзен.

Соңыннан ул бу вакыйганы хикәя итеп тә язды. Хикәясенең дә исеме "Паку" дип атала иде.

Бераз алгарак китеп булса да, әйтеп узыйм: Хәсән Сарьян белән бу сөйләшүләрнең төсмере аның Казанда басылып чыккан беренче "Хикәяләр" җыентыгына язган автографында да ачык күренә. Ул болай дигән:

*"Шабай М.*

***Синең якты иканеңне беренче очрашуда ук белеп, тоеп — эч серләремне сөйләдем. Рәхмәт аңлавыңа, саклавыңа.***

***Ваклыклардан өстен булыйк!***

*Х. Сарьян.*
*7/XII-62".*

"Шабай М" дигәнен Сарьян бергә кушып, "Шабаем" дип укып биргән иде. Бу аның Казанга килгәч чыгарган беренче китабы булды.

Ә Казанга килүе...

1960 елның яз-җәй айлары үтеп китте. Көз җитте.

Хәбәрләшеп торырбыз дип аерылышкан булсак та, ни өчендер Сарьяннан хат-хәбәр күренмәде. Мин инде: "Берәр эшкә урнашкандыр, тынычлангандыр..." — дип уйлый башлаган идем.

Ә ул — Хәсән Сарьян — октябрь аеның яңгырлы-юеш бер көнендә хәбәрсез-нисез генә килде дә керде! Радиокомитетка, минем эш бүлмәсенә.

Кочаклашып күрештек. Исәнлек-саулык, хәл-әхвәл сорашу китте.

— Менә, килдем әле... — дип, фикерен өзеп кенә әйтеп бетермичә туктап калды Сарьян.

— Килеп яхшы иткәнсең. Мин үзем дә бередән күчәргәрәк торам әле, — дидем мин.

— Нишләп? Кая күчәсең?

— Балалар газеты "Яшь ленинчы" яңадан ачыла. Шунда димлиләр.

— Ала-а-ай... Бәлки, миңа да урын табылыр шунда, ә?

— Бәлки... Сөйләшергә кирәк булыр.

Хәсән Сарьянның Казанга килүе шулай булды. Ул ялгызы гына килгән. Уфада сөйләшенгәнчә, танышу-белешү, эш эзләп карау өчен дип килгән иде ул.

Казан ана мәрхәмәтле булды. Озак та үтмәде, Сарьян "Азат хатын" журналы редакциясендә җаваплы сәркәтип булып эшли башлады.

Килгән айларында берара Сарьян миндә дә кунгалап йөрде. Әмма

минем квартир шартлары бик кысынкы чак: өч бүлмәле квартирның ике бүлмәсендә — биш-алты кешелек гаилә, бер бүлмәсендә — без. Шул бер бүлмәдә ирле-хатынлы икебез, яшь бала...

Килеп керер иде дә Сарьян, ике кулы белән ишек яңагына таянып, бусагага баскан килеш кенә җыр сузып җибәрер иде:

Ялан еркәйден ай көккүге юк,
Үд Уралкайыма кайтайым...

Шулай моңлана иде Сарьян... Әлбәттә, җиңел булмагандыр аңа: гаиләсе Уфада калды, үзенең торыр куышы юк...

Аның хатыны Фирүзә ханым Уфаның ниндидер бер техникумында укыта иде булса кирәк. Кечкенә Рифкать ул вакытларда кем кулында булгандыр — әйтә алмыйм.

Әмма Хәсән Сарьян җебеп төшмәде, югалып калмады. Ул татар язучылары арасында үз урынын тиз таба алды. Тыштан сабыр-салмак күренсә дә, эшчән, дәртле-җегәрле егет иде Сарьян. Кыш-яз үтеп, җәй айлары җитүгә, Уфадан гаиләсен дә алып килде. Фатир мәсьәләсе дә уңай хәл ителде. Алар Казан финанс-экономика институты артындагы тау башында — агач йортларның берсендә яши башладылар. Ул фатир Әмирхан ага Еникидән калган иде бугай.

Хәсән Сарьян тиз арада — өч-биш ел эчендә оста хикәяче булып танылды. Аннары "Әткәм һөнәре" (1965), "Бер ананың биш улы" (1976), "Җәза" (1978) кебек җыйнак-тыгыз повестьлар иҗат итте. Тел белеме һәм әдәби-тәнкыйтькә багышланган күп санлы мәкаләләр язды. Тәрҗемә өлкәсендә дә уңышлы гына эшләде.

Мин аның иҗатына төпле анализ ясарга җыенмыйм, урыны ул түгел. Анысы тәнкыйтьчеләр эше. Мин Сарьян турында үзем белгәннәрне генә язам.

Хәсән Сарьянның Казанда үткән унсигез ел гомере безнең күз алдында булды. Хәтта Идел буендагы бакчаларыбыз да янәшә иде. Әйе, Сарьян турында күп сөйләргә мөмкин. Аерым алып сөйлисем килгәне — аның туган якларын сагынуы, шигъри табигатьле рухы-җаны турында.

Үзенең туган ягы Илешне, Агыйдел, Сөн, Базы су буйларын исенә төшергәндә, Сарьян бөтенләй үзгәреп китә иде. Гадәттә сабыр-салмак Сарьян күз алдында шагыйрьгә әйләнә дә куя!

Татарстан китап нәшрияты Туфан Миңнуллин төзегән "Агыйделкәй" (1989) исемле бүләк китап бастырып чыгарган иде. Анда "Агыйдел" сүзе кергән халык җырлары тупланган —дүрт йөздән артык җыр! Шуның ничәсен белә иде икән Хәсән Сарьян? Мин менә шул китапны актарып утырсам, күп кенә җырлар колагыма Сарьян дус тавышы булып яңгырап керәләр... Иллә дә сөенер иде ул бу нәни китап өчен!

*"...Агыйдел!*

*Бармы безнең чын татар җырларында синнән дә күп җырланган гайре бер елга!..*

*Әгәр дә мин елына бер сиңа кайтып, чабатасыз малай чагым кебек, иртә таңда салкын чыклар ярып буйларыңны бер әйләнмәсәм; чык күзедәй ак суыңда сары сагышларымны бер басмасам; бабамнарның сөяге түшәлгән җылы туфрагыңа битем куеп орынмасам — мин үземне башка җирдә, хәтта Казанымда да бу тикле дә нык ватанлы тоймас идем.*

*И иртәләрең ак томанлы Ак Иделем!"*

Хәсән Сарьян үзенең "Туган як хикәяләре" (1972) исемле китабын "Туган як моңы" дигән нәсер-уйлану белән ачып җибәреп, әнә шулай язган иде. Шунда ук ул: "Мин Агыйдел буйларының искитмәле ямёнә карап, миңа кадәр унике буын элек болгар угланы Гәрәй бабабызның яр-юлдашы, карендәш-якыннары белән Казан йорты Масрадан баш бирмичә чыгып киткән, арлар* иле аша ике Идел кичеп, бу җирләрдә торак тапкан чагын гүя үзем күргәндәй

---

* Арлар — удмуртларны элек шулай атап йөрткәннәр. Х. Сарьян искәрмәсе.

күз алдына китерә алам..." дип яза. Шуннан Сарьян, Агыйделгә бәйле рәвештә, үзенең уникe буын нәсел-нәсәбенең тарихын сөйләп бирә. Аны һәр чорның тарихына, шул җирләрдә яшәүче башка кавем халыклар язмышына кушып сөйли. Үз уй-хисләрен: "... ярдан ярга тибеп, колындай уйнаклап, Агыйделем ага... И минем туган җирем — уникe буын буена сулап туймас сулышым!.." дип тәмамлый Сарьян.

Йә, кайсыбыз тагын үз туган җирләре, үз нәсел-нәсәбе турында моннан да көчле, моннан да хисле итеп әйтеп бирә ала? "... Ярдан ярга тибеп, колындай уйнаклап..." — моны бит болай матур, җанлы итеп шагыйрьләребезнең дә бик күбесе яза алмый.

Хәсән Сарьян минем иҗатымның да нәкъ менә шул ягын — үз күңеленә якын булганын тотып алып бик матур мәкалә язган иде. "Туган җиренең шагыйре" дип атала иде ул мәкалә. Аны башта "Социалистик Татарстан"да (1976 ел, 18 апрель), аннары "Уеңны уйдырып сал..." дигән китабында (1977) бастырып чыгарды.

Чын мәгънәсендә җир кешесе иде Сарьян. Табигать баласы иде. Идел буеннан бакча җире алып, шунда казынып-чокынып йөргән көннәре ин бәхетле көннәре булгандыр аның. Сарьяннар кишәрлегендә ике зур имән бар иде. Шуның берсе астына кертеп, үз кулы белән сандык шикелле җыйнак-пөхтә йорт житкерде. Агач-тактаише әйберләргә бик кытлык чаклар иде. Юктан бар итеп салды йортын Сарьян. Имән туры килгән күп кенә бакчачылар агачларын кистеләр-төпләделәр. Сарьян кисмәде. Алай гына да түгел, икенче зур имәне төбендә ул дүрт сутыйга да тулмаган бакча җиренең дүрттән бер өлеше кадәрен чирәмен дә күтәрмичә калдырды. Ничек бар шулай, кыргый бер "болын" хәлендә. Җәй буена сулар сибеп, шул үз "болынын" кадерләп-карап тотар иде. Икешәр мәртәбә печәнен дә чабып ала... Хәзер дә ул яшел кишәрлек шулай кыргый хәлендә тора. Анда кыр чәчәкләре үсә, куе-куе булып юа күтәрелә...

Яшерен-батырын түгел, Сарьян ярлы яшәде. (Ә кайсы татар язучысы байлык-муллыкта, бал-май эчендә генә яши соң?!) Ул күп яза алмады, аз язды. Һәр язганы йөрәгеннән сыгылып-саркып кына чыгар иде. Ул конъюктура дигәнне, көнем өчен дигәнне белмәде. Әдәбиятка бер вакытта да хыянәт итмәде, итә алмады. Үзе исән чакта Хәсән Сарьянның татар телендә нибары алты китабы чыгып калды. Юкарак кына алты китап... Язганнарының байтагы, шул исәптән, югарыда телгә алган "Ноктalы өтер" исемле сатирик повесте да, дөнья күрә алмыйча, сөзелеп кала барды. Ни әйтәсең, торгынлык еллары иде. Бик кысынкы, кысылган еллар. Матди кысынкылыктан битәр, рух кысынкылыгы...

Мин Татарстан китап нәшриятында баш мөхәррир булып эшли идем. Ул елларның албастыдай басып торган тынчу һавасы, искә төшкәндә, әле һаман да күңелләрне болгата... Югары оешмаларга чакыртып, "келәмгә бастырып" җаныңны ашый торган заманнар иде ул. Күпме язучылар белән, шул исәптән, рухи якын булган дуслар белән дә, ачылышлы булырга туры килә иде. Өстән тыялар, ә җаваплылыкны син күтәрергә тиеш...

Менә шундый шартларда бик авырлык белән генә басылып чыккан "Уеңны уйдырып сал..." дигән китабына автографын Сарьян:

*"Марс дуска — Бу китап фәкать синең тырышлык аркасында дөнья күрде. Сиңа озын, тигез гомер телим. Иҗади уңышлар сиңа.*
*Автор Х. Сарьян. 11.01.78"* —

дип язган да "фәкать" сүзенең астына сызып куйган.

Их, Сарьян дус... Миңа озын гомер теләгәнсең дә бит, үзеңә теләмәдеңме икәнни соң? Китабыңны язып бүләк иткәннән соң, нибары сигез ай да ун көн генә яшәргә калган булган икән бит үзеңә...

Әйе, Хәсән Сарьян иртә китте, уйламаган-көтмәгәндә китеп барды ул. Аңа әле кырык сигез генә яшь иде. Танылган язучы булып өлгереп-пешеп җиткән генә чагы иде аның. Язасы да язасы иде әле аңа! Бүгенге көннәрне күрәсе, иркенләп бер иҗат итәсе иде... Өстәлендәге язу машинкасында җөмләсе

ярты юлда өзелеп калган кәгазь битен күргәч, үзебезнең дә йөрәкләр өзелеп төшәрдәй булган иде...

Юкса, таза, тыгыз бәдәнле кеше иде Сарьян. Физик эшне бик яратты. Минә дигән балта остасы иде. Аның "Әткәм һөнәре" повесте нәкъ менә шул балта остасы булуыннан чыгып язылган да. Аннары Сарьян бик ярдәмчел иде. Бер-бер каккалыйсы-суккалыйсы эшең булдымы, хәзер ялт иттереп эшләп тә бирә.

Менә шулай тыныч-матур гына яши идек әле без. Дөрес, Сарьянның баш өянәге кебек хикмәте бар иде. Бакчада эшләгәндә башын ул һәрвакыт яулык белән тасмалап, кысып бәйләп йөри иде. Ләкин сәламәтлегеннән бер дә зарланмый иде алай.

1978 елның 21 сентябре көнне Хәсән Сарьян кинәттән генә вафат булды. Без аны бераз сибәләп-пыскаклап торган моңсу көндә җир куенына салдык. Үзе яраткан җир куенына...

Без — сугыш елларының ач-ялангач, ятим балалары — байтак каләмдәшләребезне шулай яшьли югалттык. Ләбиб Айтуганов, Тәүфикъ Камалиев, Газиз Мөхәммәтшин, Зиннур Насыйбуллин, Ренат Рәхимов, Егор Уткин, Мәсгут Шәрифуллин...

Белмим, кем ничектер, әмма мин үзем боларның барысын да үткән сугыш корбаннары дип саныйм. Сугыш кыравы суккан, ачылып өлгерә алмый калган чәчәкләр булдылар алар...

Миндә Хәсән Сарьянның җанлы тавышы язылган магнитофон тасмасы бар. Үзен сагынганда еш кына мин шул тасманы тыңлыйм. Сарьянның салмак тигез тавышы моң булып күңелгә инә. Сарьян дус инде менә ничәнче мәртәбә яңадан минем белән сөйләшә...

"Мин сүземне юкка гына туган җир дип башламадым, — ди ул. — Чөнки туган җирнең туфрак җылысын, үз халкының күкрәк җылысын йөрәк ите белән тоймаган шагыйрь минем йөрәгемә дә керә алмый, ана шулай ук башка халыклар күңеленә дә юллар ябык була. Үзеңнең туган җиреңнең, үз халкыңның син булмаганда кыен булачак бер күзәнәге булганда гына, син юлны башкаларга да киң ярырсың... Без — туган җиребез баласы бит!"

Туган жирендә туйганчы яши генә алмадың, Сарьян...

Ә синең яраткан Агыйделең һаман шулай ага да ага, ага да ага... Үз сүзләрең белән әйткәндә, ярлары да кеше гомере сыман, кителеп-кителеп кенә юыла тора, юыла тора...

Хәсән Сарьянның бакчасындагы имәннәре һаман шулай шаулап утыра. Таза имәннәрдәй буй җиткереп, үзләре әти булган өч улы — Рифкате, Булаты, Айраты гаиләләре белән бакчага килеп тулган көннәрдә имән төбендәге яшел "болын"да балалар чыр-чуы тынмый. "Болгар угланы Гәрәй бабай"дан соңгы унөченче-ундүртенче буын татар балаларының — Сарьян оныкларының куанычлы чыр-чулары бу. Аларда Хәсән Сарьян каны да ага — тормыш елгасы, Агыйдел кебек, һаман алга омтыла.

## ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

### Миргазиян Юныс

# АКЪӘБИНЕҢ КАБЕРЕ ЯНЫНДА

## 1

Катлаулы эш ул әдәби әсәргә бәя бирү. Бигрәк тә талантлы язылган әсәргә. Совет чорында, әдәбият белән обком җитәкчелек иткән чорда, язучыларны обоймага тыгып сөйләшү модага кереп киткән иде. Шул обойма ысулында фикерләүдән, язучының кайсы обоймага эләгүенә карап бәя бирүдән, без әле һаман арына алмыйча интегәбез. Дөрес, әдәбият белән партия җитәкчелек итүнең уңай яклары да булган икән. Моны без әле генә аңлый башладык. Шулай да совет чорының мирасы — күмәк аң, стереотип ысулында фикер йөртү, шаблон бәяләү — безне әле бик озак эзәрлекләп киләчәк...

Һаман шул балык башы... Әдәбият өлкәсенә кагылу белән, шәхеслек мәсьәләсенә килеп бәреләсең. Гадәттә, язучының әсәрен журналда басканда, аның фамилиясе янына әдипнең барлык чиннарын, алган бүләкләрен, ничә китап язуын тезеп китәләр. Дөрес, бу титулларның файдасы зурдыр. Китап чыгарганда, фатир алганда, нинди дә булса өстенлек яулаганда бик тә кирәк язучыларның махсус рәвештә эшләгән рейтинглары булуы. Ә менә китапны укыганда һәм аны укып чыкканнан соң бәя биргән чакта авторның кем икәнлеген алдан белү бары тик комачаулый гына.

Кайвакытта мин Тукаебызны да кызганып куям. Даһи дибез, татар халкының бөек шагыйре, аның горурлыгы, дибез. Аңа баш иябез һәм еш кына Тукайның нигә даһи икәнлеген, ни өчен аның иҗатта шулай югары күтәрелүен һич тә аңлый һәм аңлата алмыйбыз. Алай гына да түгел әле: кайберәүләр Тукайның даһи икәнлеген белү белән канәгатьләнеп, әсәрләрен укымаска да була дип ихлас күңелдән ышанып йөри.

Бер профессор белән Әмирхан Еники иҗаты турында әңгәмә корып утырабыз. Ул әдәбиятыбызның аксакалын күкләргә чөеп мактый.

— Әмирхан Еникинең иҗаты дөнья әдәбияты казанышларына тиң! — ди профессор. Ә мин исә:

— Дөнья әдәбиятында зур казанышларга ирешкән әдипләр буа буарлык. Шуларның конкрет кайсысына тиң? — дигән сорау куям.

— Син инде бәйләнмичә кала алмыйсың, — ди профессор. —Сине нәкъ шуңа күрә дә беркем яратмый. Әйттем бит, дөнья әдәбияты казанышларына тиң дип. Сиңа шул җитмимени?

Әйе, Әмирхан Еники безнең аксакалыбыз буларак, соңгы елларда хөрмәтне дә күрде, дан-шөһрәткә дә мохтаҗ булмады шикелле. Аңа багышлап язылган рецензияләр, алган бүләкләре дә, дәрәҗәләре дә, Аллага шөкер, җитәрлек тоела миңа. Шул ук вакытта күңелем сизә, барыбер, нидер җитенкерәми. Шушы исемне ишеткәндә мин үземне аның әсәрләренә карата бурычлы сизеп йөрим. Юк, аңа карата гына да түгел әле миндәге эчке киеренкелек. Әйтерсең, мин алган әҗәтемне кайтарып бирмәгәнмен һәм гөнаһлы рәвештә

бурычлы булып йөрим. Кемнәргә карата сизәм мин бу тойгыны? Илдар Юзеевкә, Роберт Әхмәтҗанга, Солтан Шәмсигә, Равил Рахманга, Зөлфәткә, Наис Гамбәргә, мәрхүм Мәҗит Рәфиковка, Фәрваз Миңнуллинга — тагын әллә кемнәргә карата үземне бурычлы итеп сизеп, оялып, уңайсызланып йөрим. Башкалар да тоямы икән менә бу уңайсызлыкны? Ә кемнедер күкләргә чөеп мактыйлар, асылда сукыр бер тиенлек мактар җире булмаса да. Кемнедер рәнҗетәләр, чынбарлыкта исә аның кылган гамәлләренә карап гел баш иеп, сокланып торырга тиеш булсак та. Менә шундый чакларда минем бәгъремне нәрсәдер тырный. Шундый вакытларда яшәү шул кадәр авыр, михнәтле тоела ки: нигә соң Газраил мине онытып йөри икән?.. дип уйлаган чакларым еш була.

Әйе, әдәби әсәрдәге казанышларны — хакыйкатьнең чагылышын, эчтәлек тирәнлеген, әдәби тәгаллекне фән һәм философия, социаль психология законнарына таянып анализлау урынына без тизрәк мактау куыклары очыра башлыйбыз. Ә бит иҗатның иң зур казанышы — тәгаллек. Тәгаллеккә ирешү өчен исә яшәешне белү, санап чыгу гына җитми. Тормышның газаплы вә куанычлы мизгелләре башта әдипнең үз язмышына сеңеп, әсәргә шуннан кайнап чыгарга тиешләр алар. Язучы яшәешне башта үзенә сеңдерә, ә аннары сурәтләү, сүз тылсымы, метафоралар аша ак кәгазьгә күчерә. Бүгенге көндә кешеләрнең бәгырьләрен нинди әшәкелек тырный? Аларның өмет-баглаnышлары кайсы тарафка юнәлтелгән? Адәм баласының иркен кем, нинди көч буа? Йөрәк җәрәхәтләренә кемнәр тоз сала? Язучының төп вазифасы шушы сорауларга җавап эзләүдән гыйбарәттер дип уйлыйм мин. Әмирхан аганың “болай язарга ярамый” дип сыкрануы да нәкъ шушы турыда иде.

## 2

Фатих ага Хөсни бер хатында: “Миргазиян, соңгы вакытта сине мактый башладылар. Сак бул, уяулыгыңны югалтма. Аңларга тырыш, кайсыдыр төркем сине үз обоймасына тыгарга җыена”, — дип язган иде. Дөрес, китап язу җаваплылыгын өстенә алган бәндә һәр очракта җылы сүзгә, танылуга сусап яши. Бигрәк тә укучы игътибарына, өлкән әдипләрнең җылы сүзләренә мохтаҗ ул кулына каләм алган бәндә. Чөнки Әдип, каләмен йөрәк канына манып, бәгырьләрен әрнеткән мәсьәләләрне ак кәгазьгә салып, укучыга сузды бит. Бу язма аның халыкка кайнар мөрәҗәгате бит! Туган халкын кисәтер, аны ялгыш юлдан барудан туктатыр өчен эшли ич ул бу эшне. Язучы җавап көтә. Юк, рәхмәт көтәргә тиеш түгел ул. Ул бит ялгышуны исбат итте. Бу гамәл өчен башыңнан сыйпамыйлар. Ул аны белә. Барыбер көтә ул җавапны. Ә җавап юк... Язучы шомлана башлый. Сабырлык бетә. Чын язучы белми, белсә аңламый — хакимият тирәсендә ялаnып йөрүче теге ялагайларның мактау сүзләрен һәм дәүләт бүләкләрен үзара оештырып, хәрәмләшеп алуларын аңламый ул. Түземе беткәч, ул рәнҗи башлый һәм — финал табигый... Әдип агулана. Талант никадәр көчле булса, әдипнең агулануы да шул дәрәҗәдә аяусыз була... Күпме талантларны харап иттек без әдип язмышын боз йөрәкле адәмнәр кулына тапшырып.

Бу турыда без мәрхүм Фәрваз Миннуллин белән серләшкән идек. Ике тапкыр Тукай бүләгенә тәкъдим итеп, Әмирхан Еникине ике тапкыр мыскыл итеп төшереп калдыргач, әдәбиятка хезмәт итүне изге эш санаучылар бик нык рәнҗеделәр. Ул рәнҗү шәхсән бер әдәбият түрәсенә юнәлтелгән иде. Аның исемен атап әйтәсем килми. Мин инде аның канына тозны аз салмадым. Шул серләшү вакытында Фәрваз миңа Әмирхан аганың иҗатына багышлап китап язарга җыенып йөрүе турында сөйләде һәм мине юатты: “Нәрсә ул аңа Тукай бүләге! Нинди генә ловкачта юк ул бүләк. Әмирхан Еникинең иҗатын яктырта алырлык фәнни эш кирәк”. Һәм Фәрваз әдипнең иҗатына багышлап китап язарга җыенып йөрүе турында сөйләде.

Әдәбият түрәләренең урынбасары булып эшләде Фәрваз Миңнуллин. Нәшриятта төпкә җигелеп сөйрәде бу авыр, тынгысыз, соңгы чиктә ләгънәтле

эшне. Көнкүреш чытырманлыгы, гаилә мәсьәләсе — яшәешнең нинди генә тармагында кыйналмады мәрхүм Фәрваз. Үз файдасын, үз җаен оештырырга, җайларга, умырырга никадәр тырышса да өйрәнә алмый иманлы кеше. Вөҗданлылык кирәгеннән артык көчле иде мәрхүмдә. Һәм ул китте... Аның күп, бик күп планнары калды. Өмет-багланышлары калды. Хыяллары калды. Өеп-өеп эшләгән игелекләре калды. Һәм шулар арасында — Әмирхан ага Еникинең иҗатына багышланган зур, ихласлыкка сугарылган китап язылмыйча калды.

Ул чакта Миннуллин тәрәзәләре бакчага караган иркен, мул һавалы, ике бүлмәле фатирда яши иде. Урамының исемен дә оныттым инде мин. Нәшрият йортыннан өскә таба җәяү менмәле иде. Ул фатирда башта Гомәр ага Бәширов, аннан соң Ләбибә Ихсанова яшәгән. Чиста, җыйнак яши иде Фәрваз шул ояда. Килү белән мина бер кочак китап бүләк итә. Зәвыклы, китапның җанын аңлый торган кеше сайлаган китапларны. Аннан соң өстәл янына утырабыз. Гади ризык. Татлы, туры авылдан килгән, кибет подвалларын күрмәгән ашамлыклар. Аракыдан түгел, сөйләшүдән исерәбез... Һәм шундый бер утыруда сөйләде Фәрваз аксакалның иҗатына багышланган китабының нинди авазда һәм нинди максатлар белән язылачагын. Талантлыны талантсыздан аера белмәү, бигрәк тә аерырга теләмәү — татар әдәбиятының иң зур фаҗигасы! Шушы фикердән башлады Фәрваз язылачак китабы турындагы сүзне һәм дәвам итте. Ни өчен талантны танырга теләмиләр? Чөнки танымау — урта кул иҗатчы өчен искиткеч файдалы. Урта кул, искиткеч оста итеп китап чыгара белә. Урта кул хакимияткә яраша, ялагайлана белә. Китап чыккач, үзенә мәдхия җырлата, реклама ясый белә. Урта кул урта кулны шундук танып ала. Алар үзара оеша беләләр. Оешу белән генә чикләнеп калмыйлар урта куллар. Алар бик оста җитәкчелекне үз кулларына ала беләләр. Талантлы язучы исә —ялгыз. Ярдәмсез! Ул мантый алмый. Талантлылар үзара оеша да белмиләр, аларга җитәкчелекне дә тапшырып булмый. Җитәкчелек итәргә — бигрәк тә, обкомга буйсынып эшләгәндә — яраша белү, ялагайлык күрсәтә белү дә кирәк. Талантлы язучы бит андый эшкә сәләтле булмый.

Мин бу турыда укучыга сөйләп аңлатам. Фәрваз исә шушы проблеманы язылачак китабының эчтәлеге белән, фәнни телдә әйткәндә, концептуаль яктан җиткерергә тиеш иде укучыга. Әле дә хәтеремдә, шул сөйләшүдә без урта кул язучы белән халтурщик арасындагы аерманы ачыкладык. Халтурщикны без рэкитер (ул чакта бу сүз әйләнешкә кермәгән иде әле) белән чагыштырдык, урта кулны — ришвәтче белән. Талап алучы ул тиз тотыла. Ришвәтче исә гомер буе тыныч кына кара эшен эшли бирә.

Фәрваз мәрхүмнең хыялы турында яздым да, уйга калдым. Бәлки ул китап басылып та чыккандыр? Аны мин генә күрми калганмындыр? Яисә китап урынына мәрхүм зур мәкалә белән генә чикләнгәндер?

## 3

Әмирхан Еникинең әсәрләрен мин күптән укыйм. Аның үзе белән танышу, аралашу һәм хат алыша башлауга да инде шактый еллар узды. Тәҗрибәле әдипнең фатихасын ишетеп тору иҗат эшендә зур терәк ул. Бигрәк тә Фатих Хөсни вафатыннан соң андый терәккә мохтаҗ идем мин. Ялгызлык газапларын язучыдан да ачы тойган башка кем бар бу дөньяда? Ул ялгызлык бигрәк тә кулыңа каләм алып ак кәгазь каршына утыргач тоела. Ак кәгазьдә — шундый пакьлек! Син шул аклыкка карадан билгеләр куя башларга тиеш. Пычранмасмы икән ак кәгазь? Куркыныч эш бит ул китап язу. Хакыйкать кыйбласын тотсаң, ялганчыларны рәнҗетәсең... Алар бит аз түгел. Ялганлый башласаң, дөреслектә яшәүчеләргә карата әшәкелек эшлисең. Китап язу бит ул үз иркеңнән башыңа бәла алу. Ут белән су арасында ялгыз калу шикелле... Тагын читкәрәк тайпылып алыйк әле...

Азатлык көрәшен башлап җибәрү белән латышлар, эстоннар, литвалылар үзара сүз куешкандай дәррәү урыслар белән үз туган телләрендә сөйләшә

башладылар. Гаҗәп көчле психологик шом салды бу тактика колонизаторларның йөрәкләренә! Алар кинәт югалып калдылар һәм зарлана башладылар. Безгә дә мөмкин иде бит бу ысулны куллану. Үзара туган телдә сөйләшеп йөрү, "өлкән агай"ларга да үз телебездә дәшү татарның әле исән, манкортлашып бетмәгәнлеген белгертер иде һәм алар безнең белән исәпләшми булдыра алмаслар иде.

## 4

"Әйтелмәгән васыять"не минем әдипнең "аккош җыры" (лебединая песня) дип атыйсым килми. "Соңгы китап" дигән китап язылган булса да Әмирхан агада татар халкының бүгенге хәлен укучы күңеленә җиткерерлек әсәр иҗат итәрдәй җегәр бар әле. Дөрес, зур, көчле әсәр язар өчен андый әсәргә теше үтәрлек укучының булуы да шарт. Тоташтан диярлек телевидение карауга күнегеп беткән укучыга Лев Толстой "Сугыш һәм тынычлык" эпопеясен бүләк итә алмас иде. Чөнки чын язучы белән урта кул арасындагы аерма шуннан гыйбарәт: чын язучы әсәр язганда укучы белән туктаусыз серләшә, бәхәсләшә, аңа үзенең рәнҗүләрен әйтеп зарлана, хәтта аны сүккәләп тә ала. Ә урта кулга җинелерәк, аңа түрәләрнең нәрсә теләгәннәрен белү җитә.

Гаҗәпләнерлек хәл бит бу. Минем бер әшнәм, обком ишегенең кайсы якка ачылганын белгәннән соң, үзенең элекеге темаларын ташлап, гел алдынгы колхоз председательләре, "даһи" обком секретарьләре турында гына язарга тотынды. Әмирхан Еники дә "Табиевның фатихасыннан" соң "Әйтелмәгән васыять"не язарга тиеш түгел иде. Әмма сирәк булса да очрый икән андый хәлләр дә. Татар әдәбиятында мондый хәлнең булганын хәтерләмим мин. Гаяз Исхакый мисалын китерсәк кенә инде? Ә менә әдәбиятыбызның горурлыгы — Галимҗан Ибраһимов — большевиклар белән әшнәләшкәннән соң революциягә кадәр язылган әсәрләрен җентекләп "эшкәртеп" чыккан.

Ниһаять, "Әйтелмәгән васыять"кә да килеп җиттек. Бәлки бу повесть турында фәнни анализлар бардыр? Әдәбият белгечләренең, язучыларның бу әсәр турында язганнарын бик күп укысам да минем очратканым юк. Мөхәммәт Мәһдиев, мәсәлән, Әмирхан Еникинең әсәрләрен "моңсу" дип атый. Чыннан да, моңсулык татарга гына диярлек хас сыйфат ул. Һәм шуны да онытмаска кирәк: Казан ханлыгын канга батырып ташлаганга кадәр татарлар моңсулыкны белмәгәннәр. Шул тарихи фаҗигадан соң барлыкка килгән моңсу мескенлек, моңсу томаналык, моңсу беркатлылык, моңсу күңел сукырлыгы — дистәләгән моңсу сыйфатлар...

"Әйтелмәгән васыять" 37 китап битенә сыеп беткән. Кыска повесть. Кайбер язучыларның хикәяләре бу әсәрдән ике-өч тапкыр зурырак була. Сюжет — максимум гади. Акъәби далада тизәк җыеп йөргәндә, үзенең авыру икәнлеген сизеп ала. Кайтып ята. Урыныннан торып йөри алмый башлагач, күрше хатыны карчыкны бераз карап тора. Ниһаять, кортканың авырып китүе турында аның балаларына хәбәр итәләр. Уфадан Акъәбинең кызы белән кияве килеп алып китәләр. Карчык анда айдан артык авырып ята. Ниһаять, әҗәленә атна-ун көн кала, балалары авыруны больницага салалар. Карчык үлә. Аны күмәләр. Күрше хатын авылдан Акъәбинең сандыгы белән әйберләрен җибәрә. Карчыкның балалары, кияве, килене, оныгы шул әйберләрне нишләтергә, кая куярга белмичә аптырашта калалар. Ниһаять, ул милли кием-салымны, ритуал бизәнү әсбапларын театрга илтеп тапшыру...

Әйе, гап-гади кебек. Әсәр 1965 елны язылган. Татарстан җиреннән елына йөз миллион тонна нефть талап алынган, шул нефтьне валютага сатып, валюта акчасына танклар, туплар, Калашников автоматлары ясап, шуларны җир шарының төрле төбәкләренә кан коярга озатып торган чор. Язучылар берлеге конвейрларыннан бер-бер артлы кирпеч-кирпеч романнар, производство эпопеяләре агылып чыгып торган чор. Кәҗә асраудан, тавык тотудан, тизәк җыюдан башканы белмәгән надан карчык турында әсәр язган Әмирхан Еники. Әллә тилеме икән ул? Нефть турында, КамАЗ төзүчеләр турындагы темаларга

атланган язучыларның романнарыннан бермә-бер кыска повесть язган әдипкә талант булмаса, бу әсәр турында сүз кузгатып торуның кирәге дә калмас иде. Әгәр әсәрдә гаҗәп серле — юк, серле генә түгел, тылсымлы символлар булмаса, аны анализлап вакыт үткәрүнең кирәге дә булмас иде.

Әсәрдә башкортлар турында сүз бара. Акъәбинең килене Мария Васильевна һәм дүрт оныктан тыш барлык персонажлар — башкортлар. Ә без шул башкортка багышланган әсәрне, нигә үзебезнеке итеп кабул итәбез? Шушы сорауга җавап тапмыйча үтеп китү — әсәрнең төп идеясен аңламау дигән сүз.

Акъәбинең киявен автор "Чакмагыш башкорты" дип атый. Бармы башкортлар Чакмагышта? Әсәр башкортлашу чорында язылган. Бусы бер. Икенчедән, чын татарлык, иң борынгы, иң асыл гореф-гадәтләр нәкъ шул башкорт төбәкләрендә сакланып калган. Казан губернасына күз салып алыгыз әле, хөрмәтле укучы. Патша заманында Казан губернасы Каспий диңгезе аша Иран белән чикләшкән булган. Ким дигәндә өч йөз чакрым Каспий ярлары һәм Гурьев каласы Казан губернасыныкы булган. Аңлашыламы?

Вакыйгаларның Башкортстан җирендә баруы да очраклы түгел. Явыз Иван фаҗигасыннан соң яулап алучыларга ярашу, тез чүгү исән калуның төп шарты итеп куелгач, баш бирергә теләмәүчеләр көньяк-көнбатышка таба кача башлыйлар. Казан тирәсендә калучыларга яшәү искиткеч авыр була һәм исән калу өчен колониаль сәясәтнең диспетчер пунктына әверелгән Казанга, Казан арты төбәге ярашырга мәҗбүр була.

Менә мин "Әйтелмәгән васыять"тәге символлар турында язам. Ничек аңлатыйм икән? Сүз көче, аның бөек тылсымы, колачлар житмәс тәэсире беткәнлектән, әйтәсе сүзне, тапшырасы фикерне дәвам итәргә теләгәндә тешең-тырнагың белән ябышасың символга. Ябышасың һәм очып барган самолетның коерыгына тотынгандай ычкынып та китәсең... күп, бик күп кирәк символ тудырыр өчен! Талант кирәк иң беренче чиратта! Зур, бик тә зур тәҗрибә кирәк һәм бар көченне, кырып, себереп, сыгып чыгарып эшләү кирәк. Һәм тагын ни кирәк? Билгеле, символ тудыра алу бәхетенә ирешә алу кирәк. Эзләп карагыз әле безнең чорда язылган әдәби әсәрләрдән чын символны... Арзанлы ливер колбасасы ясаган шикелле күзгә ни күренсә шуны ак кәгазьгә тутырып язылган натурализм әсәрләреннән табарга тырышып карагыз әле символларны? "Әйтелмәгән васыять" кай чакларда миңа тоташ символлардан торган шикелле тоелып китә.

Бер символ — шагыйрь. Әсәрдә ул аҗаган шикелле ике генә урында күзгә чагылып югала: мәҗлесне ташлап Акъәби янына кереп сөйләшеп чыкканда һәм карчыкны җирләгәндә. Шул ук вакытта, повестьның подтекстында ул синең күңеленә кереп оялап, әсәрнең башыннан ахырына кадәр даими катнашып бара. Алай гына да түгел, шагыйрь — әсәрнең төп герое, аның доминантасы. Ә автор үзе персонажларның барысына да тигез карый. Тәҗрибәле язучы белә: әсәрдәге геройларның берсен яратуыңны, икенчесен, киресенчә, күрә алмавыңны яшерүе шактый кыен. Әмирхан Еники, чыннан да, персонажларның берсен дә мактамый, хурламый, аларның игелекләренә сокланып мәлҗерәп тә төшми. Әсәрдә бердәнбер бәя бирүче — шагыйрь. Бусы тышкы яктан. Эчке, спонтан яктан шагыйрь — әсәрнең вөҗданы, аның пәйгамбәре һәм казые. Әгәр шушы персонажны алып ташласаң, әсәр күзгә күренеп ярлыланыр иде.

Бары тик төрки халыкларга гына хас, Шәрык ысулларындагы тагын бер символ. Мең яшәгән Локман Хәкимне хәтерләткән Миңлебай карт та әсәрнең башында күзгә чагылып кына китә дә, финалда нәкъ Хозыр-Ильяс кыяфәтендә кабат пәйда булып:

— ... Аккилен кайтмадымы әле? — дип сорый күрше хатыны Гарифәдән.

— Куй, Миңлебай бабай, үлгән кеше кайтамыни, ничек телең барып сорый, — дип ачулана Гарифә.

— Алдама, — ди ул таягының башын селкеп. — Аккилен үлмәде ул, китте генә... Китте генә... Кайтыр, насыйп булса, кайтыр... Ә син учагын карый тор, учагын... Учагында ут сүнмәсен..."

Гаҗәп тирән кинаяле, көчле символика кереп оялаган әсәр эченә. Әгәр шул символ-криптограммаларны чишә башласаң, печтек кенә повесть зур бер роман-эпопеягә әйләнеп куя. Автор юри шулай мистик ысулда язганмы соң әллә бу әсәрне? Юк, билгеле. Төгәллек үзенең иң биек ноктасында үзеннән-үзе символга әверелә. Билгеле, монда әйтелмәгән сүз (подтекст), авторның әсәрдәге вакыйгаларга, коллизиягә карата уянган тойгылары, тәңречелек чорларында ук татар табигатенә, аның милли рухына сеңеп калган күңел көче — барысы, бәйнә-бәйнә, повестьның тукымасына сеңеп, аны цементлаштырып барган. Вакыйгасына, персонажның табигатенә, аның үзенчәлегенә абсолют тәңгәл килгән сүзне эзләп табу таланты, сүзләр арасындагы ятышлылык, әсәр моны — санап бетерерлекмени соң әсәрдәге әдәби сыйфатны, янгыраншы, сүз тылсымын көчәйтүче сыйфатларны.

Кабат символикага, минем сөекле аргамагыма, атланыйк әле. "... Дала буйлап кылганнар йөгерә, кылганнар йөгерә", — дип башланып китә "Әйтелмәгән высыять" һәм финалда шушы увертюра җөмлә кабат әйләнеп килеп, бөҗра ясый да, "... куыша-куыша йөгергән кылганнар арасыннан, озын карагай таягын җир үлчәгәндәй алга ташлап" килгән Миңлебай карттан болай әйттерә: "Кайтыр, насыйп булса, кайтыр... Ә син учагын карый тор, учагын... Учагында ут сүнмәсен." Ничек аңларга бу символны?

Кылганнар йөгерүе — безнең ерак кыпчак, болгар, нугай, бәҗәнәк һәм башка күп төрле исемнәргә бүленгән, асылда исә бербөтен, төрки бабаларыбызның ирекле киңлектә яшәүләре. Миңлебай бабай исә, шул ерак бабаларыбыздан килгән илче, безне Акъәби яшәеше, аның васыяте белән тоташтыручы үлмәс көч, арадашчы. "Учагында ут сүнмәсен" — бусы инде әле бүгенге көнгә кадәр безнең аңыбызга, иманыбызга кереп урнаша, күңелебезне кузгатып, өмет-багланышлыбызны бер кыйблага туплый алмаган милләт җаны.

Шушы кечкенә генә повестька сыйган символларның барысын да ача, аңлата башласаң озакка китәр иде. Әнә бит, автор үзе дә шагыйрь аркылы Акъәбинең кем икәнлеген укучыга аңлаттыра. "Башкорт (автор бу исемне биредә милләт исеме итеп кенә алмаган) халкының изге җанлы анасы", — дип символны ача Шагыйрь Акъәбинең кабере өстендә. — Әмма нәрсә беләбез без аның хакында?" "... Сез нәрсә әйтә аласыз гомере буе сезнең өчен өзелеп яшәгән әсәегез турында?" Бу сүзләр Акъәби балаларының бирчәеп беткән иманнарына кислота сипкәндәй тәэсир итә. Алар бер генә мизгелгә булса да айныгандай итеп: "Безобразие бу!" — дип Шагыйрьгә ташланалар.

"Колхоз машинасына салып җибәрелгән карчыкның иске яшел сандыгы" да тирән мәгънәле символ. Сандыктан да борынгы, аннан да милли нинди йорт җиһазы бар? Ул бит моннан ничә мең еллар элек уйлап чыгарылып, күчмә чорлардан бирле безнең әби-бабаларыбызның даими юлдашы булып, шкаф, карават, урындык, өстәл — шуларның барысы урынына кулланылып киленгән. Сандык эчендәге әйберләргә килсәк, алары да — милли символлар. Халкыбызның борынгы сәнгать өлгеләре тупланган сандык эченә. Сәнгать кенә дә түгел, ритуаллар эченә кереп эрегән бәйрәм шатлыклары, һөнәрне сәнгать таләпләренә җиткереп камилләштерү, эстетик кануннар — кыскасы, яшәешне бизәп, тормышка ямь, җан кертеп, балкытып торучы көнкүреш җиһазлары алар. Авторның үзенә сүз бирик:

## 5

"Барысы да җыелып беткәч, сандыкны идән уртасына куеп ачтылар. Ачып җибәрүгә, алар өстә генә яткан ак бәз кәфенлекне күрделәр. Һәм, күреп, берәр сүз әйтү түгел, бер-берсенә күтәрелеп карарга да ничектер кыймадылар, ак материяне тик сак кына бер читкә алып куйдылар. Аннары бөкләп салган кием-салымнарны чыгарырга тотындылар. Менә әсәйләренең тәңкәле җиләне, читләренә ука тоткан сары хәтфә камзулы, алтынга манган тәңкәле һәм төрле ташлар тагылган бөяте (хәситәсе), вак мәрҗәннән эшләнгән кашмавы белән белән чәчкабы, беләзек, муенса, чулпылары, кыз чагында үз

кулы белән чүпләп суккан кызыл башлы сөлгеләре килеп чыкты. Шулай ук аталарының кызыл сәдәпле кара кәзәкие белән камчат бүреге дә килеп чыкты — карчык шушы көнгә кадәр аларны да саклап торган икән, бичара... Актарына торгач тагын бер хикмәтле әйбер табылды: бу аталарының яшь чагында тотып йөргән кыска саплы, күн чуклы, өч җәпле, һәр җәбенең очына көмеш пластинка бөкләп кидерелгән бик шәп камчысы иде".

Әсәрдә пейзажга, тормыш агымына, персонажларны сурәтләүгә шул кадәр урын тар, сүз гаҗәеп саран тотылган. Әсәрдә сандык эчендәге әйберләрне теркәүгә Әмирхан Еники, ничек әйтим, мин хәтта татарча сүз дә таба алмыйм, урысча әйткәндә скрупулезная дотошность белән туккән. Этнографка, милли көнкүренеш, милли бизәнү сәнгате әсбапларын өйрәнүче галимгә берниндн белешмә карап азапланасы да юк. Әллә кайсы ерак, чал гасырлардан килгән төркиләрнең, шулар арасында татар-башкортның сәнгатен яктырта, бәяли алырлык әйберләр теркәлгән бу исемлеккә! Һәм мәсьәләне искиткеч төгәл, дөрес аңлаучы, дөрес бәяләүче белгеч төзегән әле бу исемлекне! Автор бу әйберләрне юкка гына Акъәбидән җыйдыртып, аның килен булып төшкәндә алынган сандыгына тутыртмаган. Бу да — символ! Гасырларны һәм төркиләрнең Гоби чүленнән алып Карпат тауларына кадәр җәелгән яшәешләрен күп гасырларны үзара теркәп, тоташтырып торучы, аларның зәвыкларын, рухи байлыкларын раслаучы документаль хәзинәне саклаучы һәм аларны киләчәк буыннарга тапшырырга тиешле илче дә булган икән ләбаса Акъәби. Балалары аны шушы бөек вазифаны үтәүдән мәхрүм иттеләр. Нинди юл белән? "Ахырда, уйлаша торгач, башта Суфиян, аннары Гөлбикә дә яшел сандыктан чыккан бөтен кием-салымнарны театрга илтеп тапшырырга риза булдылар", — дип аңлата автор. Ә кәфенлекне нишләттеләр? Бу турыда мәгълүмат юк. Автор тими бу чиктән тыш катлаулы проблемага. Хәл итүне укучының үз карамагында калдыра. Һәм дөрес эшли.

Урыслашуның да бер чиге бар. Исән чагында милләткә каршы әллә нинди әшәкелекләр эшләп йөрсә дә, татар кешесе, үлгәч, барыбер урыс зиратына кереп ятарга теләми. Чөнки ул мәңгелек каршында кинәт югалып кала, соңгы адымны атларга аның тәвәккәллеге дә, көче дә җитми. Мәңгелеккә бары тик милли ритуаллар аша, ата-бабадан калган гореф-гадәтләр ярдәмендә генә тоташып була икән. Якты дөнья белән саубуллашканда менә шушы хакыйкать адәм баласының күзен ача. Чыннан да бит: тереләр мәетнең күзен ябалар, мәет исә, шушы мизгелдә тереләрнең күзләрен ачарга мәҗбүр итә. Биредә дә газиз балалары үз әниләрен мәңгелек белән тоташудан мәхрүм итүләрен кәфенлекне күргәч кенә аңлый алдылар. Шуңа күрә алар "хәтта бер-берсенә күтәрелеп карарга да ничектер кыймадылар..."

Акъәбидән калган милли мирастан тулысынча баш тартмыйлар балалары. Алар үзләренә кирәкне сайлап кына алалар. "Хикмәтле камчы шунда ук барысын да кызыксындырды", — дип аңлата автор.

— Да-а, менә бу ичмасам реликвия! — диде кияве дә сокланып. — Тик кем саклар аны?

— Аның хуҗасы бар, — диде Суфиян катгый рәвештә һәм улы Геннадийга борылып, тантаналы итеп әйтте: — Мә, улым Гена, ал бабаңнан калган чуклы камчыны... Белеп тор, Шәяхметовлар кулында йөргән камчы булыр бу..." Күрдегезме хакимият символы — камчының кем кулына күчүен?

Гореф-гадәтләр, йолалар, рухият, сәнгать һәм мәдәният символларын совет чорындагы урыслашу тулысынча юкка чыгарса да, власть, хакимлек, көч һәм буйсындыру символы булган камчыны күрү белән ул аны үзенеке итә. Аңа шундук хуҗа да табыла. Власть, буйсындыру инде тулысынча урыска әйләнгән, маржадан туган Акъәбинең оныгы Геннадий кулында булырга тиеш. Хакыйкать мизгеле бу. Драманың кульминация ноктасы...

Тагын бер әйбергә хуҗа табыла. "Гөлбикә шулай да әсәенең төсе итеп, уртасына кызыл якут куеп, саф көмештән челтәрләп эшләнгән ике зур чулпыны үзенә алып калды". Чулпы саф көмештән, борынгы көмештән эшләнгән, шуңа күрә, бусы —байлык. Димәк, байлык символы да власть символы белән берләшеп манкортлашкан буынга күчте. Шушы ике нәрсәдән баш тартмадылар.

Баш тартмадылар гына түгел, Рәсәйнең данлыкны музейларын карагыз. Эрмитаж, Оружейная палата, Тарих музейлары Казан ханлыгын җимереп канга батырып ташлаганнан соң урыс империясе кулына эләккән алтын-көмеш асыл ташлар, мәнлелек белән бәхәсләшеп эшләнгән даһи бизәнү әсбаплары белән тулы. Аларның Казан ханлыгыннан, Бөек Болгардан, Хаҗитарханнан, Кырымнан, Себер ханлыгыннан, яисә Хазарстаннан икәнлеген сез калган гомерегезне фида итеп эзләсәгез дә таба алмаячаксыз. Хәзинәләрнең нинди юл белән музейга килеп эләгүләре, нәкъ безнең ерак бабаларыбыз кушкан тау, елга, үзәнлекләрнең исемнәре алыштырылган шикелле, җентекләп, гаҗәеп оста оятсызлык белән алыштырылган. Әнә, урысның бөеклек һәм даһилек символы Монамах бүреге Үзбәк ханның сеңелесе Кончакның Мәскәүгә киеп килгән бүреге булып чыкты бит тикшерә башлагач. Андыйлар күп, биниһая күп! Без хәтта бабаларыбызның археологик казулар вакытында җыелган матди һәм шаһиди истәлекләрен дә үзебезнеке икәнлеген анлый алмыйча томаналанып йөрибез. "Ананьев культурасы" дип атала Идел болгарларының ата-бабалары калдырган мираслар... Шәһри Болгарның үзен Спас исеме белән каплап бастырып куйганнар... Биләр исә Куйбышев исеменең астында калган... Менә шушындый аянычлы югалу — юкка чыгуларның ничек барлыкка килүләренең беренче этабын "Әйтелмәгән васыять"тә Дәүләкән морзасы гаҗәп төгәл, истә калырлык, үзен татар-башкорт санаган кешене тетрәндерерлек рәвештә күрсәтә һәм дәлилли алган.

Әсәрдә бирелгән манкортлашу процессының һәр детален сөйли башласак, язма бик озынга китәр иде. Ике генә мисалга тукталып китик. Акъәбинең улы Суфиян марҗага өйләнә. Оныклар инде йөз процент урыс! Тамырларында яртылаш башкорт каны агуга карамастан. Өлкән оныгы әбисе әле Юлкотлыда чагында өч көнгә кунакка килә. Ләкин ара бикле! Әби белән онык арасына тимер пәрдә корылган. Чөнки әби бер кәлимә сүз урысча белми, онык — башкортча. Бетте элемтә. Аралашу тәмам. Аңлашу да бетте. Арада бушлык. Уфада әбисен күрергә башка оныклары: Татьяна, Светлана, Рита, Борис та килә. Авторның үзеннән әйттерик аларның очрашу мизгелен: "Кызлар әбиләрен сырып алдылар, шаулап: "Здравствуйте, дорогая бабушка, — дип күрештеләр..." һәм "дорогая бабушка"га жирафка, яисә гиппопотамга караган шикелле карап тора башладылар. Телсезлек. Ул гына да түгел. Оныклар белән әби бер-берсенә тоташа, бер-берсе белән элемтәгә керә алмый торган ике ят, үзара ялгана алмый торган вакуум, упкын бүлде аларны. Хәтта Акъәбинең улы марҗага өйләнмәгән булса да аерма әллә ни зур булмас иде. Автор искиткеч төгәл психологик дәлилләү белән Суфиянның солдофонлашуын күрсәтә. Аның инде баш миендә ике сыр — буйсыну һәм буйсындыру, күңелендә ике хис — урыс коралының бөек көче белән горурлану, шушы горурлыкка каршы чыгучыларга гайрәтле нәфрәт кенә калган. Учакта ут сүнеп бара...

Кызы Гөлбикә ягыннан ассимиляция процессы ничек тамыр җибәргән? Гөлбикә нечкә күңелле, әнисен ихлас ярата, ихтирам итә торган хатын. Әмма ул әнисеннән читләшкән, үзе читләшүен тоймаса да. Автор аның Акъәбидән читләшүен махсус яшермәгән. Кире сыйфатлар да такмаган Әмирхан Еники Акъәбинең кызына да, киявенә дә. Автор тасвирлавында менә аларның әдәби сурәтләре: "Машинадан җәйге габардин пальто, күк эшләпә кигән зур, таза гәүдәле бер ир белән ефәк плащ кигән, зәңгәр косынка бәйләгән озын буйлы ябык кына бер хатын чыктылар". Бәлки бүгенге укучыга бу атрибутлар таныш та түгелдер? Габардин пальто, күк эшләпә киеп йөрүче таза гәүдәле ирләр, әгәр шуңа "Волга"га утырып килүләрен дә өстәсәк — обком номенклатурасы иде инде. Миңа, мәсәлән, бу ирле-хатынлы кешенең кем икәнлекләрен аңлатыр өчен өстәмә сүз түгел, өстәмә хәреф тә кирәкми.

Гөлбикәнең ире — үз милләттәше, башкорт бит. Бәлки аңа ассимиляцияләшү мәҗбүр түгелдер? Юк шул. Әгәр син номенклатур "бәхет"кә ирешә алдың икән: "Рус түгелмен, ләкин россиян мин" дияргә тиешсең! Юл бары тик бер һәм катгый. Башка юл юк. Или — или... Дөрес, сине беркем үгетләми, куркытмый. Әгәр "Волга"га утырып йөрисең, өеңдә җыештыручы тотасың, рәхәт яшисең килә икән — телисеңме-юкмы, үзеңнән-үзең күчәсең син өлкән

абзыкайлар ягына. Күчәсең һәм бетте китте! Синең кабинетың, "Т" хәрефе рәвешендәге өстәлең, ниһаять, "зур йорт"ның һавасы ук мәҗбүр итә ассимиляциягә. Әнә бит, карчыкның тиз арада өзлегәсе ачыклангач — әгәр Акъәби өебездә үлсә, мөселманча күмәргә, мулла чакырырга кирәк булачак дип куркып — аны тиз генә больницага илтеп тыгалар. Кияве шундый карарга килгәч, Гөлбикә аңа каршы төшә алмый. Хәтта карчыкның малае, отставкада булуына карамастан, карчыкны үз өендә җан бирдертәсе килми. Полковник бит... Отставкада булса да... Марҗа хатыны алдында, урыслашкан балалары алдында да әллә ничек — батмый бу эш...

Автор Акъәбинең читкә киткән кече улы һәм өлкән кызы барлыгын әйтеп кенә үтә. Алар китеп югалганнар. Әниләре белән элемтә өзелгән. Туганнары белән дә аралашып яшәмиләр алар. Урыста ифрат тәңгәл сүз бар бу хәлне аңлатыр өчен: "отрезанная ломоть..." Бәгырьләрне әрнеткән шул ике баланы күрәсе килү газабын Акъәби үзе белән гүргә алып китә. Һәм, минемчә, аларны шушылай күрсәтү — авторның зур уңышы.

## 6

1991 елда Әмирхан Еникинең өч томлык сайланма әсәрләре чыккач, гадәттәгечә, һәр өч китапның эчтәлекләрен карап чыктым. Кабат укыйсым килеп китте. Бу юлы кычкырып укыдым һәм сүзләрнең яңгырашыннан мелодиягә якын бер тезмә барлыкка килде. Аннан соң кычкырып укымыйча гына һәр әсәр исеменең эчке мәгънәсен үзләштереп утырдым. Безнең татар халкы соңгы ярты гасырда башыннан кичергән вакыйгаларның эчке-рухи кичереш тезмәсе итеп кабул иттем мин бу исемнәрне: "Уяну". "Саз чәчәге". "Йөрәк сере". "Рәшә". "Әйтелмәгән васыять". "Вөҗдан". "Без дә солдатлар идек"... . "Гөләндәм туташ хатирәсе". "Бала". "Ана һәм кыз". "Ялгыз каз". "Мәк чәчәге". "Кунакчыл дошман". "Икенче көнне". "Тауларга карап". "Бөке". "Кем җырлады?". "Ялгызлык". "Туган туфрак". "Шаяру". "Яшьлек хатасы".

## 7

"Әйтелмәгән васыять"нең татар әдәбиятына булган тәэсирен сизмичә калу мөмкин түгел. Бүгенге көндә аларны онытып торсак та, татар әдәбиятына яңа көчләр, бүгенге таләпләрне күтәрерлек, әдәбият куйган шартларны үтәрлек талантлар килде. Зөлфәт Хәкимнең һәм Фәнзаман Батталның иҗатына күз салып карагыз. Аларның сурәтләү ысуллары, метафоралары, күтәрелгән тематикалары тышкы яктан гына Әмирхан Еникинекеннән үзгә шикелле тоела. Тирәнтенрәк анализ ясый башласаң, болар "Әйтелмәгән васыять"тә куелган проблемаларны чишүне дәвам итә.

Татар язучылары арасында камил иҗат культурасы, профессиональ яктан әзерлекле язучы Солтан Шәмсинең иҗатын тикшереп, аңа бәя бирер вакыт та җитте шикелле. Тарих өлкәсендә моңа кадәр Солтан шикелле вакыйгаларның татар ягын да, урыс ягын да шул дәрәҗәдә җентекләп, ышанычлы чыганакларга таянып язган әдип бар идеме әле? Аннан соң Солтан Шәмси иҗатында мин моңа кадәр татарда кулланылмаган диярлек инструментның — тарих фәлсәфәсен (историясофия) эшкә җигелүен күреп шатланам. Солтан Шәмсинең иҗатында да нәкъ Әмирхан Еники күтәргән проблема беренче урында кала килә.

Айдар Хәлимнең соңгы елларда проза, публицистика, шигърият өлкәсендә искиткеч уңышлы эшләвенә күз йомарга тырышсак та, аның иҗатын урап үтү мөмкин түгел. Дөрес, Айдарның алымы, аның сурәтләве, метафоралары Әмирхан Еникинекенә капма-каршы диярлек. Ә тема шул ук. Без аны, ни кадәр тырышсак та инкяр итә алмыйбыз.

Шагыйрь Зөлфәтнең соңгы елларда матбугатта күренгән публицистикасы турында язганны очратмадым мин. Аның һәр әйткән сүзе лазер чаткысы шикелле гайрәтле, нәтиҗәле. Зөлфәтне дә мин "Әйтелмәгән васыять" кузгаткан

темада эшләүчеләр рәтенә куяр идем. Һәм шушы көнгә кадәр тәнкыйтьтән җылы сүзне чиктән тыш аз ишеткән талант иясе Роберт Әхмәтҗанны. Аның шигырьләрен күрү белән минем җаным сыкрый башлый, аның бер әсәренең ("Төнге кошлар") исеме искә төшә.

Безнең әдәбиятыбызда бер якты йолдыз шундый күркәм булып кабынып китте дә, үзенең кыска гомере эчендә, җуелмас эз калдырып сүнде. Фәиз Зөлкарнәй турында сүз бара. Мин телгә алган талантлар нәкъ шушы шәхес тирәсендә туплана башлаганнар иде. Изге урын буш булмый диләр урыслар. Әдәбиятның рәсми җитәкчеләре танырга теләмәгән талантларны бәлки киләчәктә Равил Рахмани үз канаты астына сыендыра алыр? "Әйтелмәгән васыять" ачкан юлны һаман киңәйтеп, һаман шул кыйблага карап баручы Гамил Афзалны оныту зур гөнаһ булыр иде. Мин инде Зөлфәтне, Роберт Әхмәтҗанны бүгенге көндә татар шигъриятенең җанын (бәлки вөҗданын да) тәшкил иткән төркемнән аерып алдым. Мөдәррис Әгъләмов турында еш искә алалар, ә менә шул йолдызлыктагы Наис Гамбәрне күп очракта оныталар. Розалина Шаһиева да шул якты йолдызлар белән бер йолдызлыкта яна дип уйлыйм мин һәм сизенәм: мин аларның күбесен төшереп калдырдым, рәнҗемәсеннәр иде. Чыннан да бездә шигърият шул кадәр тәэсирле, татар шагыйрьләре турында уйлаганда горурлык уяна.

Хәзер инде шушы сөйләшүгә кыска гына йомгак ясыйк та, тәмамлыйк. Әйе, совет чорында әдипләр ач яшәмәделәр. Кайсылары? Хезмәт ияләренең йөк аты аты шикелле көне-төне бил бөгүчеләргә, шәрә күкрәк белән амбразура каплаучыларга мәдхия җырлаучы әдипләргә җил-яңгыр тигермәделәр. Урыс әдәбияты инде ул чорны онытты диярлек. Түшләрен тутырып лауреат билгеләре, алтын йолдыз тагып йөрүчеләр инде күптән отставкада. Ә бездә? Казанда яшәүче татар язучылары бүгенге әдәбият вазгыятен миннән яхшырак беләләр. Шулар әйтсен татар әдәбиятының нинди хәлдә икәнлеген. Мин аңлыйм, бу язмадагы әрнүле сүзләрем чынбарлыкны үзгәртә дә, әдәбиятыбызга ярдәм дә итә алмаслар. Шулай да аңларга тырышып карыйк әле. Кат-кат, туктаусыз тырышып карыйк.

Бүгенге көн ни өчен шулай катлаулы? Чөнки коммунистик пропаганда адәм баласының кулы, аның аттан да талымсыз эшләве турында гына язарга рөхсәт итте. Адәм баласының кайгы-хәсрәтләре, милләтнең язмышы, инкыйраз турында язу — бу тыелган тема иде. Нәкъ әнә шул җан әрнеткеч хәлләр — милләт язмышы турында Әмирхан Еники "Әтелмәгән васыять"ендә язып чыкты. Бу теманың әле һаман көн тәртибеннән төшкәне юк. Чөнки татарның рухи тормышында экологик афәт. Бу хакта халык аңына бары тик әдәбият кына җиткерә ала. Чөнки әдәби әсәр тарихны, бүгенгелекне, киләчәкне бергә тоташтырып, ялган белән хакыйкать арасындагы яшеренеп торган эзне күрсәтә.

*Әлмәт. 1998 ел,апрель*

*Әдәбият тарихына*

# АЛТЫН УРДА ӘДӘБИЯТЫ

## Мәхәббәтнамә

Хәрезем төбәге монгол яуларына кадәр дә, аннан соң яңа оешкан Алтын Урда дәүләтенең бер өлешенә әверелгәч тә, үз вакыты өчен бай матди һәм мәдәни үзәкләрнең берсеннән санала. XIY йөз уртасында әнә шул җирлектә "Мәхәббәтнамә" поэмасы иҗат ителә. Әсәрнең язылу урыны турында текстның үзендә үк мондый мәгълүмат китерелә:

"Мәхәббәтнамә" сүзен монда беттем,
Камугын Сыр йакасында бөтедем.

Шулай ук анда ядкярнең тәмамлану вакыты да күрсәтелгән:

Бу дәфтәр кем, булыбтыр Мисыр канды,
Йете йөз илле түрт ичрә төкәнде.

Аңлашылганча, поэма миляди хисап белән 1353 елда тәгаълләнгән. Шуңа күрә, академик В. В. Бартольд билгеләгәнчә, "Мәхәббәтнамә" әлеге дәүләттә барлыкка килгән иң әүвәлге төрки язма истәлекләрнең берсеннән санала.

Авторның асыл исеме мәгълүм түгел. Текстта ул үзен Хәрәзми дигән нисби тәхәллүс белән белдерә:

Укыгыл "Фатиха", дор кыйбла йани,
Сөенсен бәндә Хәрәзми рәвани.

Мәгълүм булганча, Хәрәзми псевдонимы Хөҗәндинең "Ләтафатнамә"сендә ("Матурлык турында китап", XY) дә телгә алына. Сәйф Сараиның "Гөлестан бит-төрки"сендәге бер газәл дә шулай ук Хәрәзми дигән кеше тарафыннан язылган. Үз вакытында Алтын Урдада күчерелү ихтималы зур булган "Нәһҗел-фәрадис"ның Истанбул нөсхәсе ниндидер Хәрәзми исемле автор яшәгән чорда башкарылган. Әлеге фактларга нигезләнеп, Ә. Н. Нәҗип "Мәхәббәтнамә"не дә шул бер үк шагыйрь язмадымы икән дигән фикер үткәрә.

Танылган тюрколог текстагы "Сөенсен бәндә Хәрәзми рәвани" дигән мисрагка таянып һәм урта гасырда Рәвани тәхәллүсенең киң таралыш алганлыгын истә тотып, "Мәхәббәтнамә" авторының тулы псевдонимы Хәрәзми-Рәвани шәкелендә булу ихтималын белдерә. Ул үзенең хезмәтендә әсәрнең урыс теленә тәрҗемәсендә аны шулай күрсәтә дә. Әмма поэманы урыс теленә әдәби эшкәртеп чыгарган А. Старостин китапның кереш өлешендә әлеге мәсьәләгә игътибар итеп Ә. Н. Нәҗипнең фикерен шик астына ала.

Әсәрнең текстыннан аңлашылганча, шагыйрь электә фарсы телендәге шигырьләре белән дә билгеле булган:

Күңел бәхрендә күб гәүһәрләрең бар,
Дөньяда фарсы дәфтәрләрең бар.

А. М. Щербак әсәрнең шигырь төзелешенә һәм кайбер формаль моментларга игътибар итеп, Хәрәзми үз иҗаты өчен ниндидер фарси оригиналдан файдаланган булу ихтималын искәртә. Шуңа күрә ул әлеге текстны Хуҗа Гыймадеддин Фәкыйһ Кирмәни тарафыннан язылган һәм хәзерге вакытта Ташкенттагы Шәрекъне өйрәнү институты фондында саклана торган "Мәхәббәтнамә" белән чагыштырып тикшерергә тәкъдим итә.

Тексттан күренгәнчә, Хәрәзми үзенең әсәрен Мөхәммәдхуҗа бәк дигән шәхескә багышлаган һәм аңа шактый гына бәетләр юллаган. Әмма “Мәхәббәтнамә”дән башка чыганакларда ул зат турында мәгълүмат юк. Шулай да аның житәкче даирәдән икәнлегенә һәм әдәби мохитка якын булганлыгына ышанмау мөмкин түгел.

Поэмада бер генә урында булса да Алтын Урда ханы Җанибәк (1341 — 1357 еллар) тә телгә алына. Ә әсәр язылган жирлекнең, ягъни Ак Урданың (1226 — 1406 еллар) шул вакыттагы идарәчесе Чимтайның (1344 — 1361 еллар) исеме искә алынмавы мантыйк буенча бераз серлерәк тоела.

Академик В. В. Бартольд 1914 елда Англиягә гыйльми сәфәргә баргач, Лондондагы Британия музеенда әсәрнең 7914 сан белән теркәлгән күчермәсе белән таныша һәм бу турыда ул шул ук елның 23 сентябрендә Император Фәннәр академиясенең тарих һәм филология бүлегендә чыгыш ясый. Галим әлеге нөсхәнең фотокүчермәсен дә алдырткан. Ул күбәйтелеп, хәзерге вакытта Россия фәннәр академиясенең Тел институты һәм Көнчыгышны өйрәнү институты фондларында саклана.

В. В. Бартольдның әлеге хәбәре турында 1915 елда “Шура” журналы да язып чыга. Анда “Мәхәббәтнамә” Алтын Урданың мәдәни тарихын өйрәнү өчен бик әһәмиятле булачагы әйтелә һәм, мөмкин булса, мәйданга чыксын иде дигән теләк белдерелә.

Танылган Шәрекъ белгече 1922 — 1923 елларда Лондонга икенче тапкыр баргач, шул ук музейда 8193 сан белән билгеләнгән бер жыентыкта әсәрнең уйгыр хәрефләрендәге янә бер күчермәсе белән таныша. Ул аның хакында 1924 елның 27 февралендә шул ук тарих һәм филология бүлегендә доклад сөйли.

Текстның азагындагы язмалардан аңлашылганча, әлеге нөсхә әсәрнең күчермәләре арасында иң әүвәлгеләреннән санала. Аны һиҗри 835 (1432) елда рәҗәб ае башында Йәзд шәһәрендә Мир Җәлаледдин дигән идарәче боерыгы буенча Мансур исемле кеше күчергән.

“Мәхәббәтнамә”нең гарәп хәрефләрендәге ике күчермәсе Истанбулның Милли китапханәсендә саклана. А. М. Щербак Истанбул университеты китапханәсендә шул исемдә бер кульязма барлыгын, әмма аның алдагы күчермәләр белән бернинди дә уртаклыгы юклыгын хәбәр итә.

“Мәхәббәтнамә”не өйрәнү тарихына килгәндә, В. В. Бартольдтан соң 1928 елда уйгыр хәрефләрендәге текстны ориенталист Г. Клаусон бастырып чыгара.

1957-1958 елларда Шәрекъ белгече иранлы Т. Гәнжи гарәп һәм уйгыр графикасындагы текстларның тәнкыйди текстын төзеп бастыра. Ә 1959 елда галим әлеге әсәрнең сүзлеген дә нәшер итә.

Поэманың уйгыр хәрефләре белән язылган варианты А. М. Щербак тарафыннан да өйрәнелә. Ул бай шәрехләр белән текстның транскрипциясен һәм урыс теленә тәрҗемәсен эшләп бастыра. Галим үзе тикшергән нөсхә буенча фикер йөртеп, әсәрнең теле турында кызыклы гына нәтиҗә ясый. Аерым алганда, ул текстта угыз элементларының өстенлек итүен билгели һәм шуның нигезендә төрле диалектлардан торган Алтын Урда әдәби теленең ике төре турында сүз алып барырга мөмкинлеген раслый. Тел белгече шулай ук угыз элементларының күчерүче тарафыннан гына да кертелгән булу ихтималын искәртә.

Әлеге китап үз вакытында гыйльми җәмәгатьчелектә уңай бәяләмә алган.

Ә. Н. Нәҗип әсәрнең гарәп хәрефләрендә башкарылган текстын өйрәнеп, 1961 елда аның факсимилесен, бай аңлатмалар белән транскрипциясен һәм урыс теленә тәрҗемәсен бастырып чыгарган. Галим үзенең тикшеренүләре нәтиҗәсендә әсәр кыпчак-угыз катнаш телдә язылган дигән фикергә килә. Танылган тел белгеченең әлеге хезмәте тәнкыйтьтә шулай ук уңай бәяләмәгә лаек булган.

Тюрколог 1973 елда “Мәхәббәтнамә” турында үзенең янә кызыклы тикшеренүләрен бастырып чыгара. Ул анда әсәрнең Лондонда һәм Истанбулда саклана торган текстларын үзара чагыштырып өйрәнә.

Дөрес, поэманың теле турында төрле фикерләр күптәннән килә. 1918 елда төрек галиме М. Ф. Күпрелезадә үзенең бер хезмәтендә әсәр чыгътайча язылган дип билгели. Ә А. Н. Самойлович аның әлеге нәтиҗәсе белән килешми, “Мәхәббәтнамә” Алтын Урда һәм аның бер төбәге булган Хәрәземдәге жирле

диалектларны чагылдырган әдәби телдә иҗат ителгәнлеген исбатлаучы ядкяр итеп карый.

"Мәхәббәтнамә"нең тулы тексты Т. Җәлалов тарафыннан гамәлдәге үзбәк графикасында башкарылып, 1959 елда Ташкентта нәшер ителә. Үз вакытында тиешле бәяләмә алган һәм әсәрнең яңа гыйльми басмасын әзерләүгә этәргеч дип табылган әлеге китап Хәрәзми һәм аның иҗатына багышланган хезмәтләрдә, нишләптер, сирәк телгә алына.

Поэманың кайбер өлешләре Вл. Державин тәрҗемәсендә 1950 елда урыс телендә дөнья күргән "Үзбәк поэзиясе антологиясе"нә кертелгән. Ә 1961 елда шагыйрь А. Старостин поэманы урыс теленә әдәби эшкәртеп, аны бай кереш һәм аңлатмалар белән бастырып чыгара.

Әсәрнең кыскартылган өлеше 1987 елда Ташкентта нәшер ителгән "Мөбарәк мәктүпләр" дигән китапта да урын алган.

Ә. Н. Нәҗип хәбәр иткәнчә, 1971 елда Истанбул университеты доценты Г. Серткая Төркиядә табылган гарәп хәрефләрендәге ике нөсхәнең текстларын кыскача аңлатма белән "Төркия мәҗмугасе"нең унҗиденче томында бастырып чыгарган.

"Мәхәббәтнамә" әдәбият ядкяре буларак та, аның тел үзенчәлекләре дә Урта Азия галимнәре М. Н. Хыдыров, С. Касыймов, И. И. Фазыйлов, Т. Нәфәсов, Н. М. Маллаев, Х. Җ. Сөеншәлиев, А. Кыраубаева, Б. Сыгындыков, М. Юлдашбәков тарафыннан билгеле бер дәрәҗәдә өйрәнелгән.

Татар әдәбияты тарихында да, тел гыйлемендә дә әлеге әсәр үзенең тиешле урынын ала бара. Г. Рәхим һәм Г. Газиз тарафыннан 1926 елда дөнья күргән мәгълүм хезмәттә Хәрәзми иҗаты турында берникадәр мәгълүмат бирелгән. Үз вакытында Н. Хәким ядкяргә грамматик анализ ясап, аның сүзлеген төзегән булган. Ләкин ул хезмәт нәшер ителми кала.

Профессор В. Х. Хаков әсәрнең тел-стиль үзенчәлекләрен тикшерүгә сизелерлек өлеш кертте.

1963 елда басылып чыккан "Борынгы татар әдәбияты"нда "Мәхәббәтнамә" турында белешмә бирелеп, кыскартылган тексты урнаштырылган. Ә "Татар әдәбияты тарихы"ның беренче томында әлеге язма истәлеккә күләмле мәкалә багышланган. "Татар поэзиясе антология"ндә әсәрдән үрнәкләр урнаштырылган.

Әдәбият галиме Х. Госман үзенең "Борынгы төрки һәм татар әдәбиятының чыганаклары" дигән хезмәтендә Хәрәзми турында белешмә биреп, аның иҗатыннан өзекләр урнаштырган. Ул янә төрки шигырь төзелешенең төп кагыйдәләреннән тайпылышлар барлыгын билгели. Профессор моны шагыйрь нигездә башка әсәрләрен фарсы телендә язу сәбәпле, аның иҗади фикерләвендә шул әдәбият кануннары өстенлек алуы һәм аларның төрки әсәргә дә көчүе белән аңлата.

Хәрәзминең әсәре башка төрки халыкларның әдипләре, хосусан Хөҗәнди, Сәед Әхмәд һ. б. иҗатына йогынты ясаган кебек, татар шагыйрьләренә дә билгеле бер дәрәҗәдә тәэсир иткән. Аерым алганда, ул Мөхәммәдьяр, Г. Кандалый, Дәрдеманд поэмаларында һәм шигырьләрендә ачык чагылыш тапкан.

Тупланган тәҗрибәгә нигезләнеп, "Мәхәббәтнамә"нең текстын гамәлдәге татар хәрефләренә күчереп һәм тиешле аңлатмалар белән шәрехләп, аны киң җәмәгатьчелеккә җиткерү күптән өлгергән мәсьәләләрнең берсе.

## Җөмҗөмә солтан

Көнчыгышта һәм Көнбатышта Кисек баш, Ку баш, җан белән тән бәхәсе турындагы риваятьләр элек-электән билгеле. Шәрекътә әлеге сюжетны башлап шигырь юлларына салучының исеме фарсы әдәбияты классигы Фәридеддин Гаттарга нисбәт ителә.

Фарси текст әүвәл 1862 елда Тәһранда нәшер ителә. Танылган ориенталист В. Д. Жуковский бу басма һәм Санкт-Петербург җәмәгатьчелек китапханәсе фондында саклана торган Гаттар көллияте арасындагы 1612 елга караган бер күчермә нигезендә 1893 елда әсәрнең текстын урысча тәрҗемәсе белән бастырып чыгара. Әмма профессор Г. Т. Таһирҗанов үзенең кайбер текстологик эш нәтиҗәләренә таянып, әсәрнең авторы икенче бер Гаттар исемле кеше булу ихтималын белдерә.

XIY йөзнең икенче яртысында Идел буе шагыйре Хисам Кятиб шул ук мәгълүм сюжетка "Җөмҗөмә солтан" дигән дидактик эчтәлекле поэма иҗат итә. В. Д. Жуковский билгеләгәнчә, төрки автор үзенең әсәрен фарсы чыганагыннан турыдан-туры тәрҗемә итү юлы белән башкармаган. Киресенчә, риваятьнең төрле вариантлары тәэсирендә мөселманлык рухы белән нык өретелгән куләме, аерым мөстәкыйль әсәр барлыкка китергән. Күренекле Шәрекъ белгече Е. Э. Бертельс үзенең бер хезмәтендә әлеге очракта тәрҗемә турында сүз алып бару мөмкин түгеллеген раслый.

"Җөмҗемә солтан"ның бер кулъязмасы үз вакытында Кырым ханы Сәхиб Гәрәйнең китапханәсендә дә булган. 1932 елда шул нөсхәдән госманлы теленә тәрҗемә ясалган.

1910 елда Казанда "Кыйссаи Җөмҗөмә" дигән китап нәшер ителә. Аның текстында берникадәр казакъ теле элементлары да чагылыш тапкан.

"Кыйссаи Җөмҗөмә"нең текстында аны кем язганлыгы, хезмәтнең кайчан башкарылуы турында мәгълүмат китерелми. Бары тик шул ук китаптагы янә "Кыйссаи Карун дию" дип аталган икенче әсәрдәге беренче бәеттә теркәлгән Мәүлекәй исеменнән чыгып, аның авторы татар укымышлысы Мәүлекәй Йомачиков булганлыгын белергә мөмкин. Әлеге фикер башка кайбер чыганакларда да очрый.

Әлеге басма әсәрне Хисам Кятиб, Гаттарның шул исемдәге әсәрләре белән чагыштырып тикшергәндә бәлки кызыклы гына нәтиҗәләр ясап булыр иде.

Хисам Кятибнең поэмасы беренче тапкыр типография ысулы белән 1881 елда Казанда университет табыгханәсендә нәшер ителә. Аннан соң текстның берникадәр кыскартылган өлеше 1963 елда дөнья күргән "Борынгы татар әдәбияты" дигән китапта урнаштырылган. Профессор Х. Госман татар әдәбияты тарихыннан студент-ларга практик дәресләр өчен уку материалы сыйфатында поэманың тулы җыйнама текстын төзи. Бай кереш һәм аңлатмалар белән тулыландырылган әлеге китап 1970 елда Казан университетының офсет лабораториясендә бастырыла. Галим әлеге әсәр турында үзенең "Борынгы төрки һәм татар әдәбиятының чыганаклары" дигән икенче хезмәтендә дә кыскача мәгълүмат биргән. "Татар әдәбияты тарихы"ның 1984 елда нәшер ителгән беренче томында ядкяр турында киң сөйләнелә. Ә "Татар поэзиясе антологиясе"ндә текстның кыскартылган варианты урын алган.

Шунысы да мәгълүм булсын, ядкяр татар әдәбияты һәм теле тарихын өйрәнүдә генә түгел, ә урта гасыр татар социаль-фәлсәфи фикере тарихын тикшеренүләрдә дә чыганакларның берсеннән санала.

Әсәрне үз вакытында танылган әдәбиятчы Җ. Алмаз хәзерге әдәби телгә тәрҗемә иткән булган. Галимнең бу зур хезмәте белән укучылар бары тик 1996 елда гына таныша алдылар. Аны М. И. Әхмәтҗанов "Әдәби мирас"ның өченче китабында бастырып чыгарды.

Хисам Кятибнең поэмасы урта гасыр чоры һәм аннан соңгы дәвер татар шагыйрьләренең әдәби эшчәнлеге өчен билгеле бер дәрәҗәдә өлге булып хезмәт иткән. Мәсәлән, әсәрдәге кайбер алымнарның Габделҗәббар Кандалый шигырьләрендә очравы моны ачык раслый.

Авторның шәхесе турында тулы мәгълүмат сакланмаган. Бары тик әсәрнең текстында гына аңа нисбәтле зур булмаган белешмә китерелә:

Кем тарих йете йөз йетмеш иде,
Хисам Кятиб боны йазмыш иде.

Бу да әле шагыйрьнең чын исеменә тәңгәл килмичә, аның тәхәллүсе генә булуы мөмкин. Поэманың нинди шартларда иҗат ителүе дә тәгаен билгеле түгел.

Тексттан күренгәнчә, Хисам Кятиб үз чорының укымышлысы, фикер иясе булганлыгы аңлашыла. Әсәрнең поэтик үзенчәлекләре исә авторның туган тел байлыкларыннан оста файдалана белүен дәлилли.

"Җөмҗөмә солтан" әсәренең моңа кадәр табылган барлык күчермәләрен туплап, аларны фәнни нигездә текстологик яктан эшкәртеп тәнкыйди текстын төзеп, аны аңлатмалар һәм шәрехләр белән тулыландырып яңадан нәшер итү — хәзерге чор әдәбият һәм тел галимнәренең бурычы булып тора.

**Рәмил ИСЛАМОВ,**
филология фәннәре кандидаты.

# "ХАКИМ ВӘ ХӨР ГАКЫЛ БАР ДИП..."

КЕМ УЛ ШИҺАБЕТДИН МӘРҖАНИ?
МӘГЪРИФӘТЧЕ ГЕНӘМЕ, ӘЛЛӘ?..

Бөек галимебез Ш. Мәрҗани конференциясендә Мәскәүдән килгән кунагыбыз В.Ф. Пустарнаков шомлы хәбәр ишеттерде. Көнбатышта милләте буенча немец булган галим Михаил Кемпер бер китабында: "Мәрҗанидә фәнни мәгърифәтчелек юк, ул, баштан азаккача традиционалист" (димәк, урта гасырчылым чикләрендә кала. — М.Г.) дип язып чыккан икән. Мәскәү институтында да: "Ш. Мәрҗанинең менә бу фикерләрендә кайдан мәгърифәтчелек табасыз?" — дип, килешергә теләмәүчеләр бар икән дә, бу иптәш аларга, Ф. Энгельсның "күп укладлылык" теориясенә таянып: "Ул чор татар җәмгыяте үтә катлаулы, күп укладлы. Ш. Мәрҗани мәгърифәтчелегендә башка юнәлеш төсмерләре активлыгы — шул күп укладлылыкның укмашып яшәве тудырган катлаулылык, бер сызыклылыктан ераклык чагылышы", — дип аңлатма бирә, имеш. Бу да, үз исеме белән әйткәндә: "Мәрҗани язмалары күп төрле иген оныннан буташтырылган боламык" дип раслауга бәрабәр. Тегесе дә, бусы да чынлыкка туры килми. Шул рәвешле Ш. Мәрҗани һаман чын фәнни бәяләмәләрдән еракта, читтә кала.

Югыйсә бит йөз ел инде менә татар иҗтимагый фикере соңгы заман тарихында "Мәрҗани" дигән бу күренеш-феноменның асыл мәгънәсен аңларга тырышып мәш килә. Юбилейлары елларында бу эш аеруча давыллангалап ала. Һәм нәкъ шул юбилей елларында без үзебезнең аны аңлаудан һаман әле читтәрәк йөргәнебезне аеруча калку күрсәтәбез. Бу күренеш серен чишеп ат казану дәрте юбилейларда "масса күләм" "ил кизүенә" әйләнә, кайчандыр нәкъ шул дәрт "Мәрҗани мөҗмугасы" (1915) кебек хезмәтне мәйданга китергән. Һәр нинди чын (җанлы) дәртне, күптән инде "төтен җибәрү" — күз буяу белән генә алыштыруга күнектерелгән безнең заманда, "дәрт"сез дә бу "ил кизүе" аеруча бер "монументаль" төскә керде. Чөнки уйлап, баш авырттырып торасы юк ич. Юбилей көннәренә лаякатьле рәвештә, "тисә — тиенгә, тимәсә — ботакка" мантыйгына нигезләнеп, купшы мактау сүзләрен, бер-берең белән узышып, сиптерәсең. Шушы очракта гына юбилей шаулы, тантаналы, яңгыраулы, "фикри эзләнүләр югарылыгында" үткәндәй күренәчәк. Тантаналар узгач, проблеманың шул ук, элеккеге сызыгында торганы ачыклана икән, бәйрәмнән соң инде моның әһәмияте юк... Менә шулай, без һаман — Мәрҗанидән еракта эзләнәбез. Мәрҗани исә, тарихыбызда — үз билгеләмәсен, асыл урынын таба алмаган хәлдә кала. Купшы мактаулар — ясалма, шартлы күпертүләребез аңа сылана алмый, Мәрҗани аны күтәрә алмый. Чөнки моны — ялганны —ул йөкли алмый.

Ш. Мәрҗани халкыбызның бөек акыл иясе, — үз акыл көче белән зур нәтиҗәләргә ирешкән кеше, — мөҗәддите *, мөҗтәһиде! ** Бу сыйфатларны бер сүз белән генә әйтеп бирә торган аталма-терминнар телебездә юк. Ул үзе дә үзендә "хаким, хөр гакыл бар"лыгына ихлас күңелдән ышанган. Халкын да, үз тормышы мисалында дәлилләп, шуңа ышандыра, шул юлга күндерә алган. Бездә шул акыл иясенең укымышлы, галим "мәгърифәтче" булуы гына игътибар үзәгенә куела, ("тисә тиенгә"нең фикер уклары шул якка гына атыла). Асылда, бу "акыл иясе" булуның күренү (яшәү) мәйданы булган, аны шәхес буларак бербөтен тәшкил итүче тагын ике кыры, ике сыйфаты-мөҗтәһидлеге һәм мөҗәддидлеге — күзгә күренми кала. Шушы сыйфатлардан башка гына Шиһабетдин Мәрҗанине галим итеп кенә күрсәтү бәхәсле, купшы сүзгә әйләнә. Мәгърифәтче! Чын дөресен әйткәндә, кайда аның мәгърифәтчелеге? Без күзалларга теләгән мәгънәдәге олуг гыйльме? Гарәп телендә, тулысынча диярлек дини мәүзугларда гына язылган аның гыйльми әсәрләрен кемнәр генә күздән кичергән дә, кемнәр генә аннан файдалана алган?

* Мөҗәддит — янартучы, яналык кертүче.

** Мөҗтәһиде — тырышучы, тырышлык күрсәтүче; дин китаплары буенча яңа хөкемнәр чыгаручы.

Аларның — ул әсәрләрнең йөкләмәсе үтә конкрет һәм бөтенләй башка якка каратылган ич. Алардан мәгърифәтчелек эзләү — мылтык угыннан дары эзләү кебек бер нәрсә. Әйе, "дары" (мәгърифәтчелек) аларны — "укларны" аткан, аларны (сугышчанлык белән) кыздырган, аларны асыл максатка төбәүгә, уңышлы нәтиҗәгә ирешү мөмкинлегенә бердәнбер чара булган. Әмма моннан без расларга теләгән "дары — шул мылтык угы" дигән нәтиҗә чыкмый.)

Әйе, мөҗәддит — яңартучы дигән сүз; яңартучы-реформатор. Әмма Ш.Мәрҗани һич нинди реформа үткәрмәгән. Муллалыгы — гадәти муллалык. Мәдрәсәсе — гадәти мәдрәсә. Шуларны да "реформаламаган". Китаплары да — үтә традицион, дини... Әмма ул барыбер "мөҗәддит" булган, татар тормышындагы яңару хәрәкәтенә башланып китәрлек, көчле импульсны ул биргән. Юнәлешен — тәртибен ул билгеләгән. Ул кузгаткан юнәлештәге бу яңару хәрәкәте халкыбыз тормышында — җәдитчелек дип аталган. Шушы мәгънәдә ул мөҗәддит булган. Әмма Ш. Мәрҗанине хәзер без күз аллаган мәгънәдәге революционер итеп күз алдына китерә алмыйбыз. Ул кузгаланчы түгел, ә бәлки халкы карашын-фикерен, холык-фигылен, эшчәнлеген яңа кагыйдәләргә нигезләү хәрәкәтен башлап, кузгатып җибәрүче — ягъни мөҗтәһид.

Күз алдына китерик. XIX йөз. Тарих тирән үзгәрешләр чорына аяк баса. Башлыча, табигать белән алыш-бирешкә нигезләнгән, кешене, шәхесне шул мөнәсәбәтләр кагыйдәсе буенча яшәргә күнектергән элеккеге яшәеш яшәү көчен — алда калыккан һәр мәсьәләне аңлап чишү өчен сәләт-мөмкинлекләрен, кодрәтлелеген җуя бара. Шул сәбәпле, элеккечә яшәү — юкка чыгу юлына әйләнә бара. Гүя кешенең шәхесе юкка чыга; ул —гавамга, аңсыз төркемгә, үзен җитәкләүче көтүчегә мохтаҗ ике аяклылар көтүенә әйләнә бара. Хакыйкать кыйбланы дөм кара сөрем баскан мондый чорларда, чынлыкта, үз карыны, үз кесәсе турында уйлаудан башка импульсы калмаган "шома егетләр", төркем башына чыгып (ил җилкәсенә атланып), караңгылыктан файдаланып, үз кесәләрен калынайтып калырга мәш киләләр. Иң зур мәгънәсезлек (абсолют максатсызлык — чын кыйбласызлык) дәвернең иң "социаль актив" көченә әйләнә. Мәшһүр Г. Тукай мәгълүм шигырендә "имам койрык булган чак", "койрык — бойрык булган чак" дип, бу "яңаруны" бик дөрес билгели. Менә шундый шартларда халкында — "татарда да гыйрфан (аң) уты кабынуны" чагылдырып, Ш. Мәрҗани мәйданга чыга. Шул иҗтимагый җирлектә туган һәм шәхес буларак формалашкан Ш. Мәрҗани гомер юлын яңа шартлардагы һәлакәтле каршылыкларга каршы кискен конфликтта, намуслы көрәштә яшәп үтә алган. Ш. Мәрҗани бу көрәшне, бу конфликтны — чорының төп каршылыкларын фәнни-теоретик-фәлсәфи һәм иҗтимагый-практик планда дөрес юнәлештә чишү юлын билгеләгән һәм үз эшчәнлегендә шуның юлын күрсәтү югарылыгына ирешкән. Ил, халык язмышы зур куркыныч астында калган һәлакәтле чорда үз язмышыңны тарих, тәрәккыять көрәшенә әйләндерә алу, бу — кешелек тормышында иң югары дәрәҗәдәге чын батырлык. Ш.Мәрҗани әнә шул, батырлык юлына баскан. Бу батырлык юлына ул — инерция көче —башланган халык хәрәкәте, агымы, басымы астында чыкмаган, үзе эз салучы буларак юл ярган. Гыйлыме түгел, эшчәнлегенең әнә шул үзенчәлеге аны күренекле замандашлары арасында да аерым урынга чыгара, шуннан соңгы һәрбер буыннар алдында да остаз, юлбашчы булып күренеклек дәрәҗәгә күтәрә. Ул — тарихта сирәк очрый торган, яшьлек көннәреннән, бер олуг максат юлында ялгышусыз, таю-тайпылусыз атлый белгән камил шәхес. Ш. Мәрҗани сабыйлык көннәреннән үк, чорының дини-традицион белем-гыйлемен бар тулылыгында үзләштерү юлына баса. Уку елларының соңгы баскычына җиткәнче бу юлда ару-ялыгуны, чикләнү-тыелуны белми. Киресенчә, һәрчак бу гыйлемнең һичнинди мәктәп программаларына кертелми торган тирәнлекләренә, ерак катламнарына җитәргә тырыша. Тирәнгәрәк киткән саен, беренче чиратта, ул бу белемне шул көнге татар иҗтимагый тормышының актуальләшә барган сискәндергеч проблемаларын чишү юлында файдалану турында күбрәк уйлана. Шул рәвешчә, аның үзләштергән гыйлеме вакыт агышына "койрык булып" яшәүгә йөз тоткан күпчелек муллалар белеменнән башка юлга, башка максатка, башкарак кыйблага йөз тота. Үзләштергән гыйлеменең күләме, яисә нииндидер абстракт үткәнлеге белән түгел, нәкъ әнә шул яңа кыйблалыгы, яңа максатка юнәлтелгәнлеге, ул максатның чор таләбенә тәңгәл килүе — тарихи-фәлсәфи актуальлеге белән ул

башкалардан аерыла. Замандашлары әйтүенә караганда, Бохарадан укуын тәмамлап кайтканда ул инде Казанның иң мәшһүр мөдәррисен "Мулла Мөхәммәткәримнен үзен үк ел укытырлык" белемгә ия була. Ин гаҗәбе анын шундый зур, тирән белемле булуында түгел, ә менә нәрсәдә: — шул гадәттән тыш зур догматик гыйлем аны җанлы тормыш алдында "китап корты" — китап Мәҗнүне итеп кенә калдыра алмаган. Ул үзенең бу белемен хөрмәт итә, аңа ихлас ышану белән ышана. Шул ук вакытта аны схоластикадан, җансыз догматиклыктан (тәп үзенчәлегеннән) арындырып, тормышны гармонияле, нык, тотрыклы кагыйдәле бер хәлгә китерү чарасына әйләндерү турында уйлана һәм тарих күләм, галәм күләм эшчәнлектә теоретик нигез итеп файдалану мөмкинлекләрен эзләү эшенә алына.

Бохарадан укуын тәмамлап кайткач та, аны Казанның беренче мәчетенә имамлыкка чакыралар. Имамлыкка — муллалык вазыйфаларын үтәүгә керешкән атнасында ук, ул мөдәррислек-педагоглык эшчәнлеген башлап җибәрә. Тагын шундый ук хәл: мәдрәсәсендә дә ул берниндн, күзгә бәрелерлек үзгәртү-яңалык кертми кебек. Гүя традицион белемнәрне үзләштерү генә, ничектер, интенсивлаштырылган... Шул ук вакытта, үзенең үрнәге — яшәеш ритмы, омтылыш, максат, яңа идеаллары белән ул шәкертләрен яңа типтагы кадрлар итеп тәрбияли. Аларны яңа, иң заманави яшәештән читләшмәскә, киресенчә, аның үзәгендә иң актив яшәеш белән яшәргә омтылырга өйрәтә, тәрәккыятьтән, прогресстан качмаска, аны якларга, көчәйтергә тырышырга юнәлеш бирә. Шул юл белән халкыныңалдынгы кешесе — хезмәтчесе, көрәшчесе итеп тәрбияли. Үзен өйрәнергә алынган белемне тулырак, төгәлрәк үзләштерергә булыша. Болар иң гадәти, стандарт таләпләр кебек. Әмма яңа идеалга буйсындырганда, алар яңа кеше тәрбияләү чарасына әйләнәләр. Мәрҗани шәкертләре арасыннан Мәрҗанилар җитешеп чыкмасалар да, аларның һәммәсе массакүләм рәвешкә керә башлаган яңару хәрәкәтенең — җәдитчелекнең алгы сафына басканнар, яңа типтагы кешеләр булганнар. Шуңа күрә, аларга охшатып, хәтта барлык җәдитләрне — "Мәрҗани шәкертләре" дип атый торган булганнар.

Яшьлек елларыннан ук Ш. Мәрҗани каләм иясе галим буларак таныла. Башлангыч хезмәт елларында, 1853 елда ук, анын беренче китабы басылып та чыга. Шуннан соң да күп китаплар язган. Басылганнары да аз түгел. каләм көчен ул, тулысынча диярлек, торгынлык көчләренә — "койрык булган" хәлдә җәмгыятьнең "бойрык" хезмәтләренә үз монополияләрен урнаштырырга мәш килгән "укымышлыларга ("койрык" муллаларга) каршы көрәшкә карата. "Мостафад" кебек тарихи хезмәтен хәтта ул күбрәк шул көрәш материалларына нигезли. Галимнең шундый хезмәтләрен автор иҗатындагы фәнни-теоретик тикшеренүләр итеп кенә өйрәнергә тырышуларын бүгенге фәннең уңышлы адымы дип атап булмый. Эшчәнлегенең нәкъ шул юнәлешендә Ш. Мәрҗани (яңалыкны яклаганы хәлдә, яңару максатлары ягына йөз тотып), оппонентлары белән бер сызыкта торып, алар файдаланган материал җирлегендә, аларга аңлаешлы телдә генә көрәшә-бәхәсләшә. Менә шунда инде ул үзенең традицион белемне шундый тырышып үзләштерүен үтә нәтиҗәле, оператив файдалануга ирешә. Оппонентларын ул үз мәйданнарында, үз кораллары, үз алымнары чикләрендә, сыеныр урын калдырмый пешекли. Торгынлык ныгытмаларын аның түрендә торып пыр туздыра. Мәрҗанинең шул югары квалификацияле "туздыруыннан" — (киләчәккә җир, туфрак әзерләвеннән) башка бездә дә яңару, җәдитчелекнең тамырлануы, нәтиҗәлелеге шул чордагы Казакъстан, Төркестан кардәшләребез чикләрендә генә калыр иде. Революциядән соңгы мәхшәрдә ул кардәшләргә бирелгән хокуклары булмаганы хәлдә, халкыбызга андый сүлпәнлек үтә һәлакәтле нәтиҗә күрсәткән булыр иде. Ш. Мәрҗанинын бу эшчәнлегенә күз сала, аны тәкъдир итә алганыбыз юк әле. Анын бу эшчәнлегендә — "мәгърифәтчелек", хезмәтендә нинди дер абстрак фәнни-теоретик казанышлар (анда булмаска тиешле нәрсәләрне) эзләүдән арыга үтә алмыйбыз. Ш. Мәрҗанинең иң зур гыйльми-теоретик казанышы татар мәгърифәтчелеге принципларын заманча, фәнни тәгърифләүдә — фәнни-теоретик системага салуында түгел, ә бәлки татар җәмәгатьчелеген яңартуның югары нәтиҗәле (димәк, фәнни тотрыклы) яңа стратегиясен, яңа, заманча методологиясен мәйданга куюында; үз эшчәнлеге мисалында, аның үтемле, тәэсирле өлгесен җанландыруында. Заман агышына якынлаштыру юнәлешендә шул чор татар тормышына тәэсир итүнең ул оптималь юлын тапкан, сайлаган. Тарих халкыбызга анын тәкъдиме белән тартыша алырлык

башкарак берәр альтернатив вариант тәкъдим итмәгән; башка ниндидер тәкъдим җитлегерлек шарт табылмаган, булмаган. Татар тарихы — яңаруның Мәрҗани тәкъдим иткән юлы белән киткән. Ш. Мәрҗани тәгълиматы, беренче чиратта, татар халкының яңару — заман агышына якынаю стратегиясе ул; яшәеш темпын, ориентирларын һәм доминантларын төптән яңартуның татар тормышына яраклаштырылган методологиясе. Русия коллыгындагы татар тарихының синтезы һәм сөземтәсе. Ул — тарихсыз була алмый. Шуңар, Мәрҗани — тарих та, тарихчы да. Аның "Мостафадел әхбар"ына кадәр татар тарихы буенча мондый колачлы һәм күләмле әсәрләр мәгълүм түгел. Шуңа күрә аны тарих фәнебезне башлап мәйданга китерүче, аякка торгызучы дип атап була. Тарих фәнебезне дә ул "Ш. Мәрҗани масштабына" китерә, житкерә алган; ул — чуаланмаган, вакланмаган; буш хыял күпертүләрен, "очыртуларын" аңарда тапмассың. Тарихи тәсмер йөгертелгән мифлар, легендаларга да рационалист галим, хәтта, ихтимал, кирәгеннән артыграк та битарафлык, искитмәүчәнлек күрсәтә. Халыкның тарихын, үзенә мәгълүм бай чыганаклар күләмендә, системага салып бәян итә дә, тарихны да үзенең төп йөкләмәсенә (яңару хәрәкәтенә) китереп тоташтыра: халкыбыз тарихында уңай яки тискәре эз калдырган көрәшче һәм "койрык яклы" муллалар галлериясын сурәтли. Әмма бу "яңару хәрәкәте тарихы" түгел. Бай, җанлы тормыш материалын андый (догматик-схоластик) рәвешкә кертсә, — аны, бу яңаруны мәңгедән килгән бер нәрсә итеп күрсәтергә көчләнсә, — Мәрҗани Мәрҗани да булмас иде. Ул тарих өчен үзенчәлекле булмаган бу яңа материалга мөрәҗәгатьне, —чыганак базасы юкка чыгарылган татар тарихы өчен, — яңа бай чыганак базасы дип тәкъдим итә. Икенчедән, легенда, риваятьләр галәменә бирелмәстән (ягъни хакыйкатьтән читләшмәстән), реаль, җанлы тормыш җирлегендә генә тору омтылышының гәүдәләнеше дә бу. Шул рәвешчә, галим тарих фәнебезнең киләчәктә өстенлек итәргә тиешле нигез принциплары штрихларын билгеләп калдыра алган.

Империянең тотрыклы һәм интенсив рәвештә татар халкында приметивлык көчләрен яклаган, ныгыткан, үсендергән, үз халкына хыянәтне кәсеп иткән, әхлаксыз, бар начарлык-әшәкелекләргә сәләтле кешеләрне генә иҗтимагый тормыш йөзенә калкыткан сәясәте, өч гасыр дәвамында, Ш. Мәрҗанилар заманында ук инде (бүгенге дәрәҗәдә үк булмаса да), нигездә, татар тормышында шул көчләр өстенлегенмонополиясен урнаштыруга ирешкән була. Ш. Мәрҗанидай сизгер аналитик галимнең моны аңламавы, сизмәве мөмкин түгел. Шул ук вакытта, Ш. Мәрҗани бу юнәлештә әлеге көчләрнең куштанлануын күләгәдә калдырырга тырыша кебек. Әмма моны галимнең тегеләргә тинләшергә, яраклашырга тырышуы дип аңларга ярамый. Бу төр "тырышлык"ның җитди сәбәпләре бар. Ул, — һәр каршылыкны тарихи активлык һәм акыл көче белән җиңәргә алынган, шуңа ышанган кеше, — бу юнәлештә дә максималь активлыкны мәйданга китерергә тырышкан. Икенчедән, шәхес активлыгыннан аермалы буларак, кешеләрне стандартлаштыручы техника заманына күчү тенденциясе, үзенең дәртле "яшьлек еллары"нда, царизмның теге тотрыклы сәясәтен дә, күрәсең, берникадәр тәссезләндерә төшә. Үтә уяу галим күңеле моны да үткен сиземли һәм, олы тарихи максаты юлында, аны да максималь файдаланып калырга тырыша. Ш. Мәрҗани төрле, вак-төяк мәсьәләләрдә идарәче патша чиновниклары белән хезмәттәшлеккә керә һәм ул йомышларны үтәүдә теләсә кайсы бюрократны сокландырырлык тырышлык — башкаручанлык күрсәтә. Хәтта, — ихлас күңелдән, — мөфтилек дәрәҗәсе өчен көрәшеп карый... Юк, Ш.Мәрҗанида бу да —ваклану, көнкүреш стихиясе кочагына ташлану түгел: тарихи активлык күрсәтү, "койрык" муллалар сыенган "җылы урыннарны" дер селкетү, алар позициясендә зилзилә уйнату!

Күренә ки, Ш. Мәрҗани биографиясе һәм эшчәнлеге ниндидер стандарт беръяклылыклардан, абстракт өлгеләрдән ерак күренеш. Беренче чиратта, ул — көрәшче, татар яшәешен заман агышына якынайту өчен катгый көрәш байрагын күтәргән шәхес. Имамлыгында, мөдәррислегендә дә, тарихчы-галим сыйфатында да ул шул көрәш позициясендә тора. Аның тарихчы, галимлек принципларын шул зур тарих таләпләре аша караганда гына асыл мәгънәсендә аңлап була.

**Мәсгуд ГАЙНЕТДИН,**
филология фәннәре кандидаты.

*Үткен мәсьәлә*

**Адлер Тимергалин**

# КАЯ ТАБА ҺӘМ ...КАЯ ТИКЛЕ?

## Фәнни терминологиябез турында

Бер ун-унбиш елга артка чигеник әле.

Тел галимнәре, милли телләрнең функцияләре турында сүз алып барганда еш кына, әйтик, татар теленең функцияләрен көндәлек тормыш, нәфис әдәбият, милли театр, милли урта мәктәпләр кебек өлкәләр белән чикләп куялар, ә әсасый фәннәр, философия кебекләр, шулай ук идарә эшенә нисбәтле документлар, алар фикеренчә, икенче параллель тел (үги ана теле?) даирәсенә карый иде. Бу исә чынлыкта татар теленең мөмкинлекләре, потенциалы чикләнгән булуын танудан башка нәрсә түгел иде. Хәтта тел галимнәре үзләре дә еш кына җитди хезмәтләрен рус телендә язып, русча бастырып чыгаруны өстен күрделәр.

Ләкин егерменче гасыр ахырында мондый хәл озакка сузыла алмый. Әгәр телнең кулланылыш даирәсен үз теләгебез белән чиклибез икән, ул, әлбәттә, инкыйразга юл тота. Нәтиҗәсе шул булды — милли мәктәпләребезнең саны кимегәннән-кими барды, татарча матбугатка юллар тарайганнан-тарайды.

Әмма бәла монда гына түгел. Ныклы фәнни терминологиясе булмаган телдә хәзерге заманда тулы канлы һәм күпкырлы нәфис әдәбият тә, сәнгать тә, аларның теориясе дә була алмый. Чынлап та, атом төше, виртуаль кисәкчекләр мәсьәләсе белән шөгыльләнүче галим турында, аның иҗади эзләнүләре турында нинди дер җитлекмәгән телдә дөнья яңгыратырлык роман язып буламы? Яки тереклек дигән нәрсәнең иң эчкәреге серләрен ачучы генетик һәм генетика турында? Яки хәтта ракетачылар турында? Кызганычка каршы, мондый очракларда хәтта татар әдибенең дә кулы богаулы, каләме ирексез, автор үзенең фикерен кәгазьгә төшереп бетерә алмый һәм фәнни нечкәлекләрне әйләнеп узарга мәҗбүр була. Шул рәвешле әдәбиятның тематикасы бик нык — гадәттә авыл офыклары белән чикләнә. Хәтта психологик кичерешләр тирәнлеген чагылдыру өчен дә фәнни терминологияне эшкә җигәргә кирәк һәм ул җитлеккән, төгәл терминология булырга тиеш.

Мәгълүм булганча, гадәттә сөйләм телебездә безгә берничә мең сүз дә җитеп тора, күренекле әдәби әсәрдә аларның саны дистәләрчә мең исәпләнә, җитлеккән тел исә 100-150 мең сүзне үзенеке дип саный дисәк, ялгышмабыз. Ә менә фәнни терминнарга һәм атамаларга килгәндә, аларның саны чагыштыргысыз күбрәк — күпчелек телләр өчен уртак булганнары гына да берничә миллион тәшкил итә.

Байтак еллар буена Татарстан китап нәшриятында фән-техника редакциясендә эшләү дәверендә мин татар теленең фән теле була алуына, аның иң катлаулы фикерләрне һәм төшенчәләрне дә чагылдырырга сәләтле булуына ышандым. Ана телебезнең җир йөзендә иң күп кеше аңлаша ала торган үндүрт телнең берсе буларак теркәлүе юкка түгелдер дип уйлыйм.

Эш белән бәйле рәвештә миңа терминология мәсьәләләренә кагылышлы киңәшмәләрдә теге яки бу терминны татарча ничек бирү турындагы конкрет мәсьәләләрне хәл итүдә якыннан катнашырга, вакытлы матбугатта үземнең фикерләрем белән уртаклашырга, уннарча терминологик сүзлекләр төзү һәм редакцияләү өстендә эшләргә туры килде.

Башта ук берничә мисал китерүне кирәк саныйм.

Илленче елларның урталарында татарча фәнни терминологиядә (мин тәгәл, әсасый фәннәрне күздә тотам), "ике теллелек" дигән нәрсәнең нәтиҗәсе буларак, рус сүзләре өстенлек итә, кайчагында тексттагы татарча сүзләрне күмеп үк китә иде. Мәсәлән, мәктәп дәреслекләреннән башлап радиога, эреле-ваклы гәзит-журналларга кадәр русча "атомное ядро" термины "атом ядросы" дип бирелә иде. Бер бездә генә түгел, үзбәк матбугатында хәтта соңрак та ("Үзбәк совет энциклопедиясе"н карагыз) "атом ядросы" дигән терминга тап буласың.

Әлбәттә, матбугат әһелләре татар телендәге "төш" сүзен беләләр, ләкин бер кабул ителгән "ядро" сүзе шулкадәр тамыр җибәргән һәм, ул елларга хас булганча, алай-болай милләтчелектә гаепләмәгәйләре дип, татар теленең үзендә булган һәм төп терминга тәңгәл мәгънәдәге "төш" сүзеннән тәмам баш тартканнар иде. Ул елларда бит Идел елгасы юк, Волга гына "ага тора", чөнки Мәскәү юк, Москва гына бар иде гәзит сәхифәләрендә.

Миңа бер-ике ел дәвамында мәктәп физика дәреслекләрен редакцияләргә туры килде. Беренче эш итеп мин мәктәп дәреслегеннән "атом ядросы" сүзен сөреп чыгардым дип горурланып әйтә алам. Һәм бу вакытта фәкать тәрҗемәчеләр һәм рецензентлар белән генә киңәштем, чөнки әгәр дә "төш" сүзен төп термин итеп алу турында редсоветларда сүз кузгата калсаң, нәтиҗәсе нәкъ киресенчә булачагы көн кебек ачык иде. Ике теллелекнең өстенлекләре турында галим-голәмә диссертацияләр яклап мәш килгән чор иде бит.

Шул ук вакытта безнең редакция атом энергиясе һәм аны куллану турында берничә китап чыгаруны планлаштырды. Татар авторларын табып махсус яздырылган бу китапларда без "атом төше" дигән терминны кулландык һәм "төш" сүзен китапның тышына ук чыгаруны кирәк таптык. Бу китаплар турында вакытлы матбугатта рекламалар урнаштырдык. Шул рәвешле, татар сүзе фәнни терминологиядә үзенә тиешле урынны алсын өчен эзлекле һәм ныклы эш алып барылды, дияргә мөмкин. Дөрес, "төш" термины тернәкләнеп китсен өчен берничә ел вакыт кирәк булды һәм, әкренләп, ул заманнарда бердәнбер зур гәзит исәпләнгән "Социалистик Татарстан" да, Казан радиосы да авыз тутырып атом төше дип яза һәм сөйли башладылар. Хәзер, ихтимал, әлеге "атом ядросын" өлкән буын кешеләре генә онытып җиткермәгәннәрдер.

Физика һәм математика дәреслекләрендә "чылбыр участогы", "градуирлау", "простой саннар" кебек корама терминнарга каршы көрәшкәндә дә мин нәкъ шушы бик үк тугры булмаган алымны кулландым, югыйсә тешетырнагы белән каршы торучыларны җиңеп булмаячак иде. Ә болай эш иткәндә алар аңышып та өлгермәделәр шикелле. Кайберләренең, ихтимал, "югарыдан шундый күрсәтмә булгандыр, күрәмсең", дип тә уйлаган булуы бар.

Мондый очракларны мин тагын да санап күрсәтә алыр идем, тик алар тел тарихчылары өчен генә кызыклы булырдыр.

Термин өчен татарча сүз эзләгәндә беренче чиратта ана теленә мөрәҗәгать итү тиеш, әлбәттә. Кайчагында халык (тимерчеләр, балта осталары, тегермәнчеләр, киндер тукучылар һ.б.) телендә нәкъ кирәкле мәгънәгә ия булган сүзләр табыла. Заманында мин дәфтәр тотып авылыбызның барлык осталарын, бигрәк тә өлкән яшьтәгеләрне йөреп чыккан идем, чөнки яшьрәк буын ул вакытларда да инде әлеге дә баягы икетеллелек йогынтысына бирешә башлаган һәм, ватып-җимереп булса да, "поршень", "скорость", "горючее", "смазка" дип сөйли иде.

Иске китаплар актару, борынгы татар әдәбияты белән танышу, хәтта борынгы кулъязмалар белән танышлык та терминологка азык булырга мөмкин. "Борынгы төрки сүзлек"нең дә шактый файдасын күргәнем булды дип әйтә алам. Аннан соң чират кардәш телләргә җитә, аларның терминологиясен карап чыгасың, дәреслекләрен күздән кичерәсең. Теге яки бу терминның югары үсешкә ирешкән башка телләрдә ничек бирелешен тикшерәсең. Менә монда инде күп телле (5-6, хәтта 8 телле) терминологик сүзлекләр ярдәмгә килә. Совет чоры матбагасының казанышлары да булмады түгел, биш-алты "социалистик" ил берләшеп, күп телле терминологик сүзлекләр бастырып чыгаруны мин зур казаныш дип санар идем. Аларны актарып, терминның асылына төшәргә һәм, яңадан ана теленә әйләнеп кайтып, термин ясау юлларын кабат, инде яңачарак эзләргә мөмкин. Әгәр теге яки бу төшенчәне татарча бирүнең артык зур әһәмияте булмаса, яки ул мәгънәви чатаклыкка гына китерергә мөмкин булса, интернациональ терминга яки рус сүзенә тукталасың. Шуны да әйтергә кирәк, кайчагында шушыннан да яхшысы булмый. Чыннан да, нигә әле без "нейтрон" яки "нейтрино" урынына сүз ясап утырыйк? Бу кисәкчекләргә исемне могтабәр галимнәр, аларны ачкан күренекле кешеләр кушкан икән, моны кеше исеме кебек үк изге нәрсә дип санарга кирәк. Бер генә милли тел дә алынмаларсыз үсә һәм камилләшә алмый бит.

Практик терминология өлкәсендә 30 елдан артык эшләү барышында шәхсән үзем тәкъдим иткән терминнар да аз түгел. Саный башласаң, аларның мөһимнәре, оя тәшкил итә торганнары гына да йөзгә тула һәм бүген алар төрле басмаларда мөстәкыйль тормыш белән яшиләр.

Ләкин моннан бигрәк, терминологиябезнең бүгенге торышына тукталасым, аның киләчәге турында бер-ике фикер әйтәсем килә.

Хәзер каләм әһеленә бер яктан җиңелрәк дип саныйм мин. Язучы, тәрҗемәче, журналист бүген, Олжас Сөләйманов әйтмешли, "бугазыңнан кочаклаган" ике теллелек эскәнҗәсеннән азат. Әмма бүгенге иркенлекнең башка бер хәтәр ягы бар, ул да булса үз-үзеңә контроль җитмәү дигән нәрсә. Гәзит-журналлар, радио-телевидение, телне чит-ят элементлардан чистарту сылтавы белән бик кирәкле терминнардан да баш тарталар түгелме? Кирәксә-кирәкмәсә дә текстка гарәп, фарсы һәм төрек алынмаларын яки очраклы сүзләрне тутыру бу әле татарча булды дигән сүз түгел, фәннилек тә түгел, фәкать белдекле булып күренергә тырышу, модага иярү генә. Урыслар әйтмешли, мы это уже проходили.

Әйтик, кайберәүләр "логика" сүзеннән качып, "мантыйк" дигән сүз белән мавыгып киттеләр. Мин аларга саллы логика белешмәләренең эчтәлеген генә булса да актарып карарга киңәш итәр идем. Гаҗәпләренә каршы, күпчелек очракта алар "логика" тамыры катнашкан дистәләгән кушма сүзләргә һәм катлаулы терминнарга "мантыйк" сүзе нигезендә төзелгән таңгал таба алмаячаклар. Һәм кирәге дә юк! "Логика" сүзе, термин буларак, татар телендә дә нигез ташы булып торырга тиеш, югыйсә без фән телебезне гадәттән тыш ярлыландырачакбыз гына, ягъни киләчәктә үзебезгә комачау тудырачакбыз. "Мантыйк" сүзенә килгәндә, аның да үз урыны бар, ләкин татарча фәнни әдәбиятта төп термин булырга аның мөмкинлекләре чамалы. Өстәвенә, бу сүздә "схоластика" мәгънәсе дә ачык төсмерләнә.

Яки менә булачак "Татар энциклопедиясе"нең бер редакторы белән сөйләшеп торабыз. Ул, ничектер мактаныбрак, "метеорит" сүзе урынына "янарташ" сүзе кулланырга ниятләүләрен әйтеп куйды. Мин шунда ук каршы килдем, чөнки бу мәсьәлә хакында байтак уйланганым, эзләнгәнем бар. Беренчедән, мин әйтәм, метеоритлар нигездә ике төрле була: таш метеоритлар һәм тимер метеоритлар. Димәк, "таш янарташ" кебек тавтология килә дә чыга. Икенчедән, "янарташ" сүзен без "горючий сланец" мәгънәсендә байтактан кулланып килдек һәм ул анда нәкъ үз урынында шикелле. Өстәвенә, янарташ ташкүмер белән дә бутала. Кыскасы, яңа термин тәкъдим иткәнче аның бер фән өлкәсендәге

мәгънәсе башка өлкәләрдәге мәгънәсе белән кисешмиме, алар үзара сыешаламы икәнен тикшерергә кирәк. Әлбәттә, бу колачлы булуны, хәбәрдарлыкны сорый.

Энциклопедия дигәннән. Татарча ныклы терминологиянең зарурлыгы бу тарихи басманы әзерләгәндә үзен бик нык сиздерәчәк, чөнки камил терминологиядән башка фәнни энциклопедия төзү һәм нәшер итү мөмкин түгел. Димәк, энциклопедиячеләргә фән эшлекләре, фәнни оешмалар, нәшриятлар, вакытлы матбугат редакцияләре белән кулга-кул тотынышып эшләргә, эш барышында килеп туачак йөзләгән, меңләгән эреле-ваклы терминологик мәсьәләләрне бергәләп хәл итәргә туры киләчәк. Татарча энциклопедия фәнни терминологиябезнең үсеше өчен үзе бер этәргеч булачак.

Энциклопедиядә эшләүчеләрдән икенче бер иптәш миңа үзләрендә сорау уяткан бер дистә чамасы атама-терминнар исемлеген бирел, миннән фикеремне сораган иде. Шунысы куандырды, бу исемлектә минем эш практикамда очрамаган бер генә термин да юк иде. Аларның барысы да минем өчен, теге яки бу дәрәҗәдә, әлбәттә, хәл ителгән мәсьәләләр булып, минем кул аша үткән китап-брошюраларда кулланылган һәм азмы-күпме сыналган да иделәр. Мәсәлән, "неевклидова геометрия", "неорганическая химия", "нелинейная зависимость" кебек терминнар. Аларны "эвклидча булмаган геометрия", "органик булмаган химия", "сызыкча булмаган бәйлелек" дип алу, фактта, термин урынына сүз тезмәсе, аңлатма бирүдән башка нәрсә түгел, ә боларны җөмләгә кертү ифрат зур кыенлыклар тудыра — моны мин эш тәҗрибәмнән чыгып әйтәм. Мондый юл терминологияне үстерми, тоткарлый гына.

Шәрык алынмалары менә бу очракта безгә гадәттән тыш нык ярдәм итә. Безнең телебездә "нәмәхрәм (намәхрәм)", "нәмәгълүм (намәгълүм)" кебек сүзләр шактый актив. Мин югарыда әйтелгән терминнарны шушы калып буенча ясый һәм куллана торган идем (нәэвклид геометриясе, нәорганик химия һ.б. кебек сүзләр, ягъни алар үзләре зур бер оя, система тәшкил итәләр). Энциклопедияче агай боларны хуплады һәм, ихтимал, абруйлы басмада алар кулланылыр да. Шул ук вакытта мин русча "обтекание" терминын (аэродинамика) халыкчан "ягалау" сүзе белән бирергә тәкъдим иттем. Суда үсеп утырган камышларны "су ягалап ага" дип сөйлиләр. Бу сүз, әлбәттә, "Төзелеш атамалары сүзлеге"ндәге "сыпырым" сүзенә караганда мәгънәне төгәлрәк чагылдыра.

Соңгы елларда тормышыбызның төрле өлкәләренә (сәүдә, транспорт, сәясәт һ.б.) кагылышлы кечкенә сүзлекчәләр, аннары шактый күләмле берничә терминологик сүзлек тә басылып чыкты (мәсәлән, төзелеш буенча, физика буенча сүзлекләр). Гомумән алганда, бу сүзлекләрнең дөньяга чыгуын уңай бәяләргә була. Ләкин шул ук вакытта аларда терминологларны сагайтырдай тенденция дә сизелә. Мин, мәсәлән, кимендә алтмыш-җитмеш еллык тарихлары булган һәм терминологиягә ныклап кереп урнашкан "корылма", "колонна" кебек терминнарны "коргы" (яки "сөр") һәм "эстанә" сүзләре алмаштыра алмас дип уйлыйм, чөнки әллә нинди генә дәлилләр китерсәң дә, психологик барьер дигән нәрсәне алар уза алмаячаклар. "Чиксез кечкенә зурлык" термины урынына "җетек" сүзе дә бара алмас, чөнки чиксез кечкенә нәрсә белән бик кечкенә арасы, математика күзлегеннән караганда, җир белән күк арасыннан ким түгел. "Кизә" дигән сүз дә вектор сүзе кебек чын мәгънәсендә халыкара терминны җиңә алмаячак ("вектор"ына сүз тапкач, "тензор"ына да сүз эзләргә кирәк түгелме?).

"Электр тогы"н да, яңа бер сүзлектә тәкъдим ителгәнчә, "агым" дип алу максатка ярашлы түгел. "Ток" сүзе инде телдә үзләшкән һәм гадәттән тыш кирәкле бер алынма. Алайга китсә, "электрон" сүзе төптә "гәрәбә"не белдерә (гарәпчәсе "кәһраба"), "гәрәбә агымы" дип тәкъдим итәргә дә ерак калмый бит! Ә аны халыкның кабул итмәячәге көн кебек ачык.

Соңгы гасырларда фән кояшы көнбатыштан чыга — иң мөһим ачышлар шунда ясала, шулай булгач яңа атама һәм терминнар да шунда

туа. Дөньядагы барлык китапларны укып чыгу мөмкин булмаган кебек, яңа туган терминнарга милли телләрдә тәңгәл сүз табып бетерү дә мөмкин хәл түгел. Әгәр галим икәнсең, әгәр милләтпәрвәр икәнсең, халыкара терминга — сыйса-сыймаса да — кәләпүш кидереп азапланганчы, яса үзең бер ачыш (кәшеф ясa), куш аңа саф татарча исем һәм күпчелек телләр аны үзләренекедәй кабул итәчәкләр. Җитлеккән телләр шулай эшли. Җитлеккән телләр һәм галимнәр алынма сүзләрдән курыкмыйлар.

Тел үтә нечкә, нәфис нәрсә, монда чик-чаманы белү аеруча мөһим. Кайдадыр бер тапкыр очраган окказиаль сүзләр белән мавыгу гадәттән тыш корама воляпук теле генә тудырырга мөмкин. Ә чаманы белү фәкать тәҗрибәдә, җанлы практикада гына туплана торган бик кирәкле бер сыйфат ул. Терминологка оригинальлек артыннан махсус куу кирәкми, ата-бабалардан (мин монда татар терминологиясенә нигез салган Каюм Насыйриларны, Фатих Әмирханнарны, Шнасиларны, Камайларны һ.б. ны күздә тотам) килгән сүз байлыкларын саклый да белергә, традицияләрне дәвам итәргә, шуларга таянырга кирәк.

Әйтик, табигать белеменең барлык өлкәләре өчен "материя" дигән уртак бер төшенчә бар. Татар терминологиясе, үсә-камилләшә барып, ахыр чиктә бу интернациональ терминның үзен кабул итте, фәкать буталу куркынычы булмаган аерым очракларда гына без "материя" сүзе белән "карендәш", "материал" сүзен "матдә" сүзе аша бирәбез ("материальная помощь" — "матди ярдәм" яки юриспруденциядәге "матди дәлил" — "вещественное доказательство" кебек), ләкин хәтта бу очракта да "материал" терминыннан баш тартмыйбыз, чөнки бу сүз инде сөйләм теленә үк ныклап кереп урнашкан һәм киң мәгънәгә ия. Әйе, безнең иске әдәбиятта "материалистлар" мәгънәсендәге "матдиюн" сүзе дә очрар, ләкин бүгенге фән югарылыгыннан торып караганда, "материя" сүзе һәръяктан канәгатьләндерә торган термин, аңа кагылдың исә, бөтен фәнни терминологиян бүселә башлый.

Бөтен физикада, философиядә "материя" — әсасый төшенчә. Физиканың беренче сәхифәсендә үк материянең ике төрле формасы — матдә халәте һәм кыр, дулкын халәте булуы төшендерелә, аннары материаль нокта төшенчәсе кертелә.

Соңгы вакытларда, мәсәлән, "материаль нокта" терминын татарча "матди нокта" дип алуны яклаучылар табылды. Гомуми терминология принциплары моңа каршы: материя дигән нәрсә үзенең бер формасы гына булган матдәгә ("вещество"га) һич тә тәңгәл түгел. "Матдә" сүзе кыска, матур, гади дигән дәлил нигез булып хезмәт итә алмый, чөнки бу очракта гадиләштерү примитивлаштыруга, "материя", "җисем", "матдә" төшенчәләренең буталуына китерә. Мондый чигенү, мин әйтер идем, сугышта бер алган мөһим биеклекне дошман кулына тапшыруга бәрабәр. Кайбер авторлар, "матдә" белән "материя"не бутамас өчен, әйтик, "материальный мир" төшенчәсен "матдәви дөнья" дип тә тәкъдим итеп карадылар. Ләкин укучы өчен "матди" белән "матдәви" сүзләренең мәгънә аерымлыгы — алар арасындагы чик сизелмәс дип уйлыйм, ул да буталчыклыкка гына китерер сыман.

Термин — чик дигән сүз ул, ягъни ул мәгънәне чикли, теге яки бу сүзнең бик билгеле мәгънәдә генә кулланылырга тиешлеген кисәтә. Терминолог үзен чикли белергә тиеш, зәвыкка гына таянуын сизеп алу белән, үз-үзенә: "Стоп!" дип әйтерлек эчке көчкә ия булырга тиеш.

Ләкин кайчакта эш шуңа тикле барып җитә, хәтта "термин" дигән сүзнең үзен дә санга сукмыйлар, терминны атама белән бутыйлар. Урыны бу булмаса да, әйтеп китим инде: фән күзлегеннән караганда, мәсәлән, "елга" сүзе — термин, ә "Идел" сүзе — атама, "шәһәр" сүзе — термин, ә "Казан" сүзе шәһәр исеме буларак — атама, аш пешерү җайланмасы буларак исә — термин. "Тимер" — химик атама, "көрәк" — техник термин. "Тимер көрәк" тә — термин. Менә шулай чак кына нечкәләргә

өйрәнми торып, терминологияне "яңартырга" тырышу гадәттә гарип сүзләр, бер көн дә яшәми торган "ясалгылар" гына тудырачак. Каш ясыйм дип, күз чыгармыйк.

Терминологик сүзлекләр өчен мәңгелек бер кагыйдә бар: анда синонимнар мөмкин кадәр азрак булырга тиеш. Әгәр терминологик сүзлектә дүртәр-бишәр синоним тезелеп китә икән, димәк, бу норматив сүзлек түгел әле, фәкать сүзлек өчен тупланган чи материал гына.

Тагын бер мөһим шарт: кардәш телләрне, аларның кайсы юнәлештә үсүләрен күзәтеп барырга, фикер алышырга, тәҗрибә уртаклашырга кирәк. Тугандаш, якын телләрдән аерылмаска кирәк! Әгәр үзара элемтәләребез булмаса, күр дә тор: 15-20 елдан соң башкорт яки кыргыз, каракалпак укучысы безнең татарча фәнни текстның яки дәреслекләрнең ярты сүзен дә аңламаячак, ә татар теле күп халыкларга аңлаешлы телләр арасында үзенең ундүртенче урынын югалтачак.

Төрле фән өлкәләреннән татарча дәреслекләр төзүне һәрьяклап хуплау тиеш. Дәреслек авторлары колагына тагы шуны кабатлап әйтәсе килә: терминнарның алай бик тиз генә карарлашып китмәвен, кайчак моның өчен буыннар алмашыну кирәк булуын истә тоту зарур. Шуңа күрә аларны кулланылышка кертүдә үзенә бертөрле эзлеклелек белән, план нигезендә эш итәргә, яңа сүзләрнең дозасын чамаларга бик кирәк. Дәреслек аңлаешлы булсын, укучы аның телен үзләштерә алмыйча баш ватмасын, дәреслектән күңеле кайтмасын, татар кешесе язган татарча кулланмадан йөз чөермәсен, аны бер читкә куеп, кабат рус телендәге китапка барып тотынмасын — таләп шундый.

Бу күзлектән караганда, безнең беренче оригиналь дәреслекләребез нык аксыйлар әле. Чуарлык күзгә ташлана. Һәркем үзенчә "яңалык" кертергә омтыла, инде урынлашкан терминны — белеп йә белмичә — читкә тибәреп, кайчагында терминологиябез инде күптән баш тарткан сүзне тергезергә маташа. Терминологиядә нинди дер "суверен" территорияләр, фән тармаклары, аерым уку йортлары булырга тиеш түгел. Безнең гомуми мәнфәгатьләребез өстенлек итәргә тиеш. Ә моның өчен бергә җигелеп эшләү шарт. Термин нинди дер бер кафедра чикләрендә генә калмасын, массакүләм мәгълүмат тарату чараларында кулланыла башласын, сынауны ул шунда үтә, шунда чарлана һәм шомара, халык тарафыннан үзләштерелә. Гомумән, бүген булган байлыгыбызга ревизия ясауны үзмакsat итеп кую дөрес юл түгел, төп игътибарны бүген күпләп кулланыла башлаган яңа төшенчәләрне татарча ничек бирү мәсьәләсенә юнәлтү зарур, "америкалар ачуның" кирәге юк инде хәзер. Әйтик, татарча терминологиягә кагылышлы бер мәкаләдә мин "яссылык" мәгънәсендә "яссу" сүзе кулланылганын күрдем. Бар андый сүз бездә, бар. Һәм ул сүз математика терминнарын эшләүчеләргә дә мәгълүм булгандыр, дип уйларга кирәк. Ләкин алар "яссылык" терминын кабул иткәндә бу сүзнең колачлы булуын, башка конкрет мәгънәләрдән азат (нейтраль) булуын да исәпкә алганнар. Ә "яссу" сүзендә, мәсәлән, "кул яссуы" дигәндә, зурлык-кечкенәлек мәгънәсе беренче урында тора бит.

Юк, 20-30 елларда эшләгән терминологларыбыз ипине хаксызга ашамаганнар һәм татар фәнни терминологиясенең ныклы нигезен салып калдырганнар.

Матбугатта гына түгел, сөйләм телебездә дә иркен кулланылып килгән "компьютер" сүзе урынына гарип "кампитр" һәм хәтта "санак" сүзе күзгә чалына башлады. Дөрес, "компьютерлаштыру"ны "санаклаштыру"га ук барып җитмәделәр кебек әле, ләкин "кампитрлаштыру" очрый инде. Бу хакта Казанда эшләүче төрек укытучысы белән дә сөйләшкәнем бар иде, алар да, "компьютер" сүзен яратмыйча, "санау" тамырына нигезләнгән бер сүз тапканнар икән. Бүгенге "компьютер" сүзенең мәгънәсе "санау машинасы" ("счетная машина") һәм "хисаплау машинасы" ("вычислительная машина") сүзләренекеннән киңрәк. Шуңа күрә, безгә бу очракта төрек агайлар артыннан куу кирәкме соң, дигән сорау туа. Аларда "информация

кыры" бөтенләй башка бит. Госманлы теленең тарихы да үзгә, ул татар теле узган баскычларны узмаган һәм терминология ягыннан караганда төрек теле дә, аларга тикле күп элек "чистарына" башлаган венгр теле дә безнең татар теленнән алда түгелләр. Миңа калса, алар (пуристлар) тоткан юл ныклы терминологиягә илтми, илтә алмый. Шуның аркасында алар термин урынына өч-дүрт сүздән торган тезмә бирергә мәҗбүр (күп телле терминологик сүзлекләрне карагыз). Популяр нәрсәләр өчен, вакытлы матбугат өчен ярый да торгандыр бу, ләкин галимнәре җитди әйберләрне инглиз телендә язарга тиеш булалар. Кыскасы, терминологияне үстерү максатыннан чыгып караганда, әлеге телләр безнең өчен үрнәк түгел. Кем әйтмешли, хәтта киресенчә. Медицина, зоология, ботаника терминологиясендә "үле" латин теленең һаман кулланылыштан чыкмавы, актив тормыш белән яшәве фәндә нәкъ менә төгәллек таләп ителүдән килә. Практик терминология мәсьәләләрен хәл иткәндә башка фән тармакларында да бу фактны истә тоту зарур.

Компьютер программалары төзү белән шөгыльләнүчеләр тәкъдим иткән "меню" — "сайлак", "принтер" — "басак", "тонер" — "буйау", "катридж" — "буяк", "клавиатура" —"төймәсар" кебек сүзләр, татар укучысын елмайта гына, минемчә. "Меню" сүзенә бер компьютерчылар гына хуҗа булсачы! Аны бит ашханә-рестораннарда гына түгел, радиожурналистлар да кулланалар. Ә "төймәсар" сүзе төймәләр белән сату итә торган кибет мәгънәсенә генә тарта шикелле. Хәер, бусы минем субъектив фикерем. Ай-һай, кулланучылар "принтер"ны "басак" дип әйтерләрме икән? Хәтта президент кул куеп фәрман чыгарса да, бу ятышсыз сүз татар теленә кереп китә алмас дип өметләнәм.

Гомумән, компьютерга нисбәтле меңләгән (!) терминны "татарлаштырып" бетерү мөмкин түгел, мондый шөгыльнең перспективасы юк, кирәге дә юк. Хәтта терминология мәсьәләсендә алгарак киткән рус теленең дә моның өчен чара-мөмкинлекләре җитми.

Татар фәнни терминологиясе башлыча физика һәм философиядә "пространство" төшенчәсен бирүдә кыенлыкка очрап килде. Җитди әдәбиятта ярты гасыр буена диярлек русча термин — "пространство" сүзе өстенлек итте. Әмма соңгы вакытларда халыкка авыр аңлашыла торган "пространство" сүзен "фәза" сүзе белән алмаштырырга омтылыш күзәтелә. Дөрес, "фәза" сүзен без беркайчан да онытып бетермәдек, Такташ иҗаты белән генә булса да таныш укучылар бу сүзнең мәгънәсен аңлыйлар, ихтимал, аның потенциаль мөмкинлекләрен дә чамалыйлар иде. Һәрхәлдә, мин үзем "фәза" терминын куллангаладым. Тагы шунысы игътибарга лаек, бу сүздән ясалган "фәзаи" яки "фәзави" аергычы да җиңел аңлашыла. Ихтимал, бу безнең өчен утә мөһим сүзне матбугатта ешрак куллану һәм пропагандалау кирәктер.

Күптән түгел мин Казан Дәүләт университетының физфак мөгаллимнәре төзегән кызыклы гына мәсьәләләр җыентыгының татарчага тәрҗемәсен редакцияләдем. Эш процессында безгә физика буенча байтак кына терминологик мәсьәләләрне дә хәл итәргә туры килде, чөнки бу уку ярдәмлеге мәктәп дәреслекләре белән чагыштырганда фәнгә шактый тирәнгәрәк керә һәм, урыны-урыны белән, стиле ягыннан да катлаулырак. Татар теленең мөмкинлекләре менә шушындый китаплар чыгарганда сынала да инде. Шул ук вакытта алар терминологияне үстерергә ярдәм итәләр. Мәсәлән, әлеге китапта төп игътибар санлы мәсьәләләргә, ягъни хисаплауны таләп итә торган мәсьәләләргә түгел, бәлки фикерләү юлы белән хәл ителә торган мәсьәләләргә юнәлдерелә ("качественные задачи"). Китапта алар "сыйфати мәсьәләләр" дип тәкъдим ителә.

Соңгы елларда илдә иманның әкренләп аякка басуын ачык күрәбез. Йөзләгән дини китап-брошюралар, күренекле дин галимнәребезнең хезмәтләре кабат дөнья күрде, махсус дини журнал һәм газетләр чыга башлады. Баксаң, дин өлкәсе тел белгечләре өчен дә үзе бер дөнья икән. Татарча дини чыганакларда без дистәләрчә фәнни һәм фәлсәфи терминнарны да

очратабыз, һәм аларның байтагы гомуми лексик фондка ишек кага дип әйтер идем мин. Мәсәлән, дини әдәбиятта элек-электән бирле "бидгать" ("ересь"), "бидгатьче" ("еретик"), "бидгать атасы" ("ересиарх") кебек бик кирәкле сүзләр кулланылып килгән. Аларның гомуми сүзлек фондына керергә тулы хокуклары бар. Мин "танәсух" (переселение душ), "камәри ай" (лунный месяц), "әүвәлият" (действующее начало), "әфьюндар" (эфьюн кулланучы, наркоман), "бәдәни тәрбия" (физик тәрбия), "насарилар" (христианнар), "вәхи(й) килү", "дәресханә", "пакизә" (пакъ хатын-кыз), "асле-гөнаһ"), "әдәбият" (мәңгелек) һ.б. кебек сүзләрне күздә тотам. Саный башласаң, ихтимал, аларның исәбе йөздән дә ашып китәр. Кыскасы, әдәби телебезне һәм терминологиябезне баету өчен тагы бер чыганак, чишмә ачылды дип әйтәсем килә.

Ә математика, механика, химия кебек фәннәрдән татарча дәреслекләр төзүчеләргә мин иске китапларда, заманында мәдрәсәләр өчен язылган дәреслекләрдә очрый торган терминнар белән, турыдан-туры алу өчен яраклы булу-булмауларына карамастан, уйлану өчен генә булса да танышырга киңәш итәр идем. Кайбер дәреслекләр, мәсәлән Иж-Бубый мәдрәсәсендә Гобәйдулла Буби тарафыннан төзелгән "Физика" дәреслеге октябрь революциясеннән соң да чыккан әле. Кабатлап әйтәсем килә: мин һич тә иске китап-дәреслекләрдәге терминнарны кайтару яки торгызуны якламыйм. Әйтик, иске татар китапларында без "механика" мәгънәсендә "мәканык" сүзен дә, "җәрре әскаль" сүзен дә очратабыз, ләкин аларны бүгенге дәреслектә куллану акылга муафыйк түгел. "Мөсәлләс" (өчпочмак), "мөсәлләс мөнфәриҗеззавия" (җәенке почмаклы өчпочмак), "мөсәлләсат" (тригонометрия), "мөсәлләсат көрәвия" (сферик тригонометрия), мөсәлләсәт мөстәви (яссылыктагы тригонометрия) кебек гарәп алынмаларын куллану бүген артка чигенү булыр иде дип уйлыйм. "Осуле фикъһе" (юриспруденция), "сарыф һәм нәхү" (морфология һәм синтаксис), "тарихы табигый" (табигать белеме), "хикмәте табигый" (физика), "кимия" (химия), "һәндәсә" (геометрия), "җәбер" (алгебра), "нәбатәт" (ботаника), "хайванат" (зоология), "һәйәт" (астрономия), "гыйльме сәрвәт" (экономика) кебек атама-терминнар да инде узылган этаплар дип каралырга тиеш. Ләкин менә шушы искергән алынма сүзләрне дә белергә кирәк, чөнки алар да безнең тарихыбызның кызыклы сәхифәләре, безне югарырак күтәргән баскычлар.

Мин бу мәкаләмдә нигездә әсасый фәннәргә кагылышлы терминология турында гына фикер йөрттем һәм конкрет авторларны атап күрсәтмәскә тырыштым. Әмма бер күренекле фамилияне атап әйтмичә ярамый торгандыр. Яңа чыккан терминологик сүзлекләрдә, дәреслекләрдә кайбер мәкаләләрдә безнең мөгтәбәр галимебез Рифкать Әхмәтьяновның көчле йогынтысы сизелә. Борынгы төрки, диалекталь сүзләрне, гарәп, фарсы, төрек алынмаларын торгызырга, кайтарырга омтылышта аның фикерләре һәм тәкъдимнәре өстенлек итә, ә аерым авторлар аны турыдан-туры остазлары итеп күрсәтәләр. Рифкать Әхмәтьяновка минем дә ихтирамым зур, аның хезмәтләре миңа яхшы таныш һәм китап матбагасында эшләү дәверемдә безнең редакция еш кына аңа мөрәҗәгать итә торган иде. Мөрәҗәгать иткәнбез икән, димәк, файдасы тигән. Ләкин, турысын әйтим, без кайсыбер яклары белән Жюль Верн каһарманы Жак Паганельгә тартым Рифкать Әхмәтьяновның мавыгучан табигатен искә алып, аның тәкъдимнәренә төзәтмә кертүне тиеш таба идек. Ул бер якка каера, ә без аны тыя төшкән кебек булабыз, чөнки ул, тирәнгә казып төшеп, җир өстендә калган алла бәндәләрен, аларның эреле-вaклы ихтыяҗларын күздән җуя һәм без моны аның хәтеренә төшерә торган идек. Олы галимнең хатасы да олы булучан бит.

Татар теле, аның фәнни терминологиясе юл чатында тора. Кая таба? Кайсы юлдан? Кая тикле? Мин телне ирексезләмәү яклы. Табигый күчеш-үзгәрешләр яклы. Татар теленең мөстәкыйльлеге яклы. Татар теле рус теленә дә, төрек теленә дә билән бирмәскә тиеш!

□□

# Укучы сүзе

Хөрмәтле редакция!

"Казан утлары"ның һәр санын көтеп алабыз. Чөнки журнал —татар халкының чын энциклопедик басмасы, көзгесе.

Журналның "Укучы сүзе" бүлегендә Илдус Миңнехановның язмасын укыдым. Ул әлеге мәкаләсендә: "Кама аланы бистәсендә татар гимназиясе ачтык", — дип яза. Ләкин әле ул гимназиянең исеме генә "татар гимназиясе". Чөнки укучыларның яза торган дәфтәрләре, көндәлекләре, альбомнарының тышларына бары тик татарча язылганда гына ул чын татар гимназиясе булыр. Әле ул гимназиядә, әлифба, татар теле һәм татар әдәбияты дәреслегеннән кала, барлык дәреслекләр дә тәрҗемә итеп бастырылган дәреслекләр. Әле ул татар гимназиясендә укучыларның әти-әниләре өйдә чакта балалары белән матур итеп, татар телендә сөйләшергә атлыгып тормыйлар шул. Әле ул балалар өйләрендә телевизордан ничәмә-ничә программа русча тапшырулар карыйлар. Чама белән кимендә 150 сәгать була бу. Ә менә татар телендәге "Әлли-бәлли-бәү" тапшыруы исә күп дигәндә 10 минут бара. Әле җитмәсә "Тамчы" тапшыруы да —яртылаш кына татарча . Шулай итеп, татарча тапшырулар 1 % ка да тулмый. Хәзергедәй кырыс шартларда да татарча сүз әйтә алган балаларыбыз, ул марҗа балалары белән чагыштырганда, 200 тапкыр остарак сөйләшә булып чыга түгелме?

Яхшымы, начармы — шушындый шартларда да татар телендә сөйләшкән кешеләрне тыңлый белергә, кадерли белергә кирәк безгә. Бозып сөйләшмичә, җиренә җиткереп сөйләшә белгән кешеләр дә җитәрлек арабызда. Аларны тыңлый беләбезме? Безнең гимназияләребез, татар телендә сөйли белүче генә түгел, ә тыңлый, аңлый, укып белем ала торган балалар да тәрбияләргә тиештер бит?!

И. Миңнехановка мин рәхмәт әйтәм. Автор әһәмиятле мәсьәлә күтәрә. Чыннан да, сөйләм телен савыктырырга кирәк безгә. Моның өчен башкалар сөйләмен дә игътибар белән тыңлый белергә кирәк. Татар телендә матур итеп, оста итеп сөйләргә өйрәткән ярдәмлекләр, татарча кинофильмнар, видеофильмнар кирәк. Татарча спектакльләрдә дә сөйләм теле тиешле әхлакый югарылыкта түгел. Күбесендә — ызгыш, талаш, үртәшү, үчекләү, кешедән көлү.

Бу яктан юмористик әсәрләр бигрәк тә аерылып тора. Татар язучысының юмористик әсәре, гадәттә, кешенең исемен бозып әйтүдән башлана. Икенчедән, ул, И. Миңнеханов әйткәндәй, әсәр героен кыландырып, йә урысча, йә башкача сөйләтә, шуннан кызык таба. Өченчедән, язучы әдәпсезлектән кызык таба. Дүртенчедән, эчеп-исерүдән кызык таба. Татар язучыларының 99,9 % ы — белепме, белмичәме — шушылай итеп, "юмористик", "кызыклы" әсәрләр язалар. Алар — тырышканда, хезмәт куйганда — тирәнрәк, үткенрәк әсәрләр дә язып, халыкны көлдерә алырлар иде. Юк шул, болай җиңелрәк, хезмәт тә азрак китә. Юмористик әсәрнең гадел, әйбәт, үткен-үтемле булуы өчен бер шарт бар. Әсәрнең герое итеп язучы үз исемен куйсын. Шул чагында гына ул әсәр — чын сәнгать әсәре булыр. Һәртөрле газета битләрендә мондый әсәрләр аз түгел, билгеле. "Казан утлары" журналы — бу яктан алганда — талантлы әсәрләргә кытлык кичерми һәм анда басылган күр күңелле язмалар тирән эчтәлекле, кеше исемен һәм җисемен бозуга корылмаган булырлар, дип тирәнтен ышанам.

**Җәүдәт ХӨСӘЕНОВ**
Кукмара районы, Зур Сәрдек авылы.

*Саубуллашу сүзе*

# Ибраһим Салахов



Ерак Күкчәтау далаларыннан Казанга кайгылы хәбәр килеп иреште: шушы елның 7 июле таңында татар әдәбиятының аксакалы — Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Җөмһүриятебезнең атказанган мәдәният хезмәткәре, Казакъстан Республикасының мәртәбәле "Парасад" алтын ордены кавалеры Ибраһим Низами улы Салаховның тын-гысыз йөрәге тибүдән туктаган...

1911 елның 30 августында хәзерге Казакъстанның Күкчәтау шәһәрендә эшче гаиләсендә дөньяга килгән Ибраһимның әти-әнисе — Низами агай белән Маһиҗамал апа — чыгышлары буенча республикабызның Балтач районыннан. Низами агай, балта остасы буларак, Күкчәтау өязендәге күп кенә мәчетләрне сафка бастыруда катнашкан кеше.

Ибраһим Салахов башлангыч белемне мәдрәсәдә ала. Аннары Күкчәтаудагы җидееллык татар мәктәбендә укый, беренче әдәби язмалары да мәктәпнең стена газетасында дөнья күрә. Соңрак, кулъязма әдәби журналның мөхәррире итеп сайлангач, Ибраһим иҗади эш белән ныклап шөгыльләнә башлый — Казандагы "Яшь ленинчы" газетасына, Мәскәүдәге "Октябрь баласы" журналына бер-бер артлы үзенең шигырьләрен, хикәяләрен юллый...

1927 елда яшь егет Казанга килә, педагогия техникумына укырга керә. Бирердә гыйлем эстәгәндә дә ул иҗат итүеннән туктамый. Язмалары барлык татар газета-журналларында диярлек күренеп килә. 1931 елда педтехникумны уңышлы тәмамлагач, И. Салахов "Яшь ленинчы", "Кызыл яшьләр" газеталарында, "Пионер каләме" журналы редакцияләрендә эшли. 1932 елда, армиягә алынып, өч елга якын Беренче татар укчы полкында хезмәт итә, соңыннан "Укчы" исемле полк газетасының мөхәррире дә була. Армиядән кайткач, яшь язучы 1935-1937 елларда Казан дәүләт педагогия институтында белем ала. Шул чорда аның "Ярату" исемле пьесасы, "Дуэль" дигән повесте, "Постта" дигән шигырьләр җыентыгы дөнья күрә. "Мәхәббәт һәм өмет" исемле романының да аерым бүлекләре, Идел буе Хәрби округының "Кызылармеец" газетасы аша, укучыларга барып ирешә. Әмма романын аерым китап итеп бастырырга насыйп булмый — 1937 елда И. Салаховны, Кырымда дәваланучы күренекле әдип Галимҗан Ибраһимов белән элемтәгә кергәне өчен, милләтчелектә гаепләп, кулга алалар. Ибраһим ун елга хөкем ителә һәм репрессия чорының бөтен газапларын үз җилкәсендә татый.

Тоткынлыктан соң И. Салаховка Казанга кайтырга да, хәтта туган шәһәре Күкчәтауда торырга да рөхсәт ителми. Ибраһим Кызыл Яр авылына (Күкчәтау өлкәсе) җибәрелә — бирердә ул, хакимият вәкилләре янына һәркөнне барып, үзенең качып китмәгәнлеген раслап торырга тиеш була. Бары тик 1956 елда гына СССР Югары Судының Хәрби коллегиясе, эшне яңадан карап, 1938 елгы хөкем карарын юкка чыгара һәм әдипне тулысынча аклый...

И. Салахов 1962 елда СССР Язучылар союзына кабул ителә. Татарстан китап нәшриятында аның "Дала дулкыннары" дигән шигырьләр җыентыгы (1957), "Күкчәтау далаларында" романы (1965), "Төн кызы" чәчмә әсәрләр тупланмасы ( 1971), "Мәхәббәт картаямы?" повесте (1980), "Имәннәр тамыр җәйгәндә" тарихи романы (1985) басылып чыга. 1988 елда "Казан утлары"нда дөнья күргән "Тайгак кичү" роман-хроникасы (Татарстан китап нәшриятында ул әсәр "Колыма хикәяләре" исеме белән басылды) татар әдәбиятында олы бер вакыйга булды, аның өчен авторга Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелде...

Ибраһим ага "Казан утлары"ның якын дусты, киңәшчесе, тугандаш Казакъстандагы рухи илчесе иде. Без, аның якты рухы, кылган изге гамәлләре алдында башларыбызны иеп: "Хуш, Ибраһим ага, урының җәннәтнең түрендә булсын...", — дибез...

***"Казан утлары" журналы редакциясе коллективы***

## *Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан*

### ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫНДА

Татарстан Дәүләт Советының 10 июльдә үткән XV пленар сессиясендә Татарстан Республикасының Премьер-министры итеп 41 яшьлек Рөстәм Нургали улы Миңнеханов сайланды. Аңарчы ул Татарстан Республикасының Финанс министры иде.

ТРның Финанс министры итеп "Ак Барс" банкы идарәсе рәисе булып эшләгән Роберт Мусин расланды.

Дәүләт Советы Рәисенең өченче урынбасары итеп Алексеевск районы хакимияте башлыгы Алексей Демидов сайланды. Ул бу вазифаны төп эшеннән аерылмыйча башкарачак.

Дәүләт Советының яңа сәркатибе итеп Татарстан халык депутаты Валентина Липужина сайланды.

### ПЕН-КЛУБ ҖИТӘКЧЕЛӘРЕ КАЗАНДА

28 июль көнне ТР Дәүләт Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшин Бөтендөнья язучылары ассоциациясе — Халыкара ПЕН-клубның җаваплы секретаре Александр Блок һәм аның хатыны — рәссам Надежда Блок (Франция), Рус ПЕН-үзәге генераль директоры Александр Ткаченко (Мәскәү) белән очрашты. Кунаклар ПЕН-клубның эшчәнлеге белән таныштырдылар. Билгеле булганча, ул 1921 елда оеша, штаб-фатиры Лондонда. Халыкара ПЕН-клуб йөз илледән артык ил язучыларын берләштерә. Татарстан әдипләре бу мәртәбәле оешмага моннан ике ел элек — Мексикада үткән конгресста кабул ителделәр.

Очрашуда Татар ПЕН-үзәге президенты Туфан Миңнуллин, вице-президент Разил Вәлиев, үзәкнең җаваплы сәркатибе Әхәт Мушинский катнашты.

### ТАТАР ПЕН-ҮЗӘГЕ ВӘКИЛЕ УҢЫШЫ

Әдипләрнең "Аурупа — Аурупада" дип аталган Балтыйк конгрессында Татар ПЕН-үзәге вәкиле Тәлгат Бариев та чыгыш ясаган иде. Аның нотыгы мәдәният һәм цивилизацияләр вазгыяте турында сөйләүләр номинациясендә иң яхшысы дип танылды.

Әлеге олуг форум шушы елның апрелендә Юрмала каласында, Төньяк илләр Шурасы (Стокгольм) һәм Халыкара ПЕН-клуб (Лондон) химаясендә үткәрелгән иде. Хәзер Т. Бариев докладьы тексты, инглиз теленә тәрҗемә кылынып, форумның резолюцияләре белән бергә, дөньяның 134 милли әдәби үзәгенә таратылган.

### КОЛ ГАЛИ ПРЕМИЯСЕ ЛАУРЕАТЛАРЫ

Кол Гали исемендәге халыкара премиянең яңа лауреатлары билгеле булды. Әлеге бүләккә быел, татар халкының күп гасырлык тарихи-мәдәни мирасын кайтару өлкәсендәге казанышлары өчен, язучылардан — филология фәннәре докторлары, академиклар Рәиф Әмиров (Уфа), Тәлгат Галиуллин, Хатыйп Миңнегулов (Казан) лаек дип табылды.

### ЭШ КҮРСӘТКӘН ИРНЕ ИЛ ОНЫТМЫЙ

Чаллы шәһәрендә КамАЗ төзүдә башлап йөргән гаярь милләттәшебез — КПССның шәһәр комитеты беренче секретаре, Татарстан өлкә комитеты секретаре һәм гомеренең соңгы елларында Казан мәдәният һәм сәнгать академиясенең ректоры булган мөхтәрәм профессор Рәис Кыям улы Беляевка 1 августта мәһабәт һәйкәл ачылды. Әлеге монумент предприятиеләр һәм аерым гражданнарның хәйрия акчасына торгызылды.

Аңарчы Чаллының Яңа шәһәр өлешендәге иң матур урамнарының берсенә Р. Беляев исеме бирелгән иде.

### ШАГЫЙРЬНЕҢ ТҮГӘРӘК БӘЙРӘМЕ

Күренекле шагыйрь һәм җәмәгать эшлеклесе — Татарстан халык депутаты, ТР Дәүләт Советының мәдәният һәм милли мәсьәләләр буенча даими комиссиясе рәисе Роберт Миңнуллинның 50 яшьлек гомер бәйрәме Татарстанда һәм ул туып-үскән тугандаш Башкортстан җирендә зурлап билгеләп үтелде. Чаллы, Нефтекамск, Уфа кала-

ларында һәм шагыйрьнең туган жире Илеш районында Р. Миннуллинга ихлас кадер-хөрмәт күрсәтелде. Аны котларга һәр ике республиканың да күренекле шәхесләре, әдәбият-сәнгать осталары килгән иде.

Башкортстан Республикасы Президенты М. Рәхимов юбилярга "Башкортстанның атказанган мәдәният хезмәткәре" билгесен һәм дипломын тапшырды.

Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев Указы нигезендә Р. Миннуллин, мәдәниятне үстерүгә зур өлеш кертkәне, дәүләт хакимияте органнарында нәтиҗәле эшләгәне өчен, Татарстан Республикасының Мактау грамотасы белән бүләкләнде.

## ӘЛКИ ТАЛАНТЛАРЫН БАРЛЫЙ

Әлки районында шушы төбәкнең Татар Мулла авылында туып-үскән күренекле шагыйрь һәм прозаик Шамил Маннаповның 60 яшьлегенә багышланган очрашулар булып үтте. Район хакимиятенең (житәкчесе — Әмир Кыямов) чакыруы буенча, әдип үзенең туган ягына каләмдәшләре — Татарстан радиосының баш мөхәррире, шагыйрь һәм прозаик Җәүдәт Дәрзаман һәм "Мәгариф" нәшрияты директоры, әдәби тәнкыйтьче һәм шагыйрь Мөдәррис Вәлиев (ул да Әлки егете) белән кайтты. Алар катнашында Базарлы Матак мәдәният йортында һәм Алпар урта мәктәбендә әдәби-музыкаль кичәләр уздырылды. Бу кичәләрдә район үзешчәннәре һәм мәктәп укучылары Ш. Маннаповның әсәрләрен һәм аның халык арасында киң таралган җырларын башкардылар.

Шагыйрь, үзен шулай зурлаулары өчен ихлас рәхмәтен белдереп, якташларына култамгасы салынган "Өндәге төшләр" исемле яңа китабын бүләк итте.

## Ф. ЗӨЛКАРНӘЙ РУХЫНА

"Идел" журналының элеккеге баш мөхәррире — күренекле тәнкыйтьче һәм шагыйрь Фәиз Зөлкарнәйнең вафат булуына бер ел тулган көннәрдә, әлеге редакция урнашкан бинада, каләмдәшебезне искә алу мәҗлесе үткәрелде. Журналның хәзерге баш мөхәррире — язучы Рашат Низамиевның һәм редакция коллективының чакыруы буенча бирегә Татарстан мөфтие Госман хәзрәт Исхакый килгән иде. Ул, Ф. Зөлкарнәйнең якты рухына багышлап, Коръән аятьләре укыды.

18 июльдә Кара диңгез буендагы Туапсе шәһәрендәге "Раушан" лагеренда да, Татарстанның төрле төбәкләреннән килгән сәләтле балалар катнашында, Ф.Зөлкарнәйгә багышланган кичә үткәрелде. Яшьләр әдипне бер минут тынлык белән искә алдылар. Кичәдә "Казан утлары" журналының баш мөхәррире урынбасары — язучы Флүс Латыйфи каләмдәш дусты хакында истәлекләре белән уртаклашты, иҗаты һәм тормыш юлы турында сөйләде.

## БЕРЕНЧЕ КИТАП ТАНТАНАСЫ

24 июль көнне Татарстан язучылары йортында яшь драматург Данил Салиховның "Яшьлек хатам — йөрәк ярам" исемле беренче китабын тәгъдир итү тантанасы булды. "Татар китабы" нәшриятында дөнья күргән әлеге күләмле мәҗмугага авторның театр сәхнәләрендә еш уйнала торган 6 пьесасы кертелгән.

Очрашу барышында ТР Язучылары оешмасы житәкчесе Р. Мөхәммәдиев, ТР Мәгълүмат һәм матбугат министры И. Әхмәтҗанов, Татарстанның халык язучылары А. Гыйләжев, Г. Ахунов, Татарстанның халык шагыйрьләре Ш. Галиев, И. Юзеев, танылган язучылардан Ә. Баянов, Г. Зәйнашева, Р. Миннуллин, сәнгать белгече, профессор Р. Игъламов, Әлмәт драма театры директоры Т. Халитова һ.б. китапка һәм авторга карата күп кенә кызыклы фикерләр әйттеләр.

## МИЛЛӘТТӘШЛӘРЕБЕЗ ТУРЫНДА


"Нижполиграф" китап нәшриятында тарихчы милләттәшебез Мансур Хафизовның рус телендә "Нижегородские татары: очерки истории" дип исемләнгән яңа җыентыгы дөнья күрде. Ул әлеге өлкәнең архив фондларында саклана торган материалларга таянып язылган һәм бу якларда гомер кичерүче кан кардәшләребезгә багышланган.

*Тышлыктагы сурәтләр*

**Тышлыкның беренче битендә:** Кичке манзара.

# ЯҢА КИТАПЛАР

Фәнис ЯРУЛЛИН. **Күзге моң.** *Шигырьләр.* — Әлмәт, "Рухият" нәшрияты, 1998. — 224., тиражы — 3000 данә.



Моннан берничә ел элек "Татнефть" берләшмәсе ярдәме белән Ф. Яруллинның 3 томлык сайланма әсәрләре дөнья күргән иде. Менә яңадан яңа китап. Китапның аңлатма-аннотациясендә болай язылган:

"Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, М. Җәлил исемендәге яшьләр, Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләре лауреаты шагыйрь Фәнис Яруллинның бу китабына соңгы 3-4 ел дәвамында язылган яңа шигырьләре тупланган.

Аларда мәңгелек мәхәббәт яктысы, үткәннәр белән бүгенгене тоташтыручы Хәтер басмалары, Заман агышының ярсу дулкыннары, Вакыт атының офыклар аша сикереп киләчәккә чабуы, кыскасы, тормыш һәм яшәеш бизнең алдыбызга куйган барлык проблемалар, шагыйрь җанынннан тамган кандай, шигъри тамчылар булып бергә җыйналган."

Шунсын да искәртик: бу китап та "Татнефть" оештырган "Рухият" нәшриятында басылган. Җыентык авторның "Минем матурлыгым очышта" дип исемләнгән кереш сүзе белән ачыла. Китапның редакторы — Илсөяр Хәйруллина.


**Сүз тәме** *(Айрат Арсланов турында замандашлары).* Төзүчесе һәм мөхәррире: Кыям Миңлебаев. Казан. Татар. кит. нәшр., 1998 ел. 112 бит. Тиражы — 2000 данә.




Китапка Татарстанның һәм Россиянең халык артисты, Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Айрат Арсланов иҗатын тасвирлаган бәләкәй күләмле мәкаләләр, шигырьләр, истәлекләр, фоторәсемнәр тупланган. Китапта автор буларак катнашкан шәхесләрнең кайберләренең исемнәрен генә атап китүдә күпне аңлата. Алар: язучылар — Г. Бәширов, Г. Әпсәләмов, Ә. Еники, С. Хәким, Г. Ахунов, М. Львов, Н. Нәҗми, М. Мәһдиев, Г. Афзал, А. Хәлим, И. Юзиев, Н. Фәттах; артистлар — А. Аббасов, Ш. Биктимеров, В. Минкина, Ш.Сарымсаков, В. Ганиева, З. Сөнгатуллина; композиторлар —А. Луппов, Р. Еникиев; рәссам һәм галимнәр — Х. Якупов, Ф. Гарифуллин, М. Зәкиев...

Китап олуг артистның 70 еллыгына багышлап чыгарылган. Китапта А. Арслановның "Яшьлегемә кире кайтыр идем" дип исемләнгән үз язмасы да урын алган.

Индекс 73210



Язучы Әдхәт Синугыл

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARЬ
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)